# КАЗАН УТЛАРЫ




6
ИЮНЬ
1979

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары*



ТУФАН МИҢНУЛЛИН

# 1979 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА



ГАЛИ ХӨСӘЕНОВ



ДАМИРӘ КУЗАЕВА



РЕНАТ ИБРАҺИМОВ

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимнәрен карагannан соң, 1979 ел өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар.*

*1. Драматург, пьеса авторы Туфан Абдуллович Миңнуллинга, режиссер-куючы Гали Кәримович Хөсәеновка, Мәдинә ролен башкаручы Дамирә Нәҗмиҗановна Кузаевага — Әлмәт татар дәүләт драма театрында куелган «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле өчен.*

*2. М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Ренат Исламович Ибраһимовка — 1976—1978 еллардагы концерт программалары өчен.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**6**

ИЮНЬ

1979


## Бу санда


М. МӘҺДИЕВ. Таңы ерак төндә. Хикәя . . . . 3
Р. ХАРИС. Тынычлык таләп итәм. Шигырьләр . 11
М. ӘГЪЛӘМОВ. Кайдадыр күктә кояш... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Т. МИҢНУЛЛИН. Яшьлегем-юләрлегем... Пьеса . 23
А. ВЕРГАЗОВ. Нәзер. Повесть . . . . . . . . 54
Ф. ЯРУЛЛИН. Юл сайлау. Шигырьләр . . . . 111
С. ШӘМСИ. Сагыну. Хикәя . . . . . . . . . 116

ОЧЕРКЛАР

И. ЗАРИПОВ. Хыяллар остасы. Очерк . . . . 126

ӘДӘБИЯТ ГАЛИМНӘРЕ ФИКЕР АЛЫША

И. НИГЪМӘТУЛЛИНА. Әдәбият галимнәренең Бөтенсоюз киңәшмәсе . . . . . . . . . . 136
З. КЕДРИНА. Социалистик реализм — күп милләтле совет әдәбиятының уртак казанышы . . 139
Л. ЗАЛЕССКАЯ. Чорлар аша үтеп киләчәккә . . 146
Ф. МУСИН. Тарихилык юлыннан . . . . . . . . 155

СӘНГАТЬ

М. ФӘЙЗУЛЛАЕВА. Халык музыкасы һәм композитор . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. БУЛАТОВ. Батырларга дан җырлап . . . . 167

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. ӘХМӘТҖАНОВ, М. ГАЙНЕТДИНОВ. Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссасының татарча варианты . 170

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

О. ШАКИРОВА-ТАҺИРОВА. Профессор Таһиров . 172

К. МИҢЛЕБАЕВ. Тәрҗемә үрләре . . . . . . 175



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Г. САТТАРОВ.** Исемнәребез бакчасында . . . . 179
**Ә. ГАДЕЛ.** Керәшен татарларында көн-ай атамалары . . . . . . . . . . . . . . . . 183

### ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**А. САДЫЙКОВА.** Уйнап әйтсәң дә, уйлап әйт . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары—3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-63, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Ф. Кадыйрова*

Производствога бирелде 27/II-1979 ел. Басарга кул куелды 17/V-1979 ел. ПФ 09023. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83744 экз. Заказ Ц-80. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

Мөхәммәт Мәһдиев

# ТАҢЫ ЕРАК ТӨНДӘ

хикәя



Алар, алдан сөйләшкән буенча, нәкъ күрсәтелгән сәгатькә килеп җиттеләр. Кояш Мишә буендагы тәбәнәк тал куаклары арасына кереп бара иде. Җәйге җылы кич кояшның кызыл нурларын йотып бер мәлгә тынып калган, әйләнә-тирәгә тал исе, ләм исе таралган, кечкенә өермә булып анда-санда черки уйнап ала, су уртасында балык чупылдаганы ишетелеп куя иде. Кызган моторлар, бензин, резина исе болын һавасын бераз бозса да, күп тә үтми табигать җиңде: яшел корпуслы газикның да исе таралып бетте, шәһәрдән килгән зәңгәр «Волга» да аксыл-яшел тал куаклары арасында зур, мәһабәт җир чәчәгедәй күренә иде.

Артык ыгы-зыгы килмичә генә эшкә керештеләр. Фәйзи — шәһәрдәге зур гастроном директоры — «Волга»ның багажнигыннан кәгазь тартмалар чыгарды, аларны сүтә башлады. Ислам белән Фатыйх газик эченнән палатка чыгардылар, балта, чиләк, бәйләме белән утын, җыелма урындыклар бушаттылар.

— Коры закон, — диде Фәйзи кәгазь тартмаларны урнаштыргалап. — Миннән рөхсәт юк. Сез, район кешеләре, бәлки, балыкка килгән булып төтен чыкканчы төшерәсездер. Ләкин минем белән — юк. Беләм мин сезне, начальникларны...

— Монда район начальнигы дигәнең бер Фатыйх инде, кыланса шул кылана торгандыр, — диде Ислам палатка казыкларын аралап яткан көйгә. — Ә миндәй рядовой совхоз директорыннан атнасына бер йотым тереклек суын күпсенүең — кызганыч. Кем әйтмешли, бу сыйфат сине һич тә бизәми, гастроном директоры.

— Алайса безнең фикер каршылыклары байтак әле, — дип кушылды Фатыйх. — Сезнең белән телефоннан сөйләшкәндә мин болайрак күз алдына китергән идем: мин, элеватор директоры буларак, икмәк ягын карарга тиеш дип уйладым. Менә, пожалысты, ике бөтен орловский ипи белән ике батон алып килдем. Ислам — совхоз директоры буларак, ит, сөт, йомырка, яшелчә алып килергә тиеш иде, минемчә. Ә гастроном хуҗасыннан билгеле инде — бер ящик сыра, борын башына берәр шешә юньле әйбер: «Старка»мы, «Юбилейная»мы — анысы синең эш...

Фәйзи шаярмый икән: ящик өстенә ашарга әзерләгәндә берәүне дә якын китермәде, үзе турады, үзе бүлде — әмма палатка корылып ут өстендә чәйнек кайный башласа да «юньле әйбер» күренмәде. Ислам, тамак кыргалап, әллә ничә тапкыр газигы ягына борылгалап карады, әмма Фәйзи каты торды.

— Эчмәгән әйберме ул? — диде. — Менә шуны эчә башласак, я төнне күрми калабыз, я юньле сүз булмаячак, я балык тота алмаячакбыз. Безгә ничә яшь хәзер? Кырык бишәр? Кырык алтышар? Әһә, димәк, бик кысып әйткәндә дә унбишәр еллык стаж бар бу өлкәдә? Җитте. Азындык, егетләр, азындык. Чабатадан чыгып күтәрелдек тә, хәзер кыланырга яратабыз.

— Соң бит ризыгы бик затлы... — Монысын Фатыйх әйтеп карады. Ящик өстендә ризык чыннан да патша өстәлендәгечә иде. Фәйзи озын пәкесе белән бер-бер артлы өч тавыкны ботарлап тоз сипкәләде, ысланган балык, яшь кыяр, йомыркалар, банка белән тозлы помидор, яңа редис, кыяклы суган, керән, нарзан сулары...

— Эчмичә ашарга өйрәнергә кирәк, тишек борыннар, — диде Фәйзи тавык итенә керән сөртеп.

Ирләр кырык биштә кызык була: бу чорда дөньяны үз кулында тотасы, биетәсе, кнопкаларга басасы, эшне әйләндереп-әйләндереп кенә куясы, булдырасы, шөһрәт казанасы, кырыс һәм миһербанлы буласы килә. Шәп итеп эшләп, шәп итеп күңел ачасы килә. Күпләр шулай эшлиләр дә. Әмма кырык биштән соң, бәни адәмне табигать эчтән кыйный, какшата башлый. Чәч коела, баш түбәсе ялтырый — син инде ник әллә кем булмыйсың, баш түбәң ялтыраса, бер генә хатын-кыз алдында да син үзеңә игътибар яулап ала алмыйсың; инде берәм-берәм тешләр сынып чыга, баштарак моны әйтмисең, әмма яңакта хыянәтчел төстә чокырлар, җыерчыклар барлыкка килә. Инде теге ризык, бу ризык килешми. Берәүләргә ак ярамый, икенчеләргә кызыл. Берәүләр боржомисыз, икенчеләр кефирсыз яши алмый. «Минем бавырда бит, минем таш бар бит, минем давление бит», — дип сөйләнүләр әнә шул кырык биштән соң башлана.

Ихтимал, Мишә буена балыкка килгәч өч дусның, өч авылдашның да инде кайсында таш, кайсында холецистит, кайсында Боткин авыруы — әллә ниткән чуртымнар бардыр. Әнә бит берсе керәнне үзеннән читкә этеп куйды, икенчесе йомыркадан баш тартты, бу инде зерәгә генә түгел.

Төнгә кармак салдылар. Исәп җәен тоту иде. Элеватор директоры инкубатордан борынлый алмыйча томаланган берничә чеби алып килгән иде, имеш, җәен шуңа әйбәт эләгә. Караңгы төште, яр буена урнаштылар, Фәйзи икенче кат чәй куеп җибәрде, учакны рәтләде. Төнге чикерткәләр, бытбылдыклар концерты башланды. Бераздан яр буена Фәйзи дә килеп урнашты. Сүзсез, тын гына байтак утырдылар. Нәрсәдер сөйлисе, нәрсәнедер хәтерлисе иде, әмма берәү дә сүз башламады.

Бу вакытта күктә ярты ай, ертык, зәгыйфь болыт кисәкләре, елга өсте, чикерткәләр тавышы һәм шулар янында һәр берсе аерым өч шәхес бар иде. Ә... Тагын, кайдадыр, тартай кычкыра икән. Тар-р-тар-р...

Тукта әле... Мондый төн бер мәртәбә булган иде түгелме соң? Нәкъ шундый җылы төн, нәкъ шундый чикерткәләр концерты... Әллә бу — беренче мәртәбәме? Адәм баласының күңеле еш кына шулай адаша бит: бу хәл, бу халәт синдә кайчандыр булган кебек тоела. Алданасың. Юк, булмаган, беренче тапкыр бу дисең. Әмма мондый төнне күргән бар. Әйе, нәкъ шулай — өчәү: Фәйзи, Ислам, Фатыйх. Ләкин бик еракта, бик еракта калган ул төн. Ул төн әллә ни-

чек кенә шунда беткесез озын иде, ахрысы, ул төннең таңы атмады. Кайчан булды соң әле ул?

...Ул җәй матур иде, табигать җылы, яңгырлы көннәрдән бүртенеп утыра иде. Аларны, алтынчы классны тәмамлаган малайларны, колхоз сыерларын көтәргә куштылар. Авылдан ат арбасына чиләк белән тары ашы салып, аларны Җәләли агай ашатып китә иде. Көненә өч литр аш. Өч мәртәбә, берәр литрдан. Кигәвен вакытында сыер көтү кыен нәрсә, сыерлар урманнан кырга кача, алар артыннан яшь, ахмак бозаулар иярә.

Ул кичне сыер савучы кызлар да вакытында килде, кичке сөтне флягаларга тутырып авылга да вакытында озаттылар, әмма аш килмәде. Җәләлинең авылда кызмача йөргәнен, трактористларга да төшке ашны бик соң илткәнен әйттеләр. Кызлар китте, утарга малларны япкач өч малай учак янына утырдылар. Дөньяга яфрак исе, кырлык үләненең җылы, парлы исе таралган иде. Кайдадыр «кор-р-кор-р» килеп урман тавыгы көрелдәде, кичке саргылт күктә тилгән очып йөрде, якындагы агач башында пи-пи дип аның баласы кычкырды.

Әллә анысы тилгән түгелме? Кайсыдыр агач башыннан тагын бер кош өзелеп-өзелеп әнисен чакырды.

— Пил-дер-рек! Пил-дер-рек! — дип үзәк өзгеч итеп ялварды.

Эчне борып, күз алларын караңгылатып тамак ачты. Кузгалак, акбаш ашадылар, Фәйзи биек юкә башына менеп авыл ягын күзәтеп төште. Җәләли агай күренмәде.

Бераздан тамак ачканы онытылгандай итте. Тамак ачу билгеле бер вакыттан соң сусата башлый, землянкага кереп чиләктәге кое суын эчтеләр. Инде сыерлар яткан, чебен-черкине пышылдап куалар, йокларга әзерләнәләр иде. Шул чакта сүзне кем башлады икән соң әле? Фәйзи үземе? Үзедер, тамак ачкач аның ашау турында тәмләп сөйли торган гадәте бар иде бугай...

Сугыш башланасы елны кышын ук Фәйзинең этисе Мари ягына күчеп киткән иде. Фәйзинең әнисе үлгән, этисе — күнитек, ботинка төзәтү буенча оста (патша вакытында итекче булып армиядә хезмәт иткән), колхоз идарәсеннән рөхсәт алып, өй тәрәзәләрен кадаклап, малайны ияртеп һөнәргә чыгып киткән иде. Ике ел буе алардан хәбәр-хәтер булмады. Бары тик кырык өченче елның май башында гына алар корал төягән сандыкларын бәләкәй арбага салып Мари якларыннан авылга кайтып төштеләр. Оста кул Гамәли карт күрше-күлән белән артык сүз куертып тормады.

— Илдә чыпчык үлми, — диде. — Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил дигәнне беләсезме?

Үзе колхога шорник булып урнашты, орлык бәрәңгесе юнәтеп бакча утыртты. Фәйзинең (малай вакытта аның исеме Фәез иде) укуы өзелмәгән икән, анысы алтынчыга керде. Фәез мари телен өйрәнгән, урамга чыкса малайлар җыелышып аннан марича санаталар иде. Тегесе ялындырмый.

— Икыт, кукыт, — дип санап китә.

Карт белән малай Мари ягында мохтаҗлык күрмәгәннәр икән. Туган нигезгә кайтып урнашып, ачлык дигән үги ана белән очрашкач, Фәез еш кына Мари якларындагы ипине, тәбикмәкне, яшел суган турап майда болгатып пешергән табак тулы бәрәңгене, чоландагы ачыган мүк җиләген, кышка тозланган кисмәк-кисмәк ак гөмбәне, очырмага элгән йорт колбасаларын искә алып сөйли торган булды. Малай, ахрысы, бераз арттыра иде, әмма аңа әйбер әйтүче булмады. Кичен бәрәңге яки кычыткан шулпасы ашап урамга чыгып утырган малайларга «йорт колбасасы», «мүк җиләге» дигән сүзләрнең нәрсә икәнен белмәсәләр дә, тыңлавы рәхәт иде.

...Юкә башыннан төшкәч Фәез учак янына килеп утырды, болай гына учакның көлен болгатты һәм сүз башлады.

— Менә, ичмасам, без Марида вакытта, — дип сөйләп китте ул (Мари якларында йөргәнен сөйли башлаганда аның күзләре нурланып китә иде), — безнең шулай иде: иртән торышыңа хуҗа хатын бәрәңге күзикмәге пешергән була. Мае — тәлинкә төбәләмәсеннән. Бәрәңгене арчып пешерә, төя, шуны күзикмәккә җәя дә, урталай бөкләп табага салып майда чыжылдата. Син йокыдан торышка — өчаяк тулы бәрәңге күзикмәге...

Фатыйх белән Ислам аның каршына утырганнар иде, учак көленә карап Фәезне тыңладылар. Фәез исә дәртләнеп китте, кызды.

— Ә көндезгә? Мин мәктәптән кайтышка? Әтигә заказ күп килә, акчасы күп, мин кайтышка Мари хатыны биш-алты күкәй пешергән була. Ә алардагы күкәй? Безнең тавыклар чыпчык күкәе сала икән ул. Шуннан, малай, шуны ипи белән, тоз белән ашап җибәрәсең дә, ишек катындагы кисмәктән бер чүмеч мүк җиләге суын тондырасың. Аны эчеп җибәрәсең, малай, буыннарга җөгер-рә...

Фатыйх белән Ислам дәшмиләр, түбән карап тыңлыйлар. Бераздан карт юкә башына Фатыйх менеп китә, әмма авыл юлы күренми инде — караңгы төшеп килә. Тилгән баласы да кычкырмый, урман тавыгы да күрелдәми. Куе чык төшә, борынны әллә ниткән бөтнек исе кытыклый, карт юкә янынңан учак кырына Фатыйх килеп утыра.

— Берәр сыерны тартып карыйк, — ди Ислам түбән караган килеш. — Бу Җәләли сука безне үтерә бит бүген.

— Миңлехәятнең арт бакчасында печән чабып йөргән дигәннәр иде, шул сыйлаган инде аны, — диде Фатыйх өметсезләнеп. — Аның сыерларын да әлерәк кенә саудылар.

— Безгә ике-өч йотым сөт кирәк, — диде Ислам. — Ачка катабыз бит таң атканчы. Вәт сука! — Ислан яман сүгенде.

— Ярармы соң ул колхоз сыерын саву? — дип сүзгә катнашты Фәез. — Сөтне бит озатып торалар. Май заводыннан туп-туры фронтка китә, ди. Әти сөйләде. Без менә Марида вакытта...

Аны Фатыйх бүлдерде:

— Марида, Марида... Иртәнгә кадәр ничек түзәрбез? Көндезге уникедә бер калай кружка тары шулпасы ашаган көе бит без! Ә күпме чаптык? — Ул ачу белән Фәезгә карады. Ашның килмәвенә әйтерсең лә Фәез гаепле иде.

Фатыйх авыр сулады. Аяныч тавыш белән:

— Их, малайлар, бер телем ипи белән бер савыт катык ашасам, үлсәм дә үкенмәс идем, — диде.

Ислам аның белән килешкәндәй итте, әмма мәсьәләне зурданрак куйды.

— Юк, үләсе булгач аны яхшырак ашарга кирәк. Бер табак итле бәрәңге, бер бөтен ипи ашагач дисәң инде. Анда, ичмасам, ахырдан үлсәң дә ярый.

Фәез аларга каршы төште. Аңа — ябык, юка малайга — гомер кадерлерәк, бер ашау өчен генә ул аны бирергә риза түгел иде. Шуңа күрә ул каршы төште. Бер савыт катык өчен үләргә дә, колхоз сыерын савып сөт эчәргә дә ул риза түгел иде.

— Юк, егетләр, колхоз сыерының сөтен савып эчкән дигән данны күтәрәсем юк. Менә без Марида бервакыт шулай урманнан ачыгып кайттык. Иптәш малай белән. Миклай белән. Нурсолада торган вакытта. Кайттык — безнең өйдә дә кеше юк, аларныкында да. Әйдә, ди, Миклай, безнең очырмага меник. Менеп китте. Мин аста торам. Бераздан ишетәм:

— «Федя, ура пура!» — дип кычкыра бу. Марича «Монда кил»

дигән сүз. Мендем. Менсәм — очырма киштәсенә элеп куйган колбасалар. Беләк юанлыгы булыр. Киштә буйлап тезгәннәр. Андагы хуш ис, андагы сарымсаклы ит исе. Берсен өзеп алды Миклай. Сындырды. Ашый башладык... аның тәмлелеге. Беләсезме, аннан нинди тәм килә?..

Нинди тәм килгәнне Фәез әйтеп бетерә алмады, кинәт борыны белән учак янындагы көлгә барып кадалды. Фәез әсәренеп торып басты, иптәшләренә карады. Фәезгә арттан китереп сугучы Фатыйх икән. Фатыйхның күзләр алмашынган иде.

— Ялганлама! — дип чырылдады Фатыйх. — Юк ул, булмаган анда колбаса. Каян килсен ул сугыш вакытында...

— Ник булмасын? — дип чәрелдәп ябышты Фәез. —Ник булмасын? Аны сугышка кадәр үк ясаганнар. Беләсеңме биш ел торган колбаса нинди була? Авызга алгач үзе эреп китә. Беләсеңме, аннан нинди тәм килә?..

Шул мәлдә Фәез учак яныннан сөрлегеп тагын барып төште. Аның өстенә мәчедәй сикереп Ислам кунды. Исламның йодрыклары йомарланган иде.

— Син, падла! (Ислам бер елны ФЗОга китәм дип комиссияләр торып йөргән малай, шуңа күрә сүзнең төрлесен белә). Син!.. Биш елга чыдамый колбаса! Чери ул!

— Череми! Череми! Менә безнең Марида...

Фәез сүзен тагын бетерә алмады. Туп урынына тәгәрәп аның янына Фатыйх сикерде. Сикерде һәм килгән хуттан авызына чәпәп җибәрде...

— Маридамы? Маридамы? Колбасамы? Менә сиңа колбаса! Менә сиңа тәбикмәк.

Ул Фәезнең өстенә менеп утырды:

— Ялганлама! Ялганлама!..

Каяндыр таң беленгән сыман иде. Әмма таң беленәсе якны орчык төсле озын кара болыт каплаган, шуңа күрә таң бүленеп калган сыман һәм мәңгегә атмаячак сыман иде...

Учак янында гына Җәләли агайның делянкадан чыгарган утын штабеле. Ике кубометрлап булыр. Чи усак. Ислам пәкесен алып шуны каезлый башлады. Каезлаган кабыгын кабып карады. Берәр капкач ярсып-ярсып чи усакны тунарга кереште.

— Бар, кәтилүкне алып кил, — диде ул Фатыйхка. — Ә син, ялган капчыгы, учакны дөрләт. Менә дигән ботка ашатам мин сезгә...

Урман коесының суында усак кайрысы тиз пеште. Бераз тоз да сипкәч ниндидер шома, кайнар, йомшак масса ашарлык ризыкка әйләнде. Агач кашыклар белән берәр тапкыр авыз иттеләр.

— Берәр чүмеч кенә сөт савып аласы булган,— диде Ислам төкеренеп.—Аның белән генә хөкүмәт үлмәс иде әле. Сөте булса менә дигән ризык буласы бу... Хөкүмәт өчен кем кадерлерәк? Бер чүмеч сөтме, әллә өч егетме? Без, мужыт, шушы төндә исән калсак, үскәч әллә кемнәр булырбыз әле? Мужыт, менә шушы урманның лесничие, шушы колхозның председателе булырбыз? — Бу сүзләрне ул Фәезгә карап әйтте.

Әмма Фәез, барысын да онытып, инде тагын җанланган, нәрсәдер сөйләргә җыена иде.

— Ә без Марида чакта... хуҗа хатын бәйрәм көнне сөт белән майда гына таба күмәче пешерә. Зур да түгел, әнә Исламның кашыгы зурлыгында гына күмәч. Майлы табада. И тегене тотып урамга чыгып китәбез, бер тамчы ашыйсы килми. Беләсезме, нишлибез? Тәгәрмәч итеп тәгәрәтеп уйныйбыз. Ие... Билләһи! Кояштыр! Җир йотсын менә!...

— Юктыр, — диде Фатыйх авызыннан лайлалы кайнар кайрыны

тартып чыгарып читкә ыргыткач.— Булмас. Ялганлыйсың син, майтри малай. Изәм бит мин сине.

Фәез исә эшнең кая барганын һаман аңламый иде, чәрелдәп бәхәскә керде.

— Юк, билләһи менә! Майда пешкән күмәчне урам уртасында тәгәрәтеп... Миклай белән! Ул өйдәге май күмәче дисеңме! Табак тулы!

— Житте! Үтерәм мин сине! — дип, яшь үгездәй акырып Ислам урыныннан торды. — Үтерәм! Җир йөзендә бер ялганчы ким булыр.

Фатыйх та сикереп торды:

— Майтри! Күмәчне тәгәрәтәләр димени? Ризык бит ул! Бирермен мин сиңа! Башыңны култык астына кыстырып авылга кайтарып җибәрәм бит хәзер! Күмәчне тәгәрәтергә... Кара син аны!

Фатыйх тагын Фәезнең авызына сукты. Сугу тавышы Исламның да канын кузгатты.

— Каныма тоз салдың, малай, сөякләреңне тубалга тутырам бит хәзер! — дип җикеренде анысы.— Ник ялганлыйсың син, ә!

Фәез капланып ятты, ара-тирә аның үксеп елаганы гына ишетелә иде.

— Ә мин сезгә каршы кул да күтәрмим. Бер дә. Мәгез, кыйнагыз — сез икәү. Тульке мин дөресен сөйлим. Колбасаны ашадык! Күмәчне тәгәрәттек! Миклай белән!

— Тәгәрәттегезме? Ашадыгызмы? Менә сиңа, менә сиңа! Беттең син болай булгач!

Фатыйх кызган иде, ул үзен-үзе белештерми Фәезне кыйнады...

Ул төн бик озын булды. Таң атмады да атмады. Ислам арада гәүдәгә тазарагы иде, аның кинәт кенә эче бора башлады, ул бөгәрләнеп Фәез янына барып егылды. Җирдә тәгәрәп йөрде. Ара-тирә ул тәгәрәп Фәез янына ук килеп җитә. Инде бераз гына яктыра башлаган, шул яктылыкта Фәезнең шешкән иреннәре, кара көйгән йөзе күренә. Соңгы тапкыр Фатыйхның кулы гел бит тирәсендә йөрде шул. Фәез авыр ыңгырашып ята, үзе берәүгә дә берни әйтми иде.

— Таң атса килер ул. Тик аш суынган булыр инде. Аңа эләгә инде моның өчен. Прсидәтель белми инде безнең нихәлдә икәнне. Синең эчең авыртамы? Түз, завферма килсә, бер чүмеч сөт бирми калмас, — дип ул бераздан Исламны юата башлады. Әйтерсең берни дә булмаган...

— Ай-й! үләм-м-м! Эчем-м! Үл-ләм-м! — Монысы Фатыйх тавышы. Фатыйх җиргә утырган, күзләрен ямьсезләтеп, бүре баласы сыман күккә карап үкерә иде.

Тик Фәезнең генә — кыйналгангамы — эче авыртмады. Әмма аның яңак сөякләре бик сызлый, аскы ирен бияләй булып асылынган, күз төбе шешеп килә, кыза, сулкылдый иде.

Ә таң атмады да атмады...

Ул заманнан бирле утыз ел вакыт узган икән. Утыз ел эчендә ниләр булмаган? Фатыйх белән Ислам шул утыз елда армия хезмәтен үттеләр, кайткач, олыгаеп кына кичке мәктәп тәмамладылар, аннан икесе дә читтән торып югары белем алдылар. Фәез исә армия хезмәтенә яраксыз табылды — сәбәбен һич әйтмәделәр, военкоматның бөтен эше аны рентген юлында йөртү булды.

Гамәли карт үзенең алтын кулларына авылда эш беткәч озак баш ватып тормады, авыл читендәге каенлыкка сәфәр кылды.

Фәез үсте, егет булды, финанс-экономика институтына кереп, аны тәмамлады, шәһәрдә эшкә калды, хәзер — депутатлык дисеңме, орденмы, грамотамы — барысы да аныкы. Хәер, Ислам белән Фатыйх та зур кешеләр хәзер: Ислам турында ничә тапкырдыр инде

газеталарда яздылар, ничә мәртәбә аның совхозы кырларыннан телевидение тапшыруы булды. Фатыйхны әйтәсе дә юк! — Нишләп йөреш? — Менә Совминга чакырдылар әле! — Кая барыш? — Краснодарга семинарга! — Шәп икән! — Шәп сиңа, тәҗрибә уртаклашып чыгыш ясыйсы бар.

Гел шулай...

Нигәдер, бу төн дә озын булып чыкты. Җәен инкубатор чебиен кабарга һич тә ашыкмады. Таң атарга ерак иде әле. Ислам көне буе басуда йөреп арыган иде, йокыга авыша башлады.

— Төн салкыны керде, иллешәр грамм гына авыз итмибезме? — диде ул Фәйзигә юаш кына карап. Исәбе — шуны авыз иткәч теге авыр мәсьәләне кузгатып бер сөйләшү иде. Фәйзи исә (нәкъ теге вакыттагы кебек!) якын да килмәде.

— Организмың ял итсен бер, балык тотканда каян чыккан гадәт ул,— диде.

Исламның, әлбәттә, машина эчендә анысы да бар иде, әмма Фәйзи сүзеннән чыгарга намусы җитмәде. Фатыйх, гадәте буенча, бераз җиңеләеп маташты, ничек инде ул, өч дус, өч яшьтәш бергә очрашкач табигать кочагында, фәлән-төгән дип тел шомарта башлаган иде — туктап калды. Фәйзи — гомер буе аларга намус сакчысы ролен үтәгән Фәйзи — үз сүзеннән бер дә чигенердәй күренми иде. Нәкъ теге вакыттагы кебек...

— Мин бер ярты сәгать черем итеп алыйм, — диде Ислам палаткага таба авыр атлап.

— Фәйзи дус дневалить итәргә каршы булмаса, мин дә бер-ике мең секунд кына ятып торыр идем,— диде Фатыйх та.— Унбиш көн инде юньле йокы күргән юк.

Фәйзи өч кармак янында калды. Калкавычны кыймылдатучы булмады, хәер, моның кирәге дә юк иде. Иң кирәге, ихтимал, инде эшләнгән иде: теге замандагы озын төннән бирле аларның бер генә тапкыр да шулай очрашып бергә төн уздырганнары юк иде — менә бүген шуңа ирешелде, ничектер җан җылынып китте, кан тамырлары киңәйде, соңгы елларда даими рәвештә сизелеп торган буыннар сызлавы, баш авыртуы бетеп калды, тән җиңеләйде.

Тукта әле, шуңа ирешкәч тагын ни кирәк? Елга суының патшасы, шома, әмма беркатлы юләр җәен балыгын нигә дип яшәүдән мәхрүм итәргә? Ислам белән Фатыйх бераздан безне уятырсың, җәен балыгы таң җилендә камышлар селкенә башлаганда каба, диделәр. Бүген таң тиз атмас әле. Әнә көнбатыш ягыннан ялкау гына җил исеп куйды, еракта — әллә кайда! — гөрелдәү ишетелеп алды, талгын җилгә камышлар чыштырдашып куйды. Фәйзи кармак җепләрен судан чыгарды. Палатка янына килде. Палатка эчендә тигез ритм белән гырлаган тавыш Исламныкы иде. Фәйзи аның аяк очына утырды. Менә бит әйбәт уйланды әле бу. Нәкъ утыз елдан соң. Нинди юньле егет бу Ислам. Хәер, безнең яшьтәшләрнең бөтен буыны шулай булып чыкты. Безнең яшьтәшләрне кая куйсаң да була. Безнең буында эшлексезләр, ялкаулар, эчкечеләр, семья бозучылар юк. Исламның ничә ел инде яшьрәк егетләр җитәкләсен, дип урынбасарлыкка төшәсе килә. Әмма совхоз халкы җибәрми. Дөрес, бер елны Исламны (халык сизми дә калды!) авыл советы сессиясендә совет председателе итеп сайлаганнар иде. Ул вакытта әле совхозга әйләнмәгән, колхоз вакыты иде. Ике ел узганын да көтмәделәр, колхозның отчет-сайлау җыелышында халык, ай-вайга да карамастан, Исламны яңадан бертавыштан председательлеккә күрсәтте. Ул вакытта Ислам ике көн буе ике постта берүзе торып калды. Аннан ашыгыч авыл советы сессиясе җыйдылар һәм «башка эшкә

китүе сәбәпле» Исламны авыл советы председательлегеннән азат иттеләр.

Фәйзи авылга кайткалап йөри — боларны белә иде. Тыныч йокы, дускай, сиңа мондый ял бик сирәк эләгәдер...

Фатыйх исә палаткага кереп тормаган, «газик»ның арткы утыргычына сузылып яткан да, аякларын ачык ишектән салындырган, теге вакыттагыча тыныч, тавышсыз йоклый, әмма аның йокысы бик зирәк, аз гына «шылт» иттеңме — ул уяна. Сандугач йокысы. Җиңел холыклы кешеләрнең йокысы шундый була. Фатыйх — җиңел, тиз кыза, тиз сүнә. Телгә дә җор, тиешле сүзне вакытында таба, әйтә белә. Бервакыт аның хуҗалыгын карарга үзәктән зур начальник килгән. Икмәкнең ишелеп уңган елы, элеватор эшкәртеп бетерә алмый, ишек алдында сары гәрәбә тавы, бодай көшеле барлыкка килә. Явымнар башланса — ят та үл! Борчулы вакыт... Үзәктән килгән иптәш Фатыйх белән бодай тавы янында басып тора һәм болай ди:

— Менә минем өстә шундый ачык таулар ике йөздән артып китте хәзер, — ди. — Менә син минем чәчләремне кара. Синдә әле хыянәтчел ак кылның заты да юк...

— Һи-и, иптәш начальник, ди Фатыйх уйлап та тормыйча, — баш андый түгел бит, чәчне агарта торган түгел ул...

Фатыйх гел шулай — авыр вакытта да ыңгырашмыйча эшли, оптимист булып кала, көлә белә. Аның мышнаганы да ишетелми — йоклыймы ул машина эчендә, әллә уйланып ятамы?

Ә менә Фәйзи үзен белеп тора — бүген йоклый алмаячак ул. Бүгенге төннең озын булуын тели ул. Көнбатыштан тагын гөлдерәү ишетелде, камышлар тагын сөйләшеп алдылар, сүнеп барган учакның эссе көленә чыш-пош килеп яңгыр тамчылары төште. Көньяктан төньякка кадәр булган шәфәкъны иңләп кара-зәңгәр болыт каплаган һәм тоташ мәһабәт дивар булып акрын гына монда таба килә иде.

Фәйзи учак янындагы брезентка чалкан ятты. Битенә сирәк вак тамчылар төшеп кытыклый, күзне-колакны кычыттыра, әмма баш астына салган кулларны аласы, кыймылдыйсы килми иде. Җир сулый, елга камышлары серләшә, күк гөрелти-гөрелти бу якларга болыт куа, дымсу җил әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсәне — суны, камышларны, үләннәрне сыйпап уза, иркәли, сөя иде.

Инде яктырырга да вакыт җитте, әмма Фәйзи бу җылы төннең озаккарак сузылганын теләде. Аның күңелендә моңарчы кичермәгән исемсез бер хис туды. Ул хис әле бәя бирерлек дәрәҗәдә формалашмаса да, мәгәр аңа инде бер нәрсә ачыкланды: бу җылы төн, учак янында кара-каршы утыру аларның өчесенең дә кан тамырларында утыз елдан артык йөргән кирәксез таш бөртеген эреткән, һичшиксез, эреткән, болар өчесе дә бу төндә табигать балалары булып калганнар, дөньяның бөтен мәшәкатен, ыгы-зыгысын онытып табигать кочагына сыенганнар иде.

Канны сафландыра, сулышны иркенәйтә торган гөрелте һаман якынлаша иде...

1976, май.

## Ренат Харис

# ТЫНЫЧЛЫК ТАЛӘП ИТӘМ

●

Инде күптән
Кырларда ыгы-зыгы беткән.
Күренми инде күзне сискәндерерлек
Чуар гөлләр,
Урман шәрә —
Чакырып йөдәтми күңелләрне,
Кызыктырмый инде рәшәле күлләр.

Биген ача кочаклар,
Кайнарлана иреннәр,
Ягымлылана төшә сүзләр...

Ниһаять, җитте
Кешене кешегә генә бүләк итә торган
Тыныч көзләр!

●

Агачларда еллар сыры
Күзгә күренә кискәч кенә.
Сагышы да йөзгә чыга
Яшел сарыга күчкәч кенә.
Күз яшен дә яшерми ул —
Өз дә кара бер бөресен...
Табут я тәре ясасаң,
Үпкәләгәнен күрерсең.
Утка салсаң, нәфрәтеннән
Чатный-чатный янар, көяр...
Ә серләрен исән килеш
Тик шагыйрьгә генә сөйләр.

## Космоста көз

Космоста көз.
Йолдызлар сап-сары...
Галәм агачының яфраклары коелмыйлар.
Җирем агачлары инде шәп-шәрә.
Күңелем агачлары да,
Шулар сыман,
Бәргәләнә, сагышлана, шаулый, яшәрә...
Гомерем агачының да тамыры Җирдә —
Яз, җәй, көз, кыш булып үзгәрә.
Коелган яфрак белән очрашканда да күзгә-күз,
Миңа яшәү кызык —
Һәрчак үзгәрештә булу миңа үз.
Тирәмдә кыштырдыйлар сары яфраклар.
Ә космоста тып-тын үле көз.

●

*Совет космонавтларына*

Аларның һәр яклары идән, һәр яклары түшәм.
Мин һәр көн алар катына менеп төшәм.
Билгеле, яннарына кермим,
Иллюминаторларыннан гына карыйм.
Җирдә ике Кеше җитми —
Мин кешеләрне барлыйм.
Кояш батареяларыннан сөртәм космос тузанын,
Кул уңаеннан һәрбер җөйне капшап узамын —
Метеорит бәрелеп салмаганмы яра?
Борчылырсың да —
Кешене сөймәс космоста
Тере кораб.
Күңелемне сүрү итәм дә,
Корабны төрәм.
Тынычланам.
Әверелеп Галәм ирене
Төшәм Җиргә.

●

Йолдызларга төбәлеп,
Горур тора «Сөембикә» —
Казанның кызыл түбәсе.

Кичер,
Аның безенә эләгеп,
Эчеңне ярдырткан авыр болыт,
Син үтәсе юлдан
Тайпыла алмаган ул,
Чүгә алмаган мескен булып.

Рәнҗемә,
Аның очына юлыгып,
Түшеңне тырнаткан ярсу вакыт,
Калкып яшәргә дип баскач,
Калмаган ул ятып.

Кичерегез,
Рәнҗемәгез —
Күптән төзәлде ярагыз!

Сүзегезне ишетергә дип сузылып,
Янтаеп тора Сөембикә манарасы.

## Күлкегә калса

Күз күлкегә калса,
Кешегә оят
төс алдында.

Борын күлкегә калса,
Кешегә оят
ис алдында.

Колак күлкегә калса,
Кешегә оят
җыр алдында.

Кул күлкегә калса,
Кешегә оят
кыр алдында.

Аяк күлкегә калса,
Кешегә оят
юл алдында.

Баш күлкегә калса,
Баш күлкегә калсамы? —
Кешегә оят
ил адында...

## Үтерергә өйрәнәләр

Үтерергә безне өйрәнәләр...
Манекеннар, әнә, йөзтүбән
Тузан көртләренә капланганнар —
Күкрәкләре инде йөз көйгән.
Кулларында әлегә япьле таяк,
Меңәрләгән учта ышкылып,
Ул шомарган. Ул тик йөрәк күзли —
Гади таяк түгел, мушкалы.

Үтерергә безне өйрәнәләр...
Өйрәтәләр күндәм тимерне.

Тимер көпшәләрдән чыккан әҗәл
Күпме мишеньнәрне җимерде...
Алар безнең канны агызмакчы
Мишеньдәге кызыл йолдыздан.
Ә йөрәкләр безнең мишень түгел,
Тамырларда ага алсу таң.

Үтерергә безне өйрәнәләр...
Галимнәрнең миен савалар,
Атомнарны фетнәгә өндиләр,
Нейтроннарга коткы салалар.
Агуларга дуслык кулы сузып,
Микробларга тотып тәлинкә,
Ясамакчы алар Җир өстендә
Безне үтерә торган ярминкә.

Без яшәргә Җирдә өйрәнәбез!
Безнең максат авыр, катлаулы.
Аңа бәрелеп инде ничә үлем
Өс-өстенә ничә кат ауды.
Кызганычка каршы, айнадылар...
Сытып булмады шул бер орып.
Хәзер бездә әзер — Кояш кебек,
Җир шары күк ныклы йодырык!

●

Бала турындагы уйлар йөдәтә башны...
Җирнең киләчәген күрәсе килә башлый —
Балаң өлешенә тиячәген.

Син — тылсымчы, кыю фантаст.
Йөрәгең аша чор-гасырлар
Эфир булып исә.
Син — балаң гасырында.
Үз гасырыңда яшәвең, билгеле, истә...

Тәгәрмәчкә тәгәрмәч күк —
Ай кагылган Җиргә...
Һималайлар Ай кратерына кергән...
Ишелә таулар,
Сытыла шәһәрләр,
Диңгезләр ташалар шаулап...

Аһ, бала турындагы борчулы уйлар.
Әйләнәләр, ахры, чиргә...

Мин бүгенге Җирдә!

Балам турындагы уйлар
Әверелдерә мине
Нык йөрәкле,
Матур теләкле,
Изге ниятле иргә!

●

Якты аңга да килә кара уй.
Аңа үзең үк тозак корып куй.
Ә тозакны
Өскә асма —
Кара уйның
Башы аста!

## Дуслык турында

...Урындык ватылгалады —
Төзәттек тә утырдык.
Өй ишелгән чаклар булды —
Сипләдек, янә тордык.
Юллар өзелеп калганда
Күпер салып үтәсең...
Ә менә Дуслык өзелсә,
Бетәсең!

## Тынычлык таләп итәм

Кышын да, язын да, җәен дә, көзен дә
Бала тапканнан соң беренче тапкыр
Йоклап киткән ана йөзендәгедәй
Тынычлыкны күрәсем килә күк йөзендә.

Мин тынычлык таләп итәм!

Мәһабәт йөзсеннәр болытлар,
Тигез карасын туры кояш
Җанлыга да, җансызга да...
Тоташтырып Җирне болытларга,
Иген кырлары өстендә
Аллы-гөлле булып балкып торсын
Бәхет билгесе — көмеш дага!

Мин тынычлык таләп итәм!

Вакыты җитеп кенә эресен кар
Һәм җырласын ерганак булып.
Шытсын бөре, төртсен үлән...
Кызган табага тамган тамчыларны,
Буранга юлыккан бөреләрне,
Шундый язмышлы кешеләрне
Күреп беләм.

Мин тынычлык таләп итәм!

Өзелгән имән яфраклары
Ятсын имән тамырына,
Тал яфрагы — талныкына,
Каенныкы — каенныкына...

Кайгыларын тамырына җыйган
Һәм сеңдергән агач үлми, —
Халык кебек, — ныгый гына!

Мин тынычлык таләп итәм!

Сайрасын былбыл, аккош каңгылдасын,
Чыр-чу килсен чыпчык, песнәк,
Күгәрченнәр гөлдерәшсен...
Һәрберебезгә иң кадерле үз җырыбыз,
Җырларыбыз барыбызның да —
Чор тиңдәше!

Мин тынычлык таләп итәм!

Җанлыбыз да, җансызыбыз да
Эчәбез ич һава дигән илаһи сөт!
Күкнең йөзе шатлыклы да, борчулы да —
Беренче тапкыр күкрәк биргән
Ана йөзе кебек.

Мин тынычлык таләп итәм,
Таләп итәм тимердән, таштан,
Таләп итәм кулдан, баштан,
Үземнән, сездән,
Күреп арыган һәм ачылып
Беренче тапкыр шаккаткан күздән,
Илдән илгә китәчәк,
Халыктан халыкларга җитәчәк
Һәрбер сүздән,
Яңгыр тамчысыннан, җилдән,
Һәр фиркадән, һәрбер илдән,
Кыштан, яздан, җәйдән, көздән
Тынычлык
Таләп итәм
Җиргә!

1978

## Мөдәррис Әгъләмов

# КАЙДАДЫР КҮКТӘ КОЯШ...

●

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Агач шаулый, сынган ботак ыңгыраша.
Минем җанда төн белән көн очрашкандай
Чор белән чор,
Җыр белән җыр очраша...
Шаулый көннәр, шомлы еллар ыңгыраша.

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Гүләп оча заман кошы самолетлар.
Могҗизалар гадәтигә әверелә,
Искелеккә әверелә яңалыклар.
Борынларга оя тибә яманлыклар.

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Агач шаулый...
Таңга кадәр ишетелә.
Шаулый җаным, шаулый рухым, шаулый урман,
Туктатырга мөмкин аны кисеп кенә,
Ә ул шаулый, төннәр буе ишетелә.

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Җирнең кайсы ноктасында көн уртасы?!
Син ул хакта уйларга да теләмисең,
Син, бары Син җир шарының умырткасы.
Ә кайдадыр күктә кояш, көн уртасы.

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Яшәп була, эшләп була шулай гына;
Ышанмыйсың, яшәп була, диючегә,
Гомер буе кул ягына уңай гына.
Дөнья кичеп булса икән шулай гына!

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Кеше көче, кеше уе, кеше аңы,
Кеше рухы, кеше тәне, кеше җаны
Әверелә моңлы көйгә, гүзәл сынга...

...Озын төннең
Җиде төннең уртасында.

## Җыр

*Ш. Хамматовка*

Барамы ул әле киләчәккә,
Каламы ул әле безнең исем?
Үз урынын алып җырың калсын
Коммунистик сәнгать өчен!
Коммунистик сәнгать өчен!

Тартышулар, көрәш, бәхәс аша
Иҗат юлың бара, Олы Кешем!
Юл газабы — гүр газабы булсын
Коммунистик сәнгать өчен!
Коммунистик сәнгать өчен!

Купшы сүзләр басмасына басып
Кирәк тапкан, әйдә күтәрелсен,
Ә син ярып үз сүзеңне талкы
Коммунистик сәнгать өчен!
Коммунистик сәнгать өчен!

Кайбер затлар: — Бу ил бетәр, — диеп
Кычкырганда, исбат итә бел син,
Йөрәк белән, кирәк башың белән —
Коммунистик сәнгать өчен!
Коммунистик сәнгать өчен!

## Язучылар бакчасында көз

Бакчада — көз!
Соңга калган зәгыйфь җырлар
Асылынып калырлар күк,
Вакытында өзелмичә
Кырау тигән помидор күк.

Буразнага борын төртсә, —
Исең китә язучыга,
Ак кәгазьгә төшмәгәне
Җимеш булып бәреп чыга.

Көзге байлык,
Көзге муллык,
Һәркайсының күтәргәне,
Мыскыл итеп карап ята
Көзге чәчәк түтәлләре.

Кайсы каклый, кайсы тозлый,
Бетеп килә көзге эшләр...
Вакытсыз туган җыр сыман
Чәчәктәге гөлҗимешләр.

Килер язлар,
Килер җәйләр
Кыш аркылы — алда тора...
Иң югары бер ботакта
Күрмәгәннәреннән көлеп
Өлгергән бер алма тора.

## Юл

Киң түгел, бик киң түгел,
Карлы сукмак тар гына...
Кем дә юк,
Беркем дә юк.
Озата еллар гына.

Үзәк юлга кузгалам,
Галәмгә чыккан кебек.
Нәкъ шулай булгандыр күк
Моннан мең еллар элек.

Кич... Кабат кайтып бәрам,
Карлы сукмак тар гына...
Кем дә юк.
Беркем дә юк,
Каршылый еллар гына.

Ачкычны борам. Керәм.
Өстәлем тора карап.
Нәкъ шулай булыр сыман
Мең еллар узгач кабат.

...Атлар карлы сукмактан
Нәкъ шулай минем төсле,
Шул телдә язып, уйлап,
Мин түгел,
Башка кеше.

## Үкенү

Бер шагыйрьне мактадым да
Һәр адымда ишетәм:
«Шул кадәре мактап аны
Бик ашыкмадың микән?»

Мин үкенәм,
Элегрәк
Ник сүз алмадым микән?
Мин үкенәм,
Бүген мактап
Бик соңармадым микән?

## Сулар гөрелтесе

Еракларда калды, еракларда,
Без юк инде хәзер ул якларда,
Хәтеремдә сулар гөрелтесе,
Сулар гөрелтесе колакларда.

Үләннәргә инде төшкән кырау,
Ромашкалар шиңгән,
Бетте юрау.
Колагымда сулар гөрелтесе,
Ул суларга хәзер юллар урау.

Җырлар гына калды истәлеккә,
Сагышлы ай калды зәңгәр күктә,
Колагымда сулар гөрелтесе,
Очам сыман чиксез зәңгәрлеккә.

Җырларымда калды яра-эзләр,
Тоз сибелгән яра, яна эзләр.
Колагымда сулар гөрелтесе,
Күз алдымнан оча пәрәвезләр.

Алар аша син читлектә кебек,
Дөнья синсез гел чит итә кебек,
Колагымда сулар гөрелтесе,
Сулар минем аша үтә кебек.

Мин дә тынмам сулар туктамаса,
Дөнья үзе уза минем аша.
Колагымда сулар гөрелтесе,
Мин бутамам, дөнья бутамаса.

Сугарылган минем бәгырем җыры,
Җырлар белән тулы бәгырем кыры,
Колагымда сулар гөрелтесе,
Иманым нык, шөкер,
Кальбем туры!

Башак уган кебек җыр угансың,
Җырларыма орлык булдыргансың.
Колагымда сулар гөрелтесе.
Син бит мине кабат тудыргансың.

Синең аваз килми бу якларга,
Кайтавазы гына колакларда.
Син бит миңа— сулар гөрелтесе,
Үзең генә
Ерак-еракларда.

## Гел шулай тоела

I

Кургаштай һаваны
Көч белән киереп,
Яз көне тезелеп кайтканда, торналар,
Каршылый аларны
Бу тиңсез гасырның
Күркенә әйләнгән
мәһабәт торбалар.

Беренче чәчәкләр —
Күзләре туп-тулы,
Торналар җебенә
текәлеп карый.

Егерме беренче
Гасырга җиткәндә
Шулкадәр катлаулы —
Бу —
Шулкадәр гади.

II

Таңнарда яфрактан
Туфракка сикереп
Төшкәндә энҗеле
гәрәбә тамчылар,
Гел шулай тоела:
Күз яше шикелле
Әйтерсең тозлылар,
әйтерсең ачылар.
Кул сузып, ялварып,
Һәр ботак, һәр үлән
Күтәдер шикелле
кешедән яклауны...
Егерме беренче
Гасырга җиткәндә,
Шулкадәр гади —
Бу —
Шулкадәр катлаулы.

## Шагыйрь

Ул менмәкче булып биеклеккә,
Яңгыр җебенә дә асылына,
Ул ашыга,
Ул җитмәкче була
Бу дөньяның нигез асылына.

Ә тирәлек гадәттәге сыман,
Сулар һава җитми,
Шундый бөркү...

Тәрәзәне киереп ачкан сыман,
Ул күкрәген каерып
Ача беркөн.

Әрнүләре-газаплары белән
Кешелеккә үзенең җанын ача,
Әнә шулай атлап китә җирдән,
Горур атлап бара, ахыргача.

Шифа булып ява күкрәгенә
Ак карлары җирнең, яңгырлары...
Ул дөньяның асылын ачмак була,
Ә асылы аның — кеше җаны —
Аның җаны.

●

Кан коелып,
Җан кыелып беткәч,
Легендага күчкәч батырлыклар,
Аренага калка
Шома, этләч
Балык кебек уйнап, йөзе юклар.

Шундый оста алар кул чабарга,
Үрер өчен бауга ярарлыклар...
Салмак кына бара мунчаларга,
Хәтерендә кала: таза, ныклар.

Зыян да юк, дисең, файда да юк,
Күренми дә, дисең, бозыклыклар.
Шуңа микән алма корты булып
Үрмәлиләр тоташ — йөзе юклар.

Чүп үләнне көзен тамырыннан
Юк итәбез,
Тик орлыклар кала...
Икейөзлеләрдән арынудан
Орлык булып йөзе юклар кала.

●

Сау булыгыз!
Күрешкәнгә кадәр.
Вакытында сау булыгыз, ярый!
Үләннең дә көзен тәме бетә,
Сайрар кошлар туктый,
Күке арый.

Бер төш кебек
Без күрешкән көннәр,
Сау булыгыз, киләсенә кадәр!
Китеп барам, бер адым да калмый
Үткән көннәр миңа ияреләр.

## Туфан Миңнуллин

# ЯШЬЛЕГЕМ-ЮЛӘРЛЕГЕМ...

2 ПӘРДӘЛЕ МОҢСУ КОМЕДИЯ

КАТНАШАЛАР:

Гөлнара — студентка
Лилия — студентка
Рәшит — солдат
Илгизәр — Буа егете
Рафинад — көләч малай
Кара мыек — пассажир
Фәхрия карчык — ул да пассажир
Проводница
Чегән хатыны
Роза

Искәрмә: Чегән хатыны һәм Роза рольләрен бер үк артистка башкарырга тиеш. Чөнки Роза сәхнәдә күренми. Әгәр инде режиссер бик теләсә, Розаны сәхнәгә чыгара ала. Ул чакта режиссер иптәш Роза роленә тагын бер артистка табарга мәҗбүр һәм автордан егет белән кыз өчен махсус текст яздырмавы хаерлерәк булыр.

Тагын бер искәрмә: пьесада авторның лирик чигенеш формасында язылган сүзләре бар. Режиссер, теләсә, аларны спектакльдә файдалана ала. Файдаланмаса да, автор үпкәләми. Ләкин автор зинһар өчен дип үтенә — режиссер иптәш ул сүзләрне пьесадан сыздырып үк ташлатмасын иде.

Вакыйга безнең көннәрдә Ташкент — Казан поездының купелы вагонында һәм юл өстендәге станцияләрнең перронында бара. Җәй көне.

### I ПӘРДӘ

Кадерле пассажирлар! Хөрмәтле пассажирлар!.. Автор сезгә пассажирлар дип эндәшә икән, гаҗәпләнмәгез, иптәшләр. Без бит барыбыз да пассажирлар. Гомеребезнең күпмедер өлеше юлда үтә. Әгәр дә инде арттырыбрак җибәрсәң — без мәңгелек пассажирлар. Җир дип аталган гаҗәеп планетага утырабыз да Кояш тирәли әйләнәбез. Көн әйләнәбез, төн әйләнәбез — туктаусыз әйләнәбез. Җирнең туктап-туктап ала торган станцияләре юк. Ә җир өстендә станцияләр, вокзаллар бихисап. Анда — пассажирлар. Ашыгалар, ча-

---

Әлмәт татар дәүләт драма театрында сәхнәләштерелде.

балар, кабалананалар. Кайсылары туган якларына кайта, кайсылары туган якларыннан китә, кайберәүләр кая барганын да төгәл белми. Йөри адәм баласы — эзли, эзләнә. Кемнәрдер шаяра, көлә, кемнәрнеңдер күзләрендә яшь, кемнәрдер өчен барыбер: кайтса ни дә, китсә ни. Автор шулай уйланып Ташкент — Казан поездының купелы вагонында коридорда басып тора, үзе белән бергә кайтасы пассажирларны да күзәтә. Кем белә, бәлки ул шушында язарына азык та табар. Әнә ике кыз, вагон тәрәзәсенә сарылып, перронга караганнар. Кызларның берсе Лилия исемле булырга тиеш, икенчесе — Гөлнара. Әнә читтәрәк бер егет аларны күзли. Анысы, әлбәттә, Илгизәр исемле. Вокзал репродукторыннан үзбәкнең моңлы көе яңгырый.

Гөлнара *(янында басып торган Лилиягә).* Кара кыяфәтенә — Зөһрәсен озатырга килгән Таһир диярсең. Вагон артына ябышып, Казанга хәтле мине озата бар дисәм, барачак.

Лилия. Чынлап гашыйк булды ул сиңа.

Гөлнара. Булмый карасын. *(Перрондагы озатучы егеткә.)* Нәрсә?! Язармын. Син көт. Бит ныклап көт. Очень, очень жди. *(Кычкырып көлә.)*

Лилия. Көлмә инде, үпкәләтерсең.

Гөлнара. Үпкәләсен. Үпкәләүчеләр бер ул гына түгел.

Репродуктордан поездның китүе турында хәбәр итәләр: «Граждане пассажиры! Поезд номер триста восемьдесят — Ташкент — Казань отправляется с первого пути. Будьте осторожны!» Шул ук белдерү үзбәкчә әйтелә: «Хөрмәтле пассажирлар! Өч йөз сиксәненче Ташкент — Казан поезды беренче юлдан китеп ятыпты. Сак булыңызлар!»

Гөлнара *(перрондагы егеткә).* Ә? Язармын дидем ич, ә?.. Мин дә яратам. Ышанмасаң, синең эш... Ышанам, ышанам... Ярый, хуш!..

Поезд кузгалып китә.

*(Гөлнара кулын селки.)* Мескен.

Лилия. Мине күрмәде дә.

Гөлнара. Сиңа гашыйк булса, мине күрмәс иде.

Лилия. Йөгерә.

Илгизәр *(кызлар янына елышып).* Ай-яй, сиптерә. Казанга сездән алда кайтып җитәчәк бу. *(Тәрәзәгә карап.)* Азапланма, тиңдәш. Гөлнараң ышанычлы кулларда. Таныш булыйк, кызлар. Илгизәр, Буа егете. *(Кызлар эндәшмәгәч.)* Сезнең исемне беләм инде — теге егет Гөлнара дип такылдап колакны тондырып бетерде. Сезнеке ничек? Ягез инде, алай гөрбиян булмагыз, өч тәүлек бергә кайтасы. Казанга барасызмы, кайтасызмы? *(Тәрәзәдән карап.)* Калды инде, калды. *(Көйләп.)* Күз керфекләрем талганчы карыйсым калган икән...

Гөлнара *(карашы белән Илгизәрне тикшереп чыгып).* Сезгә нәрсә кирәк?

Илгизәр. Әлегә дус кызыгызның исемен белү кирәк.

Гөлнара. Хөббениса. *(Лилиягә.)* Киттек. Лилия.

Илгизәр яныннан боргаланып үтеп китәләр. Илгизәр алар артыннан карап кала да купеның ишеген ача. Анда Рәшит, Кара мыек һәм Рафинад.

Илгизәр. Инде таныша башлыйк иптәшләр-товарищлар. Исемнәрегезне, фамилияләрегезне, әтиләрегезнең исемнәрен тулы итеп әйтегез. Кыскача биографияләрегезне сөйләп бирегез. Кая барасыз, кая кайтасыз? Юл озак, ныклап танышып куйыйк.

Кара мыек. Тел бистәсе булырга охшыйсыз. Юл буе лыгырдар булсаң, бүтән купега күч.

Илгизәр. Абый!.. Чырайны чытып сөйләшмик, абзый. Монысы әле баласы гына. Төнлә гырлый торган гадәтем бар, анасын шунда күрерсез. *(Рафинад кычкырып көлеп җибәрә.)*

Илгизәр. Нигә көләбез?

Рафинад. Кызык ич.

Илгизәр. Ярый. Юктан да кызык табып көлгәч, димәк, әйбәт егет. Исемең ничек?

Рафинад. Рафинад.

Илгизәр. Әһе, Буа шикәре. Авылдаш икәнсең. Бир кулны.

Рафинад *(кул биреп күрешеп)*. Мин Казанга барам.

Илгизәр. Әһе... Мин үзем Буа егете. Шундый район үзәге һәм тимер юл станциясе бар Татарстанда. Илгизәр Абдуллович Мостаев. Егерме дүрт яшьтә. Механизатор экстра класса. Өйләнмәгән. Милләтем — татар.

Кара мыек. Утыр, болганма.

Илгизәр. Әйе, борчак пешмәячәк, абзый, сезнең белән. Суд каршына басканчы, татулык белән аерылышырга кирәк булыр.

Рәшит *(Илгизәргә кулын сузып)*. Рәшит.

Илгизәр. Менә, монысы егетләрчә. Солдат — һәр вакыт солдат, мәгънәле. Мин дә солдат. Запастагы. Ялгамы?

Рәшит. Әйе.

Илгизәр. Шәп. Димәк, яхшы солдат. Минем кебек. Инде нишлибез? Ташкент күчтәнәчләрен ашый башлыйбызмы?

Рафинад көлә.

Син көлмә. Иң элек синең күчтәнәчләрнең башына җитәбез.

Рафинад. Ә минем күчтәнәч юк.

Илгизәр. Молодец! Минем дә юк. Ташкентта ук ашап бетердем. *(Кара мыекка.)* Абзый, куегыз байлыгыгызны өстәлгә. *(Кара мыек дәшмичә генә купедан чыгып китқәч.)* Да-а, минем белән читен булачак бу кара мыекка. *(Көйләп.)* «Сызылып киткән кара мыек...»

Проводница *(билетлар җыеп йөри)*. Билетлар...

Илгизәр. Бәш өсте. Уначенче урын — бәхетсез сан. *(Купега кергән кара мыекка.)* Телисезме минем урынга — аска, ә мин сезнең куначага кунаклыйм.

Кара мыек *(проводницага)*. Мине бүтән купега күчерегез әле.

Проводница. Ни өчен?

Илгизәр. Бездән ояла.

Рафинад көлә.

Рәшит. Агай, нигә инде сез?..

Кара мыек. Арыдым — ял итәргә кирәк.

Рәшит. Итегез, кем сезгә комачаулый.

Кара мыек. Болтуннарны җенем сөйми. *(Проводницага.)* Күчерегез мине.

Проводница. Мин күчерә алмыйм. Буш урыннар юк. Үзегез тапсагыз — алышырсыз.

Кара мыек. Ресторан кайчан ачыла?

Проводница. Сез барып җиткәнче ачылыр. *(Китә.)*

Кара мыек та чыгып китә.

Илгизәр. Я, егетләр... Фу, мәлгунь, кәефне бозды. Поездның шул ягы начар — очрый бирәү, качып та котыла алмыйсың. Күңеленә корым сылый да куя. Я, мин аңа нинди яманлык эшләдем ин-

де? *(Рафинадка.)* Әйт әле, Буа шикәре, мин аңа начарлык эшләдем-ме?

Рафинад. Юк. Үзе ул әллә нинди.

Рәшит. Юкка исең китмәсен. Ул да кеше ич, кәефе юк чагы-дыр.

Илгизәр. Әйтсен. Кешечә итеп әйтсен. Күчсә ярар иде,.. Я, ярый, егетләр! Теләсә нишләсен. Ә без күңелле итеп кайтырга тиеш. Беләсезме, өч көн бергә. Өч көн кеше гомере өчен бик күп ул. *(Рафинадка.)* Шулаймы?

Рафинад. Шулай.

Илгизәр. Ничә яшь сиңа?

Рафинад. Ундүрт тула.

Илгизәр. Сөйгән кызың бармы? *(Рафинад көлгәч.)* Нигә көлә-сең син сүз саен?

Рафинад. Кызык ич.

Илгизәр. Кызык булса, болай. Ну, Рәшит, безнең вагонда ике фәрештә бар. Берсе Гөлнара исемле, икенчесе — Лилия. Гөлнарасы үземә, Лилиясе сиңа. *(Рафинадка.)* Сиңа да берәрне табарбыз юл уңаенда.

Рафинад. Миңа кызлар кирәкми.

Илгизәр. Кирәкми дияргә ашыкма. Егет кешегә кызлар һәр вакыт кирәк. Бергәләп курчак уйнарсыз... Син дә әллә нигә күңел-сез әле, Рәшит.

Рәшит. Юк...

Илгизәр. Күзләрең моңсу. Солдат кешегә моңсу булырга ярамый. Дошманнар сизмәсен. Киттек, Рәшит. Ә син минем әйберләрне сакла, Рафинад.

Рафинад. Әйберләрегез юк ич сезнең.

Илгизәр. Юкмыни?.. Онытылып калган инде, алайса. *(Купе ишегеннән коридорга карап килеп.)* Рәшит, тәвәккәлләдек. Кыз-лар безне көтә.

Рәшит. Юк, мин чыкмыйм.

Илгизәр. Куркасыңмы?

Рәшит. Нәрсәдән куркыйм. Кызлар белән сөйләшә белмим мин.

Илгизәр. Ярый, алайса, утырып тор, Лилияне кертеп бирер-мен. Ычкындырма. *(Коридорга чыга. Тәрәзә янына басып торучы кызлар янына килә.)* Күренмиме?

Гөлнара. Кем?

Илгизәр. Егетегез. Йөгермиме?.. *(Кызлар эндәшмәгәч.)* Ке-шенең үзеген өзә торган бер нәрсә бар, кызлар: син сөйләшергә те-лисең, ә синең белән сөйләшергә теләмиләр. Сез гуманизм дигән төшенчәне беләсезме? *(Кызлар эндәшмәгәч.)* Болай ярамый... Бары-бер сөйләшәчәксез.

Гөлнара. Сезгә ни кирәк?

Илгизәр. Ул сорауны икенче тапкыр бирәсез. Өзеп әйтәм: миңа сезнең белән танышу кирәк.

Гөлнара. Таныштык ич. Сез — Илгизәр, беләбез.

Илгизәр. Анысы билгеле. Арырак китик, ныклабрак таны-шыйк. Бәлки безнең купега кунакка рәхим итәрсез? Менә дигән егет күрсәтәм үзегезгә. Сезнең теге егетегез безнең егет белән ча-гыштырганда — корчаңгы тай.

Лилия. Сез һәр вакыт шундый бәйләнчекме?

Илгизәр. Беренче тапкыр. Чөнки сез миңа ошыйсыз. Гашыйк-лар һәр вакыт бәйләнчек була. Теге егет тә поездан аерыла алмый азапланды ич.

Г ө л н а р а *(көлеп)*. Сүзегезнең дөреслеген исбатлап күрсәтегез — вагоннан сикереп төшегез дә безнең арттан чабыгыз.

И л г и з ә р. Мин андый ук тиле түгел.

Г ө л н а р а. Кызларга тиләләр күбрәк ошый.

И л г и з ә р. Шулаймыни? Алайса, менә ул шыр чыккан тиле — сезнең янда басып тора.

Г ө л н а р а. Кайсыбызга гашыйк инде ул шыр чыккан тиле?

И л г и з ә р. Әлегә анысы сер. Кайтасы юл шактый, йөрәгемне ачып күрсәтергә вакыт бар.

Л и л и я. Сез һәрчак шундыймы? Теләсә кайда йөрәгегезне ачып күрсәтеп йөрисезме?

И л г и з ә р. Ә ни булган? Җир йөзендә мәхәббәт аңлашырга дип махсус билгеләнгән урын юк. Мәсәлән, минем әти белән әни берсенберсе базарда тапканнар. Әти Казанга ит сатарга килгән булган, әни ит алырга чыккан. Әти итен кыйммәткә сатмакчы булган, әнинең акчасы җитмәгән. Киткән сатулашу һәм ул өйләнешү белән тәмамланган. Рәхмәт базарга — дөньяга мин пәйда булганмын.

Г ө л н а р а. Кыйммәткә сатарга җыенасызмы инде үзегезне?

И л г и з ә р. Сукыр бер тиен. Кызлар, нигә инде юл өстендә басып торабыз, әйдәгез безгә. Рәшит зарыгып көтәдер. Мин аңа әйттем, кунакка кызлар алып кайтам дидем.

Г ө л н а р а. Рәшитегез дә сезгә охшаганмы?

И л г и з ә р. Аллам сакласын. Акыллы, тыйнак, чибәр. Күрәсегез киләме? *(Купе ишеге янына барып.)* Килегез әле монда, карагыз әле. *(Кызлар килмәгәч.)* Килегез инде, нидән куркасыз. Лилия, килегез инде.

*Гөлнара уенга кушылып китә. Купе ишеге янына килеп купега карый да көлә-көлә Лилия янына килеп баса.*

И л г и з ә р. Я, ничек?

Г ө л н а р а. Искиткеч!

И л г и з ә р. Әйдәгез, керәбез. Әйдәгез инде. Их, нигә ялындыра икән бу кызлар!

Г ө л н а р а. Әйдә, Лилия.

Л и л и я. Син нәрсә!..

И л г и з ә р. Әһә. Аңлашылды. Лилия куркак икән. Нидәндер шикләнә. Алайса, болай итәбез. Рәшитнең үзен монда алып чыгабыз. Әзергә бәзерне көтеп ятмасын, үзе танышсын. Тик сез качмагыз, кызлар, ярыймы? *(Купега кереп китә.)*

Л и л и я. Син тагын уйнарга җыенасың, ахры.

Г ө л н а р а. Ә нигә?

Л и л и я. Арымадыңмы?

Г ө л н а р а. Ә син? Син инде үзеңне тыйнак итеп күрсәтәсең килә. Нигә кыланырга...

Л и л и я. Мин кыланмыйм. Миңа синең уйнавың ошамый.

Г ө л н а р а. Миңа синең тәти кыз булып кылануың ошамый. Ләкин аның өчен синә ачуланырга җыенмыйм. Шулай бул. Егетләр белән сөйләшмә, сөйләшергә теләүчеләрнең авызларына сук. Кияүгә чыккач, ирең үтереп мактар. Минем Лилиям миңа хәтле бер егет белән дә сөйләшмәгән дияр.

Л и л и я. Мәсьәлә сөйләшүдә түгел. Син гыйшык-мыйшык уйныйсың.

Г ө л н а р а. Кияүгә чыккач, уйнамам әле. Менә берәрсенә чынлап торып үзем гашыйк булырмын да бүтәннәргә күтәрелеп тә карамам. Ә хәзергә... Күңелемә ошаган егет очрамый икән, нишлим — уйнарга кала.

Лилия. Уен — һәр вакыт уен. Ахыры яхшылык белән бетми.

Гөлнара. Әпчи карчык син, Лилия. Эх, синдәге чибәрлек миндә булса!.. Йөзләп егет каршымда тезләнеп торырлар иде.

Лилия. Шуннан ни?

Гөлнара. Җанга рәхәт. Үзеңне хан кызы итеп сизә башлыйсың. Картаеп туртайгач, сагынып искә алырлык хатирәләр була.

Лилия. Хан кызы булуы җиңел икән. Бу егетне тезләндереп ни кызык? Ул хәзер үк тезләнергә тора.

Гөлнара. Ә ул миңа ошамый. Характерларыбыз бер. Ул да уйнарга җыена. Икәүләп уйнагач, кызык түгел. Чынлап гашыйк булганнар белән уйнау кызык. Күрдең, поезд артыннан чапты. Хат көтәчәк инде ул мескенкәй. Рәшит дигәне чибәр.

Шул вакыт Рафинад купе ишегеннән башын тыгып кызларга карый, үзе көлә. Ләкин аны эчтән тартып алалар.

Гөлнара. Сүз безнең турыда бара. Әйдә, керәбез.

Лилия. Гөлнара...

Гөлнара. Теге егетне күрәбез дә чыгабыз.

Лилия. Сиңа ничек оят түгел? Беләсеңме, алар безнең турыда ни уйлаячаклар?

Гөлнара. Аларның ни уйлавында минем ни эшем бар?

Илгизәр чыга, аңа Рафинад ияргән.

Илгизәр *(Рафинадка).* Кая чыктың, бар урыныңа.

Рафинад көлә.

Гөлнара. Егет дигәнегез шушымыни?

Илгизәр. Бусы минем стажер. Өйрәнә торсын. Рәшит кебек оялчан булып үсмәсен. Әнә, чыкмый утыра, ояла. Рафинад, сиңа апаңнарның кайсы ошый?

Рафинад *(көлә, Лилиягә күрсәтеп).* Монысы.

Илгизәр. Ялгыштың, Буа шикәре. Исеңдә тот, әгәр дә ике кыз янәшә басып тора икән, берсен аерып мактама. Икесе дә чибәр диген. Аңладыңмы?

Рафинад. Аңладым. *(Лилиягә күрсәтеп.)* Миңа монысы ошый.

Лилия китеп бара.

Илгизәр *(Рафинадның борынына чиртеп).* Үпкәләттең. Монысы, имеш. Исеме бар бит аның — Лилия. Бар, гафу үтен.

Рафинад. Үзең үтен. *(Көлә-көлә купега кереп китә.)*

Илгизәр. Сез ачуланмагыз инде, Гөлнара.

Гөлнара. Ни өчен?

Илгизәр. Малай гына әле, кемнең чибәррәк икәнен аерып бетерә алмый. Мәсәлән, миңа сез күбрәк ошыйсыз.

Гөлнара. Чынмы?

Илгизәр. Валлаһи, билләһи.

Гөлнара. Ләкин сез миңа ошамыйсыз. *(Китеп бара.)*

Илгизәр. Гөлнара, Гөлнара... *(Гөлнара артыннан чабып бара да кире борылып килә. Купега керә).* Бу юлы булмады. Кереп бикләнделәр. *(Рафинадка.)* Син бик алай узынып китмә, ярыймы, Буа шикәре? Тыңлап кына тор. *(Тәрәзәдән карап баручы Рәшиткә.)* Солдатларча түгел бу, Рәшит. Пешмәгән солдат белән разведкага йөреп булмый. *(Рафинадка.)* Димәк, сиңа Гөлнарасы ошыймы?

Рафинад. Анысы да чибәр. Тегесе әйбәтрәк.

Илгизәр. Әйбәтрәк икәнен каян беләсең?

Рафинад. Беләм инде. *(Көлеп, өстәге урынга менеп китә.)*

Илгизәр *(Рәшиткә).* Я, нигә инде чыкмадың?

Рәшит. Бәйләнмәле.

Илгизәр. Булмады. Планнар пыран-заран килде. Берәү генә булса, сиңа ялынып идемме? Икәү бит. Берсеннән икенчесен аерып алырга кирәк.

Рафинад. Аерып алгач ни була, Илгизәр абый?

Илгизәр. Ни буласын кем белгән? Өч тәүлек бит, өч тәүлек. Бушка, мәгънәсезгә узган өч тәүлек. Рәшит дус...

Рәшит. Сөйгән кызым бар минем.

Илгизәр. Кайда?

Рәшит. Ульяновскида.

Илгизәр. Булса ни? Шуңардан куркасыңмы?

Рәшит. Курыкмыйм, — яратам.

Илгизәр. Кызлар белән сөйләшмим дип вәгъдә бирдеңме, ант иттеңме?

Рәшит. Итмәсәм дә...

Илгизәр кычкырып көлә.

Нигә көләсең?

Илгизәр. Соң, юләр, нинди егет син?..

Рәшит. Мин яратам аны.

Илгизәр. Ярат соң, кем сиңа яратма ди. Ульяновскидагы сөйгән кыз һәм вагонда очраган кыз — икесе ике җан иясе.

Рәшит. Яратам мин Розаны.

Илгизәр. Роза исемлемени?

Рәшит. Роза.

Илгизәр. Бик чибәрмени?

Рәшит. Яратам мин аны.

Илгизәр. Бүтән сүз белмисеңме әллә? Ләкин шунысы бар, агай-эне, син аны яратсаң да, ул сине яратмый.

Рәшит. Каян беләсең?

Илгизәр. Беләм. Дөньяда мин күбрәк яшәгән. Хатын-кызга ничаклы турылыклы булсаң, шуның чаклы начар. Хатын-кызга турылыклы ир-ат хатын-кызның колына әйләнә. Ә колны кем ярата?

Рәшит. Мин кол түгел.

Илгизәр. Колның да нинди әле. Ул сине яратамы соң?.. Ник дәшмисең?

Рәшит. Хатка яратам дип яза.

Илгизәр. Хатка кем ни язмас? Минем армиядән язган хатларны укысаң...

Рәшит. Ул син түгел.

Илгизәр. *(кинәт үзгәреп).* Син түгел... Кайдан беләсең, бәлки мин дә чынлап язганмындыр. Ул да язды. Яратам дип язды. *(Кычкырып.)* Нигә соң, алайса, мин кайтканчы кияүгә чыгып куйган? Әйт, аңлат, нигә кияүгә чыккан? Яратам, имеш. Ярат, әйдә, ярат! Ул анда бүтәннәр белән типтерә. *(Урыныннан сикереп торган Рәшиткә.)* Утыр. Өч тиенлек Розаң өчен сугышып торырга уйламыйм. Ярат. Тик минем адресны алып кал, син хаклы икәнсең, Илгизәр абый, дип хат язарсың. *(Утыра да тәрәзәгә карап бара. Җыр суза.)*

Өй түрендә гөл түгелгән —
Сандугачлар күмелгән;
Җаның сөйгәч гаҗәп икән,
Һич тә чыкмый күңелдән.

*(Өске урыннан аптырап-гаҗәпләнеп карап торган Рафинадка.)* Нигә көлмисең, Буа шикәре?

Рафинад. Син усал икән, Илгизәр абый.

Илгизәр. Усал түгел, энекәш. Болай гына ул. Җырлыйммы тагын?

Рафинад. Җырла.

Илгизәр.

Өй артына суган чәчтем —
Уңар микән суганым;
Бер җырламый булмас инде —
Бар да минем туганым.

*(Рәшиткә)* Ачуланма, агай-эне, я, бир кулыңны. Я, без бит егет кешеләр. *(Рәшитнең кулын кыскач.)* Ышана белү, ахмаклык булса да, үзенә күрә бәхет. Ярый, мәтәлеп китсен Гөлнаралары, Лилияләре. Шулаймы, Рафинад?

Рафинад. Ә ни өчен синең сөйгән кызың кияүгә чыккан?

Илгизәр. Чыгасы килгәндер, энекәш. *(Рәшиткә.)* Син Ульяновскида торасыңмыни?

Рәшит. Юк, Арчада.

Илгизәр. Ничек соң Роза Ульяновскида?

Рәшит. Ул анда яши.

Илгизәр. Карточкасы бармы?

Рәшит. *(кесәсеннән фото алып күрсәтә).* Менә.

Илгизәр. *(фотоны карап).* Алай...

Рафинад. Миңа да күрсәтегез әле. *(Фотоны сузылып ала.)* Алай-ай... *(фото артындагы язуны укый.)* «Рәшиткә — мәңгелеккә».

Илгизәр. Әй, тозсыз әлбә, кешегә язылганны укымыйлар. *(Фотоны алып, Рәшиткә суза.)* Я, рәхәтен күр. Башта кая кайтасың соң? Ульяновскигамы, әниләрең янына — Арчагамы?

Рәшит. Белмим әле.

Илгизәр. Ульяновскийда каршы аламы соң Роза?

Рәшит. Белмим.

Купе ишеген шакыйлар.

Рафинад. Керегез.

Гөлнара *(керә).* Егетләр, пычак биреп торыгыз әле.

Илгизәр. А-а, Гөлнара. Әйдәгез, түрдән узыгыз, рәхим итегез.

Гөлнара. *(Рәшитне күзәтеп өлгерә).* Пычак биреп торыгыз инде.

Илгизәр. Пычак? Була ул, Гөлнара. Әз генә безнең янда утырыгыз инде. Пычак та була, барысы да була. Хәзер, чемоданнан пычакны алганчы гына утырып торыгыз. Менә монда рәхим итегез. *(Гөлнара утыргач.)* Пычак була ул. Пычак юктыр ул бездә, Гөлнара. Пычакны юлбасарлар гына үзләре белән йөртә. Егетләрдә пәке була. Пәке булса да ярыймы, Гөлнара?

Гөлнара. Бирегез инде тизрәк... Лилия көтә.

Илгизәр. Лилия көтә? Пәке?.. Хәзер. *(Кесәләрен капшап.)* Пәке дә юк икән минем, Гөлнара, пәке бит кияү егетләрендә генә була.

Гөлнара. Алайса, сездә булырга тиеш.

Илгизәр. Миндә? Әйе шул, булырга тиеш. Пәке дидегезме әле? Егетләр, бирегез инде Гөлнарага пәке. Лилия пәке көтә ич, егетләр. *(Рәшит, чемоданыннан пәке алып, өстәлгә куя.)*

Гөлнара *(пәкене алып).* Рәхмәт. Кияү егетегез бар икән. *(Ләкин чыгып китәргә ашыкмый.)*

Илгизәр. Нәрсә кисәсез инде пәке белән, Гөлнара?

Гөлнара. Сезнең телне.

Рафинад келә.

Илгизәр. Рәхмәт, Гөлнара, шәп әйттегез.

Гөлнара *(Рәшиткә ишарәләп).* Әллә кияү егетегезнең теле юкмы?

Илгизәр. Солдат телсез булмый, Гөлнара.

Гөлнара. Нигә соң бер сүз дә дәшми?

Илгизәр. Ояла.

Гөлнара. Ояла? *(Күлә. Рәшит алдындагы журналны алып карый.)* «Огонек». «Огонек»та шәп кроссвордлар була. Әйдәгез, чишәбез. Бәләкәй ат... Нәрсә ул?

Рафинад. Пони.

Гөлнара. Дөрес, пони. Авыл хуҗалыгы машинасы?

Рафинад. Ничә хәрефтән?

Гөлнара. Ярый, анысы калып торсын. Хәрби звание. Монысын солдат белергә тиеш инде. *(Рәшиткә.)* Нинди хәрби званиеләр беләсез?

Рәшит. Алар күп.

Гөлнара. Биш хәрефтән.

Рафинад. Майор.

Илгизәр. Синнән сорамыйлар. Буа шикәре.

Гөлнара. Журналыгызны да алып торыйм әле. *(Рәшиткә.)* Сезнекеме?

Рәшит. Мин аны укыйм.

Гөлнара. Кызганасызмыни? Кияү егетегез саран икән.

Ишек янына Фәрхия карчык килеп баса, эчтәгеләрнең сөйләшкәннәрен тыңлап тора. Егетләр аны күрмиләр.

Илгизәр. Юмарт кеше эзләсәгез, менә мин ул, Гөлнара. Киләсе станциядәге бер кочак журнал сезнеке булачак.

Гөлнара. Әнә егетегезгә бүләк итәрсез. Сау булыгыз, пәкегезне кереп алырсыз.

Илгизәр. Гөлнара, печтик кенә утырыгыз инде, Гөлнара. *(Фәрхияне күреп ала.)* Әби, сезгә кем кирәк?

Гөлнара чыгып китә. Фәрхия карчык кереп утыра.

Илгизәр. Әби, сезнең урын монда түгел.

Фәрхия. Беләм, олан. Сөйләшкәнегезне күреп туктадым, бигрәкләр дә тәмле итеп сөйләшәсез. Үзебезнең як теле шул. Кая кайтасыз, оланнар?

Илгизәр. Казан ягына, әби, Казан ягына.

Фәрхия. Менә мин дә кайтып барам әле аллага тапшырып. Ташкиннан утыртып җибәрделәр. Казанда көтеп торалар, алла боерса. Кулдан-кулга — посылка кебек инде. Отпуска алгач, бергә барып килербез дигән ие дә малай, кая аны көтеп торасың. Юлда кеше үлми. Тик менә урын җайсызрак туры килде. Аракы эчә торган кешеләр туры килде. Эчтеләр дә сүгенәләр, затсызлар. Олы-олы адәмнәр юкса. Бүтәннәргә акыл бирерлек кешеләр. Кондуктор янына барам әле, күчереп утыртмас микән.

Рафинад. Поездда кондуктор булмый, әби.

Фәрхия. Безгә барыбер инде олан — телгә ятыш булгач.

Илгизәр. Кондуктор монда түгел, кырый купеда.

Фәрхия. Анысын беләм лә. Каядыр чыгып киткән диме. Өчәү генә кайтасызмы?

Илгизәр. Дүртәү шул, әби, дүртәү. Бер дустыбыз чыгып китте.

Фәрхия. Алай икән. Билитын да алдан алып куйганые да кияү, карчык кешегә дип сорамагандыр кассирдан. Сораган булса, үзем кебек кешеләр янына биргән булырые. Ярар, түзәрмен әле. Тәмсез телле кешеләрне яратмыйм шул, тәмсез телне яратмыйм. Кырык биш ел гомер итеп, сүгенгәнен ишеткәнем булмады Габдуллаҗанның. Малай-

ларым да биргәненә шөкер. *(Рәшиткә.)* Кунакка кайтып барасыңмы, олан, бетерепме?

Рәшит. Кунакка, әби.

Фәрхия. Бик әйбәт. Исән булсаң, дөньялар тыныч булса, бетерерсең дә. Габдуллаҗан абзагыз сугышлардан исән кайтты да... Үлгәненә ике ел тула мәрхүмнең. Китәселәрем килмәгән ие дә бер төпләнгән җирләрдән, малай кайтам диде шул, Чаллы якларына кайтам диде. Мине дә үзеннән калдырмады. Аннан калып нишлим инде. Ташкинда кызым калды калуын. Үзбәк кешесендә кияүдә. Киявебез бик әйбәт тә, әниләр малайларында торырга тиеш диде малай. Габдулла абзагызны калдырып киттем шул. Берүзен калдырып киттем. Ялгызы ята мәрхүм. Карап кайтып киләм әле үзен.

Рафинад. Үлде дидең ич, әби.

Фәрхия. Үлгән булса ни? Кабере бар. Үлеп-нитеп китсәм, икебез ике төштә булабыз инде. Әтиең янына илтеп күмәрсез дим дә малайга, кая инде ул. Кабере бик җыйнак мәрхүмкәйнең. Киявем, кызым карап кына торалар инде. Кайт безнең янга ди дә кияү, кая инде. *(Рәшиткә.)* Менә синең сыман яшел җимнәчтүркәдән кайтып керде Габдуллаҗан абзагыз сугыштан — җыларга да белмим, көләргә дә белмим. Шаян кеше иде мәрхүм, әллә көтмәгән идеңме, Фәрхия, ди. Мин сүз дә әйтә алмыйча торам. Сөенечемнән төн озыны җылап чыктым. Җүләр ди Габдуллаҗан. Хәзер кайтмас шул инде, үзем барсам гына янына.

Илгизәр. Әби, әнә проводница узып китте.

Фәрхия. Ни нәрсә дидең, олан?

Илгизәр. Кондуктор узып китте дим.

Фәрхия. Шулаймы? Рәхмәт төшкере. Үзебезнең кеше булса ярар иде, ходаем. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Рафинад. Әйтергә кирәк проводницага, теге абый белән алыштырсын.

Илгизәр. Тик ят. Ул ир кеше, ичмасам, кыйнап ташларга да була. Моның белән нишлисең? Туксан еллык гомерен сөйли башласа...

Рафинад. Туксанда түгелдер ул.

Илгизәр. Илледә булсын — кирәкми.

Рәшит *(көлеп).* Миңа сөйләргә ирек бирмәс дисеңмени?

Илгизәр. Әй, сине дә әйтер идем. Каршыңда кыз сайрап тора.

Рәшит. Сыланчык. Ниенә кызыккансыңдыр.

Илгизәр. Сыланчык булуында бәрәкәт. Тик миңа сыланмый, күзе син җүләргә төшкән.

Рафинад. Валлаһи шулай, мин дә күреп тордым.

Илгизәр. Ярый, миңа Лилиясе дә ярый. Рафинадка да анысы күбрәк ошый. Егет бул, минем хакка, укаң коелмас. Розаңа хат язармын, кызлар белән сөйләшмәде диярмен.

Гөлнара керә.

Гөлнара. Пәкегез үтми икән, хуҗасына охшаган.

Илгизәр. Рәхим итегез, Гөлнара. Менә монда утырыгыз.

Гөлнара. Сөйләшмәгән егетләр белән утыруы кызык түгел.

Илгизәр. Алай димәгез, Гөлнара. Менә мин күп сөйлим дә бит, ошатмадыгыз. *(Рафинадка чыгып тор дигән ишарә ясый. Рафинад аңлап алып чыгып китә.)* Рәшит безнең аз сөйләшсә дә, һәр сүзе алтын. Гөлнара, зинһар, әз генә утырып торыгыз, мин кайтмыйча чыкмагыз, проводницаны күрәсем бар. *(Чыгып китә.)*

Гөлнара. Дустыгыз утырып торырга боерды, рөхсәтме?

Рәшит. Боергач, утырыгыз.

Пауза. Бер-берсенә карашып утыралар.

Гөлнара. Илгизәр ояла диган иде, оялмыйсыз әле, күзгә туптуры карап торасыз.
Рәшит. Сез дә карап торасыз ич.
Гөлнара. Мин үземне оялчан димәдем.
Рәшит. Мин дә әйтмәдем.
Гөлнара. Сез һәр вакыт шундый җитдиме?
Рәшит. Һәр вакыт.
Гөлнара. Артык җитдиләрне яратмыйм.
Рәшит. Рәхмәт.
Гөлнара. Сез нәрсә, минем белән сөйләшергә теләмисезме?
Рәшит. Нишләп...
Гөлнара. Сөйләшәсегез килмәсә, интекмәгез, Илгизәр кергәнне генә көтәм.
Рәшит. Көтегез.
Гөлнара. Минем әби сезнең кебек кешеләрне гөрбиян ди.
Рәшит. Әбиегез белеп әйтә.
Гөлнара. Сезне кызлар яратамы?
Рәшит. Ярата.
Гөлнара. Мин булсам, борылып та карамас идем.
Рәшит. Рәхмәт.
Гөлнара. Сөйләшәсегез килмәсә, чыгып тора аласыз. Мин Илгизәрне көтәм.
Рәшит. Гөлнарамы әле исемегез?
Гөлнара. Гөлнара. Нигә, әллә начар исемме?
Рәшит. Нишләп... Матур исем.

Пауза.

Гөлнара. Исемемне нигә сорадыгыз?
Рәшит. Болай гына.
Гөлнара. Болай гына сорамыйлар.
Рәшит. Дус кызыгыз Лилияме?
Гөлнара. Лилия.
Рәшит. Пәке сорап нигә Лилия кермәде?

Пауза. Тагын бер-берсенә карап торалар. Гөлнара түзми, карашын иң беренче булып ул ала.

Гөлнара. Карамагыз миңа алай!

Коридорда тавыш. Ишек янына Кара мыек килә. Ул кызмача. Илгизәр аны кертмәскә тырыша.

Илгизәр. Абзый кеше, сабыр ит инде.
Кара мыек. Нинди абзый булыйм мин сиңа? *(Купега үтә. Гөлнараны күрә дә аңа карап тора.)* Хто ты такой?
Гөлнара. Не тыкайте, пожалуйста.
Кара мыек. Што? Марыш отсюдово!
Гөлнара. Фу!.. *( Урыныннан тора да Кара мыекны читкә этеп чыгып китә.)*
Кара мыек. Ты сам фуфу!.. *(Утыра да Рәшиткә карап тора.)* Эләктерденмени?
Рәшит. Абый, урыныгызга менеп йоклагыз.
Кара мыек. Сука!..
Илгизәр *(Кара мыекны изүеннән алып торгыза)*. Кем сука?

Кара мыек Илгизәргә сугарга маташа, ләкин Илгизәр аны нык тотка**.**

Кара мыек *(тартыла)*. Җибәр!.. Җибәр!..
Илгизәр. Әйт, кем сука?
Рәшит. Җибәр, Илгизәр, исерек ул.

Илгизәр *(Кара мыекны нык кына итеп урынга утыртып).* Тиз айнытырмын мин аны.

Кара мыек *(тын гына, селкенмичә утыра да).* Син көчле, да?.. Спортсмен, да?.. Футболист, да?..

Илгизәр. Җитте!

Кара мыек. Боксер, да?.. Кыйна, әйдә, кыйна. Мә, үтер.

Илгизәр. Тик кенә утыр, хәзер чыгарып ыргытам.

Кара мыек Герой!.. *(Елап җибәрә. Рәшиткә күрсәтеп.)* Мин аңа әйттем штоли сука дип. Тегеңәргә әйттем.

Илгизәр. Җит-те!

Рәшит. Абый, менеп ятыгыз.

Кара мыек. Ә минем ятасым килмәсә?.. Син молодец. *(Илгизәргә күрсәтеп.)* Ә ул... Көчең белән мактанма син. Мине болай да гомер буе кыйныйлар.

Илгизәр. Әз кыйнаганнар.

Кара мыек. Да, әз. Син каян беләсең? Син болтаешь. Син бер нәрсә белмисең. *(Өске катка менәргә азаплана.)* Да, син көчле...

Илгизәр. Ботинкаңны салып мен.

Кара мыек. Салам. Салмас дип белдеңме. *(Туфлиен салып, менәргә азаплана.)*

Илгизәр аны этеп менгерә.

Илгизәр. Йокла, тавышыңны чыгарма.

Кара мыек. Да, син начальник. Герой. Кыйныйсың, да? Ә син беләсеңме нигә мин сука дим? Малай да кыйный мине, ул да герой. Әнисе өйрәтеп тора, улы кыйный. Во, шушы кулларым белән көнтөн таш ватып ашатып үстердем, хәзер кыйный. Көчле, мин хәзер кирәкмим. Әнисенә дә мин кирәкмим, аңа таза ирләр кирәк. Ә мин кем? Кыйныйлар. Во, кая минем тешләр? Малай сугып төшерде. Таза... спортсмен... Футболист, боксер... Мин бер кем түгел.

Илгизәр. Йокла диләр. Айныгач сөйләрсең.

Кара мыек тына.

Рафинад *(тынып калган).* Тешләре, чыннан да, юк.

Илгизәр. Исереп бәрелгәндер.

Кара мыек. Да, исергән, бәрелгән.

Рәшит. Ярый, әкрен, йокласын.

Илгизәр. Кәефне бозды. *(Коридорга чыгып китә.)*

Кара мыек *(торып утыра).* Герой!.. *(Тагын елап җибәрә.)* Кайтам, әнием янына кайтам. Ул мине кыйнамас. Ул миңа бармагы белән дә чиртмәде. Иң авыр чагында да сукканы булмады. Сугыш вакытында үз ризыгын миңа ашатты. Мин аны ташлап чыгып киттем. Дурак. Менә хәзер кыйныйлар... Кайтам, әнием янына кайтам. Каршында ятып җылармын, ачуланма диярмен. Ул кыйнамас. Энилар кыйнамый. *(Ята да тагын сикереп тора.)* Эни миңа этине кыйнарга өйрәтмәде. Әтине көтте ул. Һаман көтә. Кайтам, бергәләп көтәрбез. Әти сугыштан кайткан булса, кыйнар идемме... *(Кычкырып.)* Ә мине кыйныйлар... Кыйныйлар!.. Кыйныйлар!!.

Рәшит. Абый, абый, ят, тынычлан.

Кара мыек. Кыйныйлар... Ярый, мин начар ди! Начар ди, мин! Нигә ул мине үз малаемнан кыйната? Үз малаем. Николай. Коля. Битендәге миңенә хәтле минеке. Мине кыйный. *(Әкрен-әкрен тынып.)* Кайтам, әнием янына кайтам. Ул мине көтә торгандыр. *(Кычкырып җырлап җибәрә.)*

Чәчәк идек илләрдә —
Сибелдек чит җирләргә;
Тагы да чәчәк булыр идем

Кайтсам туган илләргә.
Тагы да чәчәк булыр идем...

Проводница керә.

**Проводница.** Нигә тавышланасың? Эчкәнсең икән, йокла.

**Кара мыек** *(кинәт сүрелеп).* Бетте, бетте. Йоклыйм.

**Проводница.** Син сораган идеңме күчерергә?

**Кара мыек.** Кая күчерергә?

**Проводница.** Бүтән урынга күчәм дигән идең бит.

**Кара мыек.** Күчәм, күчәм. Кыйнамагыз гына, күчәм.

**Проводница** *(Рәшиткә).* Булышыгыз... Җиденче купега. Үзе кебекләр янына. *(Китә.)*

**Кара мыек.** Күчәм, күчәм. *(Коридорга чыга. Илгизәрне күреп тайпылыбрак үтә.)* Герой! Спортсмен! *(Күченеп килүче Фәрхия белән очраша.)* Әбекәй! Саумы-исәнме, әбекәй?

**Фәрхия** *(читкә кагылып).* Бар, бар, юлыңда бул. И ходаем...

**Кара мыек.** Ачуланма, әбекәй. Минем әнием дә синең кебекләр инде...

**Проводница** *(Кара мыекны култыклап).* Әйдә, әйдә.

**Кара мыек.** Күчәм, күчәм.

**Фәрхия.** И ходаем, өрлек кебек егетләр... *(Илгизәр белән Рәшиткә.)* Күчәм әле сезнең янга, оланнар. Рәхмәт төшкере, сүземне тыңлады кондуктор. Оланнар, минем әйберләрне генә алып килсәгезче? *(Купега кереп китә.)*

**Илгизәр.** Бетте. Синеңчә булды, агай-эне, кызлар да юк, чурт та юк. Купедан чыкмаячак инде ул. Әйдә.

Китәләр. Фәрхия карчык чыга. Проводница үтеп бара.

**Фәрхия.** Рәхмәт, кызым, игелекле икәнсең. Тегеләр бер үзләре зыян-зарәт эшләмәсләр микән?

**Проводница.** Борчылма, апа, андыйларны күргән бар.

**Фәрхия.** И ходаем, шул сасы сусыз торалмыйлар микәнни соң! Аллага шөкер, ни Габдуллаҗаным, ни балаларым якын җибәрмәделәр шуны.

Илгизәр белән Рәшит Фәрхиянең чемоданнарын, төенчекләрен алып киләләр.

**Илгизәр.** Бөтен Ташкентны төяп кайтасың икән, әби.

**Фәрхия.** Аллага шөкер, бар. Кияү җитәрлек итеп тутырды. *(Сөйләнеп Рәшит белән Илгизәр артыннан купега кереп китә.)*

Ут сүнә. Ут янганда поезд станциягә килеп туктый. Гөлнара белән Лилия йөгереп үтеп китәләр. Илгизәр атылып чыгып тәрәзәдән карый. Гөлнараларны күрә.

**Илгизәр.** Кызлар, нинди станция?

**Гөлнара.** Яшел.

Илгизәр йөгереп чыгып китә, аңа купедан чыккан Рафинад иярә.

**Илгизәр** *(перронда кызларны култыклап ала).*

Казан диләр, Казан диләр,
Казанны күрсәң иде,
Шул Казанның урамында
Подручком йөрсәң иде.

Казанда әләкмәс, хет монда йөреп калыйм. Ничек йокладыгыз, кызлар? Төшләрегездә кемнәрне күрдегез? Төн буе купегызның ишеген сакладым, кердегез дә бикләндегез. Уйлап карагыз, кызлар, тәүлек-

кә якын юл кайтабыз, рәтләп сөйләшкәнебез дә юк. Үкенәчәкбез бит, беләсезме?

Г ө л н а р а *(көлеп.)* Купегызда бер кыз бар ич, сөйләшегез.

И л г и з ә р. Ай-ай-ай... Миннән ике йөз тапкыр күп сөйли. Менеп кунакладың урынына да селкенми дә. Кызлар, шушында гына торып торыгыз. Рафинад, марш минем арттан.

Чыгып йөгерәләр. Гөлнара вагон тәрәзәсен күзәтә.

Л и л и я *(көлеп.)* Күренмиме? Бу юлы уеның барып чыкмады. Бөтен егет тә поезд артыннан чапмый.

Г ө л н а р а. Бик исем китте.

Л и л и я. Китте. Мин сине беләм. Теләгәнеңне эшли алмасаң, җенләнәсең.

Г ө л н а р а. Кайчан җенләнгәнем бар? Ә ул кызык та түгел, ниндидер пешмәгән.

Л и л и я. Йөзем җимеше пешмәгән, өлгермәгән дип әйткән ди төлке.

Г ө л н а р а. Син нәрсә, минем белән талашырга җыенасыңмы? Көнләшәсең.

Л и л и я. Нидән?

Г ө л н а р а. Сиңа егетләр карамый — шуннан.

Л и л и я. Насыйбы чыгар әле ди минем эби. *(Коридорга чыккан Рәшитне күреп.)* Әнә.

Г ө л н а р а. Карама ул якка.

Л и л и я. Бик тиз бирештең.

Г ө л н а р а. Күрербез әле анысын. Миңа мәхәббәтен аңлата башлагач, аңа әйтәсе сүзләрем әзер.

Шоколадлар, морожныйлар күтәреп, И л г и з ә р белән Р а ф и н а д керәләр.

И л г и з ә р. Кызлар, сыйланыгыз.

Л и л и я. Рәхмәт, кирәкми.

И л г и з ә р. Лилия, мин ачулана да беләм. Нәрсә кыланасыз? Мин бит чын күңелдән. Курыкмагыз, әҗәткә түгел. *(Шоколадлар, морожныйлар өләшә. Рәшитне күреп алып.)* А-а-а, Рәшит хәзрәтләре. Төш әйдә.

Г ө л н а р а. Курка ул, эбисен урлап китәрләр дип курка. *(Көлә, аңа Рафинад кушыла.)*

Р ә ш и т. Озак торабызмы?

И л г и з ә р. Төш, егерме минут.

Рәшит перронга чыга, Гөлнара Лилияне култыклап тәкәббер генә китеп бара.

И л г и з ә р. Йөрәген алгансың кызның. Сине күргәч кача. *(Морожный биреп.)* Мә.

Р а ф и н а д. Ә эбигә?

И л г и з ә р. Нәрсә — эбигә?

Р а ф и н а д. Морожный.

И л г и з ә р. Кара син аны, үзе сыйланган җитмәгән... *(Кесәсеннән акча алып биреп.)* Бар ал, бир эбиеңә. *(Рафинад киткәч, кызларга күрсәтеп.)* Кара син йөрүләрен!.. Эх!.. Фигураларын кара, фигураларын!.. Ә мин Лилия белән сөйләштем.

Р ә ш и т. Эшең уңдымы соң?

И л г и з ә р. Уңдымы дип, уңар әле. Акыллы кыз. Гөлнара кебек җилбәзәк түгел.

Р ә ш и т. Сиңа бит җилбәзәкләр кирәк.

И л г и з ә р. Алай димә. Минем йөрәкнең дә чиста бер клапаны бардыр әле. Кара син аларны, ә? Лилия, чыннан да, чибәррәк. Культура институтында укыйлар. Ташкентка кунакка барганнар. Эх,

мин дә бит студент идем, Рәшит. Ике курсны бетергәч, университетны ташлап киттем, ошамады. Минә хәзер авылда җир сөрәм. Укыйсы килмәде, кызыгын тапмадым. Укуы бик авыр, стипендиясе аз.

Рәшит. Җир сөрү җиңелме?

Илгизәр. Түгел дә... Аннан соң авылда... Фәһимә...

Рәшит. Кем соң ул?

Илгизәр. Әйттем ич. Теге... мине көтмичә кияүгә чыккан сабакы. Шу-лай... Сизәсеңме, Гөлнара сине күзәтә. Үлеп гашыйк булган ул сиңа. Тилмертмә баланы. Мәхәббәт аңлатмасаң да сөйләш.

Рәшит. Ни турында?

Рафинад морожный тотып вагонга үтә.

Беләсеңме, мин Роза белән поездда танышкан идем.

Илгизәр. Билгеле. Кайда танышасың. Кеше бит хәзер юлда. Бер минут тик тормый, айкала.

Рәшит. Каршы алыр микән Роза?

Илгизәр. Анысын син беләсең инде. Беләме соң кайтасыңны?

Рәшит. Телеграмма суктым.

Илгизәр. Алай булгач ала да ала инде.

Рәшит. Алыр микән?..

Илгизәр *(кесәсеннән акча чыгарып)*. Хәзер беләбез. Күн ягы төшсә, каршы ала. *(Акча чөя, карыйлар.)* Бетте, үтүт Розаң.

Рәшит. Тагын чөй.

Илгизәр *(чөя)*. Ала килеп чыкты.

Рәшит. Әйтәм бит.

Илгизәр. Юан, өйдә, юан... Эх, карале, кара... Үтерәләр болар мине. Әйдәле, өйдә. Дүртәүләп подручком йөреп килик. *(Рәшитне сөйрәп диярлек алып чыгып китә.)*

Рафинад Фәрхияне җитәкләп купедан чыга.

Рафинад. Әйдә, әби, кызык күрсәтәм, әйдә.

Фәрхия. Кая алып барасың, рәхмәт төшкере бала, ниткән кызык?

Рафинад *(перронга күрсәтеп)*. Күрәсеңме Илгизәр абый белән Рәшит абыйны?

Фәрхия. Я, күрәм...

Рафинад. Кызларны күрәсеңме?

Фәрхия. Аларны да күрәм.

Рафинад. Әнә теге чалбар кигән кыз Рәшит абыйга гашыйк, ә Рәшит абыйның сөйгән кызы бар. Илгизәр абый башта Гөлнараны сайлаган иде, хәзер Лилиягә күчте. Әйдә, әби, артларыннан йөрибез.

Фәрхия. Әй, хәерсез бала, ни әйтә икән дип торам.

Рафинад. Әби, әйдә инде, кызык итәбез.

Фәрхия. Кызлар белән егетләр сөйләшкәндә комачау итмиләр.

Рафинад. Ә мин итәм. *(Чыгып йөгерә. Фәрхия дә вагоннан чыга.)*

Проводница. Нишләп йөрисез инде, поезд хәзер китә.

Фәрхия. Мин шушында гына торам, кызым. *(Паузадан соң.)* Бигрәкләр дә зур инде ил. Киләбез, киләбез — очы-кырые күренми. Нинди генә халыклар юк. Менә әле хәзер Чаллыда торабыз. Урамга чыксаң, шаклар катып торасың. Тип-тигез кыр булган диләр, хәзер исләрең-акылларың китәр. Үзең кайсы якныкы, кызым?

Проводница. Ташкенттан.

Фәрхия. Татар баласымы?

Проводница. Юк, казакъ.

Ф ә р х и я. Әйтәм җирле... Көн дә, көн дә тәгәрмәч өстендә йөрү туйдыргандыр да инде. Яшең дә шактый күренә. Җәмәгатең бармы?

П р о в о д н и ц а. Иремме?

Ф ә р х и я. Ирне бездә җәмәгать диләр инде.

П р о в о д н и ц а. Бар.

Ф ә р х и я. Болай чыгып китеп йөргәнгә сүз әйтмиме?

П р о в о д н и ц а. Күнеккән инде.

Ф ә р х и я. Аерым торырга күнегергә ярамый, кызым, аерым торырга иялəшергә ярамый. Мәхәббәт аерым торуны яратмый.

П р о в о д н и ц а. Нинди мәхәббәт? Мәхәббәт ул яшь чакта гына кирәк... Кер әйдә, кузгалабыз.

Ф ә р х и я *(сөйләнә-сөйләнә коридорга керә).* Юк, мәхәббәт гел кирәк. Мәхәббәтсез дөнья — сусыз дәрья...

Поезд кузгалырга сигнал. Яшьләр йөгерешеп вагонга тулалар.

И л г и з ә р. Димәк, сөйләштек — бүген кич безгә кунакка рәхим итәсез.

Кызлар үтеп китә, Р ә ш и т белән Р а ф и н а д та кереп китәләр.

И л г и з ә р. Әйдә, кер, әби, урының суынадыр.

Ф ә р х и я. Бераз карап барам әле.

И л г и з ә р. Бүген кич безнең купега кызлар кунакка керсә, ачуланмассың, ярыймы, әби?

Ф ә р х и я. Адәм көлкесе, нишләп ачуланыйм? Аракылар эчеп утырмыйсыздыр бит?

И л г и з ә р. Анысын өзеп әйтеп булмый әле.

Ф ә р х и я. Эчмәгез, балам, ямьсезләнмәгез. Кичә күрдең.

И л г и з ә р. Курыкма, без андыйлар түгел.

Ф ә р х и я. Кызлар белән сөйләшкәнгә кем сүз әйтсен. *(Илгизәр купега кереп киткәч тә сөйләнеп кала.)* Кызлар белән дә сөйләшмәгәч, егет булып йөриләр димени.

Р а ф и н а д *(ишектән башын тыгып).* Әби, морожныең эри.

Ф ә р х и я. Үзең яла, олан, минем яшьтә ниткән маружный. *(Купесыннан чыгып тәрәзәдән карап баручы Кара мыек янына килә.)* Исәнме, улым? *(Кара мыек дәшмәгәч.)* Хәзер менә авырыйсыңдыр инде. Шулай ярыймы соң? Бердән, саулыгың бетә, икенчедән, хатының, балаларың бардыр.

К а р а м ы е к. Бар әле, ычкын моннан, синнән башка да...

Ф ә р х и я. И ходаем, карап торырга кеше үзең. Нигә эчәсең болай?

К а р а м ы е к. Кит диләр.

Ф ә р х и я. И ходаем, и ходаем... *(Купега кереп китә.)*

Илгизәр чыгып, кызлар купесы ягына юнәлә.

К а р а м ы е к. Туктале...

И л г и з ә р. Я, туктадым...

К а р а м ы е к. Син суктыңмы миңа кичә?

И л г и з ә р. Сугарга кирәк иде дә кызгандым.

К а р а м ы е к. Ияк авырта.

И л г и з ә р. Баш авырта диген.

К а р а м ы е к. Баш та чатный. *(Илгизәр китә башлагач.)* Туктале, ашыкма.

И л г и з ә р. Я, нәрсә?

К а р а м ы е к. Син мине ачуланма, яме.

И л г и з ә р. Без кичә килештек инде.

К а р а м ы е к. Ул сүзне мин сезгә әйтмәдем, хатын-кызларны җенем сөйми... Тәмәкең бармы?

Илгизәр. Тартмыйм.

Кара мыек. Чибәр, таза егет идем мин. Минем аркада күп кызлар җылады. Ахырдан үзем дә килеп каптым.

Илгизәр. Сөйләдең.

Кара мыек. Әнинең каргышы төште. Чыгып киткәч хат та язмадым. Хәзер аңладым, аның каргышы төште. Аңладым.

Илгизәр. Аңлап бетермәгәнсең әле.

Кара мыек. Синдә бирәр нәрсә юкмы? Баш чатный.

Илгизәр. Эчмим.

Кара мыек. Бар әле, солдаттан сорап кара, юк микән.

Илгизәр. Ул да эчми.

Кара мыек. Ресторан ачылмады микән?

Илгизәр *(китә башлап).* Каян белим, бар да кара.

Кара мыек. Ашыкма инде. Бир мең бер сум.

Илгизәр. Куеп торганың бар мәллә?

Кара мыек. Кызганма, бир.

Илгизәр. Кит әле. *(Узып китә.)*

Кара мыек. *(Илгизәрләр купесы янына бара).* Солдат, чык әле.

Рәшит *(чыгып).* Нәрсә кирәк?

Кара мыек. Бир мең бер сум. Кызганма, бир.

Рәшит. Акчасыз кая барасыз соң сез?

Кара мыек. Сораштырма, бир.

Илгизәр *(килеп җитеп).* Солдатка акча каян килсен. *(Кесәсеннән акча чыгарып бирә).* Мә, кара аны, кичәге кебек дуларлык булсаң...

Кара мыек. Юк. *(Акчаны карап).* Мең бер генә сум кирәк.

Илгизәр. Калганын кайтарып бирерсең.

Кара мыек. Рәхмәт, кайтарам... *(Ашыгып китеп бара.)*

Илгизәр *(купеларыннан чыккан кызларны күреп).* А-а-а, кызлар. Рәхим итегез. *(Җырлап каршыларына бара.)*

Дайте ходу пароходу —
Первый номер киләдер;
Я люблю вашу породу —
Сөйкемле күренәдер.

## II ПӘРДӘ

Поезд чаба да чаба. Чапмый нишләсен — аның эше шул. Ул чабарга тиеш. Кемнәрнеңдер тизрәк кайтып җитәсе бар, кемнәргәдер тизрәк китәргә кирәк. Әмма кемнәр өчендер поездның ашыкмавы яхшырак. Автор үзе дә ашыкмаучылар исемлегендә. Кызыклы гына нәрсәләр килеп чыгарга тора шикелле. Бүтәннәргә кызык итеп тә, гыйбрәт итеп тә сөйләрлек вакыйга оешып бара. Кызганыч, бик кызганыч — автор ул вакыйгага үзе катнаша алмый. Бераз гына олыгайган. Югыйсә, Илгизәр урынында булырга каршы килмәс иде ул. Кызлар янында бөтерелер иде. Әллә Рәшит кебек булыр иде микән? Юк, андый була алмас иде, түземлеге җитмәс иде. Бәлки түземлеге дә җитәр иде дә, аның өчен бит сине сагынып, бик сагынып көтеп торган сөйгән яр кирәк. Өстәвенә, син дә аны өзелеп-өзелеп яратырга тиеш. Булды микән шундый сөйгән яр, өзелеп-өзелеп яратты микән аны автор? Фу, хәерсез, олыгайган кешенең башына әллә нинди уйлар килә. Нигә инде вакыйгага катнашы булмаган хисләргә бирелергә? Ни булса булган—яшьлек үткән. Кем белә, бәлки Рәшитне дә Роза дигән кыз сагынып, бик сагынып көтми тор-

гандыр. Анысы күренер. Әлегә яшьләр Илгизәрләр купесында. Чәй эчәләр. Рафинад та шунда, ул, гадәттәгечә, өске урынга менеп оялаган да яшьләрне күзәтә. Өйрәнә малай актыгы. Фәрхия карчык яшьләргә комачауламас өчен купедан чыгып киткән, Гөлнаралар купесында үзенә тиң дуслар тапкан. Ике марҗа әбисе белән теттереп русча сөйләшә. Искиткеч карчык бу Фәрхия әби... Ярый, ул сөйләшә торсын, авторга Илгизәрләр купесыннан ерак китәргә ярамый.

Илгизәр. Гафу итәсез инде, кызлар. Чәй генә. Бүтәнен әбиебез рөхсәт итми.

Гөлнара. Бездә ике карчык, бөтен җирдә карчыклар, нишләп йөриләр алар?

Рәшит. Нишләп йөргәннәрен үзегез картайгач белерсез.

Гөлнара. Авыз ачып бер сүз әйттегез, анысы да грубо.

Рәшит *(төзәтеп).* Дорфа.

Гөлнара. Ярый, дорфа булсын. Мин авылда үсмәгән.

Илгизәр *(көлеп яткан Рафинадка).* Әй, стажер, нәрсә анда кыткылдап ятасың? Бар, әбиең янына чык.

Рафинад. Ул болар купесында үзенә дуслар тапты. Урысча сыптыра гына әби.

Илгизәр. Бер күрүдә гашыйк булып булмый дисез. Рафинад әнә күрүе булды әбине, гашыйк та булды. Морожный ташый.

Рафинад. Син үзең...

Илгизәр. Я, кызлар, нишлибез?

Лилия. Чәй эчәбез ич.

Илгизәр. Анысы дөрес. Тик...

Рафинад. Мәхәббәт турында сөйләшегез.

Илгизәр *(Рафинадка).* Кемгә әйтәләр. Куып чыгарам.

Рафинад. Чыгара алмыйсың, билетым бар.

Гөлнара. Сезнең стажер икәнлеге күренеп тора. Рәшитнеке булса, әллә кайчан ятып йоклар иде.

Илгизәр. Яле, Рәшит, матур гына җавап кайтар әле Гөлнарага.

Гөлнара. Матур сүз белми ул.

Лилия *(Илгизәргә).* Җырлагыз.

Илгизәр. Минме? Ничек әле кинәттән генә?..

Лилия. Җырлагыз инде. Тавышыгыз матур бит сезнең.

Илгизәр. Әллә? Куш кыңгырау тавышы кебекме? Рәхмәтләр яусын, Лилия. Мактагач, әллә ничек булып китте. Начар дисәгез, үч итеп җырлап җибәрер идем... Әйдәгез, алайса, бергәләп...

Рукавица, рукавица,
Рукавица — бияли;
Бүре түгел, ашамамын,
Якынрак кил әле.

Нигә кушылмыйсыз?

Лилия. Матуррак җыр җырлагыз.

Илгизәр. Матур җырлар белмим шул мин, белгәннәре оныгылган.

Рафинад. Өй артына суган чәчкәнеңне җырла, Илгизәр абый.

Илгизәр *(кинәт җитдиләнә, җыр башлый).*

Ике аккош атып алдым,
Бауга тезелгәннәрен;
Бары үзем генә беләм
Бәгырем өзелгәннәрен.
Өстәлләрем имән такта,
Гөлләрем кыйбла якта;
Якты йолдызларга карыйм
Сезне сагынган чакта.

Икенче куплетка Лилия дә кушыла. Фәрхия карчык ишек янына килеп тыңлап тора.

Рафинад *(Фәрхияне күреп).* Полундра! Әби кайтты, таралыгыз.

Кызлар урыннарыннан торалар.

Фәрхия *(эчкә үтеп).* Утырыгыз, утыр. Җырлашыгыз. Җырыгызны ишетеп килдем. Безнең дә бар иде шундый чаклар. Әрәмәлеккә төшеп, җырлашып утыра идек.

Гөлнара. Сау булыгыз. Әйдә, Лилия. *(Чыгалар. Аларга Илгизәр иярә.)*

Фәрхия. Шулай шул, Рафинад балам, картларны яшьләр яратмый.

Коридорда кызлар купеларына таба атлыйлар.
Илгизәр аларга ялына.

Илгизәр. Кызлар, китмәгез инде, кызлар. Күңелсез бит.

Гөлнара. Сезнең күңелне ачарга без клоуннар түгел.

Илгизәр. Алай дип әйтмәгез инде, Гөлнара. Күңелле иде бит, Лилия... *(Лилиянең кулыннан тотып туктата. Гөлнара китә.)*

Лилия. Нишлисез, җибәрегез.

Илгизәр. Китмәгез инде, Лилия. Бераз гына торыйк инде.

Лилия. Җибәрегез.

Илгизәр *(Лилиянең кулын җибәрә, чын-чынлап үпкәләгән тавыш белән).* Мин бит начарлык эшләмим. *(Лилия китми, тәрәзәдән карап бара. Илгизәр ялынган тавыш белән сүзен дәвам итә.)* Нигә инде сез алай?.. Уйнап сөйләшә дигәч тә...

Лилия. Сезгә җитди булу килешми. Җырлаганда гына җитди булыгыз. Анысы сезгә килешә.

Илгизәр. Рәхмәт, Лилия. Җырлыйммы үзегезгә генә бер җыр?

Лилия. Кешеләр ял итә.

Илгизәр. Мин әкрен генә.

Сандугачым-гүзәлем,
Тибрәтмә тал үзәген;
Түзәргә калгач түзәрем,
Өзелсә дә үзәгем.

*(Паузадан соң.)* Карагыз, ничаклы утлар.

Лилия. Җырлагыз.

Илгизәр. Сез дә минем кебек җыр яратасыз икән.

Лилия. Җырны кем яратмый.

Илгизәр. Культура институтында кайсы факультетта укыйсыз?

Лилия. Сез факультетның ни икәнен беләсезмени?

Илгизәр. Нишләп белмәскә.

Лилия. Тракторчы дигән идегез.

Илгизәр. Тракторчы аңгыра булырга тиешмени?

Лилия. Алай димим. Шулай да...

Илгизәр. Ярый ла эш барып торса уңайга. *(Лилия көлгәч.)* Сез көлә дә беләсез икән.

Лилия. Рәшит, чыннан да, шулай аз сүзлеме?

Илгизәр. Әллә сез дә аңа гашыйкмы?

Лилия. Сез дә... Тагын кем гашыйк?

Илгизәр. Гөлнара.

Лилия. Шулай дип уйлыйсызмы?

Илгизәр. Уйламыйм — дөресе шулай. Сизелеп тора.

Лилия. Сизелеп тора... Бигрәк сизгер кеше инде үзегез.

Илгизәр. Сез Гөлнара белән дуслармы?
Лилия. Нигә?
Илгизәр. Минемчә, дуслар түгел. Икегез ике кеше.
Лилия. Сизелеп торамы?
Илгизәр. Күренеп тора.
Лилия. Мин нинди дә, Гөлнара нинди соң?
Илгизәр. Сез — сабыр, тыйнак. Гөлнара... Ничек дип әйтим.
Лилия. Икебез ике кеше булгач, Гөлнара сабырсыз, тыйнак түгел булып чыга инде.
Илгизәр. Алай ук дип әйтмим. Шулай да...
Лилия. Ярый ла эш барып торса уңайга... Сез җырлагыз. Юк, җырламагыз, көйләгез генә.

*Илгизәр көйли башлый. Купеда Фәрхия карчык сөйли, Рафинад авызын ачып тыңлый, Рәшит тәрәзәдән карап бара.*

Фәрхия. И-и, яшьлеккә ни җитә. Яшьлегем — җүләрлегем, яшьлегем — гүзәллегем дип белми җырламыйлар.
Рафинад. Син дә юләр идеңме, әби?
Фәрхия. Юләр дә идем, гүзәл дә идем шул. Әти-әнигә иркә кыз булып үстем. Авылдагы бер егет белән дә рәтләп сөйләшмәдем. Бик күтәрмә борыныңны, чиләк элеп куярлар дип бәет әйтәләр иде минем хакта егетләр. Габдуллаҗан бабаңны гына санга суга идем. Яратканмындыр инде. Аңарга да сер бирмәдем болай. Ул сызгыргач капка төбенә чыгам чыгуын, шуннан арысы юк — Габдуллаҗаннан көлеп, мыскыл итеп тик утырам. Габдуллаҗан тузынып кайтып китә, мин көлеп калам. Көлеп калам да өйгә кереп яткач үкенәм. Озак азапладым мәрхүмкәйне. Чыдый алмый авылдан чыгып китте. И үкенүләрем, и ямансулаганнарым. Бер елдан соң гына кайтты. Көттем. Кайтты да — туп-туры безгә. Сине алырга кайттым, ди. Мин тагын тилерәм бит, юләр. Сиңа дигән кызлар мич артында күмер ашый, дим. Бераз торды да бу авылда, исеңә төшәр, үкенерсең, дип тагын китеп барды. Әле дә күз алдымда, менеп бара, мескенкәем, Идел тавыннан, мин капка төбеннән карап торам...
Рафинад. Шуннан артыннан чаптыңмы?
Фәрхия. Чаптым шул. Тенеш урманы авызында куып җиттем. Муенына асылындым.
Рафинад. Үбештегезме?
Фәрхия. Әлләниләр беләсең, хәерсез бала. Кем хәтерләгән аларын, безнең заманда үбешү югые да сыман. Хәзер генә ул, тиливизыр кабызыр хәл юк, үбешергә тотыналар. Менә шул. Авылга борылып кайтып туйладык та, мине алып китте Габдуллаҗан эшләгән җиренә. Шунда төпләнеп калдык инде. Ул шунда мәңгелеккә калды инде.
Рафинад. Чибәр идеме бабай?
Фәрхия. Чибәрлеген кем тикшергән — җаның тарткач. *(Рәшиткә.)* Син, олан, нигә әле кызларыгыз янына чыкмыйсың? Утырма мине тыңлап, минем сүзнең бетәсе юк.
Рафинад. Ульяновскида сөйгән кызы бар аның, әби.
Фәрхия. Бер дә белмәгәнең юк, рәхмәт төшкересе. Кая кайтасың соң үзең, барасыңмы?
Рафинад. Казанга барам, кунакка.
Фәрхия. Үзеңне генә ышанып чыгарып җибәрәләрме?
Рафинад. Һәй. Мин бәләкәй чактан ук поездда йөрим инде.
Фәрхия. Замана балалары — уйлап та бирмиләр. *(Рәшиткә.)* Сөйгән кызыңны уйлап ямансулап утырасыңмы?
Рәшит. Сез дә ямансулаган ич, әби.

Ф ә р х и я *(Рәшитне аркасыннан сөеп).* Бәхетле баладыр сине көткән кеше.
Р а ф и н а д. Һәй, әллә кайчан кияүгә чыккан инде ул.
Ф ә р х и я. Авызыңнан җил алсын, хәерсез бала.

Коридорда Лилия белән Илгизәр тәрәзәдән карап баралар.

Л и л и я. Ниндидер шәһәргә җиттек.
И л г и з ә р. Әйдәгез, карап менәбез.
Л и л и я. Гөлнарага әйтик.
И л г и з ә р. Курыкмагыз инде — урламам. *(Лилияне култыклап ала.)*
Л и л и я. Җибәрегез.

Чыгып китәләр. Рәшит тә купедан чыгып тәрәзәдән карап тора. Гөлнара күренә.

Г ө л н а р а. Лилия! *(Рәшит янына килеп.)* Лилияне күрмәдегез-ме?
Р ә ш и т. Әнә йөриләр.
Г ө л н а р а. Ә сез нигә чыкмадыгыз?
Р ә ш и т. Өченче кеше артык.
Г ө л н а р а. Аны да беләсезмени әле сез?
Р ә ш и т. Беләм.
Г ө л н а р а. Тагын ниләр беләсез?
Р ә ш и т. Бүтән берни дә белмим.
Г ө л н а р а. Кызганыч. *(Паузадан соң.)* Кызлар белән сөйләшкәнегез бармы сезнең?
Р ә ш и т. Бар.
Г ө л н а р а. Кем инде ул бәхетле кеше?
Р ә ш и т. Сез.
Г ө л н а р а *(көлеп).* Шаярта да беләсез икән.
Р ә ш и т. Беләм.
Г ө л н а р а. Тагын ниләр беләсез?
Р ә ш и т *(Гөлнарага туры карап).* Гөлнара.
Г ө л н а р а. Тыңлыйм сезне.
Р ә ш и т. Сезгә миннән ни кирәк?
Г ө л н а р а. Нигә алай дор-фа?
Р ә ш и т. Юк, чынлап. Сезнең белән сөйләшәсем килмәгәнне күреп торасыз...
Г ө л н а р а. Күреп торам.
Р ә ш и т. Соң, шулай булгач?.. Нигә соң?..
Г ө л н а р а. Дәвам итмәгез, кирәкми.
Р ә ш и т. Дөресен әйтәм, чибәр кыз сез, бик чибәр...
Г ө л н а р а. Кирәкми, дидем... Әйтегез әле, мин сезгә ошыйммы?
Р ә ш и т. Чибәр кыз, дидем.
Г ө л н а р а. Чибәрләр күп.
Р ә ш и т. Сез шуларның берсе.
Г ө л н а р а. Сезгә шул чибәрләрнең берсе белән кешеләрчә сөйләшү бик кызганычмыни?
Р ә ш и т. Юк, билгеле.
Г ө л н а р а. Шулай булгач...
Р ә ш и т. Сез бит кешеләрчә сөйләшергә җыенмыйсыз. Сез минем белән уйнарга җыенасыз.
Г ө л н а р а *(чын-чынлап аптырап).* Менә сиңа мә. Ничек уйнарга?
Р ә ш и т. Анысын үзегез беләсездер.
Г ө л н а р а. Әйе... Кызык... Сезгә ул турыда кем әйтте?
Р ә ш и т. Беркем әйтмәде.
Г ө л н а р а. Мин сезне...

Рәшит. Юнмаган бер агач пүләне дип уйлаган идегезме?
Гөлнара. Алай ук дип уйламаган идем дә... Кызык...
Рәшит. Кызык шул, Гөлнара абыстай.
Гөлнара. Миннән көләсезме? Гаепләргә уйлыйсызмы?
Рәшит. Нигә гаепләргә? Поездда вакытны үткәрергә кирәк ич. Сезнең урында мин дә шулай эшләр идем.
Гөлнара. Нигә шулай эшләмисез?
Рәшит. Сәбәпләре бар.
Гөлнара. Мин нигә шулай эшлим?
Рәшит. Сәбәпләре бардыр.
Гөлнара. Сезгә ничә яшь?
Рәшит. Солдатка ничә яшь була?
Гөлнара. Алайса, сез вакытыннан элек картайгансыз.
Рәшит. Миңа ул сүзне еш әйтәләр.
Гөлнара. Кызлармы?
Рәшит. Кызлар да.
Гөлнара. Илгизәр белән Лилия кешеләрчә сөйләшеп йөриләр.
Рәшит. Йөриләр.
Гөлнара. Ә сез минем белән ке-ше-ләр-чә сөйләшергә ризамы?
Рәшит. Баш өсте.
Гөлнара. Ничек була соң ул кешеләрчә сөйләшү?
Рәшит. Аптыратыйммы-тинтерәтимме дигән уен бар безнең якта.
Гөлнара. Рәхмәт сезгә. Сезне сөйләштерергә генә иде уем. Туйганчы сөйләштек, ичмасам. Тагын аз гына сөйләшик инде. Я, тагын берәр сүз әйтегез.
Рәшит. Бүгенгә җитәр.
Гөлнара. Иртәгә кайтып җитәбез. Сез дә Казангамы?
Рәшит. Аннан да ары.
Гөлнара. Әйдәгез, йөреп керәбез.
Рәшит. Хәзер кузгалабыздыр.
Гөлнара. Әйдәгез инде, мин сездән үтенеп сорыйм. *(Рәшит ризалаша. Чыгып китәләр. Гөлнара әллә юри, әллә чынлап көлә.)*
Проводница *(ул перронда тора)*. Ерак китмәгез.
Гөлнара. Юк, апа, шушында гына йөрибез. *(Китәләр.)*

Кара мыек чыга.

Кара мыек. Кайсы станция.
Проводница. Сиңа барыбер түгелмени?

Пауза.

Кара мыек. Сызраньга кайчан җитәбез?
Проводница. Сиңа нәрсәгә Сызрань? Эч тә йокла, Казанда уятырмын.
Кара мыек. Ачуланмагыз инде.
Проводница. Ачуланмагыз дигән була тагын, культурный.

Пауза.

Кара мыек *(егетләргә, кызларга карап)*. Йөриләр.
Проводница. Йөриләр шул. Синең дә шундый малаең, кызың бардыр.
Кара мыек. Ба-ар... Да-а...
Проводница. Фу... Торма янымда.
Кара мыек *(читкәрәк китеп)*. Да-а... Җирәнәләр. Сырага аракы кушып эчә идем, сарымсак белән закусить итә идем, тәмәке тарта идем, фу дип әйтмиләр иде. Синең кебекләр бишәү-алтау арттан чабып йөриләр иде. Болар — чепуха. Хәзер... Да-а... Во — тешләр юк.

**Проводница.** Башың исән булганга рәхмәт әйт.
**Кара мыек.** Ничава, яшәп карарбыз әле... Да-да, йөриләр.

*Егетләр, кызлар үтеп баралар.*

**Илгизәр** *(Кара мыекка).* Тагын баш авыртамы? *(Көлә.)*
**Кара мыек.** Мин сиңа сдачаны бирдем.
**Илгизәр.** Бирдең. *(Үтеп китәләр.)*
**Кара мыек.** Көлә. Мин синнән дә кәттә идем, салага.

*Поезд кузгалырга сигнал.*

**Проводница.** Утыр, китәбез. Әй, кызлар, егетләр!.. *(Егетләр, кызлар шаулашып утыралар. Тәрәзә каршына тезеләләр. Кызларга бәреләбәреләләп Кара мыек үтеп китә.)*

**Гөлнара** *(Кара мыекка).* Әй, син чамалап...
**Кара мыек** *(борылып).* Малчи, гад.
**Илгизәр.** Әле син тагын... *(Кара мыекка таба бармакчы була. Лилия аны тотып кала.)*
**Лилия.** Кирәкми.
**Рәшит.** Бигрәк яратмый ул сезне, кызлар.
**Гөлнара.** Яратмаса тагын. Шушылар картая да яшьләр, яшьләр дип яшьләрне сүккән булалар. Бандит.
**Лилия.** Кешеләр нигә рәхимсез булалар икән.
**Илгизәр.** Дурак диген.
**Лилия.** Юк, рәхимсез. Моның күзләрендә нур юк. Кайбер күзләргә карасаң, җан өши.
**Илгизәр.** Минем күзләр ничек, Лилия?
**Лилия.** Үзегезгә килешеп тора.
**Илгизәр.** Үзем ничек?
**Гөлнара.** Искиткеч, Илгизәр. Аполлон.
**Проводница** *(үтеп бара).* Ничек, күңелләме?
**Илгизәр.** Шәп, апа.
**Проводница.** Шулай булсын. Тик шаулашмагыз, пассажирлар йоклый.
**Илгизәр.** Апа, сез безгә ачуланмыйсызмы?
**Проводница.** Ни өчен?
**Илгизәр.** Мин Ташкентка барганда, проводница купедан да чыгармады. Юл буе кычкырып барды.
**Проводница.** Безнең эш шундый.
**Илгизәр.** Сез андый түгел бит.
**Проводница.** Сез тәртип бозмыйсыз. Көлешкәннән ни зыян. Сезнең яшьтә дә көлмәгәч... Көлеп калыгыз — еларга өлгерерсез. *(Үтеп китә.)*
**Лилия.** Ярый, тыныч йокы, егетләр. Гөлнара, әйдә.
**Илгизәр.** Ашыкмагыз инде, Лилия.
**Лилия.** Булды, җитте.
**Гөлнара.** Тыныч йокы, Рәшит.
**Рәшит.** Тыныч йокы.

*Кызлар китә.*

**Илгизәр.** Борчагыгыз пешә башлаган. Ә син кәҗәләнәсең...
**Рәшит.** Без болай гына...
**Илгизәр.** Я, я, беләбез. Розаң каршыларга төшсә, әләклим.

*Ут сүнә. Ут янганда поезд станциядә тора. Яп-якты көн. Лилия белән Гөлнара перронга чыгалар.*

**Гөлнара.** Тегеләр күренми...
**Лилия.** Озаклама Илгизәр, атылып чыгар.

Гөлнара. Син мине дә уздырып җибәрдең әле.
Лилия. Ә миңа ул ошый. Яхшы егет.
Гөлнара. Каян белеп өлгердең?
Лилия. Моңлы кеше начар була алмый. Күптәнге афоризм...
Гөлнара. Котлыйм. Мине дә котлый аласың. Аерылышканда елап калачак. Тик кызык түгел. Мокыт. Ярар бу юлга шундые да.
Лилия. Мокыт түгел ул, минемчә.
Гөлнара. Кем соң?
Лилия. Ниндидер уе бар кеше кебек.
Гөлнара. Уй? Аңамы уй? *(Ясалма көлә.)*

Кызлар янына чегән хатыны килә.

Чегән хатыны. Погадаю, погадаю. *(Гөлнарага.)* Ай красавица, черноглазая, давай я тебе погадаю. Все я тебе скажу. Что было, что будет, все, все скажу. Озолоти ручку, милая.
Лилия. Әйдә, китәбез моннан. *(Китәләр.)*
Чегән хатыны *(алардан калмый).* Очень ты счастливая, красавица. Счастье большое тебя ждет. Дай погадаю.
Гөлнара. Нигә миңа бәйләнде ул? *(Чегән хатынына.)* Я сама цыганка.
Чегән хатыны. Дай погадаю. Про любовь твою скажу. Покажи ручку, милая.
Гөлнара *(кулын сузып).* Ну-ка, скажи.
Лилия. Нишлисең син?
Гөлнара. Әйтеп карасын, кызык ич. *(Көлә.)*
Чегән хатыны. Озолоти ручку, красавица.
Гөлнара. Бир әле шуңа.
Чегән хатыны *(акчаны алып салып).* Счастливая ты, милая. И любовь у тебя счастливая. Любишь ты одного, думаешь ты, что он тебя не любит. Любовь твоя любит тебя. Ждет твоего возвращения. Озолоти ручку, красавица, еще скажу.

Коридорга Илгизәр чыга. Кызларны күрә.

Илгизәр *(купега кычкыра).* Рәшит, Рәшит! Әйдә, тиз бул. *(Үзе чыгып йөгерә.)*

Коридорга Рәшит, Рафинад, Фәрхия карчык чыгалар.
Рафинад перронга ук атылып чыга. Кызлар янына килә.

Нәрсә ди?
Чегән хатыны *(Илгизәргә күчеп).* Какое счастье тебя ждет, милый. Дай скажу.
Илгизәр. Давай. *(Чегән хатынына бер сум акча суза.)*
Чегән хатыны. Дома тебя ждет счастье. Было у тебя горе большое, любовь твоя счастливая.
Илгизәр *(кулын тартып алып).* Беләсең пычагым.
Рафинад. Илгизәр абый, мин дә, мин дә...
Илгизәр. Акчаң бармы соң?
Рафинад. Синдә бар ич.
Илгизәр. Тапты әндри казнасы. Әллә син... Мә... *(Рафинад чегән хатыны янына йөгерә.)*
Илгизәр. Рәшит, чык. Сына бәхетеңне.
Рәшит. Син сынадың ич.
Илгизәр. Мин көтмәячәкләрен беләм, сиңа кирәк. *(Чегән хатынына.)* Әй, цыганка, иди сюда. *(Чегән хатыны килгәч.)* Погадай ему. *(Рәшитне күрсәтә.)*
Чегән хатыны. Выйди сюда, выйди, красавец, все скажу.
Илгизәр. Деньги я даю, ты ему так скажи. Ждут его или нет.

Чегән хатыны. *(Илгизәрдән акча ала, Рәшиткә сөйли).* Ждет тебя красавица. Ждет не дождется. Любовь у тебя счастливая. *(Илгизәргә.)* Спасибо, милый. *(Ашыгып бүтән вагоннар янына китеп бара.)*

Фәрхия. Бер генә дә яман сүзе юк, рәхмәт төшкеренең. Кętәләр ди, бәхетле ди. Бөтен кешегә шулай ди.

Рәшит. Шулай димәсә, кем аңа акча бирә.

Илгизәр. Болар да халтурить итәргә өйрәнделәр.

Фәрхия *(Илгизәргә).* Акчаңны кызганмыйсың син, олан. Уңга-сулга сибәсең.

Илгизәр. Шуның өчен кыш буе, яз буе трактордан төшмәдем. Кайткач, тагын утырам. Рафинад, минем арттан. *(Рафинадны ияртеп чыгып китә.)*

Искереп, таушалып, кыршылып беткән чемодан тотып, Кара мыек чыга.

Проводница. Кая барасың?

Кара мыек. Билетны бир.

Проводница. Казанга хәтле бит билетыгыз.

Кара мыек. Булса соң, сатам.

Проводница. Эчәргәме?

Кара мыек. Анысы минем эш.

Проводница. Чемоданың үзеңнекеме?

Кара мыек *(чемоданын каерып ачып).* Мә тикшер, мә. Карак што ли мин сиңа? Бир билетны.

Фәрхия. И ходаем! Монысы беткән бәндә, бүтәннәрен үзең сакла.

Проводница. Утыр урыныңа. Монда калып нишлисең син, башың бераз эшлиме?

Кара мыек. Эчмим мин аны.

Проводница. Нигә каласың соң, алайса?

Кара мыек. Эшкә урнашам.

Проводница. Кем ала сине эшкә?

Кара мыек. Мине монда беләләр. Мин монда эшләдем. Ну, бир билетны тизрәк.

Проводница кереп китә.

Фәрхия. Яшьлегендә тайпылган, хәзер игә керә алмый инде, бичара. Заклад салган маллар кебек йөри ата баласы диген.

Мороженыйлар күтәреп, Илгизәр үтеп бара.

Кара мыек. Әй, син. Кил әле монда.

Илгизәр. Я, килдем...

Кара мыек. Карама миңа җирәнеп.

Илгизәр. Я, ни әйтәсең?

Кара мыек. Ачуланма мине, ярыймы.

Илгизәр. Авызыңны чамалабрак ачсаң ачуланмам.

Проводница. Ал билетыңны.

Кара мыек. Тукта. *(Илгизәргә.)* Кил әле монда. *(Читкә китеп баса.)* Кил инде. *(Илгизәр килгәч.)* Илгизәр бит әле син?

Илгизәр. Илгизәр.

Кара мыек. Ачуланма мине. Аракы эчсәм, дуракланам.

Илгизәр. Эчмә.

Кара мыек. Авылдан бит әле син?

Илгизәр. Я, әйтсәң әйт, мороженый эри. Акча кирәкме?

Кара мыек. Алып кайт мине авылыңа.

Илгизәр. Синеме?

Кара мыек. Курыкма, минем паспорт бар.

Илгизәр. Безнең авылда сиңа ни калган?

К а р а  м ы е к. Плотник мин. Алып кайт. Әни янына болай кайталмыйм мин, бераз акча эшләргә кирәк. *(Елап.)* Алып кайт. Әчмим, сука буду, әчмим.

И л г и з ә р. Сүгенмә.

К а р а  м ы е к. Юк, юк, бетте. Синнән куркам мин... Син мине калдырма монда.

И л г и з ә р. Әле калырга җыенган идеңмени?

К а р а  м ы е к. Нишлим... Алып кайт... Илгизәр, алып кайт... Энекәш, ну, алып кайт.

И л г и з ә р. Туктале. Уйларга ирек бир. *(Рафинадны чакырып.)* Рафинад, мә, морожныйларны апаңнарга бир. *(Рафинад морожныйларны алып киткәч.)* Күрсәт әле паспортыңны.

К а р а  м ы е к *(паспортын алып бирә).* Менә, мә, кара.

И л г и з ә р *(паспортны карап).* Кырык җиде яшь. Минем әти белән бер яшьтә. Пропискадан да төшмәгән.

К а р а  м ы е к. Җибәрермен, тиз төшерерләр

Поезд кузгалырга сигнал.

Алып кайт, энекәш. *(Илгизәр артыннан бара.)*

И л г и з ә р. Елама ачу китереп, утыр.

Утыралар. К а р а  м ы е к җирдә яткан чемоданын алып керә. Бирәүгә дә бирелмәскә тырышып, үз купесына үтә.

Ф ә р х и я. Акча сорыймы?

И л г и з ә р. Юк ла.

Р ә ш и т. Серләрегез килеште сезнең. Кызларың үпкәләделәр, кереп бикләнделәр.

И л г и з ә р. Кызлар кайгысы түгел әле монда, агай-эне.

Р а ф и н а д. Нигә елый ул, Илгизәр абый?

И л г и з ә р. Әйдәгез, чәй эчәбез. *(Рафинадка.)* Миңа морожный калдырдыңмы?

Р а ф и н а д. Синеке эри башлады да...

И л г и з ә р. Молодец... Әйдә.

Ф ә р х и я. Маладис димә. Азынмасын. Каян чыккан ул кеше өстенә салыну. Әтиеңнәр юлыңа биргәннәрдер. Таш тишегеннән чыккан диярсең. Әйдә, кер, хәерсез бала.

Ут сүнә. Ут янганда кич. Илгизәрләр купесында аншлаг. Рәшит журнал караштырып бара, Фәрхия карчык үз урынына аякларын бөкләп менеп утырган, Илгизәр өске урыннарның берсенә менеп яткан, Рафинад та үз урынына өскә кунаклаган, башын аска салындырган — Фәрхия карчыкны сөйләндереп кызык тапмакчы.

Р а ф и н а д. Әби, син сызгыра беләсеңме?

Ф ә р х и я. Кит, хәерсез бала... Ят тыныч кына, абыеңнар ял итә.

Р а ф и н а д. Илгизәр абый йокламый ул. Төн җиткәнне көтә, аннары Лилия янына чыгып китә. Әби, ә син җырлый беләсеңме?

Ф ә р х и я. Белмәскә ни. Без җырлап үстек. Сезнең сыман радио җырлаганга ышанып ятмадык.

Р а ф и н а д. Әби, җырлап күрсәт әле, ә.

Р ә ш и т. Азаплама әбине.

Ф ә р х и я. Азапласын. Азаплар өчен туган бала. Җырлый белмәскә ни тагы. Кешеләр каршына чыгып җырламасак та, җаен таба идек. Габдуллаҗан бабаң да җырга маһир кеше иде. Җырлап җибәрерие сузып. Бер җыры бикләр дә инде истә калган.

Безне кеше сөйләр инде
Хагын да, нахагын да.

Нигә тотып алмадылар
Кочагымда чагымда.

дип әйтер иде.

**Рафинад** *(сикерә-сикерә көлә).* Әби, син аны җырлап күрсәт.

**Фәрхия.** Әкрен, җимерелеп төшәсең, хәерсез бала. Юктан да кызык табасың, рәхмәт төшкерессе.

**Илгизәр** *(аска карап).* Әби, тагын кабатла әле шул җырны.

**Фәрхия** *(куанып).* Әллә ошаттыңмы, балам? Рәхмәтләр яусын үзеңә. *(Җырны бу юлы көйләп кабатлый.)* Күп җырлар белә идем дә, онытыла шул инде хәзер.

**Рафинад.** Әби, әби, ә бии беләсеңме?

**Фәрхия.** Биедем, малаемның да, кызымның да туенда биедем. Габдуллаҗан бабагыз белән кара-каршы төшеп биедек. *(Илгизәргә.)* Карасана, тәмам сыланды бит бу бала миңа. Кеше кешегә елыша шул. Теге адәмне дә әйтәм әле. Тотынып торырга урын эзли, бахыр. Атаңнар ачуланмас микән инде иртеп кайткан өчен?

**Илгизәр.** Кем белгән әле анысын.

**Фәрхия.** Булмас, игә китерә алмассың.

**Илгизәр.** Килмәсә, китәр дә барыр.

**Фәрхия.** Бара инде, бара. Йөри инде каңгырап. Кара син аны, йөрәге үлеп үк бетмәгән икән әле. Әни янына болай кайталмыйм диме? Хәерлегә булсын инде.

**Рафинад.** Әби, ә син русча сөйләшә беләсеңме?

**Илгизәр** *(Рафинадның маңгаена чиртеп).* Ярый, булды. *(Аска сикереп төшә.)*

**Фәрхия.** Әбисеннән көлеп яткан була инде. Күрше бүлмәдәге марҗалар белән сөйләшеп утырганыем, шуннан көлә.

**Илгизәр** *(Рәшиткә.)* Чыкмыйсыңмы?

**Рәшит.** Юк.

Илгизәр коридорга чыга. Тәрәзә каршына килеп баса. Янына Кара мыек килә.

**Кара мыек.** Җитмибезме әле, энекәш?

**Илгизәр.** Әллә Буаның кайда икәнен белмисеңме? Бар, йокла. Сагалама мине — калдырмам.

**Кара мыек.** Рәхмәт, энекәш. *(Китә.)*

Гөлнара үтеп бара.

**Илгизәр.** Гөлнара, Лилия чыгамы? *(Гөлнара эндәшми үтеп киткәч.)* Алай икән. *(Тәрәзәгә таба борыла, Фәрхия карчык җырын көйли.)*

Безне кеше сөйләр инде
Хагын да, нахагын да;
Нигә тотып алмадылар
Кочагымда чагымда.

Гөлнара кирегә үтеп бара.

**Илгизәр** *(аның юлына аркылы төшә).* Гөлнара, әллә миңа үпкәләдегезме?

**Гөлнара** *(дорфа).* Үткәрегез. *(Ләкин үтеп китәргә ашыкмый.)*

**Илгизәр.** Гөлнара, мин яңагыма сукканнарны гафу итәләм. Ләкин бер сәбәпсезгә минем белән турсаеп сөйләшкәннәрне җенем сөйми.

**Гөлнара.** Бик яхшы.

**Илгизәр.** Мин сезне үпкәләтерлек сүз әйтмәдем.

**Гөлнара.** Минем просто сөйләшәсем килми, китегез юлдан.

**Илгизәр.** Рәшит ачуын миннән аласызмы?

Гөлнара. Причем Рәшит. Төкердем мин сезнең солдатишкагызга.

Илгизәр. Төкererлек егет түгел ул солдат.

Гөлнара. Булмагае, китегез.

Илгизәр *(юл биреп).* Рәхим итегез. *(Гөлнара тәкәббер генә китеп бара. Илгизәр карашы белән аны озатып кала.)* Алай...

Нигә тотып алмадылар
Кочагымда чагында...

Лилия *(килә).* Хәерле кич, Илгизәр.

Илгизәр. Хәерле кич. Гөлнарага ни булган ул, минем белән сөйләшергә теләми.

Лилия. Белмим. Арыгандыр.

Илгизәр. Кызык бу кешеләр.

Лилия. Һәр кешенең үз холкы.

Илгизәр. Һәр кешенең үз холкы шул... Иртәгә Буа. Авыл. Трактор.

Лилия. Әллә нишләп моңсуланып калгансыз әле.

Илгизәр. Авылда чакта чыгып качасым килә, чыгып киткәч сагынам. Әтәчләр кычкырып көлерлек, тракторны сагынам. Төнлә бер ялгызым җир сөрергә яратам. Трактор үзе белән үзе сөйләшеп бара да бара, син уйлыйсың да уйлыйсың.

Лилия. Ялгызлыкны ярата торган кешегә охшамагансыз.

Илгизәр. Каян беләсез сез мине... Төнлә ай яктысында сөрелгән җир матур. Үзенә бер төсле кара. Көндез бер төсле кара, ай яктысында икенче төсле. Безнең як җирләре...

Лилия. Беләм. Мин үзем Апас районыннан.

Илгизәр. Апаслылар опасный... Каратунга төшәсезме?

Лилия. Юк. Элек Казанга.

Илгизәр. Апаска кайчан кайтасыз?

Лилия. Бер-ике көннән. Аннан сентябрьгә хәтле торам.

Илгизәр. Үзенәме Апасның?

Лилия. Юк. Барышка.

Илгизәр. Укып бетергәч, кая җибәрәләр?

Лилия. Үзебезнең авылга. Колхоз укыта мине.

Илгизәр. Мин хат язсам, җавап язарсызмы?

Лилия. Рәшит нигә кача ул Гөлнарадан?

Илгизәр. Качмый.

Лилия. Чыкмый ич купедан да.

Илгизәр. Шундый егет инде. Һәр кешенең үз холкы. Бик кәприз кыздыр бу Гөлнарагыз. Булачак иренә ходай сабырлык бирсен.

Лилия. Изге догагыздан ташламагыз инде, Илгизәр хәзрәт.

Илгизәр. Ташламабыз, аллаһы боерса... Сөйгән кызы бар аның Рәшитнең. Ульяновскида. Каршы алырмы, юкмы дип борчыла. Гыйшык-мыйшык уйнап, Гөлнараның кәефен табарга кәефе юк.

Лилия. Бик ярата инде, күрәсең.

Илгизәр. Күрәсең. Кызы ничек икән, анысын иртәгә күребез.

Лилия. Гөлнараның уйнаганын каян беләсез?

Илгизәр. Уенны сизеп була, Лилия, чынын сизеп булмый.

Лилия. Оста уйнасалар, сизеп булмый.

Илгизәр. Оста уйнасалар, булмыйдыр шул... Булмыйдыр. *(Кинәт шаян тонга күчеп.)* Минем Казандагы абыйның хатыны бар. Абый ялгыш кына бер сүз әйтсә, авырый башлый. Йөткерә, төчкерә, башым әйләнә дип идән уртасына егыла. Врач чакырталар, врач авыру табалмагач, зыяны тимәс әле дип бирәр укол кадый да китә. Абый җиңгинең уйнаганын сизми, пошаманга төшә, гафу үтенә. Һәм җиңги, ходайның хикмәте, шунда ук терелә.

Л и л и я. Бәлки ул чынлап авырудыр.

И л г и з ә р. Бәлки авырудыр да. Ләкин ул кинодагыча, театрдагыча авырый. Ә абый чын-чынлап чирли, тик ул кычкырып, шаулап чирләми. Абый инде бөкрәеп беткән, җиңги кызлар кебек. Абый үлгәч тә ике тап-таза ирне туздырачак әле ул.

Л и л и я. Алай сөйләшмәгез, ямьсез.

И л г и з ә р. Бетте, бетте. Кайчак ычкынып китәм, гафу итегез.

Л и л и я. Ә сез минем белән ни өчен сөйләшәсез, уйныйсызмы?

И л г и з ә р. Минме? Әгәр дә чын дөресен әйтсәм...

Л и л и я. Чын дөресен әйтегез.

И л г и з ә р. Чын дөресенме? Чын дөресен, беләсезме, кайчан әйтермен?

Л и л и я. Кайчан?

И л г и з ә р. Ә сез?

Л и л и я. Мин?

И л г и з ә р. Сез миннән ни өчен качмыйсыз?

Л и л и я. Сорауны башта мин бирдем.

И л г и з ә р. Эләктердегез сез мине. Тирән сөрәсез. Беләсезме, кайчан?

Л и л и я. Кайчан?

И л г и з ә р. Поезддан төшкәндә... Юк, анда да түгел. Әгәр дә мин сезгә кайткач хат язсам... Юк, алай да түгел... Әгәр ике-өч ай узганнан соң да хат язсам, чын дөресе шул була.

Л и л и я. Нигә ике-өч ай?

И л г и з ә р. Бусы — икенче сорау. Инде сез әйтегез.

Л и л и я. Минме? Әгәр дә сез ике-өч ай узганнан соң миңа хат язып, мин сезгә җавап яза алсам... *(Көлешәләр.)*

И л г и з ә р. Килештек, алайса *(Лилияне кочакламакчы була.)*

Л и л и я. Монысы иртәрәк.

И л г и з ә р. Кайчан?

Л и л и я. Әгәр дә сез миңа ун ел буе хат язып, мин ун ел буе җавап язып тора алсам...

И л г и з ә р. У-ун ел! Картаябыз ич.

Л и л и я. Блокнотыгыз бармы?

И л г и з ә р. Нигә?

Л и л и я. Эх, сез!.. Хат язарга җыенган кеше.

И л г и з ә р. Ахмак! Аңгыра мин. Шул турыда уйлап йөрдем бит.

Л и л и я. Акланмагыз. Бу юлга гафу итәм.

Илгизәр тиз генә купега кереп, бәләкәй генә куен дәфтәре белән ручка алып чыга.

И л г и з ә р. Кайсы хәрефне ачыйм, Лилия.

Л и л и я. Үзем табармын. *(Куен дәфтәрен алып яза да дәфтәрне Илгизәргә суза.)* Мәгез, югалтмагыз.

Ут сүнә. Ут янганда Илгизәрләр купесындагылар Рәшит тирәсендә мәш киләләр. Аны тарихи очрашуга әзерлиләр.

И л г и з ә р. Сине күрүгә үк егылып китәчәк Роза.

Ф ә р х и я. Гинирал инде, гинирал.

Р а ф и н а д. Эби генералны да белә!

Ф ә р х и я. Белмәскә. Дөнья күргән кеше ләбаса.

И л г и з ә р. Димәк, нишлибез?.. Портфелең әзер...

Ф ә р х и я. И ходаем, хәзер солдат та партфил белән йөри.

И л г и з ә р. Портфелең монда торып тора. Портфельсез генә чыгасың. Әгәр дә каршы алса, бер-ике көн тор дисә, стажер портфелеңне чыгарып бирә. Әгәр дә...

Р ә ш и т. Анысын әйтмә.

Илгизәр. Ашыкма, ни әйтәсемне белмисең. Әгәр дә каршы алып, мин дә синең белән Казанга хәтлеме, Арчага хәтлеме барам дисә...

Рәшит. Алай булмый.

Илгизәр. Алла диген — дөнья бу... Барам дисә, портфелең ул кергәндә өстәл өстендә торачак. Күрсен, белсен кем икәнлегеңне.

Рафинад *(көлә, башына Рәшитнең фуражкасын алып кия)*. Мин төшимме Рәшит абый булып?

Фәрхия. Кыланма. Китер картузын. *(Фуражканы алып, өстен алъяпкыч итәге белән сөртә.)* Габдуллаҗан бабагызның башында пилутка диган нәрсә иде.

Илгизәр. Тәк, значоклар тәртиптә, погон үз урынында, яка ак. Төймәләр бераз каралган.

Рәшит. Кичә генә чистарттым.

Илгизәр. Яхшы, бата алай булгач. Тәк... Тагын нәрсә... Ах, аңгыра сарыклар без, беләсеңме?

Фәрхия. Ни булды, ходаем?

Илгизәр. Чәчәк юк. Онытканбыз.

Рәшит. Анысы инде...

Илгизәр. Ярамый. Солдат һәр вакыт солдат булырга тиеш.

Рафинад. Чәчәкне каршы алучы алып килә.

Илгизәр. Өйрәтмә — борының юеш. Нишләргә?

Рафинад. Проводница купесында банкада чәчәк бар.

Илгизәр. Молодец. Синнән дә солдат чыгачак. Әҗәткә алып торабыз. *(Чыгып китә.)*

Фәрхия. Кай арада күреп өлгерә диген. *(Рәшиткә.)* Төймәләреңне чишеп тор, улым, тирләрсең.

Илгизәр *(чәчәк бәйләме тотып керә)*. Булды. Килеп җитәбез. Мәскәү вакыты белән өч сәгать егерме минут. Әзерләнегез. Рәшит баштан чыга, аннан әби, аннан Рафинад, мин — замыкающий. Киттек.

Коридорга чыгалар. Тезелешеп басалар. Читтәрәк Гөлнара белән Лилия. Төркем чыккач, Гөлнара кереп китә, Лилия дә аңа иярә.

Рафинад. Кызлар качты.

Илгизәр. Күпне күрмә. *(Рәшиткә.)* Йөрәк ничек, урынындамы? Каушама. Кызлар егетләрнең каушавын сизмәскә тиеш. Шулаймы, әби?

Фәрхия. Беренче күрешүләре түгел ди ич.

Илгизәр. Барыбер... Җитәбез. *(Рәшиткә.)* Карап бар, күренәме? Тик үзең тәрәзәгә капланма, сынатырга ярамый. *(Ләкин Рәшит аны тыңлар дәрәҗәдә түгел, тәрәзәдән перрондагы бөтен кешене барлап бара.)*

Рәшит. Күренми.

Илгизәр. Ашыкма. Тәк, килеп җиттек. Ашыкмыйча гына чыгабыз. *(Рафинадка.)* Син Рәшит абыеңа асылынма, без читтәрәк торырга тиеш. *(Рәшит атылып чыгып чаба.)*

Фәрхия. И ходаем, чәчәген дә онытты.

Перронга чыгалар.

Рәшитнең чабып йөреп Розаны эзләгәнен күзәтәләр.

Рафинад. Килмәгән. Менә ышан хатын-кызга.

Фәрхия. Кабаланма, хәерсез. *(Шәп кенә итеп Рафинадның арт ягына сылый.)*

Рафинад. Нишлисең, ә?

Фәрхия. Күптән кулым кычытып кайтып килә. Тик кенә тора белмисең.

**И л г и з ә р.** Күңелем сизгән иде.
**Ф ә р х и я.** Килер. Иртә бит, трамвайлар йөрмидер.
**И л г и з ә р.** Кичтән вокзалга килеп кунмагач, юк инде ул.

Рәшит килә, сөмсере коелган.

**Ф ә р х и я.** Поезд торадыр бит әле.
**И л г и з ә р.** *(Рәшиткә.)* Нык тор, агай-эне.
**Р ә ш и т.** Килергә тиеш иде.

Гөлнара белән Лилия коридорга чыкканнар.
Күзәтәләр. Гөлнара кычкырып көлә.

**Р а ф и н а д** *(кинәт кычкырып җибәрә).* Килә!.. Килә!..
**Ф ә р х и я.** Кайда, балам?
**Р а ф и н а д.** Әнә!.. Йөгерә!..

Рәшит, Розаны күреп алгач, аңа каршы йөгерде. Әйе, Розаның пассажирларга бәрелә-сугыла йөгергәнен, Рәшитнең аңа каршы чапканын күрде автор, әмма очрашкан мизгелләрен күрмәде. Шул мизгелдә автор үзе дә хискә бирелеп, күзләрен чытырдатып йомган иде. Аннан ул ни өчендер вагон тәрәзәсенә карады. Гөлнараны күрергә теләде булса кирәк. Әйе, Гөлнара белән Лилия вагон тәрәзәсеннән Рәшит белән Розаның очрашуын күзәтәләр иде. Гөлнара үзе көлгән була. Ләкин мондый көлү Гөлнараның элекке көлүе түгел шул инде. Авторның күзенә тәрәзәдән карап торучы Кара мыек та чалынды. Карашы моңсу-моңсу иде Кара мыекның. Бик күп кызлар күргәндер ул, ләкин мондый очрашу тәтемәгәндер мескенкәйгә. Кызганыч, ике гашыйкның очрашу мизгелен күрми калды автор. Ничек очраштылар икән? Кыз, йөгереп килеп, егетнең муенына сарылды микән, әллә икесе дә берьюлы кочаклаштылар микән, әллә инде бербérсенә якынайгач, икесе дә нишләргә белми туктап калдылар микән? Һәрхәлдә, автор алар ягына караганда, гашыйклар күренмиләр иде инде. Кыз белән егетне ашыгучы, кабаланучы пассажирлар каплаган иде.Ниләр сөйләштеләр икән безнең заманның Таһир һәм Зөһрәсе? Хәер, табылгандыр ла сүзләр. Фәрхия карчык әйтмешли, и ходаем, булды микән безнең дә шундый чаклар? Гафу итегез, автор тагын хискә бирелә башлады. Илгизәрләр перронда көтеп тора лабаса. Әнә Илгизәр нидер әйтте дә бугай.

**И л г и з ә р.** Безгә дә барырга вакыт җитте. Киттек!..

Илгизәр чәчәк бәйләмен тотып алдан бара, аңа Фәрхия карчык белән Рафинад ияргән. Сәхнәдән чыгып китәләр.

**Г ө л н а р а.** Бик инде. Табак бит, песи борын. *(Пауза. Рафинад йөгереп керә.)*

**Р а ф и н а д** *(куанычы эченә сыймый, кызларга кычкыра).* Кала! Рәшит абый монда кала! *(Купедан портфельне алып, тагын чыгып чаба.)*

**П р о в о д н и ц а** *(аны туктатып).* Билетын алырга онытмасын.

**Р а ф и н а д.** Әйтермен. *(Чыгып китә.)*

**Л и л и я** *(Гөлнараның мөлдерәп тулган күзләрен күреп).* Тилермә.

**Г ө л н а р а.** Кит!..

**Л и л и я.** Үзең башладың уенны. Шулай инде, иркә балага уенчык бирмәсәләр елый.

**Г ө л н а р а.** Каян беләсез?.. Нәрсә беләсез? Уен!.. Барысы да уен ди. Минем әллә чынлап гашыйк булырга хакым юкмы?!


П ә р д ә.

**Азат Вергазов**

# НӘЗЕР

ПОВЕСТЬ

*
* *



Үтәмеш кыясы үткен киртләчләре белән салынкы болытларны ерткан да күккә үрләгән. Кичке эңгердәге болытларның сәләмә ертыгында кызгылт кан саркыгандай. Тирә-юньдә йөрәкләрне чемердәтерлек тынлык. Бу өнсезлектә зиһен я бөтенләй туарыла, тынып кала, я, бәйгегә чыккан аргамактай, ярсып чабарга тотына. Тынгысыз уйлар бер бәйдән ычкындымы, тиз генә йөгәнлим димә: андый халәттә тауның салкын сыртына аркаңны терәп утыру да, башыңны ташка бәрү дә тынычлык китерми. Сабырлык иңми кешегә.

Җамалиның хәле бүген дә шулай. Берсен-берсе кысрыклап җәфалаган уйлардан башы чатный, күзе алдында саргылт түгәрәкләр бии. Киемнәренә капкан ялкынын йөгереп сүндерергә азапланган бәхетсездәй шул бәйләнчек уйларыннан арынырга исәбе. Тик яшькелт төстәге киндер кожаның төймәләрен ычкындырып, тау киртләчләренә таба кызулаган саен уйлары да кызулый, тәмам котыра. Аптырагач, ул өметсезлеккә бирелеп туктап кала:

— Җә, мин синнән кайчан котылырмын?

— Беркайчан да! — ди хатын-кыз тавышы.

— Кеше гомере мәңгелек түгел.

— Ә мин синең гомерең белән генә яшәмим.

Җамали ярсып күзләрен уа. Чөнки әлеге хатын-кызның кара-кучкыл йөзе аның күз алдында ук. Какча кыяфәтендә буйсынмас көлемсерәү.

Җамалиның йөрәге тимер читлеккә эләккән бичара коштай тарсылдарга тотына.

— Шул чаклы да мәрхәмәтсез булырсың икән...

Хатын коңгырт күзләрен кыса төшеп тавыш-тынсыз көлә:

— Булдыра алсаң куып җибәр. Мин бит сиңа үзем килмим. Теләгем дә юк.

— Элек тә каты бәгырьле идең син.

— Ә син боламык идең... Арыш боламыгы. Чак кына оешкан булсаң...

Җамали чәбәләнә:

— Хатын-кызга шул тикле кансыз булу килешми. Хатын җаны наз була.

— Ә мин наз күрсәтмәдеммени сиңа?.. Мин бит син тилене яраткан идем... Ишетәсеңме, яраткан идем!..

— Ә мин яратмадыммыни?.

— Сөю-ярату шулай буламы?

— Ничек була?.. Әйт, ничек була?!.

— Бичара... Әйт әле, сиңа ничә яшь хәзер?

— Ул чакны егерме биштә идем...

— Ә хәзер алтмышны узгансың. Миннән ике тапкыр өлкән. Тик шул тикле дә яшәп мине аңларлык кодрәт җыймагансың.

— Сине аңлап буламыни?

— Нишләп булмасын, мин дә кеше. Тик минемниләр күргәнем хакында уеңда бармы?

— Бар кебек. Тик аңлый алмыйм...

— Ә син яхшылап хәтерлә. Зиһенеңне җыеп.

Җамали кашларын җыера, йөзен чыта, аннары киреләнергә тотына:

— Кирәкми! Башым катты. Чатный, ух, чатный!

— Тыпырчынма, тиле. Гүргә кергәнче чуалган йомгакны җыярга кирәк!

— Җыеп ни мәгънә?

— Кеше җирдә кылганнарын чуалган килеш калдырырга тиеш түгел.

— Мин ул чаклы ни кылдым соң, ни?..

— Димәк, кылмаганнарыңны да...

— Булдыра алмыйм...

— Булышырмын. Утыр таш өстенә. Аяк өсте арырсың.

— Таш салкын... өшетә...

— Гүр аннан да салкынрак та... Утыр, утыр.

Җамали буйсына. Эчке киелеген җиңә торган ниндидер миһербансыз көч әйтерсең күзгә чалынмас тимердәй куллары белән аны зәмһәрир суыгы ингән ташка кадаклый. Ул шунда сеңә, кечерәя, күләгә төсле булып кала. Гәүдәсе буйлап әледән-әле йөгереп үткән вак дерелдәү дулкынын баса алмаудан гаҗизләнеп, ыңгыраша-шыңшый ялварырга тотына:

— Зинһар, берәр сәгатькә генә бер үземне калдырып тор, ә? Тәмам беттем бит инде, кешелектән чыктым...

— Минем белән булганда — син кеше. Чөнки мин синең уянган вөҗданың.

— Соңгы вакытта әрсезләндең, чат ябышып ятасың...

— Бу яхшыга. Кешелегең кайта.

— Син минем кешелегемме?

— Кешелегең дә, кешелексезлегең дә. Икесе бергә.

— Барыбер каты бәгырьле син.

Бер мизгелгә дә Җамалиның күз алдыннан китеп тормаган какча гәүдәле утыз яшь тирәләрендәге хатын аның каршына ук килеп, мүкләнеп беткән яшькелт ташка чүгәли. Күксел томан аша коңгырт күзләре белән аның күзләренә бага. Карашы чәнечкеле — бәгырьнең иң сизгер җиренә чаклы үтә. Сикереп торасы да, әллә кайларга йөгерәсе, шашып-томырылып тау киртләчләренә үрлисе килә. Ләкин үрләп нишлисең — барыбер шуышып түбән төшәсе...

— Я, бераз тынычландыңмы инде?

— Тынычланмый ни кыласың...

Хатын тагы көләргә тотына:

— Бигрәк тә йомшак шул син. Ярый, хәзер генә катыланмассың инде. Үләргә вакыт җиткәч кенә...

— Үләргә?.. — Җамали кубарылып урыныннан сикереп тора: — Җук, җук, үләргә җыенмадым мин... Җук, җук, син нәрсә?..
— Курыкма, тиле... Үлем — бары истәлеккә күчү.
— Ярый ла сиңа ансат.
— Шулай да әҗәлдән куркасың.
— Әҗәлдән түгел, яман истәлек кала... Ә чуалганны, чияләнгәнне сүтәрлек дәрман юк!
Хатынның түземлеге төкәнә. Ул капыл гына Җамалиның кожан изүеннән умырып ала да, ачу белән тотып селки:
— Җебемә, ир бул!
— Ах, бугазны шул тикле буасың, тын алыр әмәл юк... Бушат азрак...
Хатынның куллары теләр-теләмәс языла. Кожан изүе кошның каерылган канаты кебек...
— Рәхмәт... уф, тәмам тирләп чыктым...
Хатын янә Җамалиның каршындагы ташка елыша:
— Я, рәткә килдеңме бераз? Йомгакны җыя башларга вакыт...
— Һай, каты бәгырьле син!
— Ташла! Син менә минем Уразмәткә ничек килеп чыгуымны хәтерлә...
— Авыр хәтерләве. Бик тә авыр!.. Нинди вакыт иде бит... Егерме беренче ачлык елы...

# I

...Нәрсә соң бу? Җамалиның бөтен тәне чуен кабыкка салынган кебек. Чуен кабык каты, кытыршы. Селкенгән саен бүлтәеп торган чыгынтылары сөяккә тикле батып керә. Кымшанмаска иде дә... Кемдер аны юри бер яктан икенче якка авыштыра... Уф! Шул чаклы да инде... Чуен тырнаклар әллә ничә җиргә берьюлы батып, җелекләрне суыргандай итте. «Җибәрегез!» дип кычкырасы килде Җамалиның. Никтер тавышы чыкмады. Ә... Иреннәр дә чуен келәшчә белән кысып алынган икән... «Уф, уф!» Бу аның үз тавышымы соң?.. Җамали ыңгырашмаска тырышты. Тик әлеге кызганыч ыңгырашу авазы якында гына ишетелде. Тамак чатнап кипкән. Бер йотым гына су булсачы. «Бер йотым су!» Сукыр әнисе ишеткән, ахры. Суны тамчылап-тамчылап иренгә тамыза. Өйдә су юктыр шул. Сукыр килеш ничек су алып кайтсын соң?.. «Әни, әни, дим!» Дәшми. Ә үзе барыбер ишетте, ахры. Тамчыларны күбрәк тамыза ич. Ә тамчылар пешереп ала.
Кинәт нидер дөбердәп ауды. Ялгыш сөртенеп самаварны идәнгә төшереп җибәрдеме әни? Ялт итте, ут чыкты, ахры. «Әни, әни, нишләдең?»
Җамали көч-хәл белән күзләрен ачып, як-якка карады. Дөм-караңгы, берни күренми. Бары орып яңгыр ява. «Кайда соң мин?» Яткан урыны бигрәк каты... Тукта, арба ич бу... Ат арбасы?.. Яңгыр? Кайдан килгән яңгыр?..
Арба кинәт янтаеп чокырга төшеп алды. Тирә-юньгә су чәчрәде. «Уф... Эссе»...
Яңгыр да юк... Бу кадәр кызуда яңгыр кайдан килсен... Әнә саргая башлаган арышлар җил килеп орынган саен кыштыр-кыштыр килә. Бар дөнья, авызын ачып, өмет белән күккә баккан. Мәрхәмәт иңеп чиләк-чиләк яңгыр орса да, эх тә дими чөмердәтеп эчәр җир дымны. Җир генә түгел, кешеләр эчәр күк суын, убылып яуган яңгырга битен, кулын куяр, тузанда шыпырдап биешкән эре тамчыларга карап сөенеченнән шаркылдар.
Җамали кытыршы теле белән кипшенгән иренен ялый... «Тамчымы соң бу? Юк, юк. Бу саташу гына. Тукта, ни өчен арбада гамьсез

генә ятам соң мин? Атны ашыктырырга кирәк иң. Тизрәк барып житәргә... Мине көтә торганнардыр. Ләкин кымшанып та булмый. Ни булган соң миңа?» Җамали хәтерен киереп барысын да искә төшерергә тырыша. Әйе, атка почта йөге төяп юлга чыкты. Юлдашы да бар иде. Сакчы егет... Ул кайда?

— Әй!.. Әй, дим!..

Беркем берни дәшми. Нәрсә соң бу?

...Әллә юлга чыкмадымы икән алар?.. Өендә авырып ятамы Җамали? Юк, юк, атны үзе җигеп капкадан дөбердәтеп чыгып китте ләбаса. Аннары нәрсә?.. Юл... тез тиңентен тузан... Сары бия шул тузанны лапыр-лапыр ера бирә.

Тәгәрмәч астыннан куерып, бөтерелеп чыккан тузан бер җәелеп, бер сирәгәя төшеп, кире кайта, кызудан әлсерәгән үсентеләргә, юлчыларның кара-кучкыл йөзенә куна, борынга тулып тамакны әчеттерә, теш арасында чатыр-чытыр килә.

Урман янында — агачлар кыштырдавы, кигәвеннәр зеңгелдәве...

Кешеләрнең, атларның теңкәләренә тия кигәвеннәр. Атлар тибенә, колакларын шаңкайта, койрыклары белән әле уңга, әле сулган селтәнеп, үзен тинтерәткән кигәвеннәрдән котылмакчы... Ә кигәвеннәр әрсез... Аларның җан саклау өчен көрәше — яшәү белән үлем арасы... Ачтан кипшенеп үлгәнче сытылып һәлак булуың артыграк, күрәсең.

Караужа тавын менеп, Бикет ягына таба борылгач та юл түбәнәя. Юлчылар атларны юыртырга тырышалар.

— На, хайван!

Каеш чыбыркы ачулы еландай бөтерелә: «чаж-чож!» Атның тузанлы сыртында аркылы-торкылы сызыклар. Сызыклар ишәя, пәрәвез җәтмәсенә охшаш челтәр хасил була.

— На!..

Сары бия тузан болыты белән ярыша-ярыша алга ыргыла. Ә тузан өере калышмаска теләп әрсезләнә: соры канатын салындырып арба өстенә кунмакчы. Ләкин, җиңелеп, юлга чалкан төшә.

Биткә килеп бәрелгән салкынча урман җиленә изүләрен ачып кинәнә кешеләр.

Ат юыртудан туктауга тирә-юнь тагын өнсезләнеп кала. Чәч толымнарын як-якка үреп төшергән аксыл киемле каеннар... Тып-тын усаклар... Хәвефле матурлык... Һәр агач ышыгына куыш-куыш куркыныч яшеренгән төсле...

«Саташам, ахры... Ә шулай да, нәрсәдер булды бит, булды!..»

Кем әйтте әле шул куе чытырманлыкта куыш әмәлләп юлбасарлар яши дип? Сакчы егет бугай. Әйе, ул. Ә аннары юраганнары юш килде: юкәләр куелыгыннан күләгәләр төсле мыштым гына сузаеп биш кеше чыкты да, Җамалилар юлына аркылы төште..

Нишләргә? Алга баруны дәвам итәргәме, әллә атны борып алып, бар көчкә килгән якка куаларгамы? Ләкин соң инде. Озын буйлы, йөзен керпе энәләредәй сакал баскан адәм йөк янына якынлашты. Тәмәке сорады.

Җамали тәмәке янчыгын куенынан тартып чыгарган арада, калган дүртесенең күзләре комсызланып йөккә салган капчыкларны капшады. Ә анда хатлар, кыйммәтле әйберләр, акчалар...

— Кая барыш? — дип сорады озын буйлысы тәмәкесен теле белән ябыштырып.

— Бирегә генә, Бикеткә без, — диде Җамали. Аннары хәйләгә керешеп өстәп куйды: — Менә артка калган юлчыларны көтә-көтә бара идек.

Озын буйлы кеше ашыкмый гына тәмәкесен кабызды да, янаулы мәгънә биреп, каешланып беткән кара бәрхет кәләпүшен алга этеп куйды.

— Һе, яп-яшь башың белән алдап торасың тагы... Җәле, арбадан төш! Төш диләр сиңа!

Җамалиның аркасы буйлап җанын куыра торган суык йөгерде.

Ә сакчы егет капыл гына мылтыгын тегеләргә төзәп кычкырып җибәрде:

— Не смей, атам!

Тик ул атарга өлгермәде, аю хәтле дүрт ир дәррәү кубып сакчы егеткә ябырылды.

Түзеп калыр чакмы — бөтен тәнен оеткан әшәке салкынлыкны җиңеп, Җамали да тегеләргә ташланды. Ул әле берсенә, әле икенчесенә йодрыгы белән кизәнде, аяклары белән тибенде. Аның үзенә дә сукты-лар: чигә буйлап кискен авырту телеп үтте. Җен ачуын чыгарган бу авырту әллә ниткән йөгәнсез, кыргый ярсу уятып, әлеге хәрәкәтен тот-карлаган йөрәк өшүен кысып чыгарды, бөтен барлыгын биләп, тоеп булмас көчкә әйләнде. Җамали хәтта бар дөньясын онытты, күз алдында явызланып кыйшайган йөзләр, буталып әүмәкләшкән котсыз гәүдәләрдән гайре берни күрмәде. Шушы кызулыкта берсенең арт ягына чыгуын да сизми калды. Ә анысы, арттан килеп, Җамалиның якасыннан каерып алды да, колак төбенә шундый тондырды, ул, куакларга сыдырылып, черек агач өстенә үк барып төште.

«Кара, бу Чимай Мәләге генә түгел икән... Баш белән берне утыртып Мәләкнең борынын кара кан иткән идем дә бит...» Мокыт кына күренсә дә, сакчы егетнең үзендә дә көч бар мин сиңа әйтим, ничә албасты ябышса да, тәки мылтыкны тегеләргә бирмәгән. Ике кулы белән шуңа ябышкан да, башына сугуга да, тибүгә дә карамый, тартыла, тырмаша... Талкына-йолкына торгач, тегеләр кулыннан ыкчынып, мылтыгы-ние белән канауга мәтәлеп китмәсенме... Ә аңа шул гына кирәк тә: сикереп торды да «шарт» итеп тегеләрнең берсенә атып та җибәрде. Ядрә эләккәне эчен тотып җиргә ауган арада, Җамали да аптырап калган озын буйлыны сугып екты. Ә анысы, җиң эченнән ялтырап торган хәнҗәр чыгарып, яман сүгенә-сүгенә Җамалига ташланды.

«Бугазга гына кадый күрмәсен».

Җамали үзенә якын килгәнче үк аны аягы белән тибеп очырмакчы иде, ләкин тегенең хәнҗәре чабатасын үтә тишеп аяк табанына кадалды. Ул да булмады, уң чигәсенә нindидер каты әйбер белән китереп ордылар... Дөнья бер якка авышып китте, нарат кәүсәләре каядыр югары очты. Шул чак башында: «Әгәр үтерсәләр?» дигән шомлы уй җемелдәп үтте. Шул уеннан коты очып, бөтен барлыгын җыеп иңкүлеккә таба тәгәрәргә ашыкты. Шул рәвешле ул юлбасарлардан котылмакчы иде. Ләкин әлеге хәнҗәр белән кадаганы аны болай гына ычкындырырга теләмәде, күрәсең, артыннан килеп ярсый-ярсый итекләре белән типкәләде. Инде Җамалиның башында бары бер уй чәбәләнде: «Ничек булса да исән калырга... исән калырга... исән калырга...» Ул пиджәгенең якасын күтәреп башын сакларга тырышты. Ләкин кайсыдыр килеп башына дагалы итеге белән типте.

«Бер дә җәлләп тормыйлар инде». Томаланган аңы аша ул ату тавышларын да абайлады бугай... Ә аннан соң берни хәтерләми...

...Янәшәдә генә сакчы егет ыңгырашып куйды.

Җамалига аң кайта башлады:«Кыйнаганнар, кыйнаганнар да, икебезне дә арбага салып җибәргәннәр икән... — Ләкин кая барабыз соң без? Торырга иде... Ай, бар тән үтереп сызлый. Кузгалыр хәл юк. Җитмәсә, өс-баш манма су... Яңгыр яуган икән шул... Каты яуган...»

Ул яткан көе капшанып капчыкларын эзләде. Менә берсе, икенчесе... кискәләнеп беткән. Ертыкларыннан өчпочмаклы кәгазьләр тырпаеп тора... Хатлар... Арба төбе тулы... юешләнеп, изелеп беткән хатлар... Бүтән капчыклар кая? Җамалиның эче жу итеп китте. Акча һәм

әйберләр тутырган капчыклардан җилләр искән. Ул ярсып егетне йолкырга тотынды:

— Тор, тор, капчыклар җук!

Егет ыңгырашты гына.

«Тизрәк кайтып җитәргә кирәк!.. Бәлки талаучыларны куа чыгарлар!..»

Кинәт ат туктап калды. Кызганыч кешнәп тояклары белән җирне тырнады.

— На, на, бахбай!

Җамалиның тавышы бик зәгыйфь чыккангамы, бия тыңламады.

— На, диләр сиңа!

Ат кузгалмый да.

«Кай җир соң бу?»

Җамали ыңгырыша-ыңгыраша көч-хәл белән торып утырды. Янгыр туктаган. Бары яшен яктысы гына офыктагы төн пәрдәсен ертып бар дөньяны яктыртып ала.

«Кара, Кирәмәт тегермәне түгелме соң бу? Кайтып җиткәнбез икән ләбаса».

— На, на!

Бия янә кешнәп бер яктан бер якка тайпылса да, барыбер алга кузгалмады.

«Ни булган соң?... Әллә каршында бүре бармы?»

Җамали авырлык белән аягын арбадан салындырып җиргә басмакчы иде, ләкин булдыра алмады... Үзәк өзгеч авыртудан аңы томаланды аның...

Бераз хәл алгач, сызлануын җиңеп әкрен генә дымланган җиргә чүгәләде дә, үрмәләп-шуышып атның алгы ягына чыкты. Нинди йомры карамчык соң бу? Калфагы, күлмәге... хатын-кыз ич бу. Йөзтүбән яткан, үзе җып-җылы. Тере, ахры.

Җамали көч-хәл белән аны чалкан әйләндерде. Йомры күкрәге янына колагын куеп йөрәк тибешен тыңламакчы иде, кыз торып утырды

— Ә, нишләвең бу? Кем син?

Кызның капыл торып утыруыннан Җамали башта үзе дә сискәнеп китте. Беравык ни әйтергә белми аптырап торды. Аннары шактый тупас итеп:

— Котың чыкмасын сана!.. Ашамам, — дип куйды.

— Сиидиләрне беләбез... Кагылма миңа! Юлыңда бул!

— Син... син бу былчыракта нишләп ятасың соң?

— Анысы синең эшең түгел. Бар, бар!

Кыз яшь болан җитезлеге белән сикереп торды да, иниктер чайкала-чайкала, әрәмәлеккә тайпылды.

— Качма әле, кыргый тәре! Лүтче минә арбага утырырга булыш миңа.

Кыз туктап калды.

— Алдыйсың.

— Валлаһи газим алдамыйм... Менеп утырыр хәлем җук.

Кыз шикләнә-шикләнә Җамалига якынлашты. Шул чак арбадагы егет ыңгырашырга тотынды. Кыз тагы шып туктады.

— Котың чыкмасын дим ич инде... Безне эт итеп кыйнап ташладылар... Күлмәкләрне дә аерып бетергәннәр...

Кыз бераз тынычлана төште, ахры, курка-курка гына басып Җамали янына килеп чүгәләде. Егет болытлар арасыннан баккан саран ай яктысында таныш түгел кызның түгәрәк, матур йөзен төсмерләде. Аның кайнар сулышы егеткә көч өстәгәндәй булды.

— Авыртамы? — дип сорады кыз егетнең шешеп чыккан битләренә бармаклары белән кагылыр-кагылмас.

— Авыртмас сиңа...
— Явызлар...
— Әйдә булыш әле... Җәтерәк бул!
Җамали бар көчен җыеп җирдән күтәрелә башлады. Кыз аңа хәленнән килгәнчә булышты. Җамали анын йомшак иңнәренә таянган хәлдә, сыгылма гәүдәсенең дерелдәвен, артык көч куюдан калку күкрәгенең бер күтәрелеп, бер төшеп талпынуын тойды.
Ниһаять, Җамали арбага менеп утырды.
— Әйдә, утыр арбага, — диде ул кызга, — тизрәк кайтып житик әле, анда күз күрер. — Ул атка чөңгереп алды. — На, бахбай!
Сары бия шуны гына көткән кебек кызу алдырып китте. Авылга житүен сизептер инде, юырта ук башлады. Арба дыңгырдаудан Җамалиның бар җире сыкрый — түзәр чама юк... Житмәсә, авылга кергәндә юл түбәнгә китеп бия тагын да кызулый төште. Ниһаять, Җамалиның тәкате калмады:
— Тр-р-р, хайван, тр--тр-р-р! Үтерәсең!
Ат бөтенләй туктап калды. Җамали хәлсез тавышы белән кызга дәште:
— Ни... Кем дип әйтим соң сиңа?
— Сәгадәт диген.
— Сәгадәт, менә нәрсә, мин шушында гына торам... Ике йорт калдырып өченчесе безнеке... Хәлең ярыйсы булса, син Минайларга бар...
— Минайларга? Кем соң алар?
— Табарсың... Авылда иң бай кеше ул.
— Иң бай? Юк, бармыйм!
— Зинһар, тыңла сүземне... Үзем барыр идем, рәтем жук шул...
— Соң?
— Бар да әйт: почтаны талаганнар, диген. Мин капка төбендә көтәрмен.
— Ә теге кешең? Хәле мөшкелдер аның.
— Һай, тушыны!.. Бар инде җәтерәк!
Сәгадәт бүтән карышмады. Арбадан җиңел генә төште дә төн караңгылыгына кереп чумды.
Кыз киткәч, Җамали сакчы егетне капшап карады. Һаман аңына килми әле. Каты эләккән шул. Үзе болай сулый да кебек.
«Кеше тел тибрәтә алганда сөйләшеп кал икән...»
Ләкин Җамалиның күз алдында әле бер-ике генә сәгать элек булып үткән канлы вакыйга яңара башлагандай булды: юлбасарларның явызланып кыйшайган йөзләре, усал ялтыраган күз бәбәкләре... Җамалига чытырдатып ябышкан озын буйлының авыр итеп еш-еш сулавы... Кара, бу юлбасар да түгел икән ич. Ул бары Җамали белән бил алышырга чыккан көрәшче. Ә аяк астында ямь-яшел чирәмлек... теге Уразмәт инеше буендагы кебек... Тирә-юньдә кешеләр... Гөр киләләр... Сабан туе ла бу... Аның биленнән алышкан егетнең кулында пычак түгел, бары сөлге... Ләкин бик нык итеп кысып алган ул Җамалиның билен. Тик Җамалиның да бирешергә исәбе юк. Беләкләрендә көч ташып торган чакта... Менә ул әлеге егетнең биленнән чытырдатып кысып үзенә таба тартып китерде дә баш аркылы бер кырыйга томырды. Сабан туенда Җамалиның аста ятканы булмады бит. Юк! Анда көндәшенең кулында хәнҗәр түгел, сөлге... сөлге генә. Ә монда... Монда сөлге түгел. Шуңа пинжәгенең якасы белән башын яшереп ятты Җамали. «Үтерә генә күрмәсеннәр..» Ә сакчы егет?.. Җамали, өстенә пычрак су түгелгәндәй, калтыранып куйды. Их, әле көче бар иде ләбаса аның! Сикереп торып ялгыз калган сакчы егет янына атылып барыр чамасы бар иде!.. Ник шулай итмәде Җамали? Ник?! «Ничек тә исән каласы иде»... Ә Җамалины барыбер типкәләделәр... Үлгән кеше төсле селкенмичә ятса да типкәләделәр.

Әле генә Җамали, аңсыз көе ыңгырашып яткан сакчы егеткә карап: «Кеше тел тибрәтә алганда сөйләшеп кал икән», — дип уйлаган иде. Ә хәзер юлдашының ыңгырашуы берәр төрле сүзгә охшап куйганда бөтен тәне белән тетрәнеп: «Әгәр ул телгә килсә?» дип коты алынды. Ул бу коточкыч уйны башыннан куарга тырышты. Ләкин күз алдына тагы кыйшайган йөзләр, явызланып елтыраган хәнҗәрдәй карашлар пәйда булды... «Ә теге ниткән кыз булды соң әле ул? Коңгырт күзле, ябык кына... Бигрәк ябык инде. Көзге яфрактай очып китәр төсле. Үзе безнең як кызына охшамаган. Бездә анынча киенмиләр. Каян килгән диген... Өстенә ат баса язгач та кымшанып бакмый. Юеш җирдә ятуын белә. Нәрсә булды икән соң аңа? Авыргганмы әллә? Я бер-бер хәл булганмы?.. Хәлсез көе йомыш куштым тагы. Минай дөнья кубарыр инде. Барысын аякка бастырыр. Үзең куа чык дип бәйләнмәсә ярый ла...»



Минайга ни, теләсә нәрсә әйтсә дә килешә, авылда бер бай, тупырдашып торган дистәләгән аты, абзар тулы сыер-сарыгы... Өстәвенә, Кирәмәт тау башындагы җил тегермәне дә аныкы... Ә бит ничә ел гына элек Минай үзе дә гади почта йөртүче иде. Тәбәнәк кенә алмачуар алашадан гайре берничә сарыгы, икеме-өчме шунда мүкләк кәҗәсе бар иде аның. Ә бер елны, бүрткән арыш ашап, әлеге алмачуары да күбенеп җан бирде.

Шуннан соң Минай бер атна чамасы бөтен дөньясын утка ягардай булып бәреләсугыла йөрде дә, эшләп кем баеган, беткән баш беткән дип, Шәкүр караклар компаниясе белән аралаша башлады. Гөнаһысына кермик, ул үзе беркайчан да урларга бармады. Әмма тегеләр урлап кайткан атларны сатарга, эвеш-тәвеш китерергә үтә дә хирес булды. Минайның бу эшен Җамали гаепкә санамады. Ала-сата икән, нәрсәсе бар. Урламый ич. Акчасы булса Җамали үзе дә бер бик әйбәт ат юнәтеп җибәрер иде әле. Ә Минай өчен бу кәсепнең әҗере ярыйсы гына иде, ахры, алланың бирмеш бер көнендә ул менә диган атка тиенде. Башта бергә, аннары икегә, өчкә... Шуннан китте баеп Минай... Хәтта хезмәтчеләр дә тота башлады. Хәер, иген чәчкән-урган чакларны гына көнлекләп яллый иде аларны Минай. Шулай да анын тирәсендә гел кайнашып йөргән җирән мыеклы, җемелдәп торган яшькелт күзле Мәләк атлы берәү бар иде... Җамалиның яшьтәше... Тик үзен аңламассың — итәк астыннан ут йөртергә бик оста иде. Минайга шундый кеше кулай булган, күрәсең... Аннары Минайның Кирәмәт тау өстенә тегермән салдырып йөргән көннәре. Үзе әле дә почта йөртүче булып исәпләнсә дә, инде ул эшне башта әлеге бөдрә чәчле малаена, соңрак бүтәннәргә куша башлаган чагы...

Җамали шул бүтәннәрнең берсе була инде. Калага тикле әллә ничә почта тукталышы бар. Җамали мари ягыннан килгән почтаны кабул итеп ала да, йөкне сакларга куелган сакчыны ияртеп, Карауҗа аркылы Бикеткә китә. Ә Бикеттә Җамалилар китергән капчык-капчык хатларны, акчаларны һәм бүтән почта әйберен икенче берәүләр үз йөгенә күчереп Казан ягына юл тоталар...

Урмандагы коточкыч күренешләр яңадан Җамалиның күз алдында яңара башлады. Кинәт Җамалиның үз-үзенә ачуы чыкты: «Нәрсә соң мин җук белән саташам?.. Җанымны сакларга тырышканмын, имеш... Булса ни, минем урында һәркем шулай эшләр иде... Талаучылар белән әллә якалашмадыммы? Юкка шуның тикле кыйнаганнармы алар мине?.. Егетне дә кыйнаганнар, мине дә... Икебезгә дә тигез эләккән. Аның миннән сыеграк булуына әйтерсең мин гаепле...»

Җамали шулай үз-үзен тынычландырып азапланганда, төн пәрәнҗәсен икегә аерып, башта Сәгадәт, ә аннары Мәләк пәйда булды.

— Кайда Минай абзый?.. Нәрсә диде?..

Җамалиның калтыранган иреннәреннән бүселеп чыккан беренче соравы шушы иде.

— М-минай абзый килә алмады шул, тфү,тфү...

Мәләк гел шулай: үзе бик мөһим дип санаган хәбәр әйткәндә, гаҗәпләнгәндә, яисә ярсыган чагында еш-еш мышкылдап тора да, сүзен тытылдатып бетергәч, монысы да калмасын дигән шикелле төкеренеп куя.

Ә Җамалиның үз кайгысы кайгы: «Мөгаен, чаптар атлары белән талаучыларны куа чыгаргадыр нияте.

Тапмасалар ни нәрсә була инде миңа? Ни нәрсә?».

Мәләк Җамалиның йөзенә якын ук килеп карады да башын чайкап куйды:

— Тфү, тфү, бигрәк яман бизәгәннәр үзеңне, агайне.

Ул озак кына телен шартлатып торды. Аннары талаучыларның ата-бабаларын астын-өскә китереп сүгә башлады. Җамали Мәләкнең кем икәнен яхшы белгәнгә, аның сүзен чынга алмады, билгеле. Тик Мәләкнең тел төбендә нинди мәкер ятканын белә алмады ул. Хәер, бөтен тәне ут янып әрнегәндә шул идемени егетнең кайгысы?

Капка төбендә кешеләр сөйләшкән тавышны ишетеп булса кирәк, әнисе Хөббениса кабалана-кабалана өй баскычыннан төшә башлады. Карчык шактый вакыт капка келәсен таба алмый изаланды, аннары шыңгырдатып капканы ачты да куллары белән капшанып урамга чыкты.

— Улым, син кайттыңмы соң, бәбкәм?

Карчык улының авызыннан сызланып чыккан бу өнгә шикләнә биреп, акрын тавыш белән:

— Кайткансың икән шул... Ник дип өйгә кермисең соң? Бер-бер хәл булмагандыр бит? — дип сорап куйды.

«Ни дияргә? Барысын да сөйләп бирсәң әни карчык тәмам вәсвәсәгә төшәр... Сөйләмәсәң, барыбер беләчәк бит... Калтыранган куллары белән капка баганасын бертуктаусыз капшавы әле дә тикмәгә түгел... Әйтерсең үзенең шик-шөбһәләренә иң дөрес җавапны гомерендә ничаклы ачы хәбәрне үзе аркылы үткәргән пар капка баганасы әйтә ала?..» Тамырлары бүртеп-бүртеп чыккан сөякчел кулларга, кулларга гына түгел, карчыкның какчыл тәненә имән багана бәлки ныклык, чыдамлык өсти торгандыр!..

Япон сугышында ире үлеп калгач, бу кайгылы хәбәрне шушы капка баганасына сөялеп эченә йоткан иде Хөббениса. Шул чакта күкрәген авырттырып көйдергән хәсрәт утын шушы имән баганага кысып сүндергән иде... Пыскып калган соңгы шаукымы тол калган чибәр хатынның йөрәген тагы ничә айлар сыкратса сыкратты, әмма кешеләр алдында «уф!» дип аһ ормады ул. Хәер, шушы имән баганадай нык, тупылдап торган чагы иде аның. Шулай да җиңел булдымыни... Әле ныгып җитмәгән кызы Җәмилә белән улы Җамалидан әллә ни игелек көтеп булмый, тормыш арбасының төбенә Хөббенисаның үзенә җигеләргә туры килде. Ирләр урынына да калгач, барысын да эшлисең шул: чыгын ат җигеп сука сукалау дисеңме, бишәр потлы капчык күтәрү дисеңме — берсе дә калмый. Тик авыр күтәрү хатын-кыз заты өчен бер дә эзсез генә узмый икән. Башы бик каты сызлап күзе күрмәс булды Хөббенисаның. Әле ярый балалары исән-сау булды. Тик алар үсеп җитте дигәндә генә башта Җәмиләсе күрше авыл егетенә ябышып чыкты, инде малае — Җамали...

— И, ходаем, ни генә булды үзеңә, бәбкәм. Сулу алуларыңа тикле гыжлап тора ләбаса.

Шик-шөбһә катыш өмет белән ялварган ана җаны улының: «Җук, бернәстә булмады, әнием, бары бераз арылган гына», дип назлап-

юаткан җавабын көтте. Тик ул җавап урынына нәкъ аның каршында гына бер кыз баланың мөлаем авазы ишетелде.

— Ул-бу юк, анакаем... Яшь ит төзәлер...

Ана кеше мондый юатуның ни икәнен яхшы белә. Шуңа да ул:

— Балакаем, балакаем, — дип, калтыранган ике кулын улы ягына сузып, төнге бушлыкка таба атлады.

## 2

Сакчы егет тәки аңына килә алмыйча икенче көнне дөнья куйды. Аны Уразмәт зиратына алып барып җирләделәр. Җамалиның да хәле шәптән түгел иде. Өйгә кереп сәке өстенә хәзерләгән мамык түшәккә аву белән ул ялкыннары ыжгырып торган коточкыч упкынга убылгандай булды. Бу упкын әллә ниткән төпсез — төшәсең-төшәсең — чиге юк. Ялкыны кара-кучкыл күләгәләр төсле. Бу шомлы күләгәләр салкын боздай салынкы канатлары белән уттай янган тәнне ике яклап шундый каты кысалар, сулавы авыр була башлый, тын җитми. Бөтен гәүдә дерелди. Бу хәлдән ычкынмак булып талпынсаң, төпсезлеккә таба кызурак очасың. Шул чаклы кызу — йөрәк пәрә-пәрә килеп оеп китә. Аннары кара-сары түгәрәкләр бергә буталып, бар дөнья әйләнергә тотына.

Дөнья бизәкләрен гомерлек төн белән алыштырган карчык үзенең газиз баласын тәрбияли дә, дәвалый да алмасын белә. Шуңа ул Сәгадәткә ялвара:

— Кызым, зинһар безне шушы хәлдә ташлап китә күрмә инде... Җамалием бераз аякка басканчы гына булса да бездә торып торсаңчы... Алла үзеңне рәхмәтләреннән ташламас...

Сәгадәт күнде. Дөресен әйткәндә, кызның аяк атлап керер бүтән бусагасы да юк иде бит. Аннары, һәр хатын-кызга хас булганча, көчсезләргә, бәлага юлыкканнарга шәфкать күрсәтү теләге Сәгадәт өчен дә ят түгел иде ич...

Беренче көннәрне кыз авыру яныннан бөтенләй диярлек китмәде. Әледән-әле аңа куе чәй эчерде, ут кебек янган маңгаена юеш чүпрәк куеп торды.

Ә егетнең хәле һаман авырайды. Тәнендәге әллә ни чаклы яралары әрнеп сызлау өстенә, табанына талаучылар хәнҗәре кадалган аягы гөбедәй булып шешеп чыкты.

Сәгадәт кырыйлары кызарган яраларга каз мае сөртеп, Җамалиның шешенгән аягын үги ана яфраклары белән урап бәйләп куйды.

Боларның барысы Җамали өчен ерак төш кебек.

— Хәлең ничек соң, улым?.. Кара җимеш кабып бакмыйсыңмы? Салкын әйрән эчермикме?

Әнисенең тавышы.

Җамалиның иреннәре селкенә.

Озак та үтми, Җамали кысылган иреннәренә сак кына орынган агач җамыякны тоя.

Сәгадәт авыру егет янында тәүлекләр буе керфек какмый утырды. Хөббениса әби Сәгадәткә авыр икәнен сизә. Шуңа ул: «Бар, кызым, бераз ял итеп ал», — дип улы янына капшана-капшана үзе килә. Ләкин кыз мамык мендәргә башын төртергә өлгерми, Җамали сызланып ыңгырашырга тотына, я чатнаган иреннәрен ялап су сорый. Мондый чакта карчык егет сораган нәрсәне ялт кына табып бирә аламыни? Ул урыныннан кузгалганчы, Сәгадәт атылып торып, әх дигәнче авыру сораганнарны табып та китерә.

Өченче көн дигәндә Җамалиның хәле аеруча начарланды. Ул ешеш сулый, үзе авыз эченнән һаман нидер сөйләгәндәй итә. Сүзләре аңлаешсыз... Өзек-өзек...

Нидер эшләргә кирәк... Бәлки доктор чакыртыргадыр. Тик Уразмәттә доктор юк. Доктор өчен биш-алты чакрымлап барасы. Ә тышта төн. Җитмәсә, ничә тәүлек инде бер өзлексез яңгыр коя. Күкнең төбе төшкән диярсең. Сәгадәт бу якларны белсә икән әле... Бармый да ярамый. Күрәләтә пәһлевандай егетне харап иттермәссең бит.

Җамали саташты да саташты. Ул инде Сәгадәтнең кара төндә тез тиңентен пычрак ерып, абына-сөртенә доктор эзләп китүен дә, юлда адашып йөрүен дә, әнисенең аның өстенә иелеп үкси-үкси кан-яшь түгүен дә белмәде. Урта яшьләрдәге доктор ирнең аны тыңлап караганнан соң башын чайкап бер мәл нишләргә белми утыруы, аннары, дарулар каптырып, төрле киңәшләр бирүе кайдадыр еракта калган аңлаешсыз төш сымак кына...

Таң беленеп килә иде. Хуш исле мәтрүшкә салып кайнаткан чәйне авызына бал кашыгы белән берничә кат салганнан соң, егет тирән йокыга чумган. Төнге пычракта арып-алҗып, тәмам кешелектән чыгып беткән Сәгадәт тә стенага башын сөяп, ничектер черем итеп җибәргән. Кыштырдаган тавышка кыз кинәт уянып китсә, ни күрсен, егет күзләрен тутырып аңа карап тора. Сәгадәт егетнең бу сәер карашыннан әллә нишләп китте.

Ә егет көлемсерәгәндәй итте дә, акрын гына:

— Ник курыктың?.. Мин шулай кеше куркытырлыкмыни? — дип сорады.

— Юк, юк, — диярга ашыкты кыз. Ә үзе егетнең шардай ачылган күзләренә гаҗәпләнеп карады. Кара тутлы булгач, егетнең күзләре дә чем-кара, я коңгырттыр дип уйлаган иде ул... Күр, күзләре зәп-зәңгәр икән...

— Ай-һай, озак йоклаганмын! — дип, тәмле генә итеп киерелеп куйды Җамали. Ә син гел шулай стенага сөялеп утырдыңмы?

— Гел түгел... Кайчагында гына... Ә син йокла, йокла, сиңа йокларга кирәк, — диде кыз беркатлы итеп.

Егет кызның коңгырт күзләренә карап торды да, ни әйтергә белмичә:

— Абау, күзләрең, — дип уфтанып ук куйды.

— Зур, иеме?

Кызның бу сүзләреннән егет көлеп җибәрмәкче иде, ләкин шундук чыраен сытып ыңгырашырга тотынды.

Сәгадәт ашыга-ашыга кашык белән аңа су эчерде, ә үзе:

— Сиңа сөйләшергә ярамый, тыныч кына ятарга кирәк, — дип сөйләнде.

Җамали кызга каш астыннан гына карады.

— Әллә яралары сызлаганга гына ыңгыраша бу дип уйлыйсыңмы? Йөрәк авыртканга ыңгырашам мин белсәң!

Егет авыртудан, ахры, чыраен сыта төшеп күз кабакларын йомды.

Сәгадәт яңадан тынлык белән йөзгә-йөз калды. Бу өйдәге кешеләр өчен ул һаман әле томанлы билгесезлек. Кем ул? Кайдан килгән? Ни өчен килгән? Эчендә ниләр яна? Кем белсен. Күзләр күңелнең тәрәзәсе дибез дә... Укып кара син шул серле билгесезлекне бу тәрәзәләр аша. Әйе, анда моң, хәсрәт шәүләсе күрерсең... Бәлки күз яшьләре дә. Ә нидән ул, кем рәнҗеткән бу мөлаем кызны — кем әйтеп бирер? Беркем дә әйтмәс. Хәтта Сәгадәт үзе дә. Хәер, кыздан бу хакта кемнең сораганы бар соң әле? Бу өй эчендә бүтән борчу, бүтән кайгы...

Үзара сөйләшкән тавышка Хөббениса әби дә уянган иде. Ул, улы ягына борылып:

— Улым, син дәштеңме соң? — дип сорады.

— Мин, әни, мин...

Карчык кабалана-кабалана урыныннан торды:

— Хәлең ничек соң, улым?

— Ярыйсы, әни.

— Шулай гына була күрсен, балам. Тизрәк савыгырга язсын.

...Җамали, аңына килеп, хәле бераз җиңеләя төшкәч тә әлеге почта акчалары белән җенләнде.

— Их, саклый алмадым бит, алмадым... Нишләтәләр инде хәзер мине?

Хөббениса әби:

— Балам, кайгырма, сыерны сатып булса да түләрбез, башың гына исән булсын, — дип юатырга тырышса да, Җамали кулын гына селекте:

— Сыер, дисең син, әни, бөтен йорт-җирең дә җитмәячәк бит аны түләргә...

Җитмәсә, өйдәгеләрне тагы да шөбһәгә төшереп, нииндидер кырыс йөзле кеше ияртеп Минай килеп чыкты. Өстенә солдат шинеле, башына йолдызлы фуражка кигән утыз яшьләрендәге ят кунак ишектән күренүгә, Җамалиның бөтен тәне бизгәк тоткандагыдай калтыранып куйды.

Сәгадәт җил-җил килеп өй эшләрен эшләп йөри иде. Тегеләр Җамалидан хәл-әхвәл сорашкан арада, ул җәһәт кенә Хөббениса әби янына килеп, аның колагына нидер пышылдады. Карчыкның шунда ук чырае бозылды. Ул ашыга-кабалана сәкедән төште дә, Сәгадәт ярдәмендә, кече якка үтте. Борынын еш-еш тартуыннан, каны качкан иренен мимылдатуыннан менә-менә елап җибәрер төсле иде ул.

Минайны да алыштырып куйганнармыни. Башка вакытта керүенә гөлдерәп торган тавышы белән бөтен өйне тутырыр иде. Бүген авызына су капкан диярсең: тикшерүче сораганда да җавабы «әйе», «юк»тан узмый. Өстәвенә, кулларын кая куярга белмәгән кебек әле ак күлмәге өстеннән кигән казакиенең чабуларын тарткалый, әле сирәк җирән сакалын угалый. Бу хәл Җамалиның шөбһәсен тагын да арттырды: «Минай булып Минай шулай җебеп калгач...»

Менә әлеге кеше Җамали яткан сәке кырына килеп утырды. Фуражкасын бер кырыйга салып куйды да, хәрәкәтсез зәңгәр күзләрен Җамалиның агарынып калган йөзенә төбәп, тонык тавышы белән булып узган хәлләрне сораштыра башлады. Җамали тотлыкты, сүзләрен бутады... Ә тикшерүче, чыраен бераз сыта төшеп, аның һәр сүзен күңеленә сеңдерә бара иде. Кайвакыт ул аскы иренен тешләп нидер чамалап тора. Аннары урыныннан торып кулын артка куя да, идән такталарын шыгырдата-шыгырдата, салмак хәрәкәт белән арлы-бирле йөри башлый. Беркем бер сүз дәшми. Шушы тирән тынлыкта идән шыгырдавы, ят кешенең дулкынланып торган саргылт чәчләрендә коршау сыман фуражка эзе төшеп калган башын вакыт-вакыт күтәреп, нидер белгәндәй зәрлекле карашы белән өйдәгеләргә карап алуы хәвефле серлелекне тагы да арттыра. Җамалига инде күптән тикшерүче аның язмышын хәл итеп куйгандыр, бары капкынга ныграк эләктерү өчен генә тырышадыр кебек тоела башлый. Шуңа ул элеккедән дә битәр каушый, чәбәләнә... Мондый чакта тикшерүче, менә бит нинди мәгънәсез егет, дигәндәй, Минайга борылып карый. Җамали мич буенда утырган Минайның кызгылт чыраена, явызланып киткәндәй тоелган яшькелт күзләренә ялварып бага: эттән алып эткә салып тиргәсә тиргәсен, тик бар гаепне аңа өеп, батыра гына күрмәсен.

Минай аны эттән алып эткә салып та сукмәде.

— Егетләрне ачуланып ни кыласың. Алар куркып качып китмәгәннәр ләбаса, үз җаннарын җәлләмичә малны сакларга тырышканнар әнә, — дип егетләрне яклап маташты. Аннары сирәк мыегын сыпыргалап: — Нишлисең, миңа килгән каза икән, зыянның бер өлешен үзем капламмын инде, — дип өстәп куйды.

Алар киткәч, Хөббениса әби:

— Әнә бит, Минай бөтенләй үк миһербансыз түгел икән, үзем түлим, дип тора, алла боерса, — дип авыз ачкан иде, Җамали:

— Бер өлешен генә ди бит... Ә калганын бездән түләтәләр инде болай булгач, — дип карчыкның гайрәтен сүндерде. Тик шулай да өйдә элеккечә үк кара кайгы куермый иде инде.

Аның сөреме сыегайгандай булды. Хөббениса әби дә:

— Җан биргәнгә җүн бирер ходай теләсә, — дип, түр сәке өстендә сабыр гына чайкалып утыра бирде.

3

Җамали бәлага тарыган көннән бирле бер айлап вакыт узып китте. Аның битендәге, шулай ук тәнендәге яралары савыкты. Бары тик хәнҗәр кадалган аяк табаны гына һаман төзәлеп бетми әле. Шулай да егет инде аксаклап булса да йөри. Йорт-каралты тирәсендә дә нидер кайнаштыра.

Сәгадәт күбрәк өй эшләрен карый. Бу соңгы көннәрдә ул таңнан торып Җамалиларның арышын урырга ашыга иде. Ә аннары бодай урырга тотынасы. Җиргә кичке эңгер кунаклагач кына өчәү бергә табын янында җыйнала алар. Менә шунда инде Җамали белән Сәгадәтнең күзләре очраша. Ике кайнар караштa һаман шул ук әйтелмәгән сер. Хәер, инде сүзләр кирәк микән?.. Кайчагында күзләр бер-беренә белдерәсе теләкне телләргә караганда яхшырак әйтә беләләр ич. Кайчакта сөю турында иң сайланган сүзләр әйтелсә дә, анда чемердәп йөрәккә үтәрлек назлы караш булмаса, ул яфраксыз агач шикелле мәгънәсез, шыр булып кала...

«Шулай гына була күрмәсен».

Бу — Хөббениса әбинең дә теләге. Чөнки авыр көннәрендә мәрхәмәт кулы сузган игелекле кыз белән улы арасындагы җылы мөнәсәбәтне ул да сизә, бу дуслыкның үсә баруына куана, кызны үзенең булачак килене итеп күрәсе килә иде. Ләкин ни өчен ул һаман ачылмый? Мөлаем тавышында нинди бер дә җуелмас сагыш соң аның? Сирәк кенә көлеп куйганда да эреми ич бу моңсулык. Карчык үзенең күпьеллык тәҗрибәсе белән нидер чамалый, нидер сизенә. Улының язмышына соры күләгә булып төшәрлек ниндидер күңелсезлек булыр сыман.

Шулай да Сәгадәтнең бүгенгечә сүз башлавын һич көтмәгән иде Хөббениса әби.

Гадәттә, бусагадан атлауга, Сәгадәт барысының хәлен сораштыра иде, бүген ул никтер тавыш-тынсыз гына кайтып керде. Сүзсез генә чәй әзерләде. Кызның шулай эченә бикләнүенә Җамали да пошаманга төшкән иде.

— Ни булды, Сәгадәт?

— Берни булмады.

— Булмады сиңа... Күзем җукмы?..

Сәгадәт бераз дәшми утырды да, болай дип сүз катты:

— Миңа бүтән җиргә күчәргә кирәк. Ни әйтсәң дә, кыз балага егетле йортта яшәү килешми.

Хөббениса әби капшана-капшана Сәгадәт янына елышты.

— Син үз кызыбыз шикелле ләбаса.

— Әнә кеше әллә ниләр сөйли. Мине сезнең... Әй лә, әйтүе дә уңайсыз...

— Нәрсәсе уңайсыз ди аның... Ие, мин дә ишеттем... Сине безнең килен дип сөйлиләр икән...

Сәгадәт оялып тәрәзәгә борылды:

— Минем эти-әнием дә юк...

Менә кайчан җай чыкты. Җамали каушый-каушый инде кайчаннан тел очында йөрткән сүзләрне әйтеп калырга ашыкты.

— Минем әнием синең әни булыр... Кал син бездә, Сәгадәт, кал! Зурдан купмасак та, хәлебездән килгәнчә туй ясарбыз!..

Сәгадәт шашкын ярсулык белән тәрәзәдән купты:

— Минем... Минем балам бар ие бит!..

Җамали яшен суккандай авызын ачып катып калды. Әйтәм, узган тормышы хакында сораша башласаң, Сәгадәт сүзне икенчегә бора, я, берәр эш тапкан булып, чыгып китә иде... Менә эш нәрсәдә икән... Җамали ни диярга дә белмәде. Бары Хөббениса әби генә ничектер үзгәреп киткән тавышы белән сорап куйды.

— Кайда соң ул балаң?

— Зинһар сорамагыз! Гаеп итеп тә калмагыз!

Ул шулай диде дә, елап җибәрмәс өчен яулык читен тешләп, ишеккә ташланды.



## 4

Сәгадәт китте. Җамалиның йөрәк түрендәге иң нечкә кылы авырттырып чыңлап калды. Ни әйтсәң дә, ул бу каратутлы, мөлаем карашлы кызыйга ияләшеп беткән иде бит.

Шул көннәрдә Җамалины Минай үзенә чакыртты. Җамали, аягы төзәлеп җитмәү сәбәпле, урамга әллә ни чыгып йөрми иде әле. Хәер, хаҗәте дә булмады моңарчы.

— Ник чакырды икән? — дип борчылды Җамали. — Шул таланган акча хакындадыр әле. Сыерны сатмый булмас... Ярый әле, йорты да китмәсә...

— Әй, ходаем, ярдәмеңнән ташлама, бәндәләреңнең күңеленә мәрхәмәт сал, — дип сөйләнә-сөйләнә, Хөббениса әби улын өй баскычына басып озатып калды.

Таякка таянып аксый-аксый урамнан үткәнен Сәгадәт тә күрми калмагандыр. Нәрсә уйлады икән?

Җирән сакаллы кызгылт йөзендә һәр вакыт елмаю балкыган Минай Җамалины колачын җәеп каршы алды.

— Әйдүк, Җамали, әйдүк!

Минайның күңеле җиде кат күк катында иде.

— Котылдык бит, энекәем, тәки котылдык. Эшне яптылар. Акчасы югалган инде, чурт с ним... Менә бик кирәкле хатларны саклап калгансың икән син... Малатчина, энекәем, малатчина!

Җамали эчтән генә мыскыллы елмаеп куйды. «Саклап калган, имеш... Талаучыларга рәхмәт диген... Кирәкле хатларыңны исән калдырганнар...»

Минай шул ара хатыны Бибикамал абыстайны чакыртып табын әзерләргә кушты.

— Бу куанычлы хәл уңае белән утырып алмый ярамас... Сыйла әле егетне бер... Әгәренки ул булмаса...

— Син нәрсә, Минай абзый?.. Килешмәгәнне...

— Җә, җә, кыланма!.. Утыр өстәл янына, ризыктан да өстен түгелсең...

Табынны кече якта гына әзерләделәр. Тулы гына гәүдәле Бибикамал абыстай, киң идән сайгакларын дерелдәтә-дерелдәтә басып, табынга калай табак белән итле аш китереп куйды. Җәһәт кенә ашны куштан кашык белән таш тәлинкәләргә бүлеп чыкты. Ул да булмады, кояштай көлеп өстәлгә чәйнегә белән ачы бал килеп кунаклады. Минай абзый кара түбәтәйле башын бер якка кыегайтып, нечкә иренен көлкеле мимылдата-мимылдата балны чәчәкле бокалларга агыза башлады. Аның бөтен кыяфәтендә бу бит шактый серле һәм четрекле

эш, моның эчке мәгънәсенә төшенү һәркемнең зиһененә килмәс дигән төсмер чагыла иде.

Балны шулай барча нечкәлеген белеп кенә бүлеп бетергәч, ул лым-тулы бокалларны янәшә куйды да, бер күзен кыса төшеп, һәр икесенә салынган эчемлекнең тигезлеген чамалады. Аннары үз эшеннән бик тә канәгать булып учын-учка ышкый-ышкый:

— Җәле, энекәем, тотып җибәр кайнар килеш, хи-хи-хи, — дип кеткелдәп алды.

Җамали мөлдерәмә тулы бокалын төбенә чаклы эчеп куйды да, авызын пешерә-пешерә, кайнар ит шулпасын ашый башлады.

Аннары «кәүсәр суын» тагын бер-ике мәртәбә күтәрделәр. Эссе булып китте. Маңгайларга бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Ә Минай абзый бертуктаусыз Җамалины мактады: имеш, ул сынатмаган, имеш, ул талаучыларга үзенең кем икәнен таныткан. Аннары Минай җиңсез казакиеның эчке кесәләрен актарып, аннан кәгазь акчалар тартып чыгарды.

— Ал, энекәем, миңа эшләгән игелекләреңне буш итәмме соң!..

— Минай абзый...

— Ал, ал, ал... Алмасаң, ризалыгым юк!

Ул берничә кисәк кәгазь акчаны көчләп диярлек Җамалиның кесәсенә тыкты.

— Рәхмәт, Минай абзый.

— Үзеңә рәхмәт, энекәем...

Менә сиңа мә, Җамали Минайларга барганда бар малымнан коры калырмын инде дип, кан калтырап барган иде ләбаса. Күктән төшкән бәхетне кара син... Әйбәт тә кеше инде Минай абзый... Кеше белән кешене аера белә...

Шундый сөенечле уйлар белән кайтып килгәндә, кинәт ул Сәгадәт белән йөзгә-йөз очрашты. Бу аның өчен шул чаклы көтелмәгән хәл булды, башта сүз әйтә алмый тотлыгып калды.

— Ни... ни... Сәгадәт?.. Исәнме, Сәгадәт?

— Ярыйсы гына әле, Җамали.

— Ничек яшәп ятасың?

— Әйбәт кенә...

Җамалилардан киткәч, Сәгадәт югары очтагы Мәстүрәләрдә тора башлаган иде. Инде унҗиде яшь белән барса да, сипкелле йөзеннән әле һаман сабыйлыгы чыгып бетмәгән зәңгәр күзле, чандыр Мәстүрә белән Җамалиларның арышын урган чакта танышкан иде ул. Чөнки җирләре янәшә булып, кишәрлекләрен урып бетергән арада ызанга утырып гәпләшеп алгалый иделәр. Мәстүрә әнисе белән генә тора. Әтиләре кызыллар ягында сугышып йөргән. Чехлар Казанга кергән елларны Үтәмеш урманында кыйнап үтергәннәр. Бу эштә уразмәтләр дә катнашкан икән дип сөйлиләр сөйләвен, әмма Мәстүрә бу кешеләрнең кемнәр икәнен тәгаен генә белә алмый. Бу канлы вакыйганың шаһитлары серне чишәргә шикләнә булса кирәк, сорашсаң: «Без күрмәдек, без белмәдек», дип кенә җавап бирәләр. Мәстүрәнең әнисе Фәтхия апа шул хәсрәттән урынга ук егылган. Менә шушы көнгә чаклы тернәкләнә алмый икән әле. Фәтхия апа Сәгадәтне якты йөз белән каршы алды:

— Әйдә, кызым, әйдә, бер дә тартынып торма, өебез зур булмаса да сыешырбыз, алла боерса.

Сәгадәт шул көннән башлап Мәстүрәләрнең бар эшен эшләште. Урылган көлтәләрне кул арбасына төяп, өй артына ташып чабагач белән сугу дисеңме, өй эшләрен карашу дисеңме...

— Яңа җиргә ияләшеп буламы соң? — дип сорады Җамали.

— Ияләшми нишлисең...

— Киттең дә югалдың... Килеп тә бакмыйсың...

— Кешедән яхшы түгел. Үзең ничек яшисең соң? Аягың төзәлеп житәме инде?

— Әйбәт, Сәгадәт, әйбәт. Менә Минай абзыйлардан кайтып килешем... Теге бәладән котылганбыз икән... Сөенечтән бераз... ниткән идек... Гаеп итмә инде...

Сәгадәтнең күзендәге көләчлек кинәт юкка чыкты, алсу иреннәре тартышып куйды.

— Алай икән... Ләкин белмим, бай кеше сине тикмәгә сыйлады микән? Алар бит...

— Китсәнә, Сәгадәт. Булмаганны... Безнең Минай абзый әйбәт кеше ул...

— Ышанмыйм.

— Син нәрсә, Сәгадәт, белмисең әле син аны...

— Аны булмаса, бүтәннәренә юлыкканым бар... Ярый, китим, юл уртасында ир заты белән озак тору килешмәс.

— Китмә әле, мин сине сагындым бит, Сәгадәт...

— Кирәкмәс, Җамали...

— Сәгадәт, мин бит ихлас күңелдән...

— Хуш, Җамали, гаеп итмә...

Сәгадәт йөгерә-йөгерә китеп барды. Җамали таягына таянган килеш Мәстүрәләр капкасына кереп югалганчы аның артыннан карап калды.

Әле өенә кайтып сәкегә утыргач та Сәгадәт күз алдыннан китмәде, икедән үреп салган куе толымына таккан көмеш чулпылары колагында чыңлап торгандай булды. Әйе, яраткан икән шул аны Җамали, бик нык яраткан икән. Балам бар ие диде дә кисте дә салды. Кайда икән соң аның баласы? Берәр туганнарында калды микәнни? Ничек аны күрмичә түзеп яши ала икән соң? Шулай каты бәгырьле түгелдер лә ул. Әллә... Хәер, юрап кына нәрсә беләсең... Үзеннән сорашырга иде, белергә иде... Бәлки аңлашып та куярбыз... Сәгадәткә тиң яр Уразмәттә тагы бармыни!.. Баласы булса соң! «Сөйләшәм, бүген кичтән калмый сөйләшәм Сәгадәт белән» дип, күңеленә беркетте Җамали. Ләкин теләгенә ирешә алмады. Чөнки Сәгадәт кичен чыгып күренмәде.

Ә алдагы көннәрдә өй мәшәкатьләре килеп чыкты. Җыелган игенне эвен итеп коясы, сугасы, тегермәнгә алып барып тарттырасы... Атсыерга да печән житәрлек түгел әле... Явымнар киткәнче солы саламын, урып алган бәрәңге сабагын кышка әзерләп куясы бар...

Шул эшләр белән мәш килеп, йөргәндә Җамали бөтен җанын актарып салырлык хәбәр ишетте: Сәгадәт тирәсендә Мәләк чуала икән... «Ну, Мәләк, — диде Җамали үз-үзенә, — тәки миңа каршы төшәсең дә торасың, ә!»

Шул кичне үк Җамали ак тула оек өстеннән яңа гына үзе үргән чабатасын киеп, күк сатин күлмәгенең яка сәдәфләрен төймәләмичә генә су буена юл тотты. «Сәгадәт су юлына төшми калмас» дип уйлады ул.

Авыл читеннән үк башланып киткән кара-каршы ярдагы имәнлекләргә эңгер сыенырга өлгергән. Тик боргалана-сыргалана үткән инеш сукмагы гына тирә-юньдәге кичке караңгылыктан аерылып агарып ята. Ничәмә-ничә гашыйклар узган шул тап-такыр сукмактан атлап баруы рәхәт. Әнә таныш авыл көе яңгырый. Су буендагы егетләр җырлый аны.

Капка төбендә торасың,
Нечкә билең борасың;
Нечкә билләреңне борып
Кемне кызыктырасың?

Сәгадәтне әллә кайдан күреп алды Җамали. «Үзе генә икән. Каршы төшәргә кирәк... Аулакта сөйләшү әйбәтрәк булыр». Җамалины күргәч, Сәгадәт адымнарын акрынайтты.

— Ник килдең, Җамали?

— Килергә дә җарамый мәллә, Сәгадәт?

— Ярый, ник ярамасын... Тик...

— Ни әйтмәкче буласың?

— Сиңа кызлар беткәнме?

— Миңа син кирәк.

— Мин бит...

— Беләм лә, Сәгадәт, беләм...

— Белеп бетермисең шул, Җамали...

— Соң үзең әйттең лә, балам бар ие, дидең...

— И, шулай гына булса!..

— Тагы нәрсә соң?

— Сорама, Җамали, мин аны беркемгә дә сөйли алмыйм!

— Миңа дамы?

— Ие.

— Әй, булмагае тагы... Мин барсына да риза, Сәгадәт!

— Кирәкмәс, Җамали, бүтәннәрне тап...

— Әллә халыкта йөргән хәбәр дөресме?

— Нинди хәбәр ул тагы?

— Синең янда Мәләк чуала диләр.

— Тирәмдә йөрү генә йөрәгемә хуҗа булу дигән сүз түгел лә!

— Мин аны, койрыксыз шайтанны! Иманын суырам, билләһи!

— Җүләрләнеп йөр тагы...

— Китмә, Сәгадәт!

— Юк, тотма мине, Җамали. Әнә, кызлар судан кайта...

Шулай диде дә сыгылма көянтәсенә аскан пар чиләген сайратасайрата китеп барды Сәгадәт. Җамали беравыкны нишләргә белмичә яр кырыендагы тәбәнәк буйлы имәннәр арасына кереп оялаган әңгергә таба күзен төбәп торды. Әйтерсең шул соры томандай кичке караңгылыктан үзенең шик-шөбһәләренә җавап эзли иде ул.

«Әйтеп бетерми... Мәләк белән алыш-бирешем җук дигән була... Җук сина!»

Җамали кинәт урыныннан купты да тез тиңентен кыяк үләнне чаштыр-чыштыр ерып, гаять зур ерткычның комсыз авызыдай караеп күренгән Әпермәй чокырына таба атлады. Халык арасында Мәләк Сәгадәтне шул чокырда сагалый икән дип сөйлиләр иде.

«Җамалины алдый алмассың!..»

Мәләккә генә бирешә торган егет түгел Җамали. Аның көч чамасын яхшы белә ул. Белмәскә, кече-кечедән Уразмәт үзәнендә бил алышып, ә еш кына сугышып-тукмашып үскән малайлар бит алар. Көче белән Җамалидан күпкә калышса да, ну үҗәтлеккә дигәндә Мәләккә житкәне булмагандыр. Көрәшеп китеп үзе үлән өстенә чалкан бәргән саен: «Әйдә, тагы көрәшәбез!» — дип җанына тия торган иде ул аның. Ни хәл итсен Җамали, инде ничәнче кат булдыра алган чаклы түбән иелә дә, Мәләкнең билдән югары сыдырылган күлмәк чабуына ябышып янә алыша башлый. Читтән үзләрен күзәтеп торучы булса, җәлләп үләр иде: чеби чыккан аяклары канап беткән, муеннан инештәйborгаланып тир ага, чиксез көчәнүдән Мәләкнең борын өстендәге эшлия җизе хәтле сипкелләре менә-менә атылып чыгар төсле... Тик җиз сипкелләр атылып чыгарга өлгерми, Җамали бичара Мәләкне күтәреп тә ала, дыңгылдатып аркасы белән җиргә дә сала. Эчендә нидер өзелеп киткәнме — «кых» итеп куя Мәләк. Ләкин берние өзелмәгән икән, Мәләк аягына баскач бик эшлекле итеп җиргә бер төкереп куя да: «Тагы көрәшәбез!» — ди. Шуннан соң икенең бере кала: я

авыз-борыннар канаганчы тукмашып алырга, я чукынсаң чукын инде дип, үзең җиргә егылырга. Шунсыз күңеле булмый Мәләкнең.

Егет булып җиткәч, Мәләк тә, Җамали да Минайның уртанчы кызы Гөлбикәгә күз атып йөрделәр. Озын толымлы, чем кара күзле бу кызый Җамалины кулайрак күрде күрәсең — очраша башладылар. Бер очраштылар. Ике очраштылар. Өченче тапкыр Гөлбикәсен күрергә дип барды Җамали. Җанашы өй артындагы карт тирәккә сөялгән дә егеткә борылып та карамый.

— Үпкәләдеңме әллә, җаным? — дип сорый Җамали. Тегe дәшми.

— Бер кәлимә сүз генә әйт инде, Гөлбикә? — дип ялына Җамали. Кыз тагы дәшми. Аптырагач, Җамали кызның биленнән кочып ала да, кыяфәтен күрмәк булып йөзенә үрелә. Үрелүе була, шәлъяулык эченнән «әү, бәгърем!» дип җирән мыеклары белән Мәләк килә дә чыга. Җамали чак һушыннан язмый. Ә Мәләккә нәрсә — бөтен урамны яңгыратып хихылдавын белә. Тагы күпме шулай хихылдар иде икән — алла белсен, әмма Җамалиның шактый саллы йодрыгы салма савытына менеп төшкәч кенә шып була Мәләгең. Шуның белән вәссәлләм. Җамали Гөлбикә катына бүтән аяк та атламый.

... Җамали Әпермәйгә якынлашкан саен чокырның кап-кара авызы акрынлап соры төскә кереп зурайганнан-зурая барды. Әйтерсең ниндидер коточкыч җанвар Җамалины йотарга әзерләнә иде... Хәер, Җамалины гынамы... Ул аның бәхете, күңел куанычы булган Сәгадәтне дә суырып алыр... Кара-каршы бәрелешкән һәр мәлдә Җамали көч ягыннан Мәләктән өстен чыкса да, аңарда нидер җиңелмәгән, аска төшмәгән килеш кала: хәйләкәрлегеме, үҗәтлегеме, әллә серенә төшеп булмаслык яшькелт күз карашымы?

Менә хәзер дә, үзе булмаган чакта да, каяндыр камышлар арасыннан шул җелтер күзләр бага төсле... Багып кына калмый, җанын оета, зиһенне томалый, аяк-кулның тотрыгын кимет*ә*...

Мәләкнең шул сихерле карашына, үҗәтлегенә каршы тора алмас, алданыр Сәгадәт... Үзенең беркатлы самимилеге аркасында алданыр...

Кинәт Җамали үзенең артында гына аяк тавышлары ишетте. Ялт борылып караса... Юк, бу Мәләк түгел, иңенә аскан сулы чиләкләрен салмак тирбәлдереп, чишмә юлыннан Сәгадәт кайтып килә... Җамали, су җыелып торган сазламыкны чыштырдатып ера-ера, Сәгадәтнең каршына ашыкты.

— Җамали?.. Син кайтып китмәдеңмени әле?

Җамали җилкәләрен җыерды.

— Җамали, юл бир, узып китимче...

— Җарар инде, Сәгадәт... Китмә инде... Печтик кенә сөйләшеп утырыйк инде?..

Сәгадәт кичке тынлыкны чыңлатып көлеп җибәрде. Җамалиның шулай мескенләнеп кенә үзенә ялынуы көлке дә, әллә ничек якын да тоелды аңа.

— Ни сөйләшмәкче буласың, Җамали?

— Сүз беткәнме?.. Тормыш хәлләрен...

Җамали Сәгадәтнең кулыннан тотып алды да, аны үзенә табарак тартып китерде.

— Тукта әле, Җамали, тукта... Кайтырга ие лә... Күр, ничек караңгы төшә.

— Кайтырсың, кунып калмассың...

— Һай, Җамали...

Алар бер-берсенә шул чаклы якын басып торалар, бер-берсенең сулу алуларын, хәтта йөрәк тибешләрен ишетеп тоялар. Инде үзләре дә аерым-аерым җан түгел, ә татлы газапта эрегән бер бөтен кайнарлык кебек.

Шушы халәт Сәгадәтне куркытты, ахры, ул Җамалидан читкәрәк тайпылды. Уфтанып куйды.

— Ә Фәтхия апа миңа экиятләр сөйли... Әкиятләре дә үзе төсле... Буйсынмас, горур. Бер кыз хакында сөйләгән иде Фәтхия апа. Канатлы атка атланып яуга чыккан кыз хакында.

— Кыз баламы? Чыгар синә!

— Чыккан шул менә. Дошманнарны пыр туздырган.

— Булмаганны...

— Их, син... беләсең килсә, шул кыз шикелле ярсу атка атланып, дошманыма каршы мин дә барыр идем әле!

Җамали исе китеп Сәгадәткә күтәрелеп карады. Күз карашын күрмәсә дә, бөтен йөзе кырысланып, усалланып киткәндәй, сылу гәүдәсе атылып китәргә әзер яңа бөгелгән көянтә кебек.

— Синең нинди дошманың булсын, Сәгадәт!

— Булмаган кая!.. Дошманым булмаса, мин бу көнгә калыр иеммени?!

Һич уйламаганда, Сәгадәт үксеп елап җибәрде. Ул шул чаклы риясез итеп, сабыйларча, бөтен иңен калтыратып үкси иде. Җамали аны әллә ничек, үз-үзенә буйсынмас күңел ташуы белән кочып алды.

— Сәгадәт, җылама, зинһар дим, җылама!

Сәгадәт тамагына килеп бөялгән йөрәк үксүенә буыла-буыла:

— Мин... мин... улымны сагынам ич, һай, ничек сагынам улымны!..— дип ярсып әйтте дә, чиләк-көянтәләрен алып, сукмак буйлап йөгерәатлый китеп барды.

Соңгы мәртәбәсендә Җамали Сәгадәтне өйләреннән чакырып чыгарды.

Сәгадәт коңгырт күзләре белән Җамалиның йөрәк бәгыренә үтәрлек итеп карап алды да:

— Я инде, тагы ник килдең? — дип сорады.

— Минем синнән каласым җук, Сәгадәт!

— Ник шул тикле дә газаплыйсың мине, Җамали? Булырлык булса, теге чакны ук риза дияр идем бит...

— Күзеңә бигрәк шыксыз күренәм икән...

— Их, шулай булса!..

— Эш нидә соң, Сәгадәт, ник күнмисең?

— Сәбәбен сорама дип бер әйттем ләбаса...

— Сәбәбен дә сорамыйм, бары кулыңны бир дә, бергә-бергә тора башлыйк!

— Һай, Җамали, сине дә, үземне дә бәхетсез итәр хәлем юк... Кит, зинһар бүтән киләсе итмә!..

Җамали, нишләргә белмичә, инде җил капкадан кереп баручы Сәгадәт артыннан ташланды:

— Сәгадәт! Сәгадәт дим!..

— Сүзем бетте, Җамали!.. Хуш!

Җамали баскан урынында тораташтай катты да калды.

«Шул тикле дә газаплыйсың ди. Мин аны бер күрергә зар-интизар булып җөрим. Ә аңа минем килүем газап кына икән...»

Җамалиның дөньясы асты-өскә килде. Күкрәген авырттырып эче тулы ялкын дөрләде. Тәтене ургылып авызыннан чыгар төсле иде. «Инде нишләргә соң, нишләргә? Аны күргән саен йөрәгемне яндырып, айлар-еллар буе ут йотып яшәргәме? Җук, каядыр китәргә кирәк миңа! Күз күрмәгән, колак ишетмәгән тарафка барып олагырга кирәк!»

Кыр эшләре беткәч, Җамали күрше авылдан Җәмилә апасы белән сөйләшеп кайтты да, Хөббениса әбине сыеры, аты, өйдәге вак-төяк әйберләре белән бергә шуларга илтте. Ә үзе, өй тәрәзәләренә такта кадаклап, бүтән беркем белән дә сөйләшмичә, Уразмәттән чыгып китте.

## 5

Үрсәләнгән җанның гадәте ташу суыдай: ярларыннан ашыр да, кая баруына исәп-хисап бирмичә, күз күрмәгән тарафка томырылыр. Ярсуы ничаклы чикләнмәгән булса, ашкынган юлы да шул тикле ераккарак. Шушы халәттәге адәмнең җил-давылдай омтылышына чик куярга тырышу — файдасыз. Күзенә ак-кара күренмәс чагы бу аның. Ташу бер чакны ярына түшәп тынычланып калгандай, ул да бер заман тынып калыр, тирә-ягына күз ташлап, исәп җыяр чагы килер. Вакытның шушы арасы озын булырмы, юкмы — анысы кешесенә карап. Җамали өчен шактый озын булды бу ара. Сигез елга якын. Хәер, монда барысы бергә: йөрәгенең давыллануын басмак булып Уразмәтне ташлап китүе дә, Астрахань якларында кыдырып йөргәннән соң, казакъ далаларына барып чыгуы да... Бусы инде — гомеренең тотрыклырак, салмаграк чагы... Йөрәк кушуы буенча гына түгел, баш белән фикерләп дөнья куган көннәр... Ә Сәгадәт? Күңеленнән җуя алдымы соң аны Җамали? Юк шул, юк... Йөрәккә тирән уелганны җәһәннәм тишегенә олаксаң да чыгарып ташлап булмый икән аны. Сәгадәт үзе, ул басып йөргән чишмә сукмагы каядыр еракта калса да, күңел кыллары сузылып әллә кая — мең чакрым ары урнашкан туган якка барып кайта, сөйгәненең эзләренә моң булып төшә. Бигрәк тә Сәгадәтнең үзләрендә көн иткән чагы өзелеп искә килә, авырып ятканда баш очында утырган минутлары, коңгырт күзләрен тутырып-тутырып карап алулары... Очып кына кайтып, читтән генә булса да бәгырь кисәгенең зифа гәүдәсен күрәсе килгән минутлары аз булдымы Җамалиның. Бу теләк кайчагында шул чаклы да куәтле була, Җамали үзен көч-хәл белән генә тыеп кала иде.

## 6

... Тик үз-үзеңне йөгәнләп торуның да чиге була икән. Менә Җамали авыл башындагы Кирәмәт тегермәне янында басып тора. Бераз тын алу исәбе. Баксаң, ул үзе дә шул тегермәнгә охшаган икән: як-якка тырпаеп торган куллары җил исеп җибәрсә, тегермән канатыдай әйләнеп китәр төсле. Хәер, җил исмәсә дә, баскан урынында чайкалып-чайкалып куя Җамали. Бик арыгангамы, әллә йөрәгенең парә-парә булып теленеп китүеннәнме бу? Кирәмәт тегермәне... Азмы әнисе белән шул тегермән сукмагын таптаган аның аяклары... Инде әнисенең каберенә баш куеп аһ орырга гына кала... Җамали әллә ничек ашыгып-дерелдәп, инде ничә кабат укый-укый бөгәрләнеп беткән хатны кесәсеннән алып, ак кәгазьгә кәкре-бөкре хәрефләр белән Җәмилә апасы язган юлларга текәлде: «Әни үлде». Ләкин күңел моңа ышанмый, күңел киреләнә. Каяндыр тегермән артыннан ап-ак яулыгын җилфердәтеп әнисе чыгар кук. Чыгар да, бер авыз сүз әйтә алмыйча, еллар моңсулаткан күз карашын улына төбәп торыр... Күз төбеннән бер бөртек яшь тәгәрәр. Аннары шул күз яшен яшерергә теләгән төсле генә битен улының күкрәгенә яшерер... Ә Җамали әнисенең үксеп елавын аның арык җилкәсенең талпынып-талпынып куюыннан гына сизәр... Юк бит, юк! Дөньядагы иң якын, иң мөлаем кешенең моңсу карашын, газиз тәненең җылысын моннан соң бер вакытта да тоймас ул!

Туып-үскән йортка якынлашкан саен дулкынлана барды Җамали. Менә бала чактан бирле бик-бик таныш булган коймалар, койма буенда кычытканлык.

Ә йорт тузган. Җиргә ныграк сеңгәндер, күрәсең, тәбәнәкләнеп калган. Коймалар да искергән икән: баганалары череп әчке якка авышкан.

Сигез ел шактый гомер шул... Җамали тәрәзәгә кадакланган такталарны шыкырдатып суырып алды да, ишекнең йозагын каерып өйгә керде. Өй эче шып-шыр... Ә кайчандыр тормыш кайнаган бит шунда... Әнисе килен булып төшкән. Шау итеп туй ясаганнар... Апасы Җәмилә, ә ике елдан Җамали дөньяга килгән... Ялан аяк кына тупылдап чабып йөрүдән идән сайгаклары шомарып беткән...

Капыл гына Җамалига шундый уй килде: «Минай абзыйга барып килергә кирәк. Ни кырып ята икән? Ул мине элек якын итә иде бит».

Җамали капкадан чыкты да, түбән якка борылды. Инеш сукмагы буйлатып үзәлдына нидер уйланып барганда, әрәмәлек арасыннан кинәт кенә Мәстүрә белән Сәгадәт килеп чыкмасынмы! Йөрәге убылып төштемени Җамалиның. Сәгадәт тә бер мәлгә әллә ничек каушап-үзгәреп китте.

— Җамали? — дип сорады ул, үз күзләренә ышанмыйча.

— Мин шул... Кайттым әле менә...

— Югалган кеше дә кайтып күренер икән...

— Тәкъдирең шундый булгач... Күрешик булмаса.

Җамали ике кулын сузып башта Сәгадәт, аннары Мәстүрә белән күреште. Ә үзе күзләрен сөйгәненнән алмады. Үзгәргән, Сәгадәт, үзгәргән... Юк, картаймаган, бары йөзендәге самимилек урынына җитдилек, ул гына да түгел, кырыслык иңгән. Күзләрендә буйсынмас горурлык, үзенә чакырып торган көләч дәртлелек. Томырылып бер караса, теләсә нинди егетне телсез калдырырлык.

— Әниеңнең җеназасына гына кайтып җитмәдең.

— Очар кош булсам кана...

— Адәмнең канаты — тынмас җанында.

— ?

— Сигез елга бер кайтмый чыдар икән кеше...

Җамали, гаҗәпләнеп, Сәгадәтнең йөзенә күтәрелеп карады. Коңгырт күзләрендә йөрәк бәгыренә үтәрлек үпкә. «Онытмаган икән».

— Инде нишләмәк буласың?

— Башта йортны бер җайга китерергә исәп... Эт баш, сыер аяк әле анда.

— Бәлки өмә ясаргадыр?

— Зыяны тимәс иде.

— Бүген кичкә үк өмә ясап алабыз, шулай бит, Мәстүрә?

— Була ул!

— Без килешкә әзер булып тор!

Кызлар шулай шаулаша-шаулаша китеп тә бардылар.

Минай аның килүенә бик сөенде. Хәтта җыерчыклана башлаган күз тирәсе бераз юешләнде дә.

«Бирешкән карт, — дип уйлап алды аның турында Җамали. — Чәчләренә чал кунган икән, үзе бераз бөкрәя дә төшкән...»

Минай егетнең уйларын чамалады, ахры:

— Мине күреп гаҗәпкә калгансың, мөгаен... Калырсың кем... Әле дә ничек акылын җуймый бу карт дип шаккат, энекәем... Бетештек, тәмам кешелектән чыгардылар... Таладылар, ыштансыз калдырдылар...

Җамали карт сүзләренең мәгънәсенә төшенә башлады. Әйе, монда колхоз төзелеп ята икән... Димәк, җиле Минай абзыйга да кагылган...

— Әллә сезне дә?..

— Ничек кенә әле, энекәем, тәмам бугаздан буып алдылар... Сулар әмәл юк... Тегермәнне таладылар, кибетемне таладылар...

— Әллә кибет тә салган идегезме?

— Салдырган идем шул, гөнаһ шомлыгына каршы... Болай буласын белгән булсам... Ник шунда ипи-тозсыз кырылып бетмиләр... Ә алар игелекнең кадерен белмәделәр энә...

Җамали эченнән Минайны кызганып куйса да, аның бу чаклы аһ оруын өнәп бетерми иде. Күле тирән бит әле аның... Әллә ничаклы яшергән малы бардыр.

— И, Минай абзый, ул тикле дә кайгырма әле, мал казасы баш казасы түгел. Мал табыла, баш табылмый.

— Һе, энекәем, бушка килдеме миңа ул мал. Күз алдында лабаса, күпме тир агызып таптым бит мин аларны... Юкка бөкрем чыккан дип беләсеңме?

— Соң, нишлисең инде, заманасы шундый булгач...

— Заманасы, заманасы... Безгә генә гел артын күрсәтә ул. Әнә хәерчеләр түрә булды хәзер.

— Кемнәр соң алар?

— Кем булсын, югары оч Исмае авыл советында хуҗа булып утыра... Анысына түзәр дә идең... Ник дисәң, ул властьлар кушканны эшли. Ә менә син юлдан табып кайткан хәерче хатын бөтенләй акылдан язды!

— Сәгадәтме?

— Шул иманы качкан нәрсә...

— Булмаганны...

— Ниткән булмаган ди. Тегермәнне дә, кибетне дә шул алдыртты.

— Ни сөйлисең син, Минай абзый?

— Нәрсә бар, шуны сөйлим... Җанында Иблис асраган булган икән... Башта Мәстүрә дигән кыз белән йөреп грамотага өйрәнгән ди... Аннары советта эктиф булып йөри башлаган...

— Кем булып?

— Эктиф... Ягъни куштан... Власть эшенә тыгылырга аннан беркем сорамый да... Котыра бит... Бер Иблискә әйләнгәч, шулай була торгандыр инде... Җитмәсә, шул тиле хатынның сүзенә ышаналар, аның әйткәнен тыңлыйлар бит әле... Ниндидөнья бу, ә? Әле Мәләге каяндыр ишетеп кайткан, Сәгадәт әйтә ди, Минайның җиде яры күмгән хәзинә байлыгын беләм... Казытып алдырмый калдырмыйм дип әйтә ди... Казытыр, билләһи, бөтен дөньяңны казытыр, чыбыктан чыбыркы булган ул хатыннан барысын да көтәргә була!

— Алай...

— Менә син авылга сөйрәп кайттың ул бәдбәхетне!.. Син!.. Күпме яхшылык кылдым үзеңә... Ни белән кайтардың, ә!..

— Минай абзый, мин бит...

— Акланма, энекәем, акланма... Сез барыгыз да игелекне явызлык белән түлисез!

Җамали үзалдына сөйләнгәндәй мыгырданып куйды:

— Сәгадәт, Сәгадәт... Мин шул кызыйны чын күңелдән яратып йөрдем тагы... Чүт кенә өйләнмәдем бит аңа...

Минай кинәт кенә кара түбәтәй кигән башын калкытып Җамалига акылдан язгандай карап торды:

— Өйләнергә җөрдең?

— Белмим, Минай абзый, хәзер ни әйтергә дә белмим! Шундый да явыз, игелексез булгач...

Минай вак адымнар белән Җамалига якынлашты, калтыранган кулларын аның таза иңенә салды.

— Тукта, өйләнмәкче булдым дисеңме?

— Куй әле, Минай абзый! Зинһар башымны катырма!..

— Син, энекәем, алай итмә әле. Барса, ал син аны.

— Мин сине аңламый башладым, Минай абзый. Үзең әйтәсең...

— Мин ни әйтмәм. Әйе, алып җибәр. Шаулатып туй ясарсың.

— Нием белән шаулатыйм мин?

— Үзем бирәм. Иң яраткан энекәемә җәл түгел.

— Минай абзый...

— Бетте, бетте, бетте. Аңлаштык. Өйлән, енекәем. Аннары иплэп кенә үзе белән сөйләшерсең. Минай абзыйга тияргә ярамый диярсең. Ир — баш, хатын — муен, үзең беләсең.

Минайлардан Җамалиның кәефе кырылып кайтты. Кара син Сәгадәтне.Ниләр кыйратып ята икән. Хатын-кыз башы белән ирләр эшенә тыгылу аңа нигә кирәккәндер.

Сәгадәт белән Мәстүрә сүзләрендә тордылар. Кичкырын шау-гөр килеп тә җиттеләр.

— Я, себеркең кайда, суың кайда?

— И-и, бер нәрсә дә әзерләмәдеңмени?

— Әллә авырып киттеңме, төсең үзгәргән?

Җамалиның, чынлап та, һаман күңеле төшенке иде. Шулай да сынатмаска булды.

— Җук ла, юлдан кайтканга бераз арылгандыр...

— И-и, егет кешегә нинди ару ди ул?

— Әйтмә дә...

— Минай абзый сезгә рәнҗи анда.

Сәгадәтнең көлеп торган күзләре кинәт сүрелгәндәй булды:

— Минай абзый?.. Әллә шунда бардыңмы?

— Хәлен белешкән идем шул.

Сәгадәт дөнья бетереп өйне рәткә кертергә тотынган иде. Җамалиның шул сүзләрен ишеткәч, ул кулындагы әрем себеркесен бер читкә куйды да, аның каршына ук килеп басты:

— Чит җирдә дөнья гизеп йөргән кеше ачылып, дөньяның кая таба барганын яхшырак төшенеп кайта дисәм... Күзеңне йомып йөргәнсең, ахры, син, Җамали!

— Сәгадәт, мин бит...

— Китсәнә!

Шулай диде дә Сәгадәт, тәмам дуамалланып, өйдәге чүп-чарны тышка себереп чыгара башлады. Әйтерсең ул шулай кубарылып егет әйткән сүзләрне дә каядыр чыгарып ата, җилгә очырып җибәрә иде.

«Минә сиңа холык, — дип шаккатты Җамали, — ул мондый кызу канлы, усал түгел иде бит. Нишләп бу чаклы да үзгәрде икән Сәгадәт?»

Җамали аны тынычландырырга, әйткән сүзләренең мәгънәсен йомшартырга тырышты:

— Соң, Сәгадәт, мин бит сезгә каршы килеп түгел.

— Тел төбең кая барганы аңлашыла.

— Соң алар да кеше ләбаса!

Сәгадәт яңадан чәчрәп чыкты:

— Ә без кеше түгелме? Көнне төнгә ялгап җиткерә алмаучылар кеше түгелме?

Сүзгә Мәстүрә дә катнашты:

— Колхоз төзибез бит, Җамали.

— Беләм.

— Соң колхоз төзегәч, бөтен авыл файдалана торган тегермән, кибет ише нәрсәләр бар кешенеке дә була ич...

— Ә Минайның, — диде Сәгадәт, — кешечә яшәргә исәбендә дә юк. Караклардан һаман аерыла алмый.

Җамали бу хакта ник сүз кузгатуына үкенә башлады. Ничек булса да сүзне икенчегә борырга, бу күңелсез әңгәмәне туктатырга теләде ул.

— Җарый, җитәр булмаса. Җә бер дә жукка талашып китәрбез.

— Анысы да файдага.

— Кирәкмәс, Сәгадәт, мин сезне сагынып кайттым. Зинһар сүзгә килешмик.

— Шулай итик, — диде, ниһаять, Сәгадәт тә Җамалига чая караш ташлап. — Әйдә, тот әле чиләкне. Син су кертеп-чыгарып торырсың.

Шуннан соң алар өчесе дә уен-көлке сүзләре сөйләшә-сөйләшә баш та күтәрми эшләделәр. Берәр сәгатьтән өй сап-сары итеп юылган, бар нәрсә тәртипкә китерелгән иде. Җамали кызларны озата чыкты. Инде тышта эңгер куерган иде. Күк йөзе йолдызлар белән бизәлгән. Мәстүрә алгарак китте. Сәгадәт белән Җамали арткарак калдылар.

Җамали Сәгадәтнең кулыннан тотып алды. Кыз кулын тартып алмады.

— Мин сине оныта алмадым, Сәгадәт.

— Ә үзең юкка чыктың.

— Йөрәккә чыдый алмасаң нишләрсең...

— Тик мин ул чакта әйткән сүземнән кире кайтмадым бит, Җамали.

— Моны ничек аңларга?

— Бер сүз белән генә аңлатып булмый аны.

— Нинди аңлатып бирмәслек сүз соң ул?

— Нишләп алай булсын. Теге чакны адәм рәтле сөйләп бирә алмас идем, ие. Йөрәкнең ярасы бигрәк өр-яңа иде шул. Аннан соң сөйләү куәсем дә ярым-йорты. Хәзер була, Җамали... Укырга-язарга өйрәнгәч, сигез ел гомердә әллә ничаклы китап укылган. Кеше арасында йөрелгән. Миңа ни, очар коштай ялгыз башым.

— Сөйлә, Сәгадәт!

— Сөйләве әле дә ансат түгел, Җамали.

— Сөйлә, йөрәгеңдә саклама, тышка чыгар. Җиңеләеп калырсың.

— Тагы алҗытасың мине, Җамали. Ярый, сөйләсәм, ичмасам, артымнан йөрмәссең. Икебез дә тынычланып калырбыз.

— Алай икән...

— Түгел, түгел... Син уйлаганча түгел! — Сәгадәт Җамалига әллә ничек йөрәкне әрнетерлек итеп карап куйды. — Сине якын итмәсәм, бәхетсезлегем хакында сөйләргә дә җыенмас идем.

— Сәгадәт!

— Әйдә, инеш буена төшик.

Алар икәү генә калганнар иде. Акрын гына атлап, түбән оч инеш буена юл тоттылар. Таллыклар буена житкәч, Сәгадәт чирәмгә утырды. Җамали аңа таба елышты.

— Күпне күрдем мин, Җамали, җәберне дә, хәсрәтне дә.

Ул бермәлгә тезләрен ике кулы белән кочаклап, Үтәмеш кыясын урап алган кызгылт рәшәгә карап торды. Коңгырт күзләрендә бетмәс-төкәнмәс сагыш иде аның.

— Мин күргәнне бүтәнгә күрергә язмасын, — дип дәвам итте ул. — Биш яшемнән әтисез калдым. Ә тагы бер елдан әнием дә үлеп китте. Апам тәрбиясендә үстем мин. Җизни бик коры кеше иде. Юк кына сәбәп өчен дә таяк белән тотып ярган чаклары аз булмады. Аларның алты баласы өстенә мин җиденче булганга, тормышлары да такы-токы иде шул.

Уналты тулар-тулмаста апамнар мине авылның бер егетенә кияүгә бирмәкчеләр иде. Тартыштым, тырмаштым, ләкин чыкмадым. Яратмаганмындыр, күрәсең. Үз бәхетемне көткәнмендер. Ә ул озак көттермәде — килде. Бәхетеңне зарыгып чакыру яшенә кергәч, килә икән ул. Тик кыска булды ул бәхет. Бер елга да тулмады. Сугыш чыгып, шунда алдылар иремне. Җиңел килгән бәхет җиңел китә диләр. Дөрес түгел ул сүз. Авыр килде, җиңел китте. Апамнардан күпме тиргәү, күпме каргыш ишеткән ием мин алар теләгән кешегә чыкмаган өчен. Алардан качып егетем янына ашыккан көннәрем аз булдымыни. Очрашу урыныбыз — тау башындагы имәнлектә чылтерәп аккан чишмә яны. Бүтән гашыйклар кичен очрашкандыр. Без таңнарын очраша иек.

Чөнки кичен апам мине беркая да чыгармас ие. Ә таң безнеке. Иртүк яңгыраган сандугач җыры да, кояш чыкканчы ук офыкка сузылып менгән кызгылт нурлар да безнеке. Тик чишмә суында тирбәлүче безнең шәүләләрне кояш күрмәс. Ул ялкынга төренеп офыктан күтәрелгәндә бу шәүләләр уйнаклаган урында чуер ташлар гына ялтырап калыр...

Ирем улын күрә алмады. Ул киткәч туды малаем. Ә ни тикле зарыгып көткән ие ул аны. Эчемдә тере җан талпынуын тойган минутларда сөенеченнән үз-үзен белештерми мине кочып ала, битләремнән, чәчемнән үбә. Ә үзе бертуктаусыз туачак малай хакында сөйли. Нәрсә генә юрап бетерми ул: «Малай бик акыллы булыр, галим булыр», — ди торган ие. Шуңа улыма Галим дип исем куштым да. Шундый сөйкемле иде малай: йөзе түм-түгәрәк, бит уртасы көлгәндә батып китә. Күзләре нәкъ атасыныкы — зәп-зәңгәр ие. Унике яшь тулган булыр ие инде хәзер...

Сәгадәтнең күзләренә яшь тулды, тавышы калтыранды. Бераздан ул, аскы иренен тешләп, күкрәге эченнән күтәрелеп килгән кайнар дулкынны җиңде һәм сүзен дәвам иттерде:

— Егерме беренче елгы илдәге корылык бездә үтә зәхмәтле булды шул. Ә безнең ише ярлы-ябагайның кара көнгә җыеп куйганы буламыни аның. Без ил өстенә калдык. Ә ул елны бездә булмаганны, илдә дә булмады бит. Комбед дигәннәре булышмады түгел, булышты анысы. Тик шул тикле ач халыкка ул кайдан азык җиткерсен? Үзем алабута икмәге ашап, кычыткан шулпасы эчеп тә чыдар ием әле. Бала бар бит, бала. Күреп торам — көннән-көн улымның йөзе зәгъфыран төсенә керә бара. Күз кабаклары, бит алмалары шешенеп китте. Күтәрелеп караган саен йөрәгем тетрәнеп куя. Инде ни хәл итим соң, кемгә барып егылыйм? Авылда Мөстәкыйм атлы бер бай кеше бар барын. Тик ул безнең кук хәерчеләрнең барысына икмәк өләшер димсең? Ләкин бүтән чара да юк, күрәләтә улымны ачтан үтеримме?.. Бардым Мөстәкыймгә. Бизәкләп эшләнгән капкалары эчке яктан бикле ие. Дөбердәтүемә, ике яктан ике эте абайлап өрергә тотынды. Кире борылып китәм дигәндә генә бай чыкты. Мине күргәч, киң итеп елмайды.

— Әйдүк, Сәгадәт, әйдүк, рәхим ит, — дия-дия, өенә үк алып керде.

Өйләре шундый киң, якты. Зиннәтле паласлар белән бизәлгән. Түрдә иданнән түшәмгә чаклы көзге. Яхшы комодлар, комод тулы алтын йөгертелгән чынаяк-чәйнекләр. Югалдым да калдым. Ә Мөстәкыйм шул ара асравыннан тәмле-тәмле ризыклар китертте. Нәрсә генә юк иде анда: калҗа-калҗа ит дисеңме, бәлеш-гөбәдия дисеңме...

Мөстәкыйм үтереп мине кыстый башлады:

— Утыр, Сәгадәт, — ди. — Кунак булып килгәнсең икән, чәй эчми китмисең инде, — ди.

— Минем өс-башым әйбәт түгел бит, — дим.

— Өс-башыңны да карарбыз, — ди бай. — Бер авыл кешесе — бер кардәш кебек. Бу авыр заманда бер-береңә ярдәм кулы сузмау гөнаһ булыр. Әйдә, элек өстәл янына утыр, сүземне тыңла, — дип, кулымнан җитәкләп табын янына китерде.

Тамагым ач ие, түзә алмадым, ризыкларын ашыгып-ашыгып бер-ике каптым. Ә үзем:

— Мөстәкыйм абый, дим, зинһар, бер-ике сыныгын балама гына алып кайтыймчы, балам тук булса, мин тук, — дим.

— Ник сорап торасың аны, бер-ике сынык кына түгел, мә, бөтенесен ал, — дип, өстәлдәге барча ризыкны ашъяулыгына төреп бирде бу.

Ә мин рәхмәтләр әйтеп кайтырга ашыктым.

— Кичләтеп кил, мин сиңа дүрт-биш кадак он биреп җибәрермен,— дип калды.

Кайтып життем. Сабыем нишләргә белми: әле ит калҗасына тотына, әле гөбәдияне кабып карый... Сөенечтәндер инде, үзе әллә ниткән сәер тавышлар чыгара. Ә күзләрендә яшь бөртекләре... Түзмәдем, почмакка сыендым да үксеп елап җибәрдем. Сабыем моны үзенчә аңлаган:

— Елама, әнием, сиңа да калды, күп калды, — ди.

Ә мин аның саен елый бирәм. Тамагы туйгач, бала урамга чыгып китте. Бишташ уйнарга һәвәс ие ул.

Мин өйдә үзем генә калдым. «Бала шул, бала, — дим эчемнән, — бүген тамагы туйгач, дөньясы түгәрәкләнде мескеннең. Иртәгә нишләрбез? Алгы көннәрдә ничек яшәрбез? — дип баш ватам. — Мөстәкыйм дүрт-биш кадак бирәм, диде дә бит... Бирәм дигәч, сүзендә торыр аңысы. Тик ни өчен тиктомалга юмартланды әле ул?»

Кич булгач, курка-курка бай катына киттем. Көткән икән, капка төбендә үк каршы алды мине.

— Килеп яхшы иткәнсең, — ди. — Әйдә, мин сиңа дигәнне әзерләп куйдым, — ди.

Аның артыннан кереп киттем. Бакча ягыннан бер амбарга алып килде бу. Чылтыратып йозагын ачты да, без амбарга кердек...

— Мәңә, — ди Мөстәкыйм. — Сиңа он, ә менә монысы миннән бүләк..*

Шулай дия-дия, ул миңа әйберләр төрелгән төргәк тоттыра.

— Кирәкми, Мөстәкыйм абый, — мин әйтәм, — биргән ризыкларың өчен дә рәхмәт яусын. Әҗәткә булыр, түләми калмам, — дим.

— Нинди түләү, — ди, — ал, ал, Сәгадәт, барысын ал. Мин бит сине үз итеп, яратып. — Шулай дип, ул миңа сузыла башламасынмы. Йөрәгем алынды.

— Нишлисең, Мөстәкыйм абый? — дип, читкә атылуымны үзем дә сизми калдым. Ә ул тәмам шашынган. Артымнан чабып чыкты да, мине кочмакчы була, ә үзе бертуктаусыз колак төбемдә пышылдый:

— Берүк тавышланма, гөнаһсыз кыз түгелсең лә, нигә карышасың? Күптән күз атып йөрим үзеңә, җаным, җаен гына туры китерә алганым юк ие! — ди.

Ә мин тартылам-йолкынам, көч тә икән үземдә, мир үгеземени, җибәрми генә бит!

— Җүләр булма, — ди бу, — мин сиңа тагын бирермен, капчыгы белән бирермен! Әнә бүген үк алып китәрсең.

— Их! — дип, бар куәтемә йолкынганием, күлмәгем шатырдап аерылып та китте, мин Мөстәкыйм кулыннан ычкынып капкага ташландым. Ул, башы беткере, капкасын бикләп кергән, имеш. Тотынды этләре өрергә. Өскә үк ыргыла. Менә-менә өзгәләп ташлар төсле.

Мөстәкыйм килеп житте.

— Ярар, мәйлең, — ди бу, — алай бик кырку икәнсең, ят шунда үлән суы суырып... — Капканы ачып мине чыгарып җибәрде. Ә үзе артымнан: — Акылыңа килсәң, шулай кичләтеп килеп чык, — дип авызын ера. — Тик аң бул, хатын өйдә чакта юлыкма!

Ачуымнан, гарьлегемнән битенә төкердем дә, өйгә йөгердем. Кайтып кердем. Галимем бусагадан атлавыма зур зәңгәр күзләрен миңа текәде. Тел белән берни дә сорамый. Ә карашында өмет. Йөрәк бәгыренә үтәрлек. Баламны кочакладым да, тагы үксеп-үксеп еладым.

— Елама, әнием, — ди мескенем. — Мин ашарга сорамыйм ич.

— Түз, балам, түз, хәзер ашарга пешерәм, — дип юаткан булам үзен.

— Коймак пешерәсеңме, әнием?

— Ие, коймак, үскәнем.

Алабута уып пешергән коймакны бала авызына да алмады. Икенче көнне дә, аның алгысында да. Үзе тагын да суырылды. Кабыргалары бүлтәеп тора, аяклары неп-нечкә. Битләре шеш кенә. Кайчандыр кың-

гырау чәчәгедәй балкып янган күзләре эчкә баткан, чигә янында зәп-зәңгәр тамырлар.

Көчкә сөйрәлеп, түр сәкегә үрмәләп менә дә, аякларын аркылы-торкылы чалмаштырып утыра бирә. Ә соңгы көннәрдә сәкегә дә менә алмас булды.

— Урамга чыгар иең, улым.

— Урамда салкын, туңам мин.

Җәйге эссе бит кана. Икмәк сорап та борчымый, урынга ята да, моңсуланып калган күз карашын мин кая барсам, шул якка йөртә.

— Ашап багар иең, улым.

— Ашыйсым килми, әни.

— Эчәсең дә килмиме?

— Юк.

Бигрәк таралып төште бала. Ә мин елыйм.

— Елама, әнием, мин сине борчымам, менә шулай карап кына ятармын! — ди бала.

— Улым, бәгърем!

Юк, түзәр чамам юк!..

— Син шулай ятып кына тор. Мин хәзер кайтам...

Җаны бөтен барлыгы белән карышып чәбәләнгән, тәне чиркаnып тартышкан эшкә бара әнием... Аяклар атларга теләми. Бертуктаусыз сөртенәм. Күз алдымда Мөстәкыймнең үз-үзеннән бик тә канәгать йөзе пәйда була.

«Юк, юк!»

Капыл борылам да, кире өйгә атлыйм. Ә анда нарасыем бит. Сәләмә чүпрәкләргә сеңеп ятучы күз нурым! Тәнендәге тиресе сөякләр өстеннән тартып куйган юп-юка карынчыктай. Үзе сары, үзе салкын... Кайтам. Ләкин сабыемның тилмереп миннән нәрсә булса да өмет иткән күзләренә ничек карармын?

Гаҗизләнеп ике кулым белән чәчләремә ябышам: «Ах, нишлим соң, нишлим?! Бүтән бер генә дә чара юкмыни?.. «Каяндыр өстән коточкыч аваз килгәндәй була: «Юк шул, юк, юк, юк!!!»

Гүя ачлыктан юлда үлеп калган шыр сөяктәй кешеләр күккә иңгән дә, дөньяны иңрәтеп аваз сала: «Юк, юк, юк!»

Аңыма килеп тузгыган чәчләремне, яулыгымны рәтлим дә, үз-үземне көч-хәл белән җиңеп, тәвәккәлләгән сукмагыма тагын борылам. Үзем дерелдим, тешем тешкә бәрелә. Бу — чиксез чирканудан.

Ләкин баламны үлемнең салкын тырнагыннан коткару өчен мин барысына да барам!.. Сабыема булган мәхәббәт Мөстәкыймгә карата туган нәфрәттән көчлерәк! Шуңа үз-үзем белән тартышам...

Уемнан кире кайтканчы ашыгырга кирәк, ашыгырга! Йодрыкларым белән капкаларына ябырылам. Этләр дөнья кубара. Аяк тавышлары...

— Килдеңме, җаным?

— Юк, юк,— дим, ни әйткәнемә хисап бирмичә.— Узып кына барышым...

— Узып кына түгел инде. Син акыллы хатын ич. Әйдә, каралты ягыннан гына...

Ник мин элекке килүемдәге шикелле йолкынмыйм, ник аңа буйсынып, язмышым упкынына шуам соң? Ни булды миңа? Ә, әйе, ул... сабыем үлем алдында... Бары шулай гына аны коткарырга була...

... Ләкин улымны коткарырга соң иде инде. Мин кайтып кергәндә йөрәк бәгырем мәңгегә күзен йомган иде. Мин үз-үземне белештерми аңа ташландым:

— Улым!

Улымны җирләгәч, каберенә башымны куйдым да тынсыз калдым. Хәзер миңа йорты да, шул йортка коточкыч хурлык бәрабәренә килеп

кунаклаган бер капчык оны да кирәкми. Мин үзем дә кемгә кирәк соң хәзер? Кемгә?!

Күз алдымны томан пәрдәсе каплады, аңым томаланды. Зираттан чыккач, кая таба киткәнмен, үзем дә белмим. Бар теләгем — бу дөньядан югалу, туфракка әйләнү. Шул теләк белән агым суга кереп киттем. Тик үзем чыкканмынмы, мине кемнәрдер сөйрәп чыгарганмы — аңымда юк. Тимер дагалы ат тояклары астына ташландым, ул хайван да таптап үтмәде. Ул синең сары бия иде.

... Сәгадәт сөйләп бетергәч тә инде кызыллыгын җуеп соргылт төскә керә барган шәфәкъ ягына карап торды. Ул Җамалига бер мәртәбә дә борылып бакмады. Чөнки инде әйтеләсе әйтелгән, сөйләнәсе сөйләнгән.

— Хуш, Җамали...

— Сәгадәт...

Сәгадәт, һаман шулай үзалдына караган килеш, урыныннан купты һәм, акрын гына атлап, кичке эңгергә кереп эреде.



## 7

Шул көннән соң Җамали сәер бер хәлдә калды: әйтерсең бөтен барлыгы шыксыз кисәкләргә аерылган да, пыскып әрнеп, күгелҗем сөрем белән өретелгән бушлыкта асылынып тора. Шул кисәкләрнең талымсыз төшендә Сәгадәткә булган хис әле дә баш калкытып куя, хәтта сузаеп каядыр өскә үрләмәкче: «Ул вөҗданлы, игелекле... Хатын-кыз нарасые хакына нигә бармас...» Ләкин шунда ук ирлек горурлыгы үрсәләнеп чыга һәм тупас төстә әлеге нечкәрәк, изгерәк хисне таптап, изеп үтә: «Ни әйтсәң дә ул сиңа тиң түгел...»

Җамали бу соңгысын акылы белән куәтләргә тырыша: «Хатын кешегә бәйләнмәсәң соң... Кызлар беткәнме сиңа?..»

Әлеге талымсызы егетнең мондый ниятенә каршы күсәк күтәрә: «Алай дияргә иртә әле. Сабыр төбе сары алтын».

Сары алтын икән, сары алтын. Онытылыр өчен көннәр буе йорт эшендә кайнаша, күрше-күләнгә чана ясый, көянтә бөгә Җамали. Ә кичләрен күзенә тәмам йокы эленгәнче чабата үрә.

Соңгы көннәрдә аны колхозга язылырга димлиләр. Белгән юк, нишләсе? Анда кереп югалтасы нәрсәсе юк та. Сары биясе, теге чакны апаларына калдырып торган сыеры бар барын, тик инде бик картайганнар, үзләрен көч-хәл белән сөйрәп йөртәләр. Ә шулай да киңәшминитми генә мондый эшкә бару ярамастыр. Ләкин кем белән киңәшергә? Минай беләнме? Аның сүзенә ышануы да кыен. Бөтен дөньясына каш җыерган ул хәзер. Сәгадәтнең ни әйтере билгеле инде. Өстәвенә, шаркылдап көләр үзеннән, һаман йокылы-уяулы йөрисең икән дияр. Ник сораганыңа үкенерсең. Иң яхшысы — ашыкмаска кирәк. Ашыккан ашка пешәр...

Ләкин Җамали ашыкмаса да, дөнья ашыкты. Дөньяның умарта иледәй гөжләгән, кайнаган чагы иде шул.

Бер көнне аның янына авыл советы председателе Исмай килде. Әле бер ел элек кенә солдаттан кайтып советка җитәкчелек итә башлаган кызгылт чырайлы, куе кара чәчле бу егет, керә-керешкә калку маңгае белән тулы битләре арасына урнашкан чем-кара күзләрен җелтерәтеп, өй эчен күздән кичерде. Ә үзе калын иреннәрен суза төшеп:

— Йорт тузып бара икән, тузып... — дип куйды. Аннары өйнең читчатларын, түшәмнәрен карап йөргәннән соң сәке читенә барып утырды да, Җамалиның күз карашы белән очрашырга теләмәгәндәй, әледәнәле тәрәзәгә күз салгалап, колхоз хакында сөйләп китте.

«Һаман шул ук Исмай, — дип уйлады аның турында Җамали. — Бер җире дә үзгәрмәгән: тартык, юаш. Бу эшенә нәләшмәгәне дә күренеп тора: тотлыга-тотлыга сөйли, сүзен көтеп ала-ала тәкатең калмый...»

— Бө-бөтен авыл к-колхоз булып яшәп ятканда, көтүдән аерылган м-малдай берүзең аерылып калмассың, яшьти, — ди Исмай, һаман шулай тәрәзәгә караган килеш. Ә үзе дәү, кытыршы кулларын кая куярга белмичә аптырый.

Аннан ул авыр гына урыныннан тора да:

— Ярый, хуш иттек әлегә, — дип чайкала-чайкала ишеккә таба атлый. Тик ишектән чыгар алдыннан янә Җамалига борылып, — Ә син уйла, яшьти, уйла. — Юкса, колхозга кермәүчеләргә налог зур булачак. Сары бияңнән генә түгел, сыерыңнан ук колак какмагаең.

— Нәрсә?!

Җамали сәке өстеннән кубарылып сикереп торганын үзе дә сизми калды. Атылып чыгып Исмайның якасыннан эләктереп үк алды:

— Нәрсә диден? Сыерны да, атны да диденме? Бу үзеңчә мине өркетүеңме, ә?!

Исмай каушамады. Дәү куллары белән ашыкмыйча гына Җамалиның кыскычтай бармакларын якасыннан ычкындырды да, сабыр гына:

— Сине өркетеп ни мәгънә? Аң булып тор. Соңыннан үпкәләштән булмасын диюем,— дип әйтеп куйды.

Ул шулай диде дә, авыр-авыр атлап, өйалды баскычыннан төшеп китте.

Җамали ни дияргә белми авызын ачып калды.

«Менә сиңа юаш Исмай! Атыңнан да, сыерыңнан да колак кагуың бар, янәсе. Ул хайваннарны Җәмилә апаларымнан алып кайтып ашыктым бугай, ашыктым, — дип уйлады Җамали өйгә керешли. — Хәер, анда калдырып та ни кырасың. Тәртибе бөтен җирдә бер үктер инде».

Җамали читлеккә эләккән ерткыч җәнлектәй ишекле-түрле йөрергә тотынды.

«Нишләргә соң, нишләргә?» Алай да вай, болай да вай. Идән сайгакларын никадәр генә таптамасын, берәр юньле нәрсә уйлап тапмады Җамали. Аннары ат аранынннан сары бияне ишегалдына алып чыкты. Иярләде. Һәм, атланып, Үтәмешнең карлы юлы буйлап кырга чыгып китте. Ата-бабадан килгән имана җиренә җиткәч, атын туктатты. Йөгәненнән тоткан килеш иярдән сикереп төшеп, ызан буена килде. Ни өчендер, ызан баганасын селкетеп карады. Аягы белән типкәләп, бер карыш җирне кардан чистартып азапланды.

Җамали үзен белә башлаганнан бирле һәр карышына тикле таныш бу җирнең тиздән кулдан ычкынасын, Кирәмәт ягыннан ук чекерәеп күренгән ызан баганасын суырып ыргытачакларын башына китергәч, бөтен тәне чемердәп китте, күңеле тулды.

Атына атланып кайтыр юлга чыккач, моңарчы сигез ел буена ничек итеп туган йортыннан читтә, шушы сары биядән ничәмә-ничә еллар үз кулында үскән карт сыерыннан башка яши алуына соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп, үзен-үзе битәрләп барды. Туган ягыңны, газиз анаңны, малтуарыңны күрми тора алырлык нинди исәрлек кагылган иде икән Җамалига? Бары да шушы Сәгадәт аркасындамы? Әллә шул тиле уйлардан кеше авышып та китә микәнни? Менә хәзер Җамали бу җүләрлекне һич тә эшли алмас иде.

Атын яңадан эчке аранга ябып куйгач, шундый ук йөрәк ташуы, шундый ук сизгерлек белән ул читән буенда кар ялап торган карт сыерга моңаеп карап торды. Сарайдан печән алып чыгып үз кулыннан аны ашата башлады. Сыер сәерсенгәндәй Җамалига зур, коңгырт күзләрен төбәде. Гүя: «Бер дә булмаганны нидән болай нечкәрдең әле, хуҗам?» дия иде кебек хайванның бу карашы. Нечкәрерсең, күз ка-

расыдай карап үстергән ат-сыерыннан колак кагып кара әле. Төрле кеше төрлечә сөйли үзе... Кайсы әйтә: атларны гына берләштерәләр, сыерларга тимиләр, дигән була. Ә кайсы берсе сыерын да, сарыгын да бергә җыячаклар икән ди. Җитмәсә, Исмае да әнә ни ди бит... Тукта, Минай абзый белән киңәшеп карарга кирәк. Ул мал-туар белән эвеш-тәвеш килгән кеше. Менә ул берәр җаен тапмый калмый инде.

... Минай бу юлы Җамалины әллә ни колачын җәеп каршы алмады. Үзенең дә кәефсез чагы иде, ахры.

— Әй, Җамали энекәем, син дә миңа килеп егыласың, нчмасам... Үзем кая керергә тишек тапмый җәфаланган чакта. Ни киңәш бирим соң мин сиңа? Атың ярый әле синең, шаять анысына урын табарбыз. Ә бу карт сыерыңны... белмим инде, белмим. Түбән авыл базарына чыгарып карасаң да... Бәлки берәр тилесе табылып алып куймасмы? Үзең беләсең, заманасы ышанычсыз аның, заманасы.

Иртәгесен аллага тапшырып Җамали атын җикте дә арба артына сыерны бау белән бәйләп юлга чыкты.

Түбән авыл башына ук җыйналган базар гөр килә.

Җамали, юкә чыпталардан ясалган, корымланып беткән күмер каплары төялгән йөкләр яныннан әйләнеп үтеп, терлекләр бакырышкан якка таба атын әйдәде.

Атның чөелдереген бушайтып, тәртәдән чишеп алган тезгенне дуга мөлдергәсенә бәйләп маташканда, Уразмәтнең Түбән авылга чыга торган башында яшәүче Хәсән агай килеп чыкты.

— Нихәл, Җамали, сыерыңны сатарга булдыңмыни?

— Шулайрак, Хәсән абзый...

Хәсән агай сыерны әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан караштырды:

— Сыерың болай ару гына күренә түгелме соң?..

Хәсән агай беренчеләрдән булып колхозга кергән иде. Үзе шикелле акрын кыймылдый торган алашасын көзлектә үк колхозга тапшырды... Менә хәзер сыерга тиенергә йөри икән. Анысын да колхозга алырлар дип шикләнми микәнни?..

Җамали базарда сыерын сата алмады. Шул көннән соң миен сорау арты сорау бораулады: «Инде бу сыер белән нишләргә? Кая куярга аны? Имеш-мимеш юкка булмас — колхозга алырлар да куярлар. Шул тикле олы малдан колак каксаң ни хәл итәрсең...»

«Әгәр суеп, итен калага илтеп сатсаң?»

Бу уйдан Җамали үзе дә калтыранып куйды. Дистәләгән еллар сине сөт-май белән сыйлаган, әле дә чиләк тутырып сөт саудырган сыерны ничек суймак кирәк?

Җамалиның шушы яшенә җитеп мал суйганы юк иде. Үз хайваннарын суйганда янында да тормый иде ул. Бары суючы эшен бетергәч кенә тунашырга дип чыга торган иде...

Ләкин бу тикле олы малны югалтсаң... Мең тапкыр тиле буларсың... Тавыклар көләр үзеңнән... Тәвәккәлләргә кирәк, тәвәккәлләргә...

Җамали өйдән пычак алып чыкты. Өйалды баскычына утырды да, күкрәгендә сыкраган еламсырауны басарга тырышып, елтырап торган пычагын кайрарга тотынды...

Пычакны үткерләгәч, аякларын көчкә сөйрәп, сарайдан сүс бау эзләп тапты, озак кына аны аралап маташты... Ләкин вакыт үткән саен Җамалиның күкрәгендә урнашкан еламсырау, инде ничә еллар иләшеп беткән сыерны кызгану хисе җыйнала бирөп бугазына ук елышты...

Шулай да ул йөрәген үксеткән мескенлекне ярсып куа-куа кискен һәм тупас хәрәкәт белән сыерның арт аякларын бау белән уратып бергә җыеп китерде, аннары хайванның ал аякларына ташланды, бау элмәге бөҗра булып бергә тоташты... кысылды...

Җамали бауның башын тартып бар көченә читкә тайпылуга сыер гөрселдәп җиргә ауды. Каты төшү сәбәпле, сыерның имчәкләреннән сөт сиптереп чыкты.

## 8

Җамали йокысыннан торып тышка чыкканда, тирә-юньгә таң алдыннан гына була торган куе караңгылык сыенган иде.

Ул ашыкмый гына ат аранына кереп, сары бияне җитәкли чыкты. Сыер итен төяп калага алып барып сатканнан бирле бия ике көн инде араннан чыкмый ял итте. Эшсез тик яту хайванны шактый зарыктырган, күрәсең, ул иреккә таба бик теләп атлады. Ишегалдына чыгу белән тәнен дерелдәтеп кагынгандай итте, борын тишекләрен киңәйтеп пошкырып куйды. Алда үзен ни көткәнен сизми иде хайван.

Җамали башта капкадан чыгып урам тынлыгына колак салды. Кайдадыр авыл башында елап-елап өргән эт тавышыннан гайре өн ишетелми иде... Җамали тынычланып яңадан ишегалдына керде, сарайдан ияр алып чыгып бияне иярләде дә, йөгәненнән җитәкләп урамга алып чыкты. Тагы бер мәл урамга текәлеп карап торды. Анда-санда тәрәзәләрдән төшкән сиек күләгәләрдән башка бернинди зат күренмәвенә тәмам инангач кына, ул атына атланып боламыкка әйләнгән карлы юл буйлата авылның мари ягына чыга торган башына таба атлатып китте.

Әйе, мари ягына илтеп, сары бияне «урнаштырып» кайту иде исәбе Җамалиның. Кичтән үк бу хакта Минай белән сөйләшеп тә куйган иде. Анысы алдан барып шул авылда Җамалины көтеп торырга тиеш.

Авылдан чыкканда, төн карасын ертып таң яктысы туып килә иде. Әнә элек Минайныкы булып, хәзер колхозга күчкән ат абзарлары да караеп күренә. Юл шул абзарлар яныннан үтәсе.

«Чү, абзарлар яныннан ике шәүлә калыкты түгелме? Кем йөрер бу вакытта атлар абзарында?.. Кем?.. Бирегә таба киләләр бит... Нишләргә соң?.. Юлдан түбәнрәк шәрәләнеп утырган каеннар ышыгында посып калсаң гына инде...»

Җамали шулай итте дә... Мамыктай тирән карны ерып, каеннар куелыгына керде дә үзе аттан төште.

«Узып китә генә күрсеннәр...»

Бу ике шәүлә Сәгадәт белән Исмай булып чыкты. Таң тишегеннән ат абзарларын тикшереп йөриләр иде, күрәсең.

«Узып кына китә күрсеннәр...»

Җамали, тездән карга баткан килеш, бөтен гәүдәсе белән биягә сыенды. Сулаудан да туктаган кебек булды. Гөнаһ шомлыгына каршы, Сәгадәт белән Исмай үзләре яныннан узып барганда гына айгыр пошкырып куймасынмы?!

Тегеләр шып туктады.

— Кем ул анда?

— Мин лә.

— Ә, Җамали? Нишләп йөрисең таң беленер-беленмәстән?

— И-и, ни бит...

Җамали ык-мык итеп торганчы, Сәгадәт Җамалиның бу иртәнге сәфәрен үзенчә юрарга өлгерде:

— Сары бияне колхозга илтәсеңме әллә, Җамали?

— Ни... колхозга дип...

Эчтән генә: «Менә каптым», — дип куйды Җамали. Аның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. «Тотыгыз мине!» — дип кычкырасы килде аның. Исмай үзе генә булса, шулай иткән дә булыр иде. Монда Сәгадәт тә бар бит, һәр күргәндә, йөрәген утка салып, үзен телсез-авызсыз калдыра торган Сәгадәт...

— Дөрес эшләгәнсең, Җамали, кеше-кара кузгалганчы дигәнсеңдер инде, — диде шул ара Сәгадәт, Җамалига авыз ачарга да бирмичә, — әйдә, әйдә, без дә илтешәбез атыңны.

Җамали: «Әллә бер сүз дә әйтмичә биягә атланырга да томырылып чабып китәргәме?» — дип тә уйлады. Ләкин ни өчендер ул моны да эшли алмады. Җиргә кагып куйган казыктай, тик басып торды.

Ә Сәгадәт инде, сары бия янына килеп, аның ялларын сыйпый-иркәли башлады:

— Әйдә, малкай, әйдә. Синдәй малкайлар колхозга бик кирәк хәзер.

Атның ялын сыйпаганда, хатынның кайнар кулы Җамалиның битенә тиеп-тиеп китә иде. Рәхәт дулкын егетнең бөтен тәненә таралып, җанын парә-парә итте.

— Әйдә, малкай...

Җамалиның каршы сүз әйтерлек дәрманы юк. Томанда йөзгәндәй, ул иң арттан сөйрәлә бирә. Вакыт-вакыт атның алдына чыгып, аны тезгененнән тартып аласы, җан ачысы белән йолкып кирегә алып китәсе килсә дә, бу нияте тагы эреп юкка чыга. Хәтта хәзер атын Сәгадәт җитәкләп колхоз абзарына илтүе, бу хәл шушы хатынга канәгатьлек китерүе Җамали өчен дә сәер рәхәтлек бирә, һәм ул ат турында бөтенләй онытып, Сәгадәтнең нечкә билле бишмәте аркылы беленеп торган сыгылмалы гәүдәсенә карап бара башлый.

... Буранлы төннәрнең берсендә Җамали Минай картның чираттагы зарын тыңлап, ул «ах» дигәндә «вах» дип утырганнан соң өенә кайтырга чыккан иде. Бермәлне каяндыр буран эченнән ялварулы хатын-кыз авазы колагына чалынып китмәсенме. Җамали бар игътибарын шул тавыш килгән якка юнәлтте.

Кинәт ерак та түгел: «Коткарыгыз!» дигән ачы тавыш колакны ярып керде.

«Сәгадәт бит бу!»

Ул шулай дип уйларга өлгермәде, янәшәдәге юлдан ыргылып чаналы ат килгәне, кемнеңдер ярсып-ярсып атны камчылавы ишетелде. Җамалиның бәгырен коточкыч уй телде. Шушы минутта ук ул нидер эшләмәсә, иң кадерле, иң изге кешесен мәңгегә югалтачак! Күп уйлап торырга вакыт тар иде. Җамали, тез тиңентен карга бата-бата, ат каршысына йөгерде. Юлга килеп тә чыкты, ярсып чапкан атның авызлыгыннан эләктереп тә алды.

— Тррр!..

Ат шашынып башын өскә чөйде, ләкин килгән куәт белән алга ыргылуын дәвам итте.

— Тррр!..

— Җибәр атны яхшы чакта! Тфү...

— Әһә, син икәнсең, Мәләк!

— Җибәр!

Һәм Мәләк ярсып атны камчыларга тотынды. Җамали бар үҗәтлеген җыеп, тезгенне учына чытырдатып кысты. Ә ат, мескен, нишләргә белмичә пошкырды, тыпырчынды, бер яктан икенче якка тайпылды. Шул чакны Җамали кискен хәрәкәт белән тезгенне сул якка тартты. Ат юлдан чыгып тездән карга кереп батты.

— Җибәр атны!

— Хәзер җибәрәм мин сине!

Җамали чана янына атылып килде дә, Мәләкне толыпка төреп салынган Сәгадәт өстеннән йолкып төшерде. Ул сүгенә-сүгенә Мәләк өстенә яңадан ыргылганда, Сәгадәт толыптан араланып чыкты да, Мәләкне йодрыгы белән төяргә тотынды.

— Мә, мә!.. Хатын кирәк булган икән! Шәкүр урлаган мал түгел мин сиңа!

Җамали да айканып торып Мәләккә бер-икене тамызмакчы иде, ләкин һәр вакыт язмышны алдыйм дип нидер кырырга маташкан, тик һәр очракта үзе чалкан әйләнеп төшкән бу кешегә карата капыл гына аның күңелендә аңлаешсыз кызгану хисе уянды. Һәм сугарга дип күтәрелгән кулын кире төшерде.

Шул ара Мәләк көч-хәл белән Җамали һәм Сәгадәт арасыннан үрмәләп чыкты да бөтен әрсезлеге, үҗәтлеге белән Җамалига ябышты.

— Син... син...Ниемә дип миңа аркылы төшәсең, ә? Ниемә, тфү, тфү?

Җамалиның бишмәт якасы чытырдап китте.

— Яканы!.. — дип хырылдады Җамали, Мәләкнең кыскычтай әләктереп алган кулын бар көченә каерырга тырышып.

— Каера алмассың! Тфү, тфү... Имансыз китим менә, каера алмассың!

Җамали, «Их!» дип бар куәтенә талпынып, Мәләкне читкә селтәп ыргытты. Һәм күз ачып йомганчы Сәгадәтне чанага тибәреп, үзе дә шунда сикереп менде.

— На!!

Мәләк кинәт алдырып киткән ат артыннан ташланды. Йөгергән уңайга ул да чанага сикермәкче иде, тик Җамали аны терсәге белән бәреп җибәрде. Мәләк, барыбер үҗәтләнә биреп, ялангач куллары белән чананың артына ябышырга өлгерде. Карлы юлдан сөйрәлеп барган көе, кулына чыбыркы сабы белән сугуга да карамыйча:

— Җук, ычкынмассыз! Имансыз китим менә! Тфү-тфү, — дип гыжлый иде.

Җамали, аның суыктан кызарынып беткән бармакларын көч белән каера-каера, атка чыбыркы белән сыдырткан иде, Мәләк карлы юлга түше белән ятып калды. Ләкин шунда ук сикереп торып, томырылып чапкан ат артыннан:

— Эләгерсең, агайне! Танытырмын мин сиңа Мәләкнең кем икәнен! — дип кычкырып калды.

— Бар, бар, таныта бир! — дип җавап кайтарды аңа Җамали.

Мәләк күздән югалгач, Сәгадәт:

— Мине шушы ат белән генә өемә озатсаң икән? — дип үтенде. Җамали кинәт кубарылып Сәгадәтне кочаклап алды һәм, үз-үзен белештермичә, аның кайнарланган битләреннән үбә башлады.

— Нишлисең, Җамали, акылыңа кил!

Җамали аны ишетмәде дә. Сәгадәт дилбегәгә ябышты:

— Туктат атны! Тр-тр-тр, тр-р-р!..

Ат туктап җитмәс борын Сәгадәт чанадан читкә сикерде.

Җамали, үз-үзен белештермичә, Сәгадәт янына атылып килде.

— Хатыным бул!.. Бүген үк, хәзер үк!

Сәгадәтнең кинәт тыны кысылды. Бөтен гәүдәсе эсселе-суыклы булып китте.

— Ничек шулай кинәт кенә? Җамали, чынлап әйтәсеңме моны?

— Чынлап, чынлап! Чын күңелемнән, Сәгадәт!

Ничә көннәр, көннәр генәме соң, ничәмә еллар үзен тыеп килгән йөрәк ташкыны берьюлы ташып чыкты. Әйтерсең озак вакытлар буе бөялеп торган буаны күк күкрәп, яшен яшьнәп килгән яңгыр ерып атты!

— Сәгадәтем!

— Җамали, соң мин бит...

— Барын да беләм, барысы да минеке, бары да минеке! — дип кычкырды Җамали акылыннан язган кешедәй. — Утыр, утыр атка! Тиз бул, җаным!

Сэгадэт тагы нидер әйтмәкче иде, Җамали аның бу сүзен томалап, ярым ачык иреннәренә үзенең кайнар иреннәре белән сарылды.

9

Җамали туй уздырырга булды. Сәгадәт: «Бу мәшәкатьле заманда ниткән туй ул», — дип карышып маташса да, ул аны ишетергә дә теләмәде.

— Зурдан купмыйча гына туйлап алырбыз. Заманча гына итеп.

Шулай дигән иде дә, ләкин ул уйлаганча гына барып чыкмады. Сәгадәтне алып кайткан көннең иртәгесен Мәләк жиккән атны Минайларга илтә төшкән иде, Минай, Җамалиның өйләнгәнен белгәч, ду купты:

— И, болай булгач, туйны бөтен Уразмәткә шаулатырлык итеп уздырабыз аны! Гомергә бер килә торган йоланы әвеш-тәвеш кенә уздырып җибәреп булмый, энекәем.

Җамали кашларын җыерды:

— Кирәкмәс иде, Минай абзый. Хәзерге кыен заманда кешедән дә яхшы түгел.

— Ниткән яхшы булмаган ди, сез кемнән ким? Берегез минем тугандай энекәем, икенчегез дәрәҗәле кеше — эктифтә йөрүче.

Җамалига Минайның бу сөйләнүләре бер дә ошамый иде. «Хәйләле карт шайтан, — дип, үзалдына уй йөртте ул, — тугандай энекәем, имеш. Дәрәҗәле, эктифтә йөри, имеш. Ай-һай, хәйләле, хәленнән килсә, әнә шул эктивта йөрүчесен тереләй ашар иде бит ул». Теле сөйләсә дә, Минай картның күз карашында әнә шул усаллык үзен сиздереп-сиздереп куя шул. Әнә теге Мәләкнең Минай аты белән Сәгадәтне урларга баруы да...

Җамали усал елмайды да, капыл гына Минайдан сорап куйды:

— Мәләкнең туен да шулай зурдан ясар идегезме, Минай абзый?

Минай бер дә көтмәгәндә бирелгән бу сораудан аптырап калды:

— Мәләкнең туен? Аның ни катнашы бар ди монда?

— Җук сиңа! Туй аныкы булырга тиеш иде лә...

— Ничек аныкы? Нәрсә сөйлисең син?

Җамали Минайга сынап карап торды. «Бу шайтан карт юри шулай белмәгән булып кыланамы, әллә, чынлап та, бу эштән хәбәрдар түгелме?»

— Шаярма, Минай абзый, соң Сәгадәтне урларга дип Мәләккә үзең иң яхшы атыңны биреп җибәргәнсең бит. Үзең җигеп йөри торганын.

— Атны?.. Кайчан? Әллә... Әллә Сәгадәтне Мәләк урлаганмы?

Минай Җамалиның каршына ук килеп басты. Яшькелт күзләрен челт-челт йомгалады. «Чынлап та белмиме? Әллә шул тикле дә оста итеп кәмит ясыймы карт?» — дип уйлады ул.

— Бик урлаган булыр иде дә...

Минай өстеннән тау төшкәндәй җиңел сулап куйды.

— Аллага шөкер икән, алайса, — диде ул, җинсез сырмасы өстеннән күкрәгенең сул ягын угалап. — Ай, куркыттың, егет, тәмам котымны алдың. Аллага шөкер икән, алайса. Мин үзем дә инде... Атны син алып килгәнне күрә торып... Зиһенем бөтенләй юк, энекәем, башым эшләми хәзер. Уф, тәмам хәлем китте.

Минай, чайкала-чайкала барып, чип-чиста итеп юылган ишегалды баскычына утырды.

— Беткәнмен мин, Җамали энекәем, тәмам эштән чыкканмын икән. Бер сүз дә ярамый хәзер йөрәккә. Син нәрсә дидең әле, теге койрыксыз шайтан Сәгадәткә кул салмакчы булган диденме? Ул башсыздан булыр

да. Үзе генә түгел, мине дә батырыр дене юк нәрсә. Болай да саламга тотынып яшәгәндә... Билләһи дип әйтәм, энекәем, минем бер гөнаһым да юк. Мин берни белмим. Ул, муены астына килгере, миңа сездерми генә атны алып чыккан инде алай булгач. Моның өчен мин әле аны! Тукта, монда түгел микән үзе?

Минай баскычка таянып, көч-хәл белән аягына басты да, бөкрәя төшеп, сарайларга таба китте.

— Әй, Мәләк, син мондамы? Мәләк, пычак кергере! Мәләк дим! Иблискә әйләнгән нәрсә!

Ләкин Мәләк күренмәде.

«Юкка гына картны рәнҗеттем, ахры, юкка...»

— Ярар, Минай абзый, кирәкмәс... Миннән башка гына акыл өйрәтерсең үзенә.

Минай шунда ук Җамалиның сүзе белән килеште:

— Ә, ие шул. Хәзер синең шул кайгымыни, ие. Туктап тор, мин хәзер чыгам. Китеп калма, бак аны. Хәзер.

Минай үзенчә бик кызулагандай, вак-вак атлап, өенә кереп китте.

«Нәрсә эшләргә инде, — дип уйга калды Җамали, — бу картны туйга чакырсаң, Сәгадәт ду кубачак, чакырмасаң, яхшы түгел.»

Шул ара ниндидер төргәк тотып Минай чыкты.

— Менә, энекәем, сиңа туй расходларына ярап куяр.

Җамали ике куллап каршы төште.

— Кит аннан, Минай абзый, булмаганны... Җук, җук!..

Минай Җамалига сүз әйтергә дә ирек бирмәде.

— Ал, ал, энекәем, алмасаң риза-бәхил түгел. Туганымдай энекәемә җәл түгел.

Шулай дия-дия, Минай төргәкне көчләп диярлек Җамалиның эчке кесәсенә тыкты.

— Менә шулай. Шундый чакта да бер-береңә булышмагач, кая китә ул. Мөселманлыгыңа оят булыр ие.

— Рәхмәт, Минай абзый, рәхмәт. Туй мәҗлесенә рәхим итегез, абыстай белән. Чакыруым шушы булыр.

— Барырбыз, алла боерса, бармый калмабыз.

Җамали, капкадан чыккач, кытыршы учы белән эчке кесәсендә кабарып торган тыгыз төргәкне яньчергә тырышты. Шулай итсәң, ул күкрәгеннән уңайсызлап, күңелен чуарлап торудан туктар кебек. Ләкин төргәк яньчелмәде. Һаман шулай бүлтәеп торды.

«Ни дип алдым соң әле ул акчаны? Ни дип алдым?»

Кайткач та Җамали туры өйгә кермәде, ярамаган эш эшләп тотылган малай шикелле, башын якасы эченә җыерып, тал-чыбыктан үреп ясалган читән лапаска таба китте.

Ә өй эче туйга хәзерлек ыгы-зыгысы белән тулган иде: кайсы арыш оныннан кабартма ясый, кайсы казан астына ут тергезеп аш пешерә. Монда Мәстүрә, Җамалиның апасы Җәмилә, күрше-күлән... Мәш киләләр.

Киләсе кешеләр әллә ни күп булмаячак. Шуңа күрә табынны сәке өстенә генә әмәлләделәр. Уртага кызыл эскәтер җәелде, чит-читләргә кунаклар утырыр өчен чуар корамалар салынды. Карт-коры сөялеп утырыр дип, ян-якка берничә мендәр дә куйдылар. Зур туй булса, ирләрне, хатыннарны аерым-аерым җыйган булырлар иде. Мәҗлес алай олыдан булмагач, хатыннар сәкенең бер ягында, ирләр икенче ягында утырасы.

Кичкә таба ризык-ашамлык пешкән-төшкән, табын әзерләнеп беткән иде. Берәм-сәрәм кунаклар да җыйнала башлады. Кунаклар дигәч тә, болар — Җамалиның күрше авылдагы туган-тумачалары, Сәгадәтнең таныш-белешләре...

Менә, хатынын ияртеп, авыл советы рәисе Исмай килеп керде. Кара пинжәк, ак күлмәк кигән, олы гәүдәле, кызыл чырайлы Исмай янында кечкенә буйлы, бик хәрәкәтчән хатыны әллә ничек кәлке күренә. Җитмәсә, Исмай берүзе килгән төсле:

— Соңардым дип торам... Чат вакытында килеп басканмын икән,— дип сөйләнеп куя. Аннары ул шау итеп сәкегә утырышкан кунаклар белән күрешеп чыга.

— Туйлар сөенечле булсын.

— Шулай язсын, амин.

Тышта тагы кыңгырау шалтыраган тавыш.

— Бу кем тагы кыңгыраулар челтерәтеп килә?

— Кыңгырау чыңламый туй буламы?

Җамали ашыгып кунакны каршыларга чыга. Бераздан ишектә өстенә билле постау бишмәт, башына каракүл бүрек кигән Минай, ә аның артыннан оренбур шәленә төренгән хатыны Бибикамал абыстай күренә.

Артларыннан ябырылып кергән суык һавада бермәл йөзләре төсмерләнми.

— Туйлар мөбарәк булсын!

Иреннәр эченнән кысылып чыккан берничә тавыш:

— Амин! — дип куя.

Минай абзый белән хатыны инде өсләрен салып кунаклар белән күрешергә дип кинәләр иде. Ләкин кешеләрнең күзләрендәге салкынлыкны күреп бермәлгә аптырап тордылар. Мәҗлес тынып калды. Керфекләр дерелдәп аска тәгәрәде. Исмай, бу нәрсә инде тагы, дигән сораулы караш белән Сәгадәткә борылды. Ә Сәгадәтнең йөзе җимерелгән, зур коңгырт күзләре аптыраудан һәм ачудан менә-менә атылып чыгып китәр төсле.

Ниһаять, Минай:

— Исәннәрмесез, кардәшләр? — дип кулын сузып исәнләшә башлады. Аның артыннан хатыны да иярде.

Кунакларның күбесе «шулай кирәктер, күрәсең» дигән шикелле, берни булмагандай, Минайга кул бирде. Ә Исмай, кайнар әйбергә кагылгандай, кулын тиз генә сузып алды да, кешеләргә бу ничегрәк тәэсир итте икән, дигән төсле күзләрен тирә-юньгә йөрткәләде.

Чират Сәгадәткә дә житеп килә иде. Ул, нишләргә хәзер миңа, нишләргә, дигән кебек баскан урыныннан кузгалып-кузгалып куйды. Аның бөтен җаны чиксез киеренкелектән катып калгандай. «Дошманым икәнен белә торып, Җамали нигә чакырган аларны? Шатлык бүләк итәсе көнне йөрәгеңә шулай пычак кадасын әле». Җамалига нык рәнҗеде Сәгадәт. Бу рәнҗү чиксез ачуга әйләнеп йөрәген әрнетте. Бөтен дөньясын ярып, ачы итеп кычкырасы, бу мохиттан юк буласы килде аның. Көч-хәл белән йөгәнләп тора иде ул үзенең бу ниятен, ләкин күпме чыдап торырга була? Шул Минайлар белән бер мәҗлестә ничек күңел ачып утырмак кирәк?

Минай менә хәзер Сәгадәт янына килеп күрешергә кулын бирәчәк. Менә хәзер...

Исмай шикелле бәлки Сәгадәт тә кулын тиз генә утка тыккандай сузып алыр?

Юк! Моны булдыра алмый Сәгадәт!

Ул кинәт урыныннан кубарылып ишеккә ташланды.

— Сәгадәт!

Җамали Сәгадәтнең йөзенә бәреп чыккан киеренке эчке көрәшне баядан бирле күзәтеп тора иде.

«Нәрсә була инде, нәрсә була?» — дип, күңел кыллары зыңлап-зыңлап куя иде аның.

Менә хәзер шул кыллар шартлап өзелгәндәй булды.

— Сәгадәт!

Аптыраудан шакмакланган күзләр, кайнарланган сүзләр ыргытырга дип ачылган иреннәр ишекнең эчке ягында калды. Алда — өерелеп яуган кар, капка төбеннән Мәстүрәләргә тикле көрткә күмелә язып сузылган сукмак. Һәм шул эздән бата-чума йөгерүче Сәгадәт.

— Сәгадәт, тукта!

— Килмә арттан Җамали, килмә!

Килмиме соң? Кар түгел, таш яуса да, сукмакны көрт түгел, дәрья күмсә дә киләчәк бүген Җамали. Шашынып-ташып киләчәк!

Менә ул ап-ак күлмәктән, ак йолдызчыклар арасындагы әкият егете сыман бөтерелеп килде дә, кайнарланып, ярсып, Сәгадәтне кочаклап алды.

— Сәгадәтем, нишләвең бу?

Сәгадәт карышмады. Нечкә, сыгылмалы гәүдәсе белән талпынып, егетнең кочагына сенде. Соң Җамалидан качмады лабаса ул. Икесе арасындагы кайнар рәхәтлекне киметергә, язмышларында билгесез төен төенләтерлек сәбәптән качты. Мондый чишелмәс төен беренче көннән үк йөрәккә шом салып бүлтәеп калмасын, алгы көннәре аңлаешлы, ачык булсын өчен качты. Шуңа да ул:

— Ни өчен инде шулай эшләдең, Җамали? — дип ачынып сорады. Бу сорауда Сәгадәткә генә хас мөлаемлык та, назлану да, рәнҗү дә бар иде.

Җамали үзе дә болай эшләмәскә теләгән иде ләбаса. Ни өчен, кача-поса, үзенең иң кадерле кешесенең күңеленә яра салды ул? Ни өчен?

Аңа Минай тәкъдим иткән акча аркасындамы? Шуның өчен микәнни? Шул чаклы да комсызмыни Җамали? Юк, бу гына түгелдер сәбәп Җамалины шул Минайларга бәйләп торган җепләр әле дә өзелеп бетмәгән, күрәсең. Бу бәйләнешне Минай үзе төрле юллар белән яңарта тора, әле акча тәкъдим итә, әле хәленә кергән булып киңәшләр бирә. Ә теге чакны, почта талангач, Минай булмаса, Җамали әллә кайчан төрмәдә черер иде бәлки... Шактый яхшылыклар эшләгән шул аңа Минай. Ә нинди начарлык эшләде соң ул аңа? Бер дә искә төшми. Шулай булгач, туй мәҗлесендә утырса ни зарары тияр иде икән? Әнә нинди зурлап бүләкләр алып килгән. Чын күңеленнән туйны котлады.

— Я, ник дәшмисең, Җамали?

— Әйдә, кире кайт, Сәгадәт, җыелган халыктан яхшы түгел, кайт син, тыңла сүземне!

Сәгадәт тыпырчынып Җамалиның кочагыннан тартыла башлады.

— Юк, Җамали, теләсә ни әйт, булдыра алмыйм.

— Соң шунда Минай абзый утырганнан гына ни була ди сиңа?

— Ни була? Болай булса, беркайчан да аңлашмабыз без. Җибәр мине!

— Җә инде, Сәгадәт, икенче чакырып җөрмәм, бүгенгә кайт инде.

— Юк, әйттем — бетте... Җибәр!

— Сәгадәт!

— Җибәр дим!

— Сәгадәт, шулай итеп, тагы юлларыбыз аерыламыни? Бу көннәрне ничә еллар көткән идем бит мин!

— Ә мин соң, мин... көтмәдеммени?! — Сәгадәт сулыгып елап җибәрде. — Аңласаң, минем гомерем ике өлештән тора бит, Җамали. Берсен мин ташлап киткән иием инде. Бетте, дип уйлаган идем. Син очрадың. Синең миңа, минем ярдәмгә мохтаҗ икәнеңне күргәч, үлә алмадым мин. Шуның белән син коткардың мине! Ничек якын итмим ди мин сине!!

Сәгадәт шушы сүзләрен, Җамалиның иңенә кайнар иреннәре белән орынган килеш, әрнеп-әрнеп әйтте. Бу сүзләр егетнең иңе аша рәхәт сулкылдап, йөрәгенә тикле барып җитә, тоташ эссе дулкын булып бар тәненә тарала иде. Җамали менә хәзер үзенең бөтен барлыгы газаплы да, әйтеп бетергесез сөенечле дә рәхәтлектән торганын тоеп, шул рәхәтлекне үзеннән җибәрмәскә теләп, тыелгысыз җан ташуы белән кайнарланып пышылдады:

— Соң шулай булгач... Караңгыламыйк алгы көнебезне, Сәгадәт. Ташлап китмә син мине. Нәрсә әйтсәң дә тыңлармын.

Сәгадәт Җамалига тынып карап торды. Ышаныргамы аңа, юкмы?

— Ярый, алайса, соңгы сүзем шул: хәзер җибәр мине, булмаслыкка кыстама. Ә иртәгә таңнан мин үзем синең янга килермен. Тик бер шарт белән: моннан соң Минай белән алыш-бирештән туктасаң.

Җамали бер мәлне Сәгадәтне кочагына кыскан килеш сүзсез торды. Тик бераздан гына күзләренә карап җавап көткән Сәгадәтнең битенә иреннәре белән орынды: «Ярый, Сәгадәт, синеңчә булсын».



## 10

Авылдан чыгып бөдрә каенлык янына җиттеңме, нарат-чыршы агачыннан салынган ат абзарына килеп юлыгасың.

Капкадай киң ишекләрне ачып җибәрүгә борынга печән һәм юеш тирес исе бәрелә. Элек-электән ат карап үскән Җамали өчен бу ис таныш. Алай гына да түгел — җанга рәхәт талгынлык бирә бу ис. Монда ул үзен өендәге кебек хис итә. Чөнки бу аның дөньясы. Атларның ашыкмый гына шытырт-шытырт итеп печән чәйнәве дә, мут итеп баш чайкап пошкырып куюы да якын, үз аңа. Яз якынлашкан көннәрне яшь айгыр купшы ялын чөя-чөя дәртләнеп кешнәп җибәргәндәй, Җамалиның йөрәге әллә нишләп китә. Өстәвенә, аның сары биясе дә монда бит. Килгән саен Җамали аның хәлен белмичә узмас. Аркасыннан сөяр, куе ялын тарап җибәрер. Мондый чакта сары бия борынын Җамалиның күкрәгенә төртеп тик торыр. Сагынуын басуыдыр хайванның. Җамали да сагына шул аны. Муеныннан кочаклап, ак кашка маңгаен сөя.

Атларга булган мәхәббәте яңадан бирегә китерде Җамалины. Бу юлы хуҗа булып. Атлар караучы хезмәтенә дип. Сәгадәт тә монда эшләсе... Ул көянтә белән су ташып, атларга болгатма ясап торачак. Әнә абзар бусагасында ул үзе түгелме соң? Сәгадәт шул. Килеп тә житкән. Иңендә — көянтә-чиләге.

Җамали аран ишегенә сөялгән дә хатынының төз аякларын матур итеп басып-басып килүеннән, иңендә тирбәлгән көянтә-чиләкләрдән күзен алмый. Ә Сәгадәт Җамалига күтәрелеп карый да, башын яңадан аска ия. Бит алмалары алсуланып китә.

Җамали Сәгадәтнең көянтәсенә асылынган чиләкләрне ычкындыра да, көмештәй суны атның улагына шаулатып сала.

— Хәзер, тагы китерәм, — ди Сәгадәт, күзләреннән түгелгән нурны керфекләре астына яшереп.

— Китерерсең, Сәгадәт, тик бераз ял итеп ал.

— Шулай бер-беребезгә карашып торыйкмы? Һәр көянтә судан соң шулай итәрбезме?

— Булса соң? Кичкә чаклы бер-беребезне сагынып җәфаланмас өчен бер төштә эшләргә булдык лабаса, Сәгадәт.

— Алай ук кирәкмәс. Үтә кызыл тиз уңа, диләр.

Җамали шаркылдап көлеп җибәрә:

— Тормыш булгач гел кызыл да булып тормассың. Кояшлы чакта кызарып калырга кирәк.

Сәгадәт үпкәләп иренен суза:

— Соңыннан каралырбыз да, диюеңме инде бу, Җамали?

Җамали Сәгадәтнең янына ук атылып килә:

— Син нәрсә, Сәгадәт, авызыңнан җил алсын!

Сәгадәт яңадан керфекләрен аска төшерә:

— Болай гына әйтүем...

Шулай башланып китте бу тормыш. Аларның мәхәббәте кайнар, дәртле иде. Әйтелгән сүзләренә караганда, әйтелмәгәне күбрәк калгандыр. Сөйләсе уйлар, канатланасы хыяллар йөрәктә ташып торып та, иреннәр аларны күңелгә ябып куйса, кешеләр бер-берсе өчен тагы да серлерәк була, шул сергә таба йөрәкләр көчлерәк тартыла икән. Хәер, көннәр елларга, еллар гасырларга торырлык бу чакта, бер-берең белән сокланышыр мизгелләр әллә нигә бер тигәндер. Шул бәхетле минутлар сирәк килгәнгә бик кадерле булгандыр бу ара.

Сәгадәт Җамалига чыккач та көндәлек тормыш мәшәкатьләренә кереп батмады, элеккечә, колхоз төзүчеләрнең башлап йөрүчесе, әйдәүчесе булып калды. Муеннан эш иде аның: колхоз атларын ашат-эчерт, кулаклар белән йөзгә-йөз бәрелешеп, күмәк тормыш өчен якалаш. Хатын-кыз башы белән ирләр иңе сыгылырлык хезмәткә җигелде Сәгадәт. Үзе теләп, намусы кушканча.

Буш арада Сәгадәт өй эшләрен карады, Җамали элеккечә көянтәләр бөкте, чаналар ясады. Күрше-күлән баласы чана, я көянтә өлгермәде микән дип белешергә керсә, Сәгадәт аны башта кысып-кысып яратыр, аннары үзе пешергән тәмле-тәмле ризык белән сыйлар. Ә үзе:

— Аша, үскәнем, аша, син тамак ялгап алганчы, Җамали абыең бәлки ясап та куяр, — дип сөйләнер.

Сәгадәт бала-чаганы үлеп ярата иде. Урамда уйнап йөргән балаларга карап тору аның иң ләззәтле, шул ук вакытта иң моңсу минутларыннан булгандыр.

Бигрәк тә күрше Фәсәхәт апаның кечкенә Габдулласына гашыйк иде Сәгадәт. Ул аны юлда очраткан саен сөеп-яратып кына калмый, җитәкләп, өйгә үк алып керә. Башта нинди тәмле ашамлык бар, шуның белән сыйлый, аннары Җамалидан:

— Кечкенә Габдуллага бүген дә сыбызгы ясап бирәсеңме? — дип сорый.

Ә тегесе каш астыннан хәйләкәр елмаеп:

— Җук, бүген Габдуллага суда йөзә торган бик әйбәт көймә ясыйбыз. Ясыйбызмы, Габдулла?

— Ясыйбыз.

— Мине утыртып йөрерсеңме соң?

— Утылтып дөлелмен.

Сәгадәт, билгеле, түзә алмый. Нәни Габдулланы кайнар кочагына ала да:

— Әйбәт егет булырсың, наный, — дип, аркасыннан шап-шап сөя.

Кайчакта Сәгадәт кара тутлы, уймактай гына авызлы бу малайга кибеттән бүләкләр алып кайта. Ә чәчәк төшерелгән кәләпүшне аңа ул үзе чиккән иде.

Малай урамда очраган берсенә шул кәләпүшне күрсәтеп:

— Тәгадәт апа тикте, — дип мактанып йөрде.

Сабыйлар игътибарга, иркә-назга үтә дә сизгер халык бит ул. Алар өчен һәрчак көләч чырай, юмарт күңел булгангадыр инде, бу йорт бер көнне дә бала-чагасыз тормады.

...Көннәр кыр казлары шикелле тезелешеп бер-бер артлы үтә торды. Ямансу моңнарын, ярсу күкрәүләрен ияртеп, яз да килеп җитте. Сусыл карны ерып, челтери-челтери гөрләвекләр тәгәрәде, олы яр, зәңгәр капкаларын шыр ачып, кодрәтле ташуны каршылады.

Беренче колхоз язы кергән көннәрдә кешеләрнең күңелләре дә олы ташу көткәндәй киеренке иде. Инде шактый эшләр кыйратылган: Уразмәтнең күпчелек халкы күмәк тормыш белән яши башлаган, сукатырмалар әзер, атлар, яз җитүен тоеп кырга ашкынгандай, йөрәкләрне җилкетерлек итеп нечкә тавыш белән кешнәп куялар.

Әйе, күмәк тормыш ташуы ярларыннан кузгалырга әзер кебек. Тик шул көннәрдә уразмәтлеләрнең бәгырьләрен хәнҗәр белән яралагандай хәл булды. Язгы чәчүгә дип амбарга җыеп куелган бодай орлыгы юкка чыкты. Авыл халкы — яше-карты — олы яр буендагы Минай амбарлары янына җыелган иде. Юан нарат агачыннан салынган, еллар җиле кагылудан зәңгәрсу төскә керә башлаган амбарлар үзләре дә ятим булып калган кебек. Исмай, Сәгадәт, тагы берничә кеше амбар ишекләренең берсеннән чыгып, икенчесенә кереп нәрсәдер тикшереп йөриләр. Чырайлары караңгы, кашлары җимерелгән.

Бала-чага чыр-чу килеп амбар астында үрмәләп йөри. Олылар да башларын тыгып аскы яктан амбар идәнен карыйлар. Җамали, иелеп-үрмәләп, амбар астына эчкә үк кереп китте. Амбар идәнен калын бораү белән берничә җирдән тишкәләгәннәр. Шул тишекләрдән җиргә аккан бодай бөртекләре әле дә сибелеп ята.

— Ай-һай, бөтен колхоз бодае шул тишекләрдән генә агып бетәр микән?

— Амбарга ачкыч ярятып шуннан капчыклап ташымадылар микән бодайны?

— Кем эше булырга мөмкин бу?

— Мәләкләр кулы уйнады микәнни?

— Ул үзе генә башкарып чыга алмас иде. Хәер, аның кешеләре азмыни.

— Күпме хәзинә юкка чыккан, ходаем!

— Шул чаклы малны ничек ташып бетермәк кирәк?

— Ну, бу Мәләкләрне!

— Тизрәк тотып алырга иде үзләрен!

— Мәләк, имеш... Тапканнар бөтен бәлане сыларга бер бәндә... Сыныкка сылтау гына ич бу!

— Тагы кем булсын?..

— И җаным, үзләре үк төнләтеп бирәр җиргә урнаштырганнардыр әле.

— Бөтен халыкны ач калдырдылар менә!

Кешеләр, шау-гөр килеп, Сәгадәт белән Исмай басып торган җиргә үк якынлаштылар:

— Кая куйдыгыз безнең икмәкне? Табып бирегез хәзер!

— Караклар бораулаган, имеш! Хәйлә дә бар үзләрендә...

— Инде ничек яшәмәк кирәк? Я безгә ачтан үләргә, я?..

Исмай зәхмәт телле бу хатынның сүзен бүлде:

— Я, нишләтмәкче буласың, апай?

— Чарасын табарбыз, нәнәм, ник туганыңа үкенерсең!

Сәгадәт сүзгә кушылды:

— Чарасын табарбыз, апа кеше. Тапмый калмабыз!

— Син безгә сары май каптырма, кызый. Ач корсакка күңелне болгатыр ул.

— Сүзеңне уйлап кына сөйлә, апа.

— Бик уйлап сөйлим. Син ул килмешәк башың белән безне төп башына утырттың. Син җыйдың безнең орлыкка дигән бодайны. Син! Менә бу Исмай белән икегез!

Исмайның да ачуы чыкты:

— Булса, үзебезгә дип җыйдык мәллә?

— Кемгә дип? Кая бодай, ә? Бодай кая дим мин сиңа!

Җитмеш яшьләрендәге ак сакаллы агай карлыккан тавышы белән бөтен урамга сөрән салып, йодрыгын айкый-айкый, Исмай өстенә килә башлады. Аңа тагы берничә кеше иярде.

— Тап дим бодайны, ату мин сине!

Исмай артка чигеп куйды. Ул шактый нык шүрләгән иде, ахры. Шул чакны Сәгадәт кискен тәвәккәллек белән башын өскә күтәрде дә, әлеге агай каршына атлады:

— Кыйнарга киләсеңме? Яле, сук миңа! Сук абзый, хатын-кызга көчең җитәдер!

Агайның гайрәте сүрелә төште:

— Ач калабыз бит, ач!

— Ач калмассыз, агайлар, — диде Сәгадәт, — бодай табылачак, һичшиксез табылачак. Миңа ышаныгыз, үзем өстемә алам!

— Ай-һай, булыр микән? Урлаганны, юллый белгәннәрдер.

Сәгадәт тагы да ышандырырлык тавыш белән әйтеп салды:

— Җир астына яшерсәләр дә, табарбыз!

Шул көннән башлап Сәгадәт башы-аягы белән орлыклык бодайны эзләү белән мәшгуль булды. Иртән таңнан чыгып китә, караңгы төшкәч кайтып керә. Үзе күзгә күренеп суырылды, ябыкты.

Монарчы Сәгадәтнең колхоз тирәсендәге эшләр белән гел кайнашып йөрүенә Җамали эчтән тынып булса да түзеп килә иде әле. Ә бу юлы:

— Сәгадәт, кайчанга чаклы көн дә чыгып югалырсың син, ә? — дия башлады.

Сәгадәт баштарак дәшмичә уздырса да, соңыннан әйтми булдыра алмады:

— Үзең күреп тордың, Җамали, мин кешеләргә сүз бирдем... Ә алар миңа ышандылар. Ышандылар, аңлыйсыңмы шуны?

Ләкин ышанып ук беттеләр микән? Сәгадәт бу кадәресен үзе дә белә алмый иде әле. Барыбер әйткән сүз — аткан ук, ди.

Тагы бер-ике көннән атларны ашатырга дип ат абзарына барганда, Җамали урамда Мәләкне очратты. Ул бер кулы белән билен тотып, бөкрәя төшеп атлый иде.

Моннан берничә ел элек мари авылыннан ат урлап кайтканда, ияләре куып җитеп, бик каты кыйнаганнар иде Мәләкне. Шуннан соң ул озак кына урында авырып ятты. Соңгы елларны шактый рәтләнеп, төз басып йөри башлаган иде. Хәтта аның турында Минайның әлеге уртанчы кызы Гөлбикә белән типтерә икән дигән сүзләр дә йөрде. Анысы булыр да, чөнки бу елларны Минайларның ярыйсы ук рәте китеп, алар белән юньле кеше аралашмый башлаган иде шул. Ә Мәләккә нәрсә, үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын. Ни әйтсәң дә, әле хәзер дә Минайлардан акмаса да, тама.

Җамали белән тигезләнгәч, Мәләк туктады. Бермәлгә яшькелт күзләрен челт-челт йомгалап, әйтәсе сүзләренең мәгънәсен үлчәп торды. Җамалиның үз янында туктап торырга исәбе юклыгын абайлагач, кулы белән ашыкмаска ишарә ясады:

— Сүзем бар.

— Нәрсә тагы?

— Синең белән, агайне, исәп-хисапны өзмәдек өзүен. Шулай да... тфү, тфү...

— Сүзенне үлчәп сөйлә!

— Үлчәп караганга әйтүем, теге озын чәчеңне каты аздырасың бугай. Ир башың белән тота белмисең, тфү!

— Ул нишләгән?

— Узына. Кичә сәкедә чирләп җата идем...

— Ат урлап җөрмиләр аны.

— Эш андамыни, тфү. Билем сызлауга тәкать тота алмый ыңгырашып жатканда, синең албастың керде дә, тор, урланган орлыкны ашереп жатасың, ди. Нинди орлык булсын, сәке астында каз басып жата, дим. Алдама дип, аягымнан сөйрәде дә төшерде. Билем сынды дип торам. Күрмәгәнен күрсәтә идем, тфү, тфү, жарый янында кешеләре булды.

— Шул гынамы?

— Тагы ни кирәк? Икәүләп каныктыгыз мина! Тфү... Кара аны!

Мәләк янаулы төс биреп башын селкеп куйды.

— Жанама! Күргән синең ишене...

— Кисәтеп куюым, тфү, тфү...

— Син кем соң ул чаклы?

— Менә сез таяктан кисәү булдыгыз, тфү. Яхшылыкны да белмисез, начарлыкны да!

Жамали кашын жыерды:

— Нинди яхшылык кылганың бар?

— Мин булмасам... Минай абзый күпме ашатты сине? Ә сез...

— Тагы ни булган?

— Ни булсын, хатының, орлыкны тап, син генә урлагансың, дип, картның да тенкәсенә тия икән. Болай да инде мескенне талап бетердегез. Тфү, тфү. Жә, ник авызыңа су каптың? Әйтер сүзең беттемени?

— Жулында бул, кияү, имеш.

— Ә шулаймы? Ә син игелекне оныткан нәрсә! Тфү, тфү.

Мәләк шулай диде дә, аксый-аксый китеп барды.

Жамалиның тәмам кәефе кырылды. Ул бу әдәмне сугып жибәрер хәлгә житкән иде. Ләкин аның соңгы сүзләре эчендә туып килгән дуамал ярсуны бүтән тарафка күчерде. Сәгадәтне күрергә дип, өй юсыгына борылды ул. Ләкин хатыны өйдә юк, ә баскыч төбендә аны Минай карт көтеп утыра иде.

— Исәнме, Минай абзый!

Минай баскычтан торырга дип кузгалды, ләкин күтәрелеп бетә алмады, яңадан утырды.

— Менә килеп чыктым әле. Үзең бөтенләй оныттың карт кешене. Санга да сугып бакмыйсың.

— Оныттың дип, эш күп, — дигән булды Жамали.

— Шулай инде, энекәем, зур эш кешеләре булып киттегез бит.

— Кая инде ул!

— Менә хатыныңнан зарланырга дип килдем әле, энекәем. Ул миннән әллә ниткән бодай таптыра. Бер каныксалар каныгалар бит аны. Бер аягым жирдә, икенчесе гүрдә бит минем. Нишләп бодай урлап йөрим ди.

Минай әллә ничек кызганыч итеп елап жибәрде. Аның күз яшьләре жыерчыклы битләре буйлап саркылып сакалына агып төште. Күз кабаклары тагы да сәлперәя төшеп кызарып чыкты.

Жамали бер сүз дәшмичә Минайга карап торды. Инде бөтенләй кечерәеп калган, таякка таянып кына йөргән бу хәлсез картны чын күңеленнән кызганды ул. Ә Минай моны сизде булса кирәк:

— Зинһар әйтче кәләшеңә, энекәем. Миңа бер нәрсәләре дә кирәк түгел. Бары тынычлап үләргә генә ирек бирсен, — дип шыңшыды.

Аннары Минай, таягына таянып, көч-хәл белән урыныннан күтәрелде.

— Шушы иде гозерем, энекәем. Чак кына мөселманлыгың калган булса, шул яхшылыкны гына булса да эшлә!

— Жарый, Минай абзый, сөйләшермен. Әйтми калмам.

Минай киткәч, Жамали аның артыннан ук диярлек чыгып ат абзарына таба юл тотты. Ул абзарга килеп кергәндә, Сәгадәт атларга көрпә белән салам болгатып ята иде. Жамали дәшми генә түрдәге аран-

нарга үтте. Шулай дәшми-тынмый тимер көрәге белән агач сайгактан ат тизәкләрен кырырга тотынды.

— Ни булды, Җамали?

— Берни дә булмады, — диде, Җамали тупас итеп. Һәм сайгакны тагы да үрсәләнеп кырырга ябышты.

Сәгадәт ире янына килде. Борчулы һәм сораулы карашы белән аңа карады.

— Эшең беттемени? — диде Җамали, хатынына күтәрелеп тә карамыйча. Аның киеренкелектән яңак итләре катып калгандай иде. Шуңамы, сүзләрне әйтерсең кисәк-кисәк турап чыгара иде ул.

— Абау, Җамали, бөтенләй төсең киткән ләбаса, — диде Сәгадәт гаять тә гаҗәпләнеп.

— Китәр, китмини...

— Ник шул тикле кабардың, Җамали? Нәкъ ата күркә булгансың. — Сәгадәт көләсе килмәсә дә көлгәндәй итте.

Җамали, эшеннән тукталып, сиземен югалта төшкән яңак итләрен капшап куйды. Күз кабакларын тартып торган нерв җепселләрен йомшартырга тырышыпмы, чигәләрен ышкыштырды. Ниһаять, калтыранган куллары белән көрәген аранның ырмавына сөяде дә авылга кайтканнан бирле тартмаса да, тәмәке эзләгәндәй, кесәләренә шап-шоп сугып карады.

— Сиңа, Сәгадәт, — диде Җамали, тамагының төбе белән сүзләрне суза төшеп, — ул кирәкмәгән эшләреңне ташларга вакыт. Беркемнең хатыны да ирләр башкара торган власть эшенә тыкшынып җөрми.

— Син нәрсә, Җамали?

— Тыңлап бетер. Сиңа ни җитмәгән? Торырга өең җукмы, ачтан интегәсеңме... Җә, ни җитми?

Сәгадәтнең күзләрендә хәтәр очкыннар кабынды:

— Кем сүзен сөйлисең син, Җамали?

— Кеше сүзен.

— Юк, ярлы халык сүзе түгел бу.

— Кем генә сүзе булмасын, ни пычагыма кирәк сиңа кеше саен кереп актарынып җөрергә? Моның өчен авыл советы җукмы, милиция җукмы?

Сәгадәт ярсыды:

— Язгы чәчү җитте бит! Ә орлык юк! Кешеләргә сүз бирдем ләбаса мин!

— Бу да синең тыкшынып җөрүең бәласе. Һаман шул үләргә вакыты җиткән Минай карт белән булышасың икән.

Сәгадәт бөтенләй үзгәреп китте.

— Ә менә кем өчен йөрәгең авырткан икән синең. Бик үләргә җыенмый әле алар, җаный. Хәлләреннән килсә, бар дөньяны йотарлар иде.

Җамали йодрыгы белән аран баганасына сукты:

— Ник бу кадәр дә каның катты шул Минайга? Ни явызлыгы тиде соң аның сиңа?

— Кулакны яклыйсыңмы, Җамали?

— Җаклыйм сиңа!.. Тик гел-гел бер кешене тинтерәтү буламы? Тегермәнен, кибетен алдыгыз. Атларын да алып бетердегез! Шул җитмәгәнме? Җарый, кайдадыр бер Мөстәкыйме сине рәнҗеткән ди. Ләкин бу Мөстәкыйм түгел ләбаса! Минай бу, Минай!

— Алар барысы бер үк каннан! Кулакның намуслы кеше булуына ышанмыйм мин. Менә сез күпме бил бөгеп, ник байый алмадыгыз?

— Бәхете булган — баеган... Бәхете беткән — менә тагы ыштансыз калды. Алҗытмагыз тагы да шул картны!

— Кулаклар барыбер бетәчәк.

— Бетсә, син катышма!

— Катышмаска дисең, — Сәгадәтнең ирене тартышып куйды, коңгырт күзләре коточкыч ялтырый башлады. — Катышмаска?! Юк, Жамали, син миннән моны көтмә! Минем күз нурымдай сабыем шул кеше ашаучылар аркасында салкын гүрдә ятсын, миңа катышмаскамы? Йөрәгем үлгән дип белдеңме әллә син минем?! Кешеләр ачтан үлгән чакта алар йөзләгән пот икмәкләрен яшереп ятканнар!

Сәгадәтнең бөтен йөрәге белән шулай ачыгыйланып кычкыруыннан соң, Жамали аран баганасына сөялеп тынып калды.

Аның хатынына каршы әйтер бүтән сүзе юк иде.

II

— Габдулла, нәнәм, нәрсә эшлисең анда?

— Токыл кызыйм.

— Нинди чокыр?

— Бик тәү, бик тилән токыл.

— Үскәнем, нәрсәгә сиңа бик дәү, бик тирән чокыр?

— Токылга мин бодай тутылам.

— Нәрсә, нәрсә?

Сәгадәт кечкенә Габдулланың сакаулап сөйләшүен үзенә күрә бер мәзәк итеп тыңларга ярата иде. Шуннан тәм таба иде, ахры. Соңгы сүзләрне ишеткәч, аның йөзе шунда ук житдиләнде, кызыксынуы бүтән төс алды. Ә сабыйга нәрсә, үзе сөйләгәннең олылар өчен атналар буе чишелә алмаган табышмакның җавабы икәнен кайдан белсен.

— Бодай тутылам. Би-и-ик күп итеп.

«Бик» сүзен Габдулла шул тикле тырышып әйтте, аның хәтта бөтен йөзе чытылды, тавышы карлыгып өзелде.

Сәгадәт, үз-үзен белештерми, Габдулланы җирдән күтәреп алды.

— Үскәнем, кем шулай тутыра? Кайдан күрдең?

Сәгадәтнең бу эш белән кызыксынуы Габдуллага ошады, күрәсең, ул беравык авызын бөреп, маңгаен җыерып, нидер исәпләгәндәй торды.

— Әйт инде, үскәнем?

— Ни... без-малайлал белән ут тагалга балган иек... Тыбыклал тыйдык та, ут тактык. Анналы күп итеп бәләңге пешелдек. Анналы...

Габдулла, сөйләвеннән тукталып, бик зур эш эшләп арган кеше кебек авыр сулап куйды. Шактый мәлне сүзләр оештыра алмый авызын чапылдатып торды.

— Я, я, үскәнем?

— Анналы... анналы...

— Сөйлә инде, нәнәм...

— Анналы без йоклаганбыз.

— Шуннан?

— Мине абый уятты.

— Шуннан, шуннан?

— Әй, калаңгы, калаңгы... туңдым...

— Караңгы булганга туңдыңмы?

— Тук, салкын булганга туңдым...

— Ничек итеп җылындың соң?

— Абый әйтә: нәнәм, ди, әйдә, йөгеләбез, ди. Әй, йөгелдек узалыштан...

— Җә, җә? Уздыңмы соң?

— Узып булмады тул... Тилән-тилән токыл казыганнал... Ә токылда бодай, бодай!.. Менә моның таклы!.. — Малай колачы җиткәнче кулын җәеп күрсәтте.

— Үзең күрдеңме?

— Күлдем инде.
— Бодай икәнен кайдан белдең?
— Абый әйтте.
— Кемнәр бар ие анда, акыллым?
— Анда Мәләк абый бал ие.
— Тагы кем бар ие?
— Тагы абыйлал. Алалын белмим.
— Сезне күрмәдеме соң алар?
— Тук, күлмәделәл. Без таш алтына касып толдык.
— Ярар, үскәнем, рәхмәт.

Үтәмеш тавының урман куелыгы башланган җирендә Пәри тарлавыгы дип йөртелгән чокыр бар. Бу тарлавык үтә алмаслык әрәмәлек белән уралган. Бодай әнә шул әрәмәлеккә күмелгән булып чыкты.

Тиздән монда авыл халкының олысыннан алып кечесенә хәтле җыелды. Мәләк өеннән чыгып качмакчы булган. Ләкин аны әләктереп алып Пәри тарлавыгына китерделәр. Сәгадәт аның каршына килде дә, кулына көрәк тоттырды.

— Я, үзең күмгәнсең, үзең казы! — диде.

Мәләк Сәгадәткә күзенең агы белән карап, авыз эченнән нидер мыгырданып алды. Көрәкне алмаска ниятләп читкә тибәрде.

— Кулыңны пешерәмени? — диде бер агай мыскыллы тавышы белән. — Җиргә бодай күмгәндә дә кайнар булгандыр, түзгәнсең алай да. Хәзер дә түзәрсең, шәт. Ал көрәкне!

— Тот яхшы чакта! — дип дәррәү сөрән салды берничә кеше.

Мәләк сукранса сукранды, сүгенсә сүгенде, көрәкне кулына алмый чарасы калмады.

Ул башта чокыр өстенә тип-тигез итеп салынган куен үләнле кәсләрне кубарып әрәмәлекнең аргы ягына ташыды. Аннары кәс астында парланып яткан кызыл балчыкны актарырга тотынды. Шул тикле зур чокырны берүзе казыганга, Мәләк яныптешеп чыкты. Ләкин авылдашларыннан берсе дә аңа ярдәмгә ашыкмады.

— Махы бирмә, агайне, кияү кеше бит үзең. Кияү кеше гайрәтле була, — дип кенә җибәрделәр.

Әйе, авылдашларының «кияү» дип төрттереп әйтүләре юкка түгел. Мәләк Гөлбикәгә бәйләнеп йөри-йөри тәки үз дигәненә ирешкән иде. Моннан бер атна чамасы гына элек Минайның үз атына ук салып шул Гөлбикәне урлап кайткан иде ул. Минай соңыннан пыр тузып йөрсә дә, әллә ни майтара алмады. Мәләк тәки Гөлбикә белән яшәп калды.

Берәр сәгатьтән Мәләкнең кыяфәте кызганырлык иде. Муены-бите лычма су, күлмәге салып сыгарлык. Үзе, тауга менгән ат кебек, пошкыра-ухылдый. Гөлбикә, чокырга төшеп, киявенә ярдәм итәсе урынга, тарлавык кырыендагы бөкре талга сөялгән дә балавыз сыга. Юк, ирен кызганып еламый Гөлбикә. Үзенең шул тикле мәсхәрәгә калуыннан хурланып елый. Әле ничә еллар гына элек асыл күлмәк, читек-кәвеш киеп Уразмәт урамы буйлап сагыз чатнатып кәс-кәс йөрүләрен сагынып елый яшь бикәч.

Ниһаять, сары балчык астыннан рәт-рәт салынган такталар калкып чыкты. Монда инде ирләр түзеп калмады — өр-яңа, идәнлеккә дип ярылган такталарны чокыр кырыена үзләре алып ыргытты. Ә чокырда гәрәбәдәй сап-сары бодай лым тулып парланып утыра иде. Менә ул дөньяның тоткасы, уразмәтләрнең өмете, хыялы. Шушы кадәр нигъмәттән башка яши алуларын күз алдына да китерә алмый лабаса Уразмәт халкы. Яңа төзелеп килгән тормышта, бәлага очраган тәкъдирдә дә бүтәннәр, бөтенләй сине белмәгән кешеләр ярдәм кулы суза алуына ышанамыни алар.

Шуна таудай икмәк алдында, аллага баш органдай тезләнеп, эре бодай бөртекләрен кызган учлары аша шыбырдатып үткәрә-үткәрә

кинәнде кешеләр, тамакларына терәлгән авыр төенне йота алмыйча күзләреннән яшь бөртекләре сикереп чыкканын бер-берсеннән яшереп тә маташмадылар.

Мәләк, кешеләрнең аяктан егарлык карашыннан кая яшеренергә белмичә, яшькелт күзләрен ары-бире йөрткәләде, җирән мыегын аяусыз чәйнәде. Ләкин аны бу коткара аламыни?.. Моннан котылу чарасы бармыни дөньяда?!

Гөлбикә инде кычкырып ук елый. Аның тавышы калку күкрәгеннән үксеп чыгып, бәгырьләргә үтә. Өскә күтәрелеп каядыр баш очында тетрәнеп-шашынып тора да, талларны, сәрби агачларын сискәндереп, еракларга китә. Ә Мәләк, көрәгенә таянган да, кечерәйгәннән-кечерәя бара. Үкенәме ул бу язык эше өчен? Әллә юкмы? Үкенсә, ни өчен күз карашында буйсыну, ялвару юк... Киресенчә, ниндидер явызлык, алдагы көнгә калдырылган үч алу теләге? Ләкин кемнән? Ни өчен? Кешеләрнең үзенә карата шул тикле түземлеге өченме? Ә бит кешеләр мәрхәмәтсез дә була беләләр. Менә әлеге җирне казырга дип аңа боерган агай аның кулыннан көрәген тартып алды.

— Бар кайт, — диде ул гөбедән чыккандай тавышы белән, — калганы синең кайгың түгел.

Кешеләрне ерып Сәгадәт алга чыкты.

— Юк, кайтарып җибәрмәгез аны! — Аннары Исмайга кычкырды. — Председатель!

Авыр гәүдәсе белән чайкала-чайкала Исмай килеп житте.

— Әйе, бу җинаяте өчен җавап тотасы бар аның. Аннан соң күмелгән бодай да монын белән генә бетмәскә тиеш. Хәзер шуны күрсәтер ул безгә.

Ләкин Мәләк бүтән яшерелгән бодайны күрсәтүдән дә, бу эшне кем кушуы буенча эшләгәнен, аңа тагы кемнәр булышканын әйтүдән дә баш тартты. Бодай күмелгән җирдә бар әзләр дә юкка чыгарылган иде. Тик шул урынга бара торган юлдагы арба тәгәрмәчләре эзен үлчәп-чагыштырып карагач, ат арбасы Минайныкы булуы ачыкланды. Аны да, кулга алып, идарә йортына китерделәр. Ләкин ул:

— Мин күргән-белгән эш түгел, — дип, бу эшкә катнашы булуын инкарь итте.

Минай белән Мәләкне идарә йортына ябып төн кундырырга булдылар. Шуннан Мәләк:

— Алла хакы өчен дип әйтәм, бер үтенечемне генә үтәгезче? — дип ялварды.

— Я, әйтеп кара!

— Хатын мунчага яккан иде. Соңгы мәртәбә Гөлбикәм белән мунча чабынсам икән?..

Бик ялынгач, Мәләккә Гөлбикәсе белән мунча керергә рөхсәт иттеләр. Җамали белән бер абзый аның мунчадан чыкканын каравыллап торырга тиеш булды.

Гөлбикә мунчаны бик кызу итеп яккан, күрәсең, түбәдән сыек кына пар бөркелеп тора, тирә-юньгә юеш таш, каен себеркесе исе таралган иде.

Җамали мунча янындагы тәбәнәк эскәмиягә утырып та бакты, койма буйлап йөренгәләп тә алды, тик тегеләр чыгарга бик ашыкмадылар.

— Озак тора, озак...

Ниһаять, шыгырдап мунча ишеге ачылганы ишетелде. Такта ярыкларыннан, түбәдән өерелеп пар күтәрелде. Бераздан Гөлбикә ап-ак шәле белән ир-аттан йөзен каплап өенә таба юнәлде.

— Кара, — диде Җамали, хатынның артыннан күз атып, — бөтенләй беткән икән Гөлбикә, балтыр ите кәҗә сыйрагыдай гына булып калган. Әле бер ай да тормады ләбаса!

— Мәләк белән яшәсәң, теге дөньяга да бик тиз олагырсың...

Жамали әлеге абзый белән шулай гәпләшеп тора иде. Бер заман авызларын ачып өнсез калдылар. Ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк — мунчадан, Мәләк киемнәренә төренеп, Гөлбикә чыгып килә иде.

...Хатынының киемнәрен киеп качкан Мәләкне күпме эзләсәләр дә таба алмадылар.

Иртәгесен иртүк Минайны калага озатырга дип килделәр.

Ишегалдында инде ат җигүле, арбасында олы кеше яртылаш күмелерлек печән.

Бар да Минайның әзерләнеп беткәнен көтә. Ә Минай, өстенә күе көрән төстәге җиңле казакиен, башына өр-яңа кара бәрхет кәләпүшен киеп, кулларын терсәктән яртылаш бөккән килеш таркау хәрәкәтләр белән ишегалды буйлап эрле-бирле йөри. Йөрүе — яртыга ярган бүрәнәдән буралган абзар белән урам ягына кырынлатып салынган алты почмаклы мунча арасында.

Бер мәлне ул, нәрсәдер оныткан күк, ишегалдының кыл уртасында маңгаен кашып тора. Аннары, кинәт исенә төшкәндәй, вак-вак атлап яңадан абзарга кереп китә. Абзардан да берни алып чыкмый.

Җыйналган кешеләрдән кемдер учы белән авызын томалап көрсенеп куя, кемдер уфтанып ала. Беркем бер сүз дәшми.

Ниһаять, Минай карчыгына:

— Кая, Бибикамал, намазлыкны чыгар әле! — ди.

Бибикамал абыстай җир убылып китмәсен дигән кебек сакланып кына баса-баса өйгә кереп китә, аннан сары камыштан үреп ясалган намазлык төргәге алып чыга.

Минай, ни өчендер, озак кына намазлыкның тузанын кагып маташа. Кагып бетергәч өй нигезенә җәеп җибәрә. Читегенең бер галошын сала, икенчесе салынмый азаплый.

Намазлык өстендә аягын бөкләп озак утыра Минай. Кәләпүшле башын җиргә иеп, арык җилкәләрен калкыткангамы, бөтенләй кечерәеп калган төсле. Әллә дога кыла, әллә тик оеп утыра, белмәссең: шәмәхә төсенә кергән нечкә иреннәре әллә нигә бер генә селкенеп куя. Шул кеп-кечкенә карттан өскә сап-сары юан бүрәнәләрдән өелгән биек йорт күтәрелә. Аның өсте такта белән ябылган, тәрәзәләре зур, тәрәзә капкачларында матур сурәтләр. Алгы якта төрле галәмәттәге челтәрләр белән бизәп ясалган мәһабәт капка. Капка өстендә — нәфис кенә кечкенә мәчет.

Менә карт биленә тотынып аягына баса, читекләре белән кыштыр-кыштыр килеп, кешеләргә таба бармакчы. Тик намазлыгын онытканын исенә төшереп, янә өй түренә борыла. Әмма барып җитми — Бибикамал абыстай намазлыкны җыеп өйгә алып кереп киткән икән. Минай тагы нәрсәнедер оныткан кебек сирәк сакалын учлап ишегалды уртасында кагаеп тора.

— Атка утыр, — ди аңа Исмай.

Үзенә нидер дәшкәннәрен Минай ишеткән ишетүен, тик кем, нәрсә әйткәнен төшенә алмыйча, авызын ача төшеп, яшькелт күзләрен бер кешедән икенчесенә йөртә-йөртә шуны чамаларга тырыша.

Янына сакчылар килеп җитә.

— Әйдә утыр, карт, китәргә вакыт.

Кемдер шыңшып елап җибәрә. Бибикамал абыстай, абына-сөртенә Минай янына килеп, аның боздай кулларыннан тота. Минай калтыранган бармакларын карчыгының беләге буйлап шудырып йомшак иңнәренә орына. Бик үз һәм җылы бу тәнне, озын гомерендә һәр вакыт янәшә булган шушы тулы гына аксыл йөзне инде югалта баруын төшенгәнгәме, йөрәге өшеп куя картның.

— Туңам мин, Бибикамал, бик туңам, — ди ул. Аның тешләре тешкә бәрелә, йөзе әллә ничек күгәреп китә. — Көн суытып җибәрде, ахры, кыска туннымны чыгарасың мәллә?

Бибикамал абыстай:

— Ай ходаем, көн эссе кана, ай ходаем, — дип тәкърарлый-тәкърарлый өйгә таба кызулый. Тун алып чыгышлый өй баскычына кадаклаган ат дагасына сөртенеп чак кына егылмый кала.

— Карап җөрер идең, — ди аңа Минай. — Аягыңны имгәтерсең.

Бибикамал абыстайның йөзе сытылып китеп, күзеннән ике яшь бөртеге атылып чыга. Әллә ничек ашыгып, җайсыз гына итләч куллары дерелдәп күзләренә күтәрелә...

Минай кыска тунының бер җиңен киеп, икенчесен таба алмый азапланганда, сакчы егетләр, ярдәмгә килеп, ялт кына каптырмаларны да эләктереп, картның үзен дә арба уртасына утыртып куялар.

— Киттек, — ди берсе һәм арбага сикереп менеп тә утыра. — Ач капканы!

Капка шыңгырдап ике якка ачылып китә.

— Бибикамал, — ди Минай каяндыр мәгарәдән чыккандай тонык тавыш белән. Үзе, башын бер яктан бер якка боргалап, томанланган күзләре белән кешеләр арасыннан карчыгын күрмәкче. — Бибикамал, син кайда?

— Монда мин, Минай...

— Күрмим лә. Кайда син?

Ләкин ул аны барыбер күрергә өлгерми, җигелгән көе сәгатьләр буе зарыгып торган айгыр җилдереп капкадан чыгып китә.

Әллә кайдан атылып килеп чыккан ялан аяклы биш яшьләр тирәсендәге малай ачы итеп кычкырып җибәрә:

— Дәү эти-и!

Капкадан чыгып баручы Сәгадәт шунда ук малайны тотып ала. Йөрәк әрнеткеч бу тамашаны күрмәсен өчен, ул аның ялтыратып кырган башын күкрәгенә яшермәкче.

— Дәү этине кая алып киттеләр? Кая алып киттеләр минем дәү этине?

Башын Сәгадәтнең куеныннан алмак булып бар көченә тартыла, йолкына малай.

— Елама, нәнәм, елама.

12

Минайны калага озаткач, хатыны Бибикамал абыстай өй борынча йөреп коткы таратып йөргән: имеш, Сәгадәтнең нәсел-нәсебе бик шикле кешеләр, имеш, ул Уразмәт халкыннан җыелган байлыкны шул туганнары ярдәмендә төннәрен каядыр озаттыра икән. Ул гына да түгел, Мәләк белән бер булып, бодайны да чокырга ул күмдергән, янәсе, бу хакта сөйләшкәннәрен Гөлбикә ишетеп торган. Соңыннан, бодайның исе чыга башлагач, Сәгадәт үзе эзләп тапкан атлы булган, имеш. Әле тагы Сәгадәт Мәләкне мунчадан чыкканын сагалап торырга юкка үз Җамалиен куйдырмаган, ә анысы Мәләкне күрә торып качырган, янәсе. Хатын-кыз киеме киенеп качкан дигән сүз Сәгадәт белән Җамали уйдырмасы гына, имеш. Янәсе, Гөлбикә бу мәкерле эшнең серенә соңыннан гына төшенгән. Шуңа, Мәләк белән тормаска булып, әнисе йортына кайткан.

Минайны, янәсе, бер гаепсез көе, Сәгадәт үзенең шикле эшләрен яшерер өчен төрмәгә яптырган...

Җамали өенә кайтып кергәндә Сәгадәт юк иде әле. Почмак яктагы савыт-сабаны шалтыр-шылтыр китереп ашарга эзләп карады Җамали. Тапмагач, ачу белән ишекне дөңгелдәтеп ябып, каралты ягына чыкты. Сарайда сибелеп яткан иске такталарны тотып-тотып карады. Аларның

болай тәртипсез ятуы аның ачуын тагы көчәйтә төште. Тик бер читкә өеп куярга барыбер кулы бармады, бары тик аягы белән типкәләп, такта кисәкләрен бер кырыйга этте дә янадан өйгә керде. Аңа йорт эче шыксызланып калгандай тоелды. Шул чак ишек ачылып китте һәм бусагадан арыган кыяфәтле Сәгадәт күренде. Аның талчыккан күзләрендә юатуга, назга сусау, иң якын кешесенең көчле иңнәренә таянып бер туйганчы ял итү теләге. Хатын-кызның бу мөлаем йомшаклыгы, көчсезлеге ирләрдә һәр вакыт үзенең сөйгәнен кочагына алып иркәләү омтылышы уята. Мондый тартылу кайвакыт шул чаклы тыелгысыз була, ир кешенең иң каты бәгырьлесе дә күңел җилкеткеч әлеге теләктән тукталып кала алмый...

Тик Җамалиның эчендә кайнаган ачуы әлеге кешелекле хиснең күтәрелеп китүенә ирек бирмәде. Ул хәтта хатынының карашындагы, бөтен тәнендәге иркә-назга зарыгуны сизмәде дә.

Сәгадәт Җамалиның җылы сүзен көтеп ала алмагач, әле сүрелергә өлгермәгән өмет белән:

— Менә кайттым, — дип карады.

Бу вакытта аның талчыккан күз карашында менә-менә кабынып китәргә торган чая очкын чагылып үтте.

Җамалига: «Кайттыңмыни, Сәгадәтем!», — дип хатынын кочып, үбеп аласы гына кана.

Ул чагында Сәгадәтнең күзендәге әлеге очкын кабынып китеп мөлаем балку булып җәелер иде. Бүген ул никадәр арган булмасын, волостьтан килгән вәкил белән авылда партячейка төзү турында план корулары, вәкилнең аңа ышануы хакында ачылып-чәчелеп сөйләр иде.

Юк шул, ире аны бүтән җавап белән каршылады:

— Кунып кайтасың калган соң.

Сәгадәтнең иреннәре дерелдәп китте:

— Их син!

Ә Җамалиның яңа ташып чыга башлавы гына.

— Нәрсә мин? Син ул нинди көнгә калдырдың мине! Нәрсәләр сөйлиләр бит хәзер безнең хакта, халык икмәген каядыр олактырып җатабыз, имеш. Мәләкне мин җүри качырганмын, җәнәсе! Болар бар да синең аркада, Сәгадәт! Бары да синең аркада!

— Кулак хатыны ни сөйләмәс.

— Кулак хатыны гына сиңа! Бөтен кешенең авызында шул сүз.

— Тик сөйләсеннәр. Бер туктарлар әле.

— Җук инде, Сәгадәт, теләсә ни әйт, мин болай яши алмыйм. Җә син кирәкмәгәнгә тыгылып җөрүдән туктыйсың, җә...

— Әйтеп бетер!

— Соң, Сәгадәт, кулакта ачуым бар, дидең. Инде үз дигәненә ирештең: Минайны авылдан кудылар. Кудылар гына түгел, өтермәгә ябып куйдылар. Тагы ни нәрсә җитмәгән сиңа?

— Әйе, Җамали, Минайны авылдан кудык. Тик...

— Җә, тынычланырга вакыттыр бит инде сиңа. Чөкердәшеп кеше төсле тормыш итә башларга кирәктер ләбаса!

— Кирәк, анысы да кирәк.

— Соң, шулай булгач?

Сәгадәт, җавап кайтармыйча, сәке кырына барып елышты. Башын ике кулы белән учлап озак кына бер сүз дәшми торды.

— Җә, ник дәшмисең?

Сәгадәт, капыл гына башын күтәреп, Җамалига текәлеп карады.

— Җамали, син мине ахыргача түзеп тыңлый аласыңмы?

— Әйтеп кара.

Сәгадәт, иренен кыса төшеп, зиһен җыеп торды.

— Әйтеп карыйм, Җамали. Әйе, Минайларга шулай өермәдәй ябырылуым — минем нәфрәтемнең ташуы булды. Улыма булган мәхәббәт

тудырган нәфрәтемнең ташуы. Минайлар шул ярсу ташуның дулкынына юлыктылар. Ләкин шул дулкын белән бергә мин үзем дә бүтән дөньяга, моңарчы мин белмәгән дөньяга барып кергәнмен ләбаса. Анда бүтән кешеләр очратканмын. Моңарчы мин күрмәгән кешеләр. Син Нәгыйм абыйны яхшы беләсең. Колхозыбызны ул башлап төзергә тотынды. Ә хәзер урын өстендә ята. Әле кичә генә хәлен белергә барганием. Эше шәптән түгел аның. Шулай да уенда һаман колхоз. Ә нәрсәләр генә күрмәгән ул: патша сөргенендә дә булган, революциядә дә катнашкан. Миңа да күпме булышты ул. Акыллы киңәшләре белән дә, үзенең мисалы белән дә. Ул булмаса, белмим, миндә кабат яшәргә теләк уяныр иде микән. Теге вакытта син мине коткарсаң да, икенче яшәүне миңа Нәгыйм абый бирде. Шыншырга ирек куймады ул миңа. Укуым да, тормышны аңлый башлавым да аның аркасында. Эчемдә әйтелмәгән мең-мең рәхмәт бар аңа, беләсеңме шуны? Нәрсә белән кайтарып бетерим мин бу рәхмәтне! Тагы кем минем чаклы ук бурычлы аңа, ә? Тагы кем?!

Җамали тәрәзә кырына яны белән сөялеп ишегалды ягына карап тора иде. Тыңлый идеме ул хатыны сөйләгәнне, әллә юкмы, кинәт сүз арасында гына әйткәндәй:

— Исмай безгә кереп килә, — диде.

Сәгадәт тә башын калкытты.

— Керә бирсен...

Ул, сәкедән торып, ишеккә таба юнәлде. Ләкин барып җитмәде, зур гәүдәсен ия төшеп, ишектән Исмай килеп тә керде.

— Менә, — диде Сәгадәт иренә карап, — синең сүзгә председатель ни дияр тагы?

Икесе арасында булган сөйләшүне чит кешегә сиздергәнгә Җамалиның ачуы чыкты:

— Тагы нәрсә?

Исмай, берни аңламыйча, башын алга суза төшеп, күзләрен желтерәтеп тора иде.

— Ирем миңа моннан ары сезнең эшкә тыгылып йөрмәскә куша.

— Ә-ә, — дип сузды Исмай сүзнең ни хакта булганына төшенеп, — анысы инде сезнең эш, теләсә нишләгез, минем үземнең хәлем хәл әле.

Ул көрәк чаклы кулларын күкрәге алдында кушырып, баскан урынында таптанып куйды.

— Ни булды тагын? — дип сорады Сәгадәт гаҗәпләнеп.

Исмай, муенын кыскан күлмәк якасын бушайтырга теләгәндәй, аны бармаклары белән як-якка тарткалый-тарткалый, авызын кыегайта төшеп, башын боргалады. Әйтерсең шул рәвешле үзен буып торган кысынкылыктан шуышып чыкмакчы.

— Мин... мин, — диде ул, ниһаять, күлмәгенең төймәләрен дә ычкындырып, — авылдан китәргә булдым, Сәгадәт.

Сәгадәт аптырап калды.

— Китәргә булдың? Ничек китәргә булдың?!

— Шулай. Карьерга китәм.

Сәгадәт беравык ни әйтергә белми Исмайга карап гаҗизләнеп торды, аннары аның коңгырт күзләре ачудан тетрәнеп яна башлады.

— Качасың? Куркып качасың?!

Исмайның кабарып торган кызгылт яңаклары аксыл таплар белән капланып аска салынып төште, болай да эчкәре урнашкан кысык күзләре, Сәгадәтнең чәнечкеле карашыннан качып, тагы да түгәрәк яшеренгәндәй, чак кына желтерәп калды.

— Җук, җук, Сәгадәт, — диде ул бөтен гәүдәсе белән җыерылып.

— Нәрсә юк? Китәм дисең бит!

— Ие, китәм. Әмма ләкин куркып түгел.

— Курыкмаган кая! Җыйналган халыкка батырып сүз әйтә алмыйсың. Минайны озаткан чакта тәмам югалып калдың.

Җамали башта, үзенә кагылмый дип уйлап, аларның икесе арасындагы сүзгә катышмый утырды. Хатыны, авызыннан ут чәчеп, Исмайга ябырылганда, үзенең ир башы белән дәшми утырырга мәҗбүр булуына хурланып, шул гарьлекне тышка чыгарырга теләгәндәй әледән-әле тамак кырып куйса да түзде. Инде менә хатыны малай чактан бергә уйнап үскән Исмайны куркаклыкта гаепли башлагач, Җамалиның да эчендә нидер кузгалып куйды. «Исмайны куркытырсың бар!» — ул моны авыз эченнән генә әйтте. Аннары бу фикерен кычкырып та әйтте:

— Куркыр синә Исмай!

Гомерендә шуның ише сүзгә катышмаган иренең бер дә уйламаганда Исмайны яклап чыгуына гаҗәпләнеп, Сәгадәт тынып калды.

— Белмим инде, белмим, — диде аннары, ни әйтергә дә белмичә,— ничек шушындый авыр вакытта бөтен авырлыкны минем өскә калдырып китмәкче буласың соң син?

— Бу эшне булдыра алмыйм бит мин, — диде Исмай башын түбән иеп, — волостьтан килгән вәкил урынлыга кыздырды бүген. Һәммә эштә башлап син җөрисең, Сәгадәт. Ә мин? Шушы хәтле гәүдәм белән... жук инде, үзең уйлап кара, ничек җыен карт-коры, хатын-кыз белән сугышып җөрим ди мин? Кулым күтәрелми минем аларга.

— Ник сугышырга ди. Тел белән...

— М-менә шул каһәр төшкән тел жук шул миндә. Хәер, теле бар ла аның. Т-тик, үзем шикелле, а-авыр әйләнә. Ә т-телнең авыр әйләнүен м-мин шуннан күрәм: бу эш минекенә, җ-җанымның бер кисәгенә әйләнмәгән. М-мин үземә, эш үзенә, ягъни ике җары яшәгән күк. Ш-шул икенчесе әйтерсең, сабыйны җитәкләгәндәй, мине кулымнан тартып җөрткән. Ш-шуны аңлагач, миңа б-бик оят булып китте. Ш-шундый оят — хәтта мин кеше күзенә күренергә дә ояла башладым... Сезгә дә арт җактан гына килдем әле... Шулай булгач авылда калуны уйлыйсы да жук. Карьерга барсам, ичмасам, менә ш-шушы кулларым белән рәхәтләнеп таш ватармын. Ә болай ни илгә, ни миргә.

Шулай диде дә Исмай саубуллашып чыгып китте.

Бүлмә эчендә авыр тынлык урнашты. Әллә кайдан өйгә килеп кергән йонлач төклетура гына зең-зең итеп тәрәзә пыяласына килеп бәрелде.

Сәгадәт белән Исмай арасында булган сөйләшүдән соң Җамали хатынын яңа таный башлаган төсле шаккатып карап торды. Карар күзгә ябык кына, җип-җиңел хатында шул чаклы көч кайдан килгән? Күзләренең шашынып чаткылануын күр син! Кинәт Җамалиның йөрәге кочакка сеңеп бетәрлек шушы нечкә генә хатынга тартылып сыкрый башлады. Аннан ике-өч адымда гына утырган Сәгадәтен кулыннан тотып алып күкрәгенә кысмаса, бу газаплы да, рәхәт тә сыкрау басылачак түгел. Шунсыз икесенең дә җанында бу әрнүнең авыртуы бетеп, бары татлы рәхәтлек кенә калмас.

... Җамали йокысыннан уянганда Сәгадәт күптән торып киткән иде. Урам шау-гөр килә. Кешеләрнең йөзләре ачулы. Кулларын бутыйбутый бер-берсенә нәрсәдер сөйлиләр.

Җамали ашап-эчеп тормады. Өстенә пинҗәген, аягына чабатасын киде дә, урамга ашыкты. Хатын-кызлар аны күрү белән үзара пышылдашып алдылар. Җамали аларның ни сөйләгәннәрен төшенергә тырышса да, берни ишетмәде, бары усал елтыраган күзләреннән, өрелгән яңакларыннан ниндидер яңа бәла барлыгын чамалады.

«Ни булды, кая барасыз?» дип сораса да, аңа җавап кайтармады-

лар. Акаеп бер карадылар да, аннан читләшергә ашыктылар. Җамали да аларга иярде.

Терлек абзарлары янында сабан туемыни: халык гөж килә. Монда ире дә, хатын-кызы да. Аның Сәгадәте, тагы берничә кеше арба өстенә менеп басканнар. Җыелган халыкның гөрләвен басарга теләп, әле берсе, әле икенчесе нидер кычкыра. Тик аларның тавышы кешеләр шаушуында күмелеп кала.

Менә Сәгадәт алгарак чыкты. Аның кап-кара чәчләре, кызыл яулыгы эченнән чыгып, маңгаена таралып төшкән. Дулкынланудан һәм ярсудан болай да каратутлы бите тагын да кара кучкылланып яна.

— Кешеләр! — дип кычкырды ул, халык бераз тынгандай булгач. — Кешеләр, сезне кулаклар бутарга тырыша. Бөтен ачуларын бездән, сезне яклаучылардан алмакчы алар.

Халык арасыннан ярсулы тавышлар яңгырады:

— Мәләкне кая качырдыгыз?

— Качыруыгыз гына җитмәгән, инде бүген атлар биреп җибәргәнсез! Без йоклаганда.

«Әһә, менә нәрсә, төнлә атларны урлаганнар икән... Шуңа купкан бу яңа гау», — дип төшенә башлады Җамали.

Ә Сәгадәт кешеләрне тынычландырырга теләде:

— Ялган бу, чеп-чи ялган! Ышанмагыз! Атларыгыз табылачак. Колхоз атлары табылмый калмас... Бодайны да таптык бит.

— Телеңә салынганчы бодайның калганын тап син лутче!

— Көтеп ят, тапты ди сиңа! Әллә кайчан чыгарып саткандыр инде!

Сәгадәт үз өстенә шул чаклы оятсыз яла ягудан гаҗизләнеп:

— Ничек оялмыйсыз? Җир бит икәнсез! — дип әйтеп салды. Болай дип әйтүенә ул үзе дә үкенде.

Берничә кеше шунда ук гөлт итеп кабынды:

— Син үзең җир бит! Килмешәк!

— Безнең тормышны пыран-заран китереп ятканчы, кайдан килдең, шунда олак!

— Алдыңнан артың матур!

Кешеләр арасыннан Мәстүрәнең тавышы ишетелде:

— Кулак коткысына ияреп, үзегез өчен тырышкан кешегә ябышмагыз соң!

Мәстүрә янында торган озын буйлы ир аңа югарыдан карап:

— Син генә җитмәгән иде монда! — дип җикеренде.

— Җәмәгать, — дип сузды берсе, — шулай итеп, безнең мал арт яктан шуып бетәр микәнни? Шул хакта ни уйлыйсыз?

Халык тагын кабынып китәргә өлгермәде, Сәгадәт әйтеп калырга ашыкты:

— Ни сөйлисез соң сез? Сезнең мал — колхоз малы хәзер. Аңа кем кагылсын?!

— Һе, бодай да колхоз малы иде дә.

— Ат-арбаларны да таратып бетерерләр болай булгач.

— Төп башына утырып калачакбыз без, җәмәгать!

Шуннан китте тавыш, китте тавыш. Бу тавышны Сәгадәт тә, бүтәннәр дә туктата алмады.

Шул вакыт халыкны икегә аерып зур гәүдәле, какча йөзле Шиһап исемле кеше алга чыкты. Ул калын тавыш белән умарта иледәй гөжләгән шауны басып:

— Сеңелем, син бәлкем хак әйтәсеңдер. Бибикамалның сүзе нахактыр. Ләкин без кайдан белик кайсы хак, кайсы нахак икәнлеген? Без, керәстиян халкы, каты җиргә ике аяклап басарга күнеккән. Ә сезнең эш әлегә ни тудый, ни судый. Шулай булгач, колхозга кереп ашыктык

бугай без. Кем ничек уйлый торгандыр, мин, мәсәлән, колхоздан чыгып торырга булдым.

Ул шулай диде дә, олы-олы атлап, терлек абзарларына таба юнәлде.

Бүтәннәр дә шаулаша-шаулаша аңа иярде.

— И абзыйлар, — диде Сәгадәт гаҗизләнеп. — Яхшылыкны аңламыйсыз. Дусны дошманнан аера белмисез. Кулак хатыннарының сүзенә ышанасыз!

Ләкин аны инде беркем дә тыңламады. Халык дәррәү кубып терлек абзарына ябырылды. Шул ыгы-зыгы, талаш-кычкырыш арасында Җамали Сәгадәтне бөтенләй күздән югалтты. Аның кайгысы анда идемени... Бер-берсен этә-төртә шау итеп терлек абзарына ябырылган халык артыннан иярде ул.

Өенә кайтып җиткәндә Җамалиның башы кызган чуендай иде. Тирә-юньдә язгы ташкындай бөтерелгән чынбарлыкның асылына төшенерлекмени?! Колхоз диделәр, җирләрне куштылар, мал-туарны бергә җыеп әкәмәт ясадылар. Шуннан ни чыкты? Чәчәргә дигән бодай орлыгы пыран-заран килде. Ярый, бер өлешен таптылар да ди. Ә калганы кайда?.. Ни чәчәрләр? Хайваннар белән дә шулай булмасмыни? Әнә күпер башы Ясәви белән чыпчык Галәвинең атлары каядыр олаккан бит әле анда...

Хатын-кыз башы белән Сәгадәт тыз-быз чабып йөргән булды. Җә, ни кырды? Колхозлары таралып бетте түгелме соң?

Шул чакта дөп-дөп итеп капка каккан тавыш ишетелде. Сәгадәт микән? Юктыр. Ул капка биген ача белә ич.

Җамали ялан аягына гына чабатасын сөйрәп ишегалдына чыкты. Капка бастырыгын бер якка этәрде. Шыңгырдап капка ачылуга, кулына фонарь тоткан Мәстүрәне күрде. Тонык фонарь яктысында Мәстүрәнең куркынган күзләре чагылып китте.

«Әллә Сәгадәткә берәр хәл булганмы?» Җамалиның йөрәге авыртып кысылып куйды.

— Ни җаның белән йоклап ятасың, Җамали?

«Нәрсәдер булган икән...»

Җамалиның тыгызланып йомарланган җаны ычкынып урыныннан купты. «Сәгадәткә ни булды?!» дип кычкырасы килде аның. Ләкин шул ук секундта үзен кулга алып өлгерде. Йодрыкланган кулларын як-якка җәеп киерелә-сузыла:

— Төн җокы өчен лә, — дип куйды.

— Их син! Сәгадәт бертуктаусыз елады да елады.

— Кем кушкан...

— Кем кушкан, имеш. Үзең, шашарга җитешеп, артыннан йөргән булдың.

— Мин нишләгән?

— Җебегән син, белдеңме шуны!

— Җитәр! Әйт, кайтсын. Җөрмәсен төн пәрие булып.

— Кайтмый ул.

— А-а-алай... Һаман җылыймы?

— Юк.

— Бар әйт, тилереп җөрмәсен.

— Әйттем инде. Колагына да элми. Әллә нинди сәер ул. Бары бер сүзне әйтә: «Миңа ышанмадылар, кулак ялчыларына ышандылар», — ди. Шулай ди дә тора... Җамали, ул бер-бер хәл эшләмәгәе.

— Ни нәрсә кырсын соң ул?

— Алай димә, Җамали, зинһар, алай димә! Ул бит шулай сөйләнеп торды-торды да, халыкны ышандыру өчен нәрсә эшлим икән соң? — ди өзгәләнергә тотынды. Тынычлан, — дип карыйм, су эчертәм. Юк кына. Әйдә, мин әйтәм, волком кешеләрен чакырып кайтыйк. Бер

чара күрсеннәр шунда дим. Кирәкми, аларның эше шул гына дип белдеңме, ди. Ни битең белән безнең кулыбыздан килми, булдырмыйбыз дип, алар каршына авыз күтәреп бармак кирәк, ди. Әйтмә дә, сөйләмә дә, үзебезгә юлын табарга кирәк, ди.

Беравыктан карыйм, минем янга елыша бу. Мәстүрә, ди, таптым бит мин ни эшләргә кирәген, ди. Бу әллә ни куркыныч булмаячак, көчем җитәр, ди. Үзе шундый шат, сандугач баласы тотканмыни. Ә күзләре... Әй, күзләре нинди аның Җамали! Котырып язгы ташу кузгалганмыни! Ул нәрсәдер эшләргә җыена, кайтар син аны, Җамали! Аның юлына аркылы төшәргә көчем җитмәс минем!

— Артыннан җөри-җөри туйган инде. Бар әйт, ирең хәзер үк кайтырга кушты, диген.

— Син бармасаң, кайтмаячак ул. Әйдә, минем белән, Җамали. Әйдә, тизрәк!

— Кайтасы килсә, үзе дә кайтыр.

— Алай икән... — Мәстүрәнең тавышы калтырады. — Үкенмәссең микән соңыннан, Җамали?

— Үкенмәм!

— Таш бәгырле икәнсең!

Мәстүрә чыгып китте. Ә аның соңгы сүзләре Җамалиның колак төбендә яңгырап торды: «Таш бәгырьле икәнсең... Таш бәгырьле икәнсең!..» Җамали башын селкеп торды-торды да җан ачуы белән өстен салып атты. Почмак яктагы урын-җирне берәм-берәм сәкегә тондырып аннан-моннан урын җәйде дә башыннан ук юрганын бөркәнеп ятып карады. Ләкин әлеге өн аның бөтен тәнен өшетеп һаман яңгырый иде: «Таш бәгырьле икәнсең... Таш бәгырьле икәнсең!..»

Ул әле уңга, әле сулга борылып ятып бакты, башын юрганның эченәрәк яшерде, әмма җанын оета торган аваздан барыбер котыла алмады. Шунда кинәт аның миен яндырып юлбасарлар белән булган хәл вакытында башын пинжәгенең якасына яшереп ятуы исенә төште.

Ул кубарылып юрганын өстеннән алып ыргытты да ике аягын сәке кырына салындырып торып утырды. Караңгылык куерганнан-куера бара иде. Тәрәзәләр әйтерсең даладагы ач бүре күзләре: күңелне әллә ничек оетып, шомландырып Җамалига төбәлгәннәр...

Бу төнне Сәгадәт ире янына кайтмады. Иртә белән Мәстүрәләргә хатынын белешергә баргач, аның Бибикамал абыстай белән калага чыгып киткәнлеген ишетеп, Җамалиның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте.

«Ничек инде ул алай — кан дошманы белән бергәләп шундый озын юлга?»

Җамали моны берничек тә аңлый алмады. Сәгадәт әллә, барысына да кул селтәп, шул Бибикамаллар белән дуслашырга телиме? Булмастыр. Әллә... Юк, юк, алай дип уйлаву да куркыныч. Өстәвенә, Мәстүрә дә киткән бит алар белән. Ләкин ни өчен шул Бибикамаллардан җыенып чыгып киткән алар?..

Тукта, Сәгадәт бервакыт, Бибикамаллар аша әлеге чуала барган серле йомгакның очына чыгып булмасмы, дигән иде шикелле. Ул моны нәрсәгә таянып әйтте соң? Әйе, Бибикамалның Минайдан бик үк риза булып яшәмәвеннән... Ник дисәң, Минай үз гомерендә карчыгына бихисап этлекләр кылган икән. Калага китеп тәтәйләр белән кәеф-сафа чигеп йөрүләр дисеңме, айлар буе хәләл җефетен ир куеныннан мәхрүм итү дисеңме. Хатын-кызның хәлен хатын-кыз аңлый ләбаса. Ачылып китмәсме Бибикамал? Әйе, әйе, шулайрак сөйләгәне бар иде Сәгадәтнең. Тик, ай-һай, нәрсә генә майтара алыр икән? Минай белән этле-мәчеле яшәсәләр дә, бер үк токымнан ләбаса Бибикамал. Шул байбәтчә токымыннан. Шуны гына аңлый бит Сәгадәт. Ни өчен Мәстүрә, Сәгадәт бер-бер хәл эшләп куймагае, дип әйтте икән?

«Таш бәгырьле икәнсең...»

Тузанлы юлда эзләр ярылып ята. Менә чабаталы ике хатын-кыз эзе — Сәгадәт белән Мәстүрәнеке. Галош эзе — Бибикамал абыстайныкы. Читек-кәвеш кигән, күрәсең. Кирәмәт чокырыннан чыгып, тагы бер эз кушылган. Ир кеше эзе бу. Кем булыр икән? Таң тишегеннән Кирәмәт чокырында кем йөрер? Хәерлегә түгел бу. Җамали адымын тагы да кызулый төште. Кирәмәт тегермәнен узгач, шадра эзләр, ат юлыннан чыгып, бәбкә үләненә күмелә язган тар сукмакка борылды. Ә сукмак Олы Ярга төшеп китә.

«Үтәмеш урманына турыдан гына бәреп чыкмакчы болар.»

Җамали ашыккан көйгә кызыл балчыклы текә ярдан шуыша-тәгәри түбәнгә атылды.

Олы Ярның үзәгеннән инеш үтә. Җәен тараеп ага ул. Яз җиттеме, Олы Ярга ургылып ташу килеп төшә. Ул барча нәрсәне агыза, ташларны да, чыбык-чабыкны да, хәтта агач төпләрен дә. Ничә ел рәттән инешкә буа ясап карадылар. Әмма һәр мәртәбәсендә котырган ташу буаны ерып атты.

Җамали, аяк астындагы ташларны тәгәрәтә-тәгәрәтә, ярдан өскә күтәрелеп юлга чыкты.

Үтәмеш урманына җитәрәк, авыл зираты... Әнә коймасы, капка буе... Чү, капка янында кемнәрдер бар түгелме? Хатын-кызлар. Сәгадәтләрдер, мөгаен... Юк, Сәгадәт күренми анда. Болар Мәстүрә белән Бибикамал абыстай. Абыстай зиратка таба карап тезләнеп утырган да кулын күтәреп дога укый.

— Сәгадәт кайда?

Бибикамал абыстай кымшанып та карамады. Дога кылуын белде. Мәстүрә каушап-агарып китте.

— Ул... ул хәзер чыга. Хәзер чакырам мин аны.

Бибикамал абыстай куллары белән авыз тирәсен тиз-тиз сыпырып алды.

— Сабыр ит, Мәстүрә, сабыр ит. Сүзләре бетмәгәндер.

Җамали тәмам ярсыды.

— Нинди сүзләре? Кем белән сөйләшә ул?!

Бибикамал абыстайның агарынып калган йөзенә куксел тимгелләр бәреп чыкты.

— Әстәгыфирулла, кем улым, алай итенмә. Минем бер катнашым да юк.

Мәстүрә сикереп торды.

— Әйдә, әйдә, Җамали, күрсәтәм. Монда гына ул...

Аннары ул ачы итеп кычкырып җибәрде:

— Сәгадәт! Сәгадәт дим. Әйдә чык инде!

Мәстүрәнең тавышы имән, юкә агачларына бәрелә-сугыла үтте дә, кайтаваз булып яңгырады.

Ләкин каршы җавап ишетелмәде.

— Кем белән ул анда?

— Мәләк белән.

— Мәләк?! Мәләк дисеңме?!.

Җамали үз-үзен белештерми урман эченә томырылды.

Имән ботагына эләгеп аның күлмәге аерылып чыкты, тагы бер-ике адым атлауга ниндидер түмгәккә абынып чытырманлыкка барып кадалды. Торды да, бернигә карамый, тагы йөгерде.

— Сәгадәт, Сәгадәт дим!

Шашынып чапкан көйгә ул чак аларның өстенә барып төшмәде.

Коточкыч тамаша иде монда: Мәләк, аякларын киң ерып, Сәгадәт янына тезләнгән дә, ана бер-бер артлы хәнҗәр белән кадый иде.

Җамали бар куәткә чабаталы аягы белән Мәләккә тибеп җибәрде, Тегесе шунда ук әүмәләнеп бер читкә тәгәрәп китте.

Кызулык белән ул Мәләкнең хәнҗәрен алырга да онытты.

— Сәгадәт! Сәгадәтем!

Сәгадәт Җамалига карамады, аның карашы каядыр өскә юнәлгән иде. Кинәт бу сүрелә барган күз нурында хәвеф чагылып китте. Җамали капыл борылып караганда аның баш очында котсыз үлем булып хәнҗәр күтәрелгән иде. Ул, ерткыч җәнлектәй очып, Мәләккә ябышты да, аны җиргә бәреп пычагын тартып алды. Аннары җан ачуы белән ике колагыннан умырып тотып, башын имән төбенә бәргәләде. Үзе янадан Сәгадәткә иелде.

— Их, Сәгадәт, нишләдең син?!

Сәгадәт һаман шулай өскә караган көе елмайгандай итте.

— Минә... минә ышанырлар хәзер... ы-ша-ныр-лар...

Шунда ук аның йөзе күгәреп китте, борыны очлаеп калгандай булды.

Җамали акылын җуяр дәрәҗәгә җитеп шашынып кычкырды:

— Кирәкми, Сәгадәт, мине ташлап китмә!

Сәгадәт инде аны ишетмәде.

Яфраклар шаштырдаган тавышка Җамали кинәт сикереп торды. Бу — Мәләк шулай качып бара иде. Җамали ярсу белән аның башын шактый каты бәргәләгән. Хәзер, рәткә килеп, сыпыртырга уйлаган! «Качырмаска!» Җамали аның артыннан ташланды. Алда — урман куелыгында — канга буялган аксыл күлмәк, ул йомарлана, бөтерелә, Җамалидан ераклаша, агачлар ышыгында югалып-югалып ала.

Ниһаять, Җамалиның каршысында Мәләкнең куркынып агарынган йөзе, кыйшайган авызы. Тамыры шартлап чыгарга җитешкән йодрык аңлаешсыз кыйшайган авызга төбәлә. Тик кыйшык авыз бер урында тормый, бер яктан икенче якка авыша... Бөтенләй эреп югалганчы... югалганчы... Чырк! Йодрык сөяген кискәндәй авырту... Кыйшайган йөз томанлыкта эреп җиргә оча...

— Т-тукта, Җамали, тукта!

— Ә-ә... туктамы? Мә, мә, мә!..

Аяклар белән типкәләүдән җирдәге гәүдә гырылдап-ыңгырашып бер яктан бер якка тәгәри...

— Тукта дим! Бер сүз әйтәм, тфү!..

— Бер сүзме?.. Ә-ә... бер сүзме?.. Сүзең җук синең, җук!

— Бер-р-р сүз... тфү, тфү... Сиңа кирәкле сүз...

Җамали ухылдап туктап калды.

— Җә, ни әйтмәкче буласың, эт җан?.. Әйтеп кал җаныңны алганчы!.. Мәләк авыз-борынындагы канны тузанга буялып беткән куллары белән сөртеп алды.

— Тфү, тфү, син... син үтерәсең инде мине... үтерәсең...

— Сузма!..

— Үтерми тор... бер нәрсә әйтәм мин сиңа...

— Җә!..

Кинәт Мәләк үкереп елап җибәрде:

— Үз ирегем белән эшләмәдем мин моны!.. Эшләмәдем... Ух-ху-ху!.. Котырттылар, котырттылар... Ух-ху-ху... синең теге почта акчаларыңны да...

— Нәрсә?!

— Котырттылар бит, котырттылар!.. Ух-ху-ху... тфү, тфү...

— Әле син!..

— Җук, җук... Әҗере безгә тамды гына... Капчыклы акчаларны Минай...

— Минай?

— Ие, ул алды бар акчаны... Ә мин шыр тиле... Бодайны яшерергә дә Минай кушты... Калганының кайда икәнен әйтермен... Үтермичә түзеп кенә тор!..

— Бодай, бодай, син ни дип минем Сәгадәтемне...

Җамали тагы ярсып китеп Мәләккә типкәләп алды.

— Ух-ух, сөйлим, сөйлим, ух, сөйлим бит инде... тфү, тфү...

— Җә?!

— Бу... бу бер нәзер, тфү, тфү...

— Нәзер? Нинди нәзер?..

— Сәгадәтне бу дөньяда йөртмим дип нәзер әйткән идем... Ух-ху-ху, тфү, тфү...

— Кабәхәт!

*
* *

Җамали карт — Үтәмеш кыясына кадаклап куелгандай. Кыяның салкын сыртыннан кубарылып китәргә аның дәрманы юк. Таш стенага Җамалины терәп куйган кодрәт аның үзеннән көчлерәк. Бу — аның вөҗданы. Вөҗданы Сәгадәт йөзендә сүз алган, ул аның белән йөзгә-йөз. Җамали үзе дә көчсез, сүзләре дә.

— Мәләк шул нәзерен үтәмәкче булып...

— Юк, юк, ул үз-үзен алдаган. Бу аның нәзере түгел. Минайларның нәзере. Менә мин үземнекен үтәдем. Йөрәк кушканын.

— Йөрәк кушканын гынамы?

— Әйе, шулай. Минем нәзер намуслы кешеләрнең гадел омтылышына туры килгән.

— Нинди көчле син, Сәгадәт!

— Син көчсез идең мәллә?

— Синең алда оят миңа.

— Менә монысы миңа ошамый.

— Миңа үләргә бик авыр булыр, һай, авыр булыр.

— Миннән соң эшләгән эшең азмы?..

— Бу синнән качып тору өчен. Элегрәк синең күзеңнән югалу миңа җиңел иде. Көчем-егәрлегем буа буарлык, җитезлегем яшь боландай иде... Ә хәзер хәлсезләндем. Башны кая куяр әмәл юк. Шуңа син миңа чат ябыштың да...

— Тагы көч куеп кара. Бәлки...

— Җук, җук, мин көч куеп карадым инде. Булдыра алганча. Син биек идең. Мин сиңа якынаер өчен җирдә яхшылык эшләргә күп тырыштым: соңгы сугышта явызлыкка каршы корал күтәрдем, канымны агыздым, соңыннан күпме таш пулатлар төзедем. Ләкин вакыт үткән саен син тагы да биегрәк була бардың. Чөнки вакыт үтүе — син табынган дөньяның гүзәлләнүе иде. Ике араны кыскартырга, ай, ничек тырыштым мин. Ә син тагы да ерагайдың — биеклеккә таба.

Җамали карт томан эчендә кызгылт нурдай янган биеклеккә томырылып карады. Күз алдындагы Сәгадәтнең йөзе, тоныклана биреп, шул биеклектә ерагайды, ерагайды... Әнә инде ул илаһи йөз Үтәмеш кыясының иң очында алсу бөҗраларга төренеп дөрли. Ә Сәгадәт, хыялга тиң колачын киң итеп җәйгән дә, дөньядагы бар кешене үз туганыдай якын күреп кочарга әзер. Әйе, бар кешене. Кеше булмаганнарны түгел.

## Фәнис Яруллин

# ЮЛ САЙЛАУ

### Беркем сизмәде

«Тактага язма
Минем исемне,
Укытучы сизәр
Сөю хисеңне».

Тыңладым сине
Мин көндәм генә.
Исемеңне әйттем
Күңелдән генә.

«Клубта берүк
Утырма янга.
Кешеләр үртәп
Тиярләр җанга».

Тыңладым сүзсез
Сине тагын да.
Утырдым башка
Кызлар янында.

«Җырлап үтмә син
Өебез турыннан.
Гыйшкыңны әнкәй
Сизәр җырыңнан».

Юк, җырламадым
Сезнең урамда,
Мәхәббәтемнән
Шашар булсам да.

Үтте яшьлекнең
Язы-көзләре.
Безнең сөюне
Беркем сизмәде.

### Дуэльләр

Бер уйласаң, әле һаман
Булып тора дуэльләр.
Тик дуэльләр генә хәзер
Элеккечә түгелләр.

Атыш юк, секундантлар юк,
Хәбәр итү юк алдан:
Белмисең, кай җирдә сине
Сагалый мәкер, ялган.

Кып-кыска гомер эчендә
Никадәрле дуэльләр:
Үлем ярасын әз-әзләп
Җыеп йөри күңелләр.

●

Урам буйлап атлап барам,
Учта бер йомарлак кар.
Үз учымда эрегәнче
Шуны ыргытасым бар.

Кем куенына атыйм аны,
Кем курыкмый суыктан?
Сак булыгыз, иркә кызлар,
Сак булыгыз — ыргытам.

Ыргыттым — сиңа тиде,
Куенның ачык иде.
Шунда эреде карым.
Булдың гомерлек ярым.

## Күп баскычлы ракета кебек

Гомер буе кеше очышта,
Ничек җитә диген сулышы.
Кеше, ахры, җирнең иң камил,
Иң биеккә очар бер кошы.

Бәлләүендә яткан чагында
Әнкәсенең назлы моңнары —
Йомшак кына итеп күтәреп
Алып менеп китә югары.

Болытларга салып тирбәтә,
Галәм киңлекләрен иңләтә.
Ана моңы, ана җырлары
Канат була нәни йөрәккә.

Балалыктан чыгып җитүгә
Ак канатын бирә мәхәббәт.
Һәм башлана яңа көч белән
Зәңгәр офыкларга сәяхәт.

Ә аннары эшең, иҗатың
Омтылдыра сине биеккә.
Күп баскычлы ракета кебек
Яна-яна күтәрелә кеше,
Яна-яна менә гел күккә.

●

Җәйге төн. Тавышсыз гына
Йолдызлар ява күктән.
Җирдән йолдызларга кадәр
Мәхәббәт юлы үткән,
Юлга ай нурын сипкән.

Шул юлдан атлый гашыйклар
Җай гына, тып-тын гына.
Сөйләшеп бара үзара
Бары ике кул гына.
Куллар тулы моң гына.

Егет учында — кыз кулы,
Кош кебек оядагы:
Я кинәт сискәнеп куя,
Я тынып кала тагы.
Талпына кошның җаны.

Бер кайнарланып китә ул,
Бер салкынаеп ала:
Кыз бала үзенең язмышын
Егет учына сала,
Уйларга кала-кала.

Җавап бирә егет кулы
Бу кулны кысып-кысып.
Учларда — мәхәббәт кошы
Әй, сайрый очып-очып,
Бар җилкенүен кушып.

●

Иң матур юллар —
Син йөргән юллар,
Иң тәмле сулар —
Син биргән сулар,
Иң йомшак куллар —
Син сөйгән куллар,
Иң якты моңнар —
Син белгән моңнар.
Иң кайнар эзләр —
Син баскан эзләр,
Иң моңлы күзләр —
Син баккан күзләр,
Иң тугры сүзләр —
Син әйткән сүзләр.
Иң сабыр йөрәк —
Синең йөрәгең,
Иң талмас беләк —
Синең беләгең,
Иң изге теләк —
Синең теләгең.
Иң бөгелгән бил —
Ул синең билең.
Гөл сибелгән тел —
Ул синең телең,
Үч тотмас күңел —
Синең күңелең,
Әни!

## Мул уңыш көтәм

Мин игенче, ә алдымда
Сөрелмәгән җир.
Сөр аны, буразналар сыз,
Игеннәр үстер.

Орлыгым да әзер инде,
Сайланган-ниткән.
Тик чәчәргә ашыкмыймын,
Нәрсәдер көтәм.

Бер кояшка карап алам,
Бер карыйм җиргә.
Ашыгып, түккән көчләрем
Очмасмы җилгә?

Кире җыеп алып булмый
Чәчкән орлыкны.
Кырларыңда чүпләр үссә
Нинди хурлыклы!

Кырларым — кеше күңеле,
Шигырем — бөртек.
Яшимен һәр чәчкән җирдән
Мул уңыш көтеп.

## Юл сайлау

Болыт әйтте: әй, Кеше,
Юл сайларга теләсәң,
Сайла минем юлымны —
Монда киңлек, монда ямь.

Дулкын әйтте: әй, Кеше,
Сайла минем юлымны.
Су юллары — озын юл,
Тугайлы да болынлы.

Бәхәскә кушылды җил,
Үз сүзен әйтте ул да:
Җир юллары — кыен юл,
Чык, Кеше, шушы юлга.

Кеше әйтте: җаннарым,
Һәммәгезне аңладым —
Болыт юлын сайлармын,
Биеклек өчен җанга.
Дулкын юлын сайлармын,
Киңлек өчен хыялга.
Җилнең юлын сайлармын,
Дәртлелек өчен җанга, —
Үз юлымны сайлармын,
Барыр өчен гел алга.

•

Ялгышмам дип уйлый идем,
Адашмам дип уйлый идем.
Ләкин тормыш
Урман булып юлым япты.
Сине эзләп табар өчен
Адашуны онытып,
Ялгышуны онытып,
Карурманга чаптым.

Иелмәм дип уйлый идем,
Бөгелмәм дип уйлый идем.
Ләкин тормыш
Чишмә булып җирдән акты.
Саф суларын эчәр өчен
Иелү генә түгел,
Бөгелү генә түгел,
Түшләремә яттым.

## Биек менгән саен

Кеше йөрәгендә
Бер матурлык туса,
Күрми генә үтмик
Тыйнаклыкка сылтап.
Күтәрик без аны
Биек-биек итеп,
Күтәрик без аны
Өскә ике куллап.
Җиргә күмелсә дә,
Алтын күгәрми дип,
Коры юатулар
Кайсыбызга кирәк?!
Вакытында әйткән
Рәхмәт сүзе кайчак
Алтын тауларыннан
Була кыйммәтрәк.
Кеше йөрәгендә
Бер батырлык туса,
Күрмәмешкә салынып
Үтеп китмик тизрәк.
Батыр йөрәкләр дә
Җылы сүзгә мохтаҗ.
Батырлыкны да бит
Кешеләр хуплау кирәк.
Кеше кеше булып
Югарыга менсә,
Уйламыйк без аңа
Кирәкмәс дип терәк.
Биек җирдә анда
Җил көчлерәк,
Давыл күбрәк.
Биек менгән саен
Терәк ныграк кирәк.

1977—1978

# Солтан Шәмси

# САГЫНУ

ХИКӘЯ



*Туган ягым — Казан арты. Җиде классны Биектау районының Мәмдәл авыл мәктәбендә бетердем. Казанга килдем, һөнәр училищесында укыдым, аннан язмыш юллары Мәскәүгә алып китте. Заводта токарь, слесарь, шлифовщик, типографиядә китап басучы булып эшләдем. Шул дәвердә кичке мәктәпне тәмамладым, армиядә хезмәт иттем.*

*Күп еллардан бирле дәвам иткән төрле уйланулар, эзләнүләр Горький исемендәге әдәбият институтына китерде. Хәзер Казанда яшим, «Казан утлары» журналында эшлим. Инде күңелдәгеләрне берәм-берәм якты дөньяга чыгара башларга да вакыттыр...*

I

Ишекне ачып бусагадан атлауга авыр операция кичереп өч ай буе палатада яткан Хафизга үз бүлмәләре тансык та, матур да булып күренде. Бөтен җирдә чисталык, пөхтәлек, паркет идәннең кибеп өлгермәгән урыннары каралып тора, агач исе дә бетеп үк җитмәгән иде.

Әлфиясе ыгы-зыгы килеп йөргән арада тәэсирләнеп утырган Хафиз, кунак егете кебек кызыксынып, инде онытыла да башлаган бүлмәне күзәтте. Ул авырып ятканда да тормыш дәвам иткән ләбаса. Менә бүлмәгә дә күпме үзгәреш кергән. Хафиз һәр нәрсәне озаклап, игътибар белән күздән кичереп утырды. Суырылган ак йөзендә, коңгырт-кара күзләрендә шатлык чаткылары күренеп киткәли иде.

Менә каршы стенага яңа пейзаж эленгән. Тау итәгенә сыенган кечкенә генә авыл, биек агачлар арасыннан яссы түбәләре генә күре-

неп торган балчык өйләр, авыл өстендә көньякның юмарт кояшы балкый. Картинадан эсселек бөркелә. Салкынчарак бүлмәгә кояш нуры төшкән кебек. Төсләр дә нәкъ Хафиз ятратканча — күзгә бәрелеп тора. Өстәвенә, тар гына итеп эшләнгән рамы да кояш нуры төсле икән.

Хафиз сак кына урыннан торды, якынрак килеп линогравюраның сыйфатын, буяуларның ничек төшүен җентекләп тикшерде һәм, төгәл төшүләрен күреп, арткарак чигенде, канәгать рәвештә пейзажга тагын бер күз салды.

Түрдә, ярты стенаны алып торган киң тәрәзә каршында, ялтыравыклы кара өстәл, өстәлдәге кечкенә вазада кып-кызыл роза утыра. Хафиз, өстәл янына килеп, розага иелде. Борынына нәфис, тансык хуш ис бәрелде. Бу татлы истән аның күкрәге киңәеп киткәндәй булды; чәчәкнең исе күңелне сихерләп, җанны рәхәтлектә эретеп, күзләреңне йомарга мәҗбүр итәрлек иде. Чәчәк бөтен бер бакчаның ямен, матурлыгын, камиллеген һәм, ниһаять яшерен сихриятен үзенә туплагандыр сыман тоелды аңа. Һәм шул мизгелне хәтерендә япон язучысы Кавабата сүзләре калыкты: «Чәчәкнең матурлыгы, гүзәллеге йөз чәчәккә караганда аерым бер чәчәктә камилрәк чыгыла».

Бу ялгыз роза, чыннан да, гүзәл иде. Хафиз күзен алмыйча озак карап торды. Таҗына кунган алмаздай саф тамчыларның дерелдәп-дерелдәп куюын, бәрхеттәй йомшак таҗ яфракчыкларының нәфислеген, табигать тудырган бу камиллекнең серен акыл белән генә аңлап бетермәле түгел иде...

Кухняда өстәл әзерләп йөргән Әлфия, нидер эзләп, бу якка чыкты һәм, өстәл янында исәрләнеп торган Хафизга елмаеп кире чыгып китте. «Кара син Әлфиянең бөтен шартын китереп каршылавын»,— дип, Хафиз эченнән генә куанып куйды. Әйе, аның тормышында бик күп нәрсә Әлфия белән бәйле. Ансыз әлеге чәчәк һәм шуңа охшаш бик күп гүзәл нәрсәләр тормышына килеп кергән булыр идемени?

Аннан Хафиз стенаны тутырып тезелгән китапларына борылды. Китаплар — аның горурлыгы. Хафиз аларны гомере буе җыя. Алар сагынылган. Терелеп тагын шулар янына кайтуын нинди түземсезлек белән көтте ул... Монда да үзгәрешләр бар иде: кайбер китапларның урыны алышынган, берничәсенең урыны бөтенләй буш. «Берәрсе укырга алып торгандыр»,— дип уйлады ул һәм, якынрак килеп, тезелеп киткән бөек исемнәрне барлап чыкты. Менә ул үзенә аеруча кадерле булган бер китапны кулына алды, урта бер җиреннән ачып, таныш текстка күз салды:

«...Букет ясаучы осталар чәчәкне беркайчан да тикшерми-нитми өзмиләр; башта алар һәр чәчәкне төрле яктан карап, өзеләсе чәчәкнең кая, нинди вазага куеласына кадәр исәпкә алып эш итәләр, чөнки ясаласы букетта һәр чәчәкнең үз урыны бар. Яфракларны да, Европадагы кебек, өзеп ташламыйлар, бу — чәчәкнең бөтенлеген, гармониясен боза. Букет ясалып беткәч, оста аны бүлмәнең билгеле бер урынына куя. Букет ныграк тәэсир итсен өчен аның янәшәсендә башка бер әйбер дә булмаска тиеш. Оста тарафыннан ясалган композицияне урыныннан күчерсәң, ул үзенең кыйммәтен югалта, чөнки оста аны ясаганда, әйләнә-тирәдәге әйберләрне исәпкә алып эш иткән...»

Хафиз, китаптан аерылып, өстәлдәге розага борылды. Туры килсә дә килер икән текстка!.. Кара өстәл, нечкә генә кара сызыклар төшкән ак ваза, аңа утыртылган ялгыз роза — зәвык белән берләштерелгән бу өч әйбер берсен-берсе тулыландырып, бүлмәгә ямь өстиләр иде.

Хафизның күңеле күтәрелеп китте. Больницадан кайтып кергәннән бирле аның күңелендә җылылык арткаааннан-арта бара иде.

Әлфиянең куллары тылсым көченә ия булганын ул инде күптән белә, чөнки хатыны гади генә әйберне ничектер үзенчә борып, берәр

нәрсә белән янәшә куйса, әйбер шунда ук үзгәрә, игътибарны җәлеп итә башлый. Хафиз аның бу табигый сәләтенә соклана иде. Аның чәчәкләрне үлеп яратуын да ул хуп күрә, үзенә әйтмәсә дә, хатынының бу сыйфатына куанып бетә алмый иде.

Хафиз кулындагы әлеге китапны да Әлфия туфлигә дип чыгып киткән җиреннән табып кайтты. «Туфли табылыр, ә менә китапны ычкындырасым килмәде»,— диде ул, өйгә кайтып кергәч.

...Хафизның уйларын бүлеп, кухнядан Әлфиянең:

— Әйдә чык, өстәл әзер,— дигәне ишетелде.

Хафиз китапны урынына куйды да кухняга чыкты. Әзер өстәл янында икмәк кисеп торган Әлфияне артыннан килеп кочаклады, хуш исле чәчләренә борынын төртте, кинәт тынып калган хатынының җылы, нәфис муеныннан сак кына үпте. Аннан:

— Белсәң иде сагынганымны, Әлфиям,— дип колагына пышылдады.— Рәхмәт сиңа... Барысы, барысы өчен дә рәхмәт. Сагындым үзеңне... Өебезне сагындым...

## II

Хафиз авылда үсте. Кышларын кар-буран ерып күрше авыл мәктәбенә укырга йөрде, чаңгы шуды, ә җәйләрен... Хәер, авыл малаеның җәйләре ничек узганны бер-ике сүз белән сөйләп бетерерлекме соң? Бигрәк тә Хафиз кебек ятим малайның җәйләре ничек узганны...

Ул әтисен хәтерләми диярлек. Аны җирләгәндә Хафиз өч яшьлек сабый гына иде әле. Үзен белә-белгәннән бирле алар әнисе белән икәүдән-икәү...

Әлфия өйгә еш кына чәчәкләр тотып кайтып керә. Хатынының шуларны кадерләп вазага утыртуын, төрле композицияләр ясап, ихлас күңелдән куанып йөрүен күреп, Хафиз авылны, малай чакларын исенә төшерә һәм шәһәрдә үскән Әлфиясенең бала чагын үзенеке белән — авыл малаеның көннәре белән чагыштырып уйлана иде.

Хафиз малай чакта авылны әле машина-трактор басмаган, болыннар да актарылып кара җиргә әверелдерелмәгән иде. Ул заманда авыл җирендә яшеллек тә күбрәк, урамнар да матуррак иде; ә малайлар җәйгә чыгу белән чирәмдә ауный-ауный каз бәбкәләре каравыллыйлар иде. Тәпи йөри башлаган һәрбер бала шушы дөньяга аяк атлый, бераүнең дә башына хәзер телевизордан бик еш сөйләнелә торган табигатьне, яшеллекне, үләнне-чәчәкне саклау турындагы уй килми. Ул чакны болар беркайчан да кимемәс, бетмәс кебек тоела, шагыйрьләр дә табигать турында язганда «иксез-чиксез», «бетмәс-төкәнмәс» дигән сүзләрне ешрак кулланалар иде. Бу табигый дөнья авыл малае өчен ишек тоткасы кебек гадәти дә, күнегелгән дә иде ул чакларны. Әгәр беркөнне кояшта каралып янган, аягына «чеби» чыккан Хафиздан: «Син чәчәкләр яратасыңмы?» — дип сорасалар, ул, мөгаен, җавап урынына сиңа сәерсенеп, әллә җитешми инде моның, дип кенә караган булыр иде. Чөнки шәһәрдән кайтканнар исләре китеп чәчәк дип йөргән күп нәрсә авыл малае өчен кырда үскән чүп үләне. Ул аны утап мал-туарга сала.

Кеше табигатьне аннан аерылгач кына сагына, юксына башлый икән. Кадерен дә аерылгач кына белә. Хафизның хәзерге халәте дә, ягъни Ерак Көнчыгыш халыкларында барлыкка килгән табигатькә бәйле фәлсәфә һәм эстетика белән кызыксынып китеп, университетны бетергәч, шул юнәлештә аспирантурада укуы да нәкъ менә табигатьтән аерылу, аны юксыну галәмәте түгел микән әле! Кешегә со-

циаль продукт итеп кенә карау дөрес түгеллеген, аның табигатьтән аерылгысыз бер зат икәнлеген ул күптән чамалый иде, әлбәттә.

Кайвакыт Хафиз үзенең ничек шушы юлга кереп китүе, матурлыкны тою дигән нәрсәнең кешедә ничек яралуы, үсүе, ниһаять, ныгып, гомергә аны үзенә гашыйк итүе турында уйлана һәм күз алдына нигәдер малай чакта булып үткән бер вакыйга килеп баса.

...Ул җәйне күршедәге Нәгыймә карчык янына шәһәрдән кунакка кечкенә генә кызчык кайтты. Нәгыймә карчык ялгызы гына яшәгәнлектән, ул йортта кыска күлмәкле, чәченә күбәләк төсле ак бантик таккан ак чырайлы бу кызга аралашыр кеше, уйнарлык иптәш тә юк иде. Шуңа күрә ул гел ялгызы гына ишегалдында, бакчада, капка төбендә чуала, кулында һәр вакыт нинди дә булса чәчәк утыртылган банкамы, шешәме була. Чәчәкләрнең суын алыштырып, мыштым гына йөри. Менә ул бакча рәшәткәсенә кунган күбәләкне күреп катып кала, чыпчык сагалаган песи кебек посып күзәтә, очып китсә, озак итеп аның һавада мәтәлчек ата-ата очканын карап тора. Кыскасы, бу нәни кызның уйнарга иптәше булмаса да, ул күңелсезләнеп, ялгызлыктан интегеп утырмый. Әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсә аңа кызык, серле, ул һәр вакыт ни беләндер мәшгуль, шуның белән юанып көн үткәнне сизми дә кала. Аның үз дөньясы бар...

Бераздан кызчык батырая төште. Үзләренең капка төбенә чыгып утыргалый башлады, ерак китмәсә дә, урамда еш күренгәли иде. Ә беркөнне Хафиз аны үзләренең капка төбендә күрде.

Хафизның кызу эш вакыты — ул печән әзерли. Аларның сыеры булмаса да, олы җиленле, күп сөтле ак кәҗәләре, ике сарыклары бар. Сыер асрау ялгыз әнисенең генә көче җитә торган эш түгел иде шул. Хәер, аның вакыты да юк, ул көне-төне фермада. Кышны шул Хафиз ташыган белән чыгалар. Озынрак кышларны, аннан-моннан акча юнәтеп, күрше авыл базарыннан өстәмә печән дә алырга туры килгәли иде.

Берзаман әлеге кызчык Хафизның кырдан үлән төяп кайтканын аларның капка төбендә көтеп утыра торган булып китте. Ике бүкәнгә сузып кадакланган такта өстендә аякларын селкетеп утыруын белә. Тирләп-пешкән, тузанлы йөзеннән юл-юл булып тир аккан Хафизның ике көпчәкле арба белән килеп туктавын, арба тартасен җиргә куеп, капканы ачуын, аннан ике багана арасына кысыла-кысыла ишегалдына үтүен карап тора иде ул.

Башта Хафизның моңа исе китмәде, ләкин мондый кызыксыну көн дә кабатлана башлагач, игътибар белән кызчыкка караса, теге арбада яткан зәңгәр чәчәкләргә кызыгып утыра икән бит.

Менә Хафиз ишегалдына кереп арбасын чиште, бушатты һәм әле һаман да капка төбендә утырган кызчыкны (аның исеме Лилия булып чыкты) чакырып алып, бер банкага утыртырлык чәчәкләр сайларга кушты. Лилия, моны ишеткәч, ярамаган эштә тотылгандай, башта кып-кызыл булып кызарды, аннан ышанырга да, ышанмаска да белмичә сынап Хафизга карады. Хафиз елмаеп: «Ал, ал!» — дигәч, кыймыйча гына чәчәк араларга кереште. Матуррагы, яньчелмәгәнрәге эләккән саен күзләре бәхетле елтырый иде...

Гаҗәп хәл! Бала чакның шушы хатирәсе исенә төште исә, Хафиз әлеге кечкенә кызчык урынына үзенең Әлфиясен куеп карый. Кыска күлмәкле ул шәһәр кызы Лилия түгел, Әлфия үзе булгандыр сыман тоела башлый Хафизга. Әлфия дә кечкенәдән шулай табигатьне яратып үсмәсә, мондый зәвык, нечкәлек, нәфислек каян килер иде...

...Теге җәйне Хафиз, гомерендә беренче тапкыр буларак, бәрәңге җиреннән кулларны суйдырта-суйдырта утаган гап-гади зәңгәр чәчәкнең малга ашатудан тыш тагын бер кыйммәте бар икәнен белде.

Бу чүп үләне дип аталган чәчәкләрнең кечкенә Лилияне бәхетле итә торган нindидер көчкә ия булуын күреп, ул бик тә гаҗәпләнде. Хафиз булып Хафиз, зур үскән малай, шушы нәзек бармаклы кызчык каршында үзенең тупаслыгын сизеп, кимсенүгә охшаш бер тойгы кичерде.

Бәлки әле эстетиканың беренче сабагын да Хафизга шул кызчык биргәндер, аның алдында беренче тапкыр үзенең тупаслыгын сизү малайны сагаерга мәҗбүр итеп, әйләнә-тирәсенә игътибар белән рәк карарга, үзенең бигүк камил булмаган якларын күрә белергә өйрәткәндер... Ул кадәресен хәзер инде кем белә, әмма чәченә ефәк тасма таккан ул кызчык хәтерендә тикмәгә генә алай калмагандыр...

Шулай да табигать кочагында үскән авыл малае матурлыкка сукыр була алмыйдыр ул. Табигать — ана кебек, аны яратмый, хөрмәт итми мөмкин түгел. Табигатьнең яшел күкрәгендә кызарып пешкән җиләкләрне җыйган малайда матурлыкны сизү булмый калмас, ләкин аны әле үстерәсе, тәрбиялисе, ныгытасы гына булгандыр...

Сигезенче классны тәмамлаган җәйне Хафизлар шәһәргә күчтеләр.

## III

...Күп еллар үтте. Хафиз эшләде, аннан укыды, әле дә укый. Вакыт үтү белән ул беренче карашка файдасыз булып күренгән әйберләрнең дә зур мәгънәсе һәм файдасы барлыгын елдан-ел тирәнрәк аңлый барды.

## IV

Иртәгесен Хафиз шактый соң уянды. Кичәге көн мәшәкатьләре: кием-салымны алыштырып, документлар өлгергәнче әрле-бирле коридорда йөрүләр, өч ай буе тәмам дуслашып, туганнар кебек якынаеп беткән врачлар, шәфкать туташлары, нянялар, авырулар белән саубуллашу, күргән-белгәнне сөйләп йокысыз төннәр үткәргән палатадаш егетләр белән кул кысышып, терелеп чыгуларын теләп аерылышулар аннан сакланып кына таксида кайту (операциянең җөйләре нығып җитмәгән иде әле), кайтып кергәч, ял итә-итә Әлфия белән бишенче каттагы квартирага менү, күңелен биләп алган яңа хисләр, тәэсирләр — болар барысы да әле тазарып җитмәгән Хафизга җитә калган иде, күрәсең. Үз өендә, Әлфиянең йомшак сулышын күкрәгендә тойган килеш, изрәп, тынычланып ял иткән Хафиз.

Әлфия иртәрәк торып каядыр чыгып киткән иде. Хафиз уянып тәрәзә янына килде, чалт аяз күкнең зәңгәрлегенә сокланып карап торды. Биектә, шәһәр өстендә, карлыгачлар уйный иде. Урамның каршы ягында кара комбинезон кигән ике кеше түбә буйыйлар. Түбәнең буялган өлеше кызыл элпә япкандай кояшта ялтырый.

Аста, урамны тутырып, бакча яшелләнеп утыра; ике яклап өрәңгеләр, гөлҗимеш куаклары сузылган, уртада төрле төстәге чәчәкләр белән чуарланган клумба.

Хафиз больницага кергәндә әле бу яшеллек тә, чәчәкләр дә юк иде. Әле генә кардан ачылган клумба тирәсендәге озын урындыкларга, яз килүгә куанышып, сөякләрен җылытырга карт-коры килеп утыра иде...

Шул мизгелдә Хафизның хәтеренә уналты яшьләрендәге бер кыз килеп төште. Алар әнисе белән клумба янына атнага бер тапкыр — ял көнне генә киләләр иде. Башка көннәрне әнисенең вакыты юктыр,

кыз бердәнбер көнне түземсезлек белән көтә торгандыр, дип уйлый иде Хафиз.

Ана белән кыз скверга гадәттә төшкә кадәр үк килеп, култыклашкан килеш, акрын гына зур клумбаны әйләнәләр, аннары скверның асфальт сукмаклары буйлап китәләр иде. Кызы, тураеп каткан аякларын алмаш-тилмәш китереп, авырлык белән янәшәдә атлый. Бераз баргач, туктап ял итәләр, акрын гына нидер сөйләшәләр, кайвакыт кызның ак чыраенда елмаю хасил була. Хафиз аларны ял саен шушы тәрәзә аша күрә иде. Шуңа игътибар итте дә.

Бүген исә сквер буш булса да, Хафизның хәтеренә нигәдер нәкъ менә шул ана белән кыз килеп төште һәм ул, тетрәнеп, кызга ул-бу булды микән әллә дип уйлап куйды...

Ул тиз генә тәрәзә яныннан китте. Аның бүген үткәннәргә кире кайтасы килми иде. Зур бәладән котылган һәрбер кеше кебек, ул бүген, монысы инде соңгысы, бүтән авырмам, алдагы тормышым ямьле, матур, бәхетле булыр, дип чын күңелдән ышана, шундый өмет белән яши, план кора иде.

Урынны җыйгач, Хафизның күзенә кичәге роза төбенә куелган кәгазь чалынды. Кәгазьне алса, анда түгәрәк, йомры хәрефләр белән: «Хафизым! Мин озак тормам!» диелгән һәм аскарак, кул куясы урынга озын койрыклы кошчык рәсеме ясалган иде. Хафиз көлемсерәп кошчыкка карап торды...

Күп тә үтмәде, тышта йөрүдән алсуланып, Әлфия үзе кайтып керде.

— Әй, көннең матурлыгы,— диде ул, сумкасыннан азык-төлек бушата-бушата.— Үзе җылы, үзе тыныч, җилнең әсәре дә юк.

Әлфиянең ак тешләре җемелдәп куйды.

— Әле мин дә, уянгач, тәрәзәдән карап тордым...— диде Хафиз, башы белән якты урамга ымлап.— Күк шундый чиста, карлыгачлар уйный, скверда яшеллек, аякларны сузып үлән өстендә бер утырасы килеп китте. Әллә мәйтәм...

Хафиз сораулы карашын Әлфиягә төбәде. Тегесе аның тел төбен аңлап:

— Болынгамы, болынга барабызмы? — дип, тиз генә сорап куйды.

Хафиз «әһә» дип баш какты, куанып елмайды, сөйләп китте.

— Әле больницада ук, терелеп чыксам, беренче булып шунда барырбыз дигән идем... Больницада яшеллеккә бигрәк тә сусата икән ул.

— Ярар, барырбыз,— диде Әлфия, куллары белән Хафизның иңенә кагылып.

Хафиз аны биленнән тотып сак кына үзенә тартты, аннан күкрәгенә кысты. Назга сусаган Әлфия, хискә бирелеп, күзләре йомыла, иреннәре ачыла башлавын сиздe һәм үзен кулга алып:

— Әйдә алайса, чәй эчик тә китик,— диде.

Алар «болын», «безнең болын» дип йөргән бу җир чынында исә үлән белән капланган бер почмак булып, Хафизлар торган йорттан әллә ни ерак түгел иде.

Көннәр ачылып, матураеп киткән чакларны яки бүлмәдә озак утырып арыган, йончыган вакытларны Хафиз белән Әлфия, кинәт исләренә төшеп, җилләнеп кайтыйк әле дип, шушы «болынга» чыгып китәләр иде. Җәйге шәһәрнең кызган асфальтыннан, тузаныннан, гөрелтесеннән, бензин исе таралган бөркү һавасыннан, таш коридор булып сузылган урамнарыннан туеп, бер-ике сәгатькә генә булса да шушы кысыр җирдә онытылып, кинәт өсләренә иңгән тынлыкка колак салып утыралар.

Җыенып болынга китүләр Хафиз белән Әлфияне тагын да якынайта, җәй уртасының җылы яңгыры кебек күңелләренә сафлык өсти, хисләрен яңарта иде. Бу җирне дә бит беренче тапкыр Әлфия «табып» кайтты. Табып кына түгел, бер кочак кыр чәчәкләре дә күтәреп кайтып керде. Аннан бүлмәне болын исенә, печән өстендәге җил исенә тутырып бизәп чыкты. Нәкъ шул көннән алар бу җирне «безнең болын» дип йөртә башладылар һәм анда бару үзе бер бәйрәмгә әверелеп, гадәткә кереп китте.

Әйләнә-тирәсендә биек йортлар төзелеп, инде шәһәрнең эчендә үк диярлек утырып калган бу җир кисәге киләчәктә ни дә булса төзү максаты белән калдырылган булгандыр, күрәсең. Ләкин узган җәйне анда хәтфә палас кебек яшеллек хөкем сөрә иде әле.

Сул яктан болын шактый биек коймага барып тоташа. Койманың теге ягында ниндидер тәҗрибә участогы урнашкан, анда көнозын эш кайный, түтәлләр арасында чыр-чу килеп яулыкларын күзгә төшереп бәйләгән апалар йөри иде. Болынның түрендә тоташ пыяладан эшләнгән теплица кебек тәбәнәк, озын корылма сузылган. Пыялалары кояшта ялтырый. Кайчагында аннан эт өргән тавышлар ишетелә. Хафиз күпме кыстаса да, Әлфия анда хәтле барырга курка иде.

Хатынының эттән курка торган гадәте исенә төшеп, Хафиз елмаеп куйды, күз кырые белән генә кулын аның беләгенә салып баручы Әлфиягә күз салды. Аяз көннең каршыдан сирпелгән кояшында Әлфиянең кысыла төшкән керфекләре җемелди, йөзенә шатлык катыш дулкынлану билгеләре чыккан иде.

«Дулкынланырсың да,— дип уйлады Хафиз, үзенең дә менә бераздан болынга җитеп, бишектә тирбәлгән нарасыйдай таралып үләннәр арасында утырасын күз алдына китереп.— Быел бит беренче тапкыр баруыбыз...» Ул соңгы өч айны Әлфиянең күңелендә бер-берсен алыштырып хәвеф һәм өмет яшәвен, аның да университет белән больница арасында йөреп шактый арыган, талчыкканлыгын күреп назлы кызгану кичерде, йомшак кына итеп иңеннән кысты.

Өстәл яныннан кубып урамга чыкканнан бирле Хафиз ниндидер күтәренкелек белән һаман шул болын турында уйлады, күз алдында һаман болын тора иде. Ә болынны исенә төшерде исә, аның каршына һәр вакыт чәчәк җыючы Әлфиясе килеп баса һәм хатирәләр йомгагы сүтелә башлый...

...Ул көнне Әлфия үзен ничектер сәер тоткан иде. Әле тиктомалга серле итеп елмаеп куйгалый, әле онытылып бер ноктага төбәлеп тора, кайвакыт көтмәгәндә йөзенә кызыллык йөгерә.

Хафиз аның бу халәтен сизенсә дә, сорарга батырчылык итмәде. «Кирәксә үзе әйтер,— дип уйлады ул.— Хатын-кызның күңелендә ни генә булмас, вакытсыз соравың белән эшне бозуың бар...»

Өйләнешеп бергә тора башлаган гына чаклары. Әле бер-берсен чынлап торып аңлап та бетермиләр, күп вакыт өзелеп ярату һәм бер-береңә соклану гына кискен сүзләрдән коткарып кала, үпкәләгәндә дә тиз килештерә иде.

Ниһаять, иртәдән бирле үзен сәер тоткан Әлфия түзмәде. Тәрәзә янына сөялеп китап укыган Хафиз янына килде дә, күтәрелеп карарга тартынып, аның ак күлмәгенә төшкән вак-вак кызыл чәчәкләрнең берсен тырнагы белән бөтерергә кереште. Хафиз китабын бер читкәрәк куйды, Әлфиянең нидер әйтәсе килеп икеләнүен күреп, биленә кулын салды. Шул мәлне хатыны дулкынланып, оялып:

— Хафиз... минем кәефләрем үзгәреп тора, буемда бардыр, ахры,— диде һәм кызарган йөзе белән Хафизның күкрәгенә капланды.

Бу минутта Хафиз үзен кинәт шарлавык астында калгандай тойды, өстенә моңа кадәр кичерелмәгән яңа хисләр ташкыны ябырылды.

Йөрәгендә тоташ тантана иде, гүя ул яшәешнең тагын бер баскычына күтәрелде. Гомердә онытасы юк ул минутны!

Көтелмәгән шатлыкның беренче дулкыны үтеп бераз тынычлангач һәм аларны тагын да якынайткан бу хәбәргә күнегә алмыйча, гаҗәпләнеп, ишекле-түрле йөргәннән соң, ул көнне дә менә бүгенге кебек үк болынга дип чыгып киткәннәр иде бит...

Ул якты көн әле дә булса Хафизның күз алдында.

Менә алар икәүләшеп болынның үзләре килеп чыккан очыннан үткәрелгән тимер юлда торалар. Моннан карасаң, болын уч төбендә кебек, чөнки чуерташ өеп төзелгән тимер юл шактый биектән уза. Шул биеклектән каршыда җәелеп яткан кыргый җирне күзәтәләр. Баягы хисләргә яңалары — торган саен факыйрьләнә баручы табигать белән очрашу куанычы өстәлә.

Ләкин кая инде ул Әлфиягә мондый чакны түзеп тору! Кулларын кош канаты кебек җәеп, ул аска йөгереп төшә, биек үлән арасына кереп, бер-ике чәчәк өзә. Аннан, борылып, арттан килүче Хафизга:

— Әйдә, тизрәк... Кара син бу матурлыкны, бу киңлекне,— дип кычкыра. Аның йөзе балкый, икегә аерып тараган кара чәче кояшта җемелди.

Хафиз төшеп җиткәндә, Әлфия инде, куе үләнне ерып, шактый алга үткән иде. Хафиз да азрак эчкә узды, калкурак урынга басып, бер мизгелдә бөтен болынны күзләренә сыйдырырга теләгәндәй, карашы белән тирә-юньне айкап чыкты. Тын иде, шәһәр авазлары тимер юлның теге ягында калды, гүя бу минутта хәрәкәт туктап, тормыш кинәт тынды. Хафиз тирән итеп сулыш алды. Кара син, ә, ул китапханәләрдә утырганда җәй уртасы да җиткән ләбаса. Үләннәр ныгып, карасу-яшел төскә кергәннәр. Аксыл таплар булып уйдык-уйдык ромашка күренә, каралып, күч-күч тигәнәк үсә, салмак җилдә алабутаның юка яфраклары селкенгәләп ала, арырак, сул яктагы койма буенда, кояштан күзен аера алмыйча көнбагыш утыра.

Әлфия инде шактый ерак китте. Ул иелеп-иелеп нидер җыя, аратирә күкрәгенә төшкән толымын артка чөя, чуар блузкасы бер күренә, бер күздән югала.

Хафиз янында гына аунап яткан бетон плитага килеп утырды, кулларын артка куеп таянды да күккә карады. Бетон җылы һәм кытыршы иде. Вак цемент кисәкләре юкарган учына кадалдылар. Җир кибеп беренче тапкыр урамга чыккач та нәкъ шулай була торган иде. Кыш буе киез итектә йөргән табанның тиресе юкара, кечкенә ташка бассаң да, аяк авырта. Кешене дә мәдәният шулай нечкәртеп, сизгерләндерми микән?

Болын өстендә яткырып куелган кувшинга охшаш кечкенә болыт асылынып тора. Аннан тамчылар тамар да Әлфияне чылатыр сыман. Хафиз шул бердәнбер ак болыттан күзен алмый утырды. Тәненең бөтен күзәнәкләренә кояшның шифалы, тансык нурын сеңдереп, бу мәлне күңелен камап алган тынлыкка һәм шул ук вакытта минут саен ныгый барган ышанычка гаҗәпләнеп куйды: «Бу тынлык, әлеге күңелгә иңгән ышаныч — бәхет үзе түгел микән?..»

Утыра торгач, ул бире таба килүче Әлфияне күреп алды. Шул вакыт артта рельслар гүли башлады. Электричка якынлашып килә иде. Менә ул көтмәгәндә нечкә итеп сызгыртып куйды. Бу кискен тавыштан Хафизның күңеле әллә нишләп китте. Тавыш, моңсу көйгә әверелеп, чәчәкләр күтәреп килгән Әлфиянең баш өстеннән үтте, аннан болынга таралды, ерагайды, ерагайды да, ниһаять, бөтенләй сүнде. Шул мәлне Хафизның күңеле нечкәреп, хрусталь челтерәгәндәй булды, хисләре ташып, тыны кысылды... Аның аңында галәм киңлекләрендә туган яңа йолдыз сыман кинәт нидер кабынып, бөтен барлыгын үзенең яктысында эретте...

Болын өстеннән, үләннәрне җиңел тибрәтеп, салмак җил узды, Хафиз аның йомшак канатын тоя, күзләрен йомар-йоммас утыра бирде. Бераздан ул үзендә әйтеп бетермәслек җиңеллек сизде. Бу минутта ул инде салмак адымнар белән аңа таба килүче Әлфиянең гомерлек дус булачагына тәмам ышанган иде. Тормышлары бәлки бик җиңел дә булмас, ләкин юлларында нинди генә авырлыклар, бәла-казалар очраса да, алар барысын бергәләп җиңәрләр; бу ышанычлы, гүзәл кеше ул сайлаган авыр һәм ләззәтле эштә аның ярдәмчесе, киңәшчесе, балаларының анасы булыр; Хафиз аңа йөрәгендә кайнаган уйларын, серләрен сөйләр һәм Әлфия аны, мәрхүмә әнисе кебек үк, бер вакытта да аңламый калмас...

Шул мәлне: «Ир затка аның әнисен алыштырырдай кеше генә яхшы хатын була аладыр ул»,— дип уйлаганы инде ике ел үтсә дә хәтерендә Хафизның. Ә менә нарасыйлары аларга насыйп булмаган икән. Аны кулга алып сөю бәхетенә ирешә алмадылар...

Үткәннәр турында уйлап бара торгач, Хафиз тимер юлга килеп җиткәннәрен сизми дә калды. Инде бары тик чуерташ арасында үскән әремнәргә тотына-тотына, шпал исе аңкып торган тимер юл өстенә үрмәләп менәсе бар. Анда менсәң, каршыңда бөтен киңлеге белән болын ачылачак. Һәм күзләреңне ял иттереп бераз торганнан соң аска, яшел үләннәр кочагына ташланачаксың...

...Ләкин тимер юлның теге ягында аларны сихерләгән, күңелләренә кадерле утрау булып кереп урнашкан ул дөнья юк иде инде. Аның урынына йөк машиналары таптап-изеп бетергән кара җир, шул җир өстенә аударылган күч-күч ватык кирпеч һәм бетон кисәкләре, сынык агач-богач, кәгазь тартмалар, ниндидер саны-санга аерылган әрҗәләр, түбәтәйгә охшап тыпырдап каткан измә өемнәре, кыршаулары төшкән агач мичкәләр һәм башка мең төрле шәһәр чүбе аунап ята иде. Ә болынның аргы ягында чүплеккә әйләндерелгән бу җирне тигезләп ятучы бульдозер тавышы ишетелә. Күрәсең яңа төзелешкә мәйдан әзерләүләредер...

Хафиз белән Әлфия көтелмәгән бу күренештән катып калдылар. Әлфия, күңеле тулып, иренә сыенды. Хафиз аның дымлы күзләрен күреп, хатынын күкрәгенә кысты, юаткандай итеп бер-ике тапкыр чәченнән сыйпады...

Дөньяда нәрсәдер кимегән иде һәм моның өчен Хафиз үзен дә гаепле итеп тойды, бигрәк тә табигатьне сөйгән Әлфия алдында гаебе бар сыман иде.

Шул вакыт якынлашып килүче товар поезды чыелдап куйды. Алар юлдан төшеп, читкәрәк тайпылдылар. Менә колак төбендә, якты көнне урталай ярып, тәгәрмәчләр тукылдый башлады. Хафиз белән Әлфия юл кырыенда вагоннарның тизрәк үтеп күздән югалуын һәм әйләнә-тирәдә яңадан тынлык урнашуын көттеләр.

Изаил Зарипов

# ХЫЯЛЛАР ОСТАСЫ



Бораулаучылар көн саен таныш скважина яныннан үтәләр. Дамир Нуретдинов бригадасы аны биш-алты ай элек бораулаган иде. Егетләр, аның яныннан узганда, бер-берсенә карашып ала, кайберләре телгә дә килә:

— Һаман килеп җитмәгәннәр икән...

— Нефть чыгаручыларны әйтәсеңме?..

— Башка кемнәрне булсын.

Бу сүзләр Дамирның йөрәгенә уктай кадала. Моның өчен үзенең гаепле түгеллеген дә белә, ләкин борчылуын баса алмый. Скважинаны айлар буе эшләтми торуга һич күнегә алмый ул, ниндидер хикмәтен табып, хәлне үзгәртәсе килә. Беркөнне «иске таныш» янында бер кеше күренде. Дамирның эченә җылы бәреп керде. «Ниһаять, җитешкәннәр икән!..» Бригадир шофердан вахта автобусын туктатып торуын үтенде дә, машинадан төшмичә генә ишекне ачып, скважина янындагы кешегә эндәште:

— Нишләп нефть бирми бу? — Нуретдинов кулы белән скважина ягына ымлап алды.

Оператор ир уртасы кеше — чатнатып җавап бирде:

— Син моны бораучылардан сора, агайне. Арматураны тиешенчә кормаганнар, эшләтеп җибәрүе — мең бәла. Тирә-ягыңа да күз салып бак: мазут диңгезе бит, әй! Күрәсеңме?.. Аларга нәрсә — бораулыйлар да хуш иттек — без киттек!.. Операторлар чиләнсә дә ярый. Шул да булдымы эш?..

Дамир бригада егетләренә карап алды. Барысы да сөйләшүне ишетеп тора, хәлне үз күзләре белән күрә. Чыннан да, әйбәт эш түгел шул.

Нуретдинов шушы минутта үзенең ни уйланып, ниләр кылырга җыенып йөрүен әйтсә, бөтен бригада дәррәү күтәреп алыр иде, мөгаен. Ләкин Дамир үз күңелен күптән борчып торган фикерне һәм ниятләрен ачып салырга ашыкмады. Соңгы карарны бригадага әйткәнче, тагын җиде кат исәплисе бар әле.

«Сәер хәл, — дип уйланды үзалдына Нуретдинов. — Бораулаучылар скважиналарны срогыннан элек тапшыра. Ләкин алар әзерләгән

эш мәйданына операторлар килеп җиткәнче айлар уза, кайчагында ел да үтеп китә. Булмый болай, башкача кирәк!»

Шул «башкача» дигәне хакында бригада белән киңәшергә җыена да инде ул. Бөтен коллектив бердәм тотынса гына барып чыгачак бу эш.

Мастер башта үзенең булган тәҗрибә хәзинәсен күздән кичерде. Күп еллар буена тупланган ул, анда сөендерерлек уңышлар да, маңгайда сырларны арттырган ялгышлар да бар.

Нуретдиновның эш урыны сызымнар, саннар язылган кәгазьләр, схемалар белән тулды, үтә четерекле мәсьәләне хәл итәргә утырган галимнең эш өстәленә охшап калды. Шунысы мөһим: аның алдында яткан кәгазьләрдә теория сүзләре түгел, ә практик эш җимешләре теркәлгән. Шуларга таянып, Дамир Нуретдинов нефть скважиналары бораулаучыларның хезмәтен яңача оештырырга тели. Хәзер инде фикере ачык: кыр уртасында скважиналарны әзерләү завод конвейерындагы шикелле булсын, вышка төзүдән башлап, беренче нефть алынган минутка кадәр анда эш өзелмәсен. Бораулаучылар үзләре корган скважинадан алынган «кара алтынны» үз күзләре белән күрсен, операторлар алардан нефть чыгып торган эш мәйданы кабул итеп алсын. Дамирның нияте шундый. Бу, әлбәттә, бригадага өстәмә эшләр йөкләячәк. Моны артык мәшәкать итеп санамаслармы? Мастер шул хакта бораулаучылар белән дә киңәште. Петр Рыжиков һәм Мөхәммәтзәки Сәйфуллин аның фикерен хуплап каршы алдылар.

Бригадага яңа скважина борауларга кушылды. Гадәти генә эш түгел. Геологлар дистәләгән сорау әзерләгән — бораулау барышында шуларга җавап көтәчәкләр. Арадашчыларның да уңганлыгы, өлгерлеге тикшереләчәк. Дамир сөенеп бетә алмады. «Менә ул — скважина кору конвейерын сынап карау өчен иң җайлы вакыт!»

Идарәнең баш геологы Николай Александрович Плотников бригадага йөкләнгән яңа бурычны бик тәфсилләп аңлатты.

— Бу скважина сынау тәртибендә бораулана, — диде ул. — Бригаданың осталыгына имтихан да, арадашчыларның үзара мөнәсәбәтләрен яхшырту максатында үзенә күрә бер тикшерену дә ул. Монда бөтенесе төгәл исәпләнгән, төгәл башкарылырга да тиеш. «Авария» дигән сүзне онытыйк, әйе, телгә алынмаслык булсын андый хәтәр атама. Бурыч бик җитди: девон катламнарыннан өстәрәк нефть күлләре бармы, юкмы — шуны ачыкларга кирәк. Производство планы гына түгел, фәнни эш тә бу, иптәшләр. Карбонат ятмалары өлешен тикшерү зарури. Болары — җир асты эшләре. Җир өстендә дә анык-лыйсы нәрсәләр күп. Әйтик, арадашчылар белән элемтәләр кайда күбрәк аксый, кайсы төшендә үтә «нечкәреп» киткән — шуңа игътибар итегез. Аларның бөтен эшенә юнәлешне бригада үзе бирәчәк...

Дамир канатланып киткәндәй булды. Ләкин скважинаны тәҗрибә өчен бораулау, эш барышында хезмәтне яңача оештыру — күнегелгән, гадәти хәл түгел. Моның авырлыгын да тойды Нуретдинов. Мондый катлаулы һәм җаваплы эшне беркайчан да эшләп караганнары юк иде әле. Скважинаны иң кыска арада бораула, әллә ничә катламнан керн ал, торбаларга урнаштырылган төрле җайланмаларны сына, арадашчыларның эшен анализла — бер бригадага ничәмәничә бурыч! Барысы өчен дә иң элек мастер җаваплы.

Эшкә тотыныр алдыннан, элекке еллардагы шикелле үк, барысы бергә буровойга җыелып киңәштеләр. Сөйләшү озакка сузылды. Һәр кешегә бурыч тәгаен аңлатылды. Бу җәһәттән Нуретдиновның үз карашы бар: бораулаучыларның һәркайсы бөтен коллектив максатын яхшы белсен, шуннан чыгып үзе башкарырга тиешле конкрет эшне ачыкласын. Югыйсә, Крылов мәсәләндәгечә килеп чыгуы ихтимал:

аккош — һавага, кысла — коры җиргә, чуртан суга тарта, ә арба кузгалмый. Максатны төгәл белү коллективның көчен, өлгерлеген арттыра. Моңа инде Дамир эш барышында ничәмә-ничә кат ышанган. Белгән эш — үрчемле, белмәгән эш — мең чирле.

Буровойда киңәшеп утырган чакта икеләнүчеләр, шик белдерүчеләр дә булды.

— Беркайчан да бу хәтле күп керн алганыбыз юк иде, киметеп булмыймы соң шуны?

— Яңа җайланмаларны сыныйсы да бар бит, кернын киметергә дә ярый торгандыр...

— Геологлар йөкли торган эшләр җиңелдән түгел, планны үти алырбызмы соң?..

Дамир Нуретдинов барысына берьюлы җавап бирде:

— Бригадага зур эшләр кушалар икән, ышаналар, димәк. Бу ышанычны акларбыз, егетләр. Безгә кырык биш көн вакыт бирелә, аз түгел. Производство планы да булыр, фәнни эш тә... Бөтенесен күргәнчә башкарырбыз.

Бораулаарга керешкәч, ышаныч тагын да артты. Бригада дәртләнеп эшләде. Геологларның сорауларына җавап эзләү, яңа җайланмаларны сынау, шул ук вакытта арадашчыларның да ничек эшләвенә «күз- колак» булу бораулаучыларны шул кадәр мавыктырды — алар бернинди авырлыкны да тоймадылар шикелле. Барыннан да бигрәк, эшнең тоткарлыксыз баруы сөендерә иде. Ни кирәк булса — шул әзер! Дамир күңелендә бик күптән йөргән хыял — скважина коруда хезмәтне завод конвейерындагыча итеп оештыру гаҗәп нәрсә икән. Һәркем үз урынында, эшләр бер-беренә ялганып кына бара. Махсус идарә механизаторлары белән бораулаучылар арасында бернинди каршылык, аңлашылмаучылык юк, эш кораллары белән тәэмин итүчеләр тоткарламый, тампонажчыларга бер ым кагу җитә — шундук кирәген эшләп куялар. Скважина бораулаган җирдә тикшеренүләр үткәрү өчен килгән геофизиклар да өлгер — тикшерү өчен алынган тау токымнарын карап, нәтиҗәне бик тиз әйтеп бирәләр.

Гыйбрәтле хәл: башка чакларда эленке-салынкырак йөрергә яраткан, бораулаучыларны «кәкре каенга терәтеп» калдырудан да тартынмаган арадашчыларны алыштырып куйганнар диярсең. Теләк булганда, бөтен кирәк-яракны алдан да әзерләп куярга мөмкин икән.

Нуретдинов алар эшен дә күзәтә, дөресе, аңа үзе җитәкчелек итә. Берәр урында өзеклек юкмы, булса — кем гаепле, кайсы тарафка чаң сугарга? Барысы да бер урында, бер кул астында булгач, моны ачыклавы да кыен түгел икән. «Их, гади скважиналар бораулаганда да шулай булсачы! Бик мөмкин эш бит, югыйсә», дип уйлый Дамир. Аның үз нияте тыелгысыз: бораулаучылар хезмәтен нәкъ менә шундый конвейер булырлык итеп оештыру. Максатына ирешеп тә килә инде, ахрысы. Тик үзе генә сынатмасын, осталыгы гына җитсен.

Осталык дигәннән...

Дамир гомер буе кулындагы эшне коеп куючы кешеләргә кызыгып, сокланып карады. Алар гади адәми затлар түгел, ниндидер тылсым иясе булып күренә иде аңа. Бигрәк тә малай чагында шундый хис көчле булды Дамирда.

Кыш якынлашып килә иде. Әтисе Дамирга иске итекләр тоттырды да:

— Бар, Котдус абзыйга илтеп бир, яңартып кайтарсын, — диде.

Малай, төбе тишелеп беткән итекләрне култык астына кыстырып, кеше-кара күрмәсен бу аламаларны дигәндәй, ындыр артлап кына авылның икенче очына юнәлде. «Бу иске-москыны да яңартып була микәнни? — дип уйлады. — Карарлыгы да калмаган лабаса!..»

Котдус абзый, аның кулыннан киез итек аламасын алып, әйләндергәләп карады да караңгы почмакка атып бәрде. Дамир итекченең кул сыртында ярылып яткан сумалалы киндер җеп эзләрен күреп алды. Кызыгып, шуларга карап торды. Аның борынына тузан исе, сумала исе килеп бәрелде. «Ничек итеп иске итекләрне яңарта икән Котдус абзый?» — малайның шуны үз күзләре белән күрәсе килде. Тәбәнәк урындыкка утырган оста, аның теләген аңлагандай, үз алдында яткан өемнән киез итекләрнең берсен алды да чалгы пычак белән сызып җибәрде. Иске олтан останың кыршылып беткән күн алъяпкычына әйләнеп кенә төште.

— Шул инде безнең һөнәр, кисәбез дә тегәбез, улым, — дип, ул малайга күтәрелеп карады. Аннары, учына төкергәләп, кулларын угалады. Аның уч төпләре, кытыршы кәгазь шикелле, кыштырдап куйды. Ул кулларда Дамирга билгеле булмаган ниндидер көч, тылсым бар иде шикелле.

— Бар, бар, иртәгә төштән соң килеп алырсың, — диде оста.

Икенче көнне әйтелгән вакытка килеп, Котдус абзыйларына кергәч, малай үзенең иске киез итекләрен танымый торды. Итекче абый аларга бик пөхтә итеп олтан салган, озын эскәмиягә бастырып куйган иде. Көлеп торалар диярсең — малайның исе китте! Яңа чакта да болай ук матур булмагандыр бәлки бу итекләр. Дамир аларны күтәреп авылның үзәк урамы буйлап атлады. Күрсеннәр, янәсе, барысы да күрсен аның яңарган киез итекләрен!

Дамирның әтисе Котдус абзыйның эшен бик мактады.

— Кара син, ә! Җөйләрен нинди тигез салган! Бик пөхтә итеп эшләгән, матур итеп. Оста шул, оста кулы.

— Мондый osталыкка кем өйрәтте икән аны, әти?

Малайның әтисе мыек астыннан гына елмайды да, кулында киез итекләрне әйләндерә-әйләндерә, телен шартлаткалады, аннары җавап бирде:

— Котдус абзыйның осталыгы ата-бабасыннан килә, улым. Шундый һөнәр онытылмый. Эш остасы — бөек кеше ул, Дамир. Балта остасымы, игенчеме, тимерчеме — барыбер. Андыйлардан көнләшү дә язык түгел. Һөнәрле үлмәс, дигәннәр. Кайда эшләсәң дә, осталыкка омтыл. Тормышның хикмәте шунда...

Әтисеннән ишеткән бу сүзләр Дамирның хәтеренә тирән сеңеп калды. Соңыннан, күп еллар үткәч тә, аларны гел-гел искә төшерә иде. Берәр авырлыкка юлыкты исә, күз алдына әтисе килеп баса. Кулында Котдус абзый яңартып биргән итекләр, имеш.

— Оста бул, тормышның хикмәте шул, — дип, мыек астыннан гына көлемсери. Шуны искә төшерү Дамирны һәрчак тынычландыра иде.

...Еллар узды. Иж суы буенда беренче буровойлар корылды. Аларны күргән Дамирга һәм аның яшьтәшләренә «кара алтын» эзләүче егетләр баһадирлар булып тоелды. Авыл малайлары көннәр буе шулар тирәсендә мәш килеп йөрде. Кызык монда! Дизельләр гөрелтесе һаваны яра, җир астына төшерелгән торбалар шавы әллә кайдан — билгесез дөньядан ишетелеп тора кебек. Корыч «шәмнәр» чыңы, машиналар гүләве һәм, ташлы-комлы катламнарны бораулап, тирәндә яткан хәзинәләргә юл салучы кешеләр — барысы да Дамирның күңелен җилкетә, аны буровой янына тартып тора. Малай аңлый: Котдус абзыйсы аны иске киез итекләрен яңартып сөендергән иде, ә болар, җир астыннан нефть чыгарып, бөтен илне куандыра. Осталыкларына сокланмаслык түгел. Дамирның күңелен бораулаучы абыйлардан көнләшү дигән хис биләп алды.

Авыл халкы да буровойның үз кырларында салынуына сөенә, горурлана. Кайсы йортка килеп кермәсеннәр — бораулаучыларга

ачык йөз, тәмле сүз. Нефть эзләүче егетләрне батырлар дип зурлый авыл халкы, уңган-булганнар дип олылый. Чыннан да, үзләре дә ут егетләр икән шул. Алар осталыгы турында газеталар яза, радио сөйли. Казаннан гына түгел, Мәскәүдән дә таныш исемнәре бик еш яңгырый. Дамир яхшы хәтерли: нәкъ шул чакларда СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидатлар белән очрашу җыелышы да булды. Бораулаучы осталарның берсен кандидат итеп күрсәткәннәр икән — халык белән очрашуга килде ул. Авыл клубында игенчеләр белән бергә нефтьчеләр утырды. Яше җитмәсә дә, җыелышка Дамир да керде. Колхозчылар да сөйләде, нефтьчеләр дә. Депутатлыкка кандидатны «бораулау эшенең остасы» дип зурладылар. Җир асты байлыкларына юл салуның бик күп серләрен ачкан кеше икән ул.

Унбиш яшьлек малай күңеленә ул кеше үз һөнәрен бик яхшы белүче «зур оста» буларак кереп урнашты. Әтисе әйтмешли, эш остасы — бөек кеше ул! Аның бөеклеген бөтен халык таный.

Шул чакларда инде Дамир күңеленә үз ниятен ныгытып куйды: бораулаучы булачак ул. Ата-баба һөнәре булмаса да — үзләштерер, өйрәнер. Ни кирәк булса шуны эшләр, әмма оста булмыйча калмас. Җир асты хәзинәләренә юл ачышыр.

Солдат шинеле киеп йөргән елларда да бу уйдан кайтмады Нуретдинов. Армиядән язган хатларында авыл хәлләрен генә түгел, нефтьчеләр турында да сорашып торды. Үзе еракта булса да, Татарстанда «кара алтын» чыгаручы осталарның эшенә сокланып яшәде. Газим Гайфуллин, Мөгаллим Гыймазов, Михаил Гринь, Михаил Белоглазов, Николай Драцкий, Галимҗан Хаҗиевларны ул нефтьчеләр арасында иң югары осталыкка ирешкән кешеләр итеп күрә, алар эше турында язылган материаллар күзенә чалынса, зур кызыксыну белән укып чыга. Яшерен-батырын түгел, Дамир Нуретдинов алардан көнләшә дә башлады. Ләкин бу начар сыйфат түгел иде. Үз эшендә алар ирешкән камиллеккә омтылу, шул осталар кебек булырга ашкыну хисе көнләштерде Дамирны. «Шушы тойгы булмаса, осталык үзеннән-үзе килми, — ди Нуретдинов. — Һәр эштә шулай дип уйлыйм. Осталардан көнләшүемне берәүдән дә яшермим».

Армиядән кайтуына, Дамир бораулау конторасына килде. Аны буровой эшчесе итеп алдылар. Хезмәткә чыгуының беренче көненнән үк үзе башкарасы эшнең нечкәлекләрен бик җентекләп өйрәнергә кереште. Аныңча, осталык күзгә бәреп тормаган үзенчәлекләрне күрә белүдән башлана. Нефтьче хезмәтенең нечкәлекләрен өйрәнүдә аның үз алымнары бар. Бораулау эшенең һәр операциясен аерым өлешләргә бүлгәли дә шуларның ничек башкарылуын анализлый. Элеваторның һавада нинди хәлдә торуыннан башлап, бауларда төеннәрнең ничек урнашуына кадәр бөтенесен күздән кичерә. Эш хикмәтләрен шулай берәмлекләп өйрәнгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин дип саный Дамир Нуретдинов.

Бораулау эшенең әлифбасын үзләштерү белән бер үк вакытта ул киләчәккә дә караш ташлый. Бүген алдынгы булып саналган алымнар иртәгә гадәти булып калачак һәм искерәчәк — техника үсеше шуңа илтә. Аннары бит бер үк ысулларны да төрле кеше төрлечә куллана. Берәүләр күнегелгән юлдан бара, икенчеләре сукмакның яңасын эзли. Шул юнәлештә Дамир Нуретдинов ачасы нечкәлекләр дә булырга тиеш дип саный. Ачмый калмас ул аларны, бораулау эшендә үз сүзен әйтер. Ләкин аңарчы осталык баскычларының иң югарысына менеп җитәргә кирәк.

Дамир Нуретдинов бораулаучы булып эшләгән бригада алдынгы иде. Эше гөрләп барды. Хезмәтендә шактый танылып өлгергәч, аны

артта калучы бригадага күчерделәр. Тынгысыз, эзләнүчән бораулаучы коллективны өзеклектән чыгарыр дип өметләнделәр.

Бу бригаданың эш мәйданы геологик яктан үтә катлаулы булып чыкты. Арадашчыларның хезмәте дә ташка үлчим генә. Буровойда бер аварияне бетерүгә, икенчесе килә дә чыга. Коллектив графикны һич үти алмый. Билгеле, мондый шартларда күңел күтәренкелеге юк, кешеләрнең борыннары салынган. «Юк, үз көчеңә ышанырга кирәк», — дип уйлый Дамир Нуретдинов һәм бригада егетләренең күңелләрен күтәрергә тырыша. Ләкин моңа җор сүз белән һәм үзүзеңә ышаныч белән генә түгел, җиде кат җир астында терәлеп калган эшне алга җибәреп кенә ирешергә мөмкин.

Дамир зур өметләр белән бораuларга керешә һәм... беренче скважинаны тишкәндә үк авариягә юлыга. Тиз генә төзәтерлек тә түгел. Бригада тагын да арткарак тәгәри. Яшь бораулаучыны өмет белән каршылаган кешеләрнең аңа ышанычы какшый. Авариядә Нуретдиновны гаепилиләр, аңа административ җәза да бирелә: бораулаучы ярдәмчесе итеп калдыралар. Әмма аны җәза борчымый, бригаданың авыр хәлдә булуына хафалана ул, үз-үзен хөкем итә. «Моңарчы килгән бораулаучылар эшли алмаганны кырыштырдың син, Дамир. Алар бригаданы аксатканнар гына, ә син бөтенләй сыртына салдың. Тиз генә аякка бастырырлык та түгел...»

Иптәшләренең дә кырын каравын сизә Нуретдинов. «Күтәрә алмаган — авыр йөккә сузылыр» дигәннәр. Үрелдең дә кузгата алмадың — аңа үпкә белән текәлгән карашлар шулай әйтә кебек. Әйе, гаепле Нуретдинов, нидәдер ялгышты, ашыкты, кызыбрак китте шикелле. Уйлабрак эш итсә, бөтен колонна гөмбердәп төшеп китәр идеме? Бораулаучы, үз ялгышын табарга тырышып, бу аварияне, үзенең бөтен эшләрен, хәрәкәтләрен кат-кат күздән кичерде, ләкин хатасының нидә икәнен ачыклый алмады. Аңа тагын шунысы бик сәер булып тоелды: берәү дә аны тиргәми, ачуланмый. Барыннан да бигрәк шунысы әрнетә. Башлыклар җитлекмәгән бораулаучыны бу бригадага җибәрүләренә үкенәдер, ә эшчеләр: «Безгә чын осталар килми шул», — дип офтана иде шикелле.

Ә Дамир Нуретдинов авариядән әйбәт сабак алды. Авыр хәлнең сәбәбе ачыклангач та (бораулаучы гаепсез булып чыкты), ул үзүзен аклауны кирәк санамады. Бригада эшенең еллык йомгакларын тикшерүгә багышланган җыелышта аны тәнкыйть иттеләр, нык «пешерделәр». Әлеге «кыздыруны» урынсыз димәде, чыгып сүз әйтмәде. «Туйдан соң дөмбергә» дигәндәй, эш узгач аклануданн ни файда. Авария өчен турыдан-туры гаепле булмаса да, ул үзен сөттән пакь итеп санамады. Яшь оста, уңышсызлык өчен җаваплылыкны үз җилкәсеннән төшермичә, алдагы эштә уңышка ирешү юлын билгеләде. «Аварияләрне алдан күрә белү һәм аларны бетерү — үзенә бер осталык, — дигән сүзләр язып куйды ул үзенең күңел дәфтәренә. — Шундый осталыкка ия булганда гына зур уңышлар яуларга, ә яуланган нәтиҗәләрнең тотрыклы булуын тәэмин итәргә мөмкин. Очраклы җиңеллеккә исәп тотарга ярамый». Соңыннан үзенең бу фикерләре дөреслеген ул эше белән дә раслады. Күрәсең, авариядән алынган сабак аның кулларын салындырмаган, уйланырга, төпченергә мәҗбүр иткән һәм аңа хезмәтенең төп кагыйдәсен ачарга этәргеч булган.

Бригада җыелышында еллык эшкә йомгак ясау белән генә чикләнмәде алар. Анда мәсьәлә бөтен кискенлеге белән куелды: болай эшләү мөмкин түгел! Буровойда бөтенесен үзгәртергә кирәк — эш алымнарын да, кешеләрнең кәефен дә, тәртибен дә.

1965 ел башында бригада яңа скважина бораuларга керешә.

Дамир буровойда эшкә уңай тәэсир ясарлык «микроклимат» бул-

дырырга тырыша. Моның өчен, әлбәттә, вәгазь-лекцияләр укуның кирәге юк иде. Иртән егетләр автовокзалга төшә, бергә машина көтәләр. Аннары буровойга кадәр шактый ара автобуста узыла. Шул вакыт эчендә Дамир кешеләрнең күңел кылларын тарткалый, һәркайсын бүген буровойда башкарылачак эш турында уйланырга мәҗбүр итә, кыскасы, «психологик гимнастика» үткәрә иде. Үзең белән бергә эшләүче кешеләрнең кәефен күтәреп, аларны хезмәт көнен зур дәрт белән башлап җибәрергә ялкынландыра белү — үзе бер осталык. Бораулаучы мастерга бу да бик кирәк икән. Дамир шуңа да игътибар итте: аның психологик гимнастикасы уңышлы булган көннәрдә смена әйбәт эшли, тоткарлыклар булмый диярлек.

Вахта күзгә күренеп үзгәрә башлады. Бораулау тизлеге артты. Иң мөһиме, бригада егетләре сынатмый. Элек авария булганда кул селтиләр иде, хәзер тиз арада эшкә ябышалар. Элегрәк вахтага шәһәр айныткычыннан «сәлам юллаучылар» да булгалый иде — андыйлар тәмам бетте. Бораулау тигез бара, метрлар саны ишәйгән саен, күңелләр дә күтәрелә.

Беренче скважинаны билгеләнгән вакыттан алда төгәлләделәр. Дамир Нуретдинов вахтасы, иң югары тизлеккә ирешеп, алдынгы урынга чыкты. Бу беренче зур җиңү иде. Аннан соң уңышларның яңалары, тагын да әһәмиятлерәкләре дә булды, әмма беренче казаныш онытылмаслык икән.

Яшь бораулаучы танылган осталарның тәҗрибәсен өйрәнде, үз вахтасының эшен смена саен анализлап барды. Болай иткәндә уңышлар да, бораулау барышында күренеп өлгермәгән йомшак яклар да ачыграк төсмерләнә. Шулай өйрәнә-өйрәнә, эзләнә-эзләнә эшли торгач, Нуретдинов вахтасы беренче урында ныгыды. Дамирны инде иң яхшы бораулаучы — оста дип зурлый башладылар.

Озак та үтми, Дамир Нуретдинов кайчандыр үзен нефтьчеләр арасына алып кергән коллективка — солдаттан кайткач та буровой эшчесе булып эшли башлаган бригадага әйләнеп кайтты. Мастер итеп күчерделәр аны. Үзенә бораулау эшенең әлифбасын өйрәткән кешеләр аны хәзер ничек каршылар?.. Хәер, ничек кабул итсәләр дә, күп нәрсә Дамирның үзеннән тора. Мастер булуыңны эш урының белән түгел, осталыгың белән расларга кирәк. Ул шуннан башларга тиеш тә. Иске танышлары янына Дамир шундый уйлар белән дулкынланып һәм шактый борчылып килде.

Монда да беренче коймак төерле булып чыкты. Бораулый торган скважинада, нефть катламына җиткәч, өскә газ агымы ыргылып менде. Шешәдән атылып чыгарга торган җен шикелле, газ ташкыны йөрәкләргә шом салып гүләргә тотынды.

Тревога белән кузгатылган хәрбиләр кебек, буровойга төрле һөнәр кешеләре җыелышты. Скважинага авыр чималдан әзерләнгән измә төшереп карадылар — файдасы тимәде.

Газ ташкынының болай өскә ыргылуы бу тирәләрдә бик сирәк була торган хәл иде. Унар-унбишәр ел эшләгән мастерлар да мондый очракны хәтерләми. Шулай да ул табигый бер нәрсә. Шунлыктан, скважинадан газ бәреп чыгу бригаданың да, мастерның да гаебе булып саналмый.

Ләкин Дамир Нуретдиновны бүтән уй борчыды. Буровойга җыелган белгечләр газ фонтанын туктату нияте белән төрле фикерләр әйтә, тәкъдимнәр бирә, ә мастер — ләм-мим. Мәсьәләнең бу ягын уйламаган, моны көтмәгән иде шул. Аның урынында башка кеше — чын-чыннан оста белгеч булса, болай авыз йомып тормас иде. Дамир шулай уйлады. «Газ фонтанын томаларга башың җитмәсен, ә исемең — мастер!» — дип шелтәләде ул үз-үзен. Бу урынсыз иде, әлбәттә, әмма Нуретдинов үз-үзен тиргәүдән тиз генә арына алмады.

Холкы шундый. Бригада күпме вакытны югалта бит, моны мастерга гына сылтасалар да гаҗәп түгел, янәсе.

Авырлык күрми — җиңеллек килми дигәндәй, газ фонтанының көтмәгәндә бәреп чыгуы да, ахыр чиктә, Дамирның тәҗрибәсен баеткан гадәти бер очрак булып кына калды. Геология ягыннан катлаулы мәйданда скважиналар бораулаганда мондый хәлләр еш булгалый. Димәк, бригада моңа һәр вакыт әзер торырга тиеш. Мастер ясаган төп нәтиҗә шундый иде.

Газ чыгуның эшне тоткарлап торуны бригада кешеләре дөрес аңлады. Скважинаны тапшыру озаккарак сузылса да, икенчесен бораударга керешкәндә аларның күңелләре күтәренке иде инде.

Габдрахман мәйданындагы нефть ятмаларының «холык-фигыле» гел үзгәрә торды. Җир астына суны күбрәк кудырган саен, катлам басымы арта барды. Бу исә нефть ятмасының «холкын» үзгәртә, кичә генә яраган бораулау ысуллары көткән нәтиҗәгә китерми, яңа алымнар эзләп табарга кирәк була. Үч иткәндәй, бригаданы иң катлаулы участокларга җибәрәләр. Бер уйласаң, куанычлы хәл бу: нинди авыр шартларда да югалып калмаслыгына ышаналар, димәк. Ә икенче уйласаң — өстәмә кыенлыклар кемгә? Һаман шул ук Нуретдинов бригадасына...

Борау инде «кара алтын» катламына якынлашып килә. Геологлар монда да газ фонтаны булу ихтималлыгын кисәтеп тә куйды инде. Нефтьле катлам төнге сменада ачылачак, теләсә нинди хәлгә дә әзер тору зыян итмәс. Нуретдинов ул көнне сменадан кайтып китмәде, буровойда төнгә дә калды.

Кичке сменага Петр Рыжиков вахтасы чыкты. Дамир вахта башлыгын яхшы белә. Петр — бораулау остасы, тынгысыз кеше, кирәк чакта хәйләкәр дә. Җиһазларны күтәрү-төшерү кадәресендә аңа тиң останы табу кыендыр, тик буровойдагы ярдәмче эшләргә игътибары җитенкерәми. Колоннаны төшергән чакта ике-өч сәгать вакытны отмый калмас, ә насос-компрессор җайланмаларын җир астына «озатырга» кирәк булганда — сүлпәнләнә. Бораударга кушсаң тәүлекләр буе эшләргә әзер.

Борау нефтьле катламга җитәрәк, Дамир аны эшеннән бүлеп торырга булды.

— Бораулауны туктатып торыйк, Петр, — диде ул. — Превентор куябыз.

— Моңарчы миңа ярдәмче эшләрне кушмыйлар иде, мастер!

— Бораулауда ярдәмче эшләр юк, Петр. Превентор урнаштыруны вак-төяккә санасак, зуррагын югалтуыбыз ихтимал.

Рыжиков газ фонтаны бәрүгә каршы кулланыла торган җайланманы — превенторны теләр-теләмәс кенә куйды. Ләкин тиешенчә итеп түгел, ә кыегайтып. Газ чыга калса, аның аркылы да үтәчәк.

— Яхшылап куярга кирәк, — диде мастер.

Рыжиков, канәгатьсезлек белдереп, кул селтәде.

— Вакытны бушка уздырабыз. Метрлар югала...

Превенторны мастер үзе көйләп урнаштырды. Газ фонтанының юлын алдан ук ябып куйдылар. Шул вакыйгадан соң Петр Рыжиков вахтасы превенторны бик кыска арада — өч сәгатьтә урнаштырырга шомарып җитте.

Бу катлаулы мәйданда Нуретдинов бригадасы берничә ел эшләде.

Тайсуган авылы янында бораударга керешкән бер скважина аларны су бөркеп интектерде. Торбаларны күтәрә башладылармы — салкын «яңгыр» астында калалар. Ә тирәнгәрәк киткәч, тозлы су ташкыны бәреп чыкты. Бервакыт аның басымы шул кадәр көчәйде ки, хәтта яңа торбаны төшерерлек түгел иде. Чүп өстенә

чүмәлә дигәндәй, урта горизонтка гадәттә түбәнге катламнар өчен генә файдаланыла торган измә кирәклеге билгеле булды. Ләкин авыр измә дә фонтанны томалый алмады. Тозлы су измәне шундук эретә дә сыек боткага әверелдерә иде. Өстәвенә, юл өзелгән чак, измәне ташып өлгертә алмыйлар. Скважина асфальт юлдан ерак булмаса да, аның янына машина белән керү кыен, күп вакыт кирәк. Шундый хәл килеп чыккач, Дамир гадәттән тыш чая тәҗрибә үткәрде — асфальттан скважинага кадәр торбалар суздырды. Буровой эшчеләре мастерның кушканын үтәгән арада эш урынында бораулаучы гына калды, башкалар торба сузды, юл читенә чан урнаштырды. Шоферлар эретмәне юл читендәге чанга бушата башлагач, тоткарлык бетерелде. Вакытында кылынган кыю эмәл эшне җайга салырга ярдәм итте — скважинаны срогыннан алда тапшырдылар. Бу тәҗрибәдән мастер тагын бер нәтиҗә ясады: скважиналарны тизрәк төзү өчен ярышка шоферларны катнаштыру мөмкинлеге дә бар икән бит! Моны эшләү бораулауны тизләтәчәк — анысы инде практикада расланды.

Скважиналарны катлаулы геология шартларында бораулаган Нуретдинов бригадасы эш өстендә яңа җайланмаларны сынады, аларның производствога кертелүенә фатиха бирде. Юдыру сыекчасын күп тота торган катламнарны һәм урыннарны изоляцияләү ысулын беренчеләрдән булып алар үзләштерде. Идарә технологлары эретмәнең авырлыгын арттыру юлын да шул бригада белән бергә эшләделәр. Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институтында иҗат ителгән бик күп җайланмаларны да сынады коллектив. Бораулаучылар белән галимнәр арасындагы хезмәттәшлек соңгы ел ярым дәвамында аеруча нәтиҗәле булды. Яңа конструкциядәге турбобур сыналды, бораулау барышында эшне туктатмыйча тикшерү өчен токым алу җайланмалары тикшерелде. Забой двигателенең өр-яңасын тикшереп, эшләтеп карауны да Дамир Нуретдинов бригадасына тапшырганнар иде.

Шундый күп төрле һәм җитди фәнни-тикшеренү эшләре өстенә аларга скважинадан төрле катламнардагы кернны алу мәшәкатьләре дә йөкләделәр. Шунысын да истә тотарга кирәк: тәҗрибә, тикшеренү, сынау эшләре өчен бригадага өстәмә вакыт билгеләнмәде. Производство планы, башкаларныкы шикелле үк, киеренке иде. Шулай да булуга карамастан, коллектив айдан-айга, елдан-елга яхшырак нәтиҗәләргә ирешә һәм социалистик ярышта бер яулаган урынны беркемгә дә бирмәде. Ирешкән казанышлары белән Дамир Нуретдинов бригадасы республикада гына түгел, бөтен ил күләмендә социалистик ярышны әйдәп баручылар сафына басты.

Производство планнарын үтәүдә, яңа җайланмаларны сынауда һәм үзләштерүдә, хезмәтне яңача оештыруда коллектив ил күләмендәге әһәмиятле эшләр башкарды. Аның уңышлы тәҗрибәләре КПСС Үзәк Комитеты тарафыннан хупланды. Яңа эш алымнары бөтен нефтьчеләргә җиткерелергә тиеш дип билгеләнгән бораулау осталары арасында Дамир Нуретдинов фамилиясе дә бар иде. Бу инде бригаданың еракларга китүен раслаган дәлил булды.

Разведка өчен бораулаңган скважина төзелешендә Дамир Нуретдинов үзе күптән хыялланган «конвейер» системасын, икенче төрле итеп әйткәндә, агым ысулын тормышка ашыруга ирешә. Бригада барлык эшләр комплексын баштан ахрынача үзе башкарды һәм торбалар буйлап нефть күтәрелә башлагач кына буровойдан китә торган булды. Кара алтын чыгару өчен кирәкле компрессорны да алар шунда чакта китерделәр, ә элек алай булмый торган иде бит.

Скважинадан нефть суырта башладылар, ә Дамир Нуретдинов бригадасы яңа урында бораулаларга керешә. Мастер уйлаган «агым ысулы» шул инде: бер скважинадан нефть алыну белән, бригада икенчесен төзергә керешә. Бөтен эш чылбыр боҗралары сыман, бер-беренә ялганып бара. Шул уңышы белән бригада скважинаны эшләтеп җибәрү өчен айлар-еллар кирәк түгеллеген, ә берничә көн дә җитүен раслады.

Хәзер инде күтәрелгән биеклектән артка борылып карарга, ирешелгәннәрне күздән кичереп, нәтиҗә ясарга да мөмкин иде. Дамир Нуретдинов, «Социалистик индустрия» газетасында чыгыш ясап, республика һәм бөтен илнең нефть промышленностенда эшләүче бораулаучыларга мөрәҗәгать итте, аларны скважина төзүдәге барлык эшләрне бер наряд белән үтәргә — агым ысулы белән эшләргә өндәде. «Татнефть» берләшмәсенең танылган бораулау мастерлары — Матвей Гринь, Николай Драцкий, Галимҗан Хаҗиев, Василий Шинкин аның башлангычын бик тиз яклап чыктылар. Татарстан нефтенең бу осталары беренче скважиналарны бораулаган чакта ук хезмәтне яңача оештыруның зур әһәмияте, экономик нәтиҗәлелеге расланды. Партиянең XXV съезды нефтьчеләр алдына скважиналар төзү вакытын 25—30 процентка кыскарту бурычын куйган иде. Дамир Нуретдинов бригадасы бу өндәмәгә коммунистларча җавап бирде, скважиналар кору өлкәсендә тамырдан борылыш ясады.

СССР нефть промышленносте министрлыгы, нефть һәм газ эшкәртү промышленносте эшчеләре профсоюзының Үзәк Комитеты Дамир Нуретдинов тормышка ашырган бу яңалыкны хупладылар һәм аны илебезнең «кара алтын» чыгарыла торган башка өлкәләрендә дә производствога кертергә тәкъдим иттеләр. Әйбәт башлангыч канатлы булып чыкты. Башкортстан, Пермь, Мангышлак, Белоруссия, Украина, Казагыстан бораулаучылары агым ысулын күтәреп алдылар инде. Күптән түгел миңа Сахалинда чыга торган бер газетаны укырга туры килде. Анда «татар бораулаучыларының бу башлангычы — зур яңалык, безнең якларда да кулланыла башлады», дип язылган иде. Дамир Нуретдиновның агым ысулы скважиналар төзү вакытын һәркайда кыскарта.

Бу алым беренче тапкыр тормышка ашырылган елда республикабызда скважиналарны төзү вакыты гадәттәгегә караганда унбер көнгә кыскартылган иде. 1977 елда ул тагын бер атнага киметелде. 1978 елда бораулаучылар бөтен эш әйләнмәсен 30 көндә үтәп чыкты. Ә моннан өч ел элек моның өчен 53 көн таләп ителә иде. Кара исәп белән генә чамаласаң да, әлеге яңалыкның ил күләмендә нинди зур казанышка китерүен аңларга мөмкин. Ел саен дүрт-биш йөз мең тонна өстәмә нефть алыначак! Бу әле Төмән якларын кертмичә. Себер бораулаучылары да Дамир Нуретдинов алымы белән эшли башласа, өстәмә нефть тонналары алты урынлы сан белән билгеләнәчәк.

Ә Төмән нефтьчеләре бу яңалык белән бик нык кызыксыналар. Әлмәттә үткәрелгән Бөтенсоюз киңәшмәсендә нәкъ менә шул мәсьәлә — скважиналарны агым ысулы белән төзү турында эшлекле сөйләшү булды. Әлмәт бораулаучылары тәҗрибә уртаклаштылар, Дамир Нуретдинов хезмәтне яңача оештыруның «серләрен» ачты. Киңәшмәнең файдасы булган. «Главтюменнефтегаз» берләшмәсе бораулаучысы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты В. Громов «Социалистическая индустрия» газетасында күләмле мәкалә белән чыгыш ясады. Көнбатыш Себернең кырыс шартларында эшләүче бораулаучылар яңа прогрессив алымны үзләштерергә керешкән — мастер шуны хәбәр итә. Бу мәкалә Дамир Нуретдиновны һәм аның бригадасын бик сөендерде. Башкарган эшләре киң тарала бит — куанмаслык түгел!

Ел башында тагын бер куанычлы хәбәр килде. Анысы бригаданы гына түгел, ә бөтен идарә коллективын шатландырды. Бораулау

эшендә зур яңалык, экономик нәтиҗәле агым ысулын ачкан тәҗрибәле мастер коммунист Дамир Нуретдинов СССР Дәүләт премиясенә лаек дип табылган. Лауреат исеме — атаклы остага бөтен ил хөрмәтенең билгесе.

Дамир Нуретдиновның осталыгын бораулау «аксакаллары» да таный. «Скважиналар төзелешен — агым ысулына» дигән девиз белән башланган хәрәкәткә алар да кушылды инде. Карасаң, әллә нинди шаккатмалы серләре дә юк кебек. Бу бөтен нәрсә ачыкланып җиткәнгә, тирәнтен уйланып эшләнгәнгә күрә генә шулай тоела. «Бораулау эшендә вак-төяк нәрсәләр була алмый» дип саный Дамир. Аның өчен бөтенесе әһәмиятле: бригада кешеләренең кәефе дә, осталыгы да. Бер урыннан икенче урынга күчкәндәге төгәллек тә, тизлек тә. Бораулау барышында пөхтәлек һәм кабаланмау. Мастерның бөтен нәрсәне күздә тота белүе... Аннары тагын, бораулаучыларга һәм аларны тәэмин итеп торучы арадашчыларга аш-су китертүне дә алдан кайгыртырга кирәк. Нуретдинов буровоена килүчеләр белә: аларга анда бөтен кирәк-ярак табылачак, кәгазьгә төреп, кесәгә бутерброд тыгып баруның хаҗәте юк.

Дамир уенча, мондый, «вак-төяк» — зур эшләрдә таяныч. Җир катламнарын бораулый белү генә җитми, арадашчылар белән элемтә тотуда да осталык кирәк. Иптәшләреңнең күңелен күтәрә дә бел. Кыскасы, мастер җилкәсенә мең төрле мәшәкать өелгән.

Лауреатны хөрмәтләү кичәсендә бер дусты аңардан:

— Я, Дамир, хыялларың тормышка аштымы инде? — дип сорады.

Нуретдинов беравык уйланып торды да:

— Хыялның чиге юк инде аның, — диде.

Күрәсең, киләчәккә уйлап куйган эшләре күптер, ниятләре зурдыр. Агым ысулын тагын да камилләштерергә тели торгандыр. Эзләгән кешегә яңалык бетәмени! Табигый хәл: осталыкның чиге юк бит.

Йолдыз Нигъмәтуллина

# ӘДӘБИЯТ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕ

1978 елның октябрендә Татарстан АССРның башкаласы Казан шәһәрендә совет Көнчыгышы әдәбиятларында социалистик реализм эстетикасы һәм политикасының актуаль проблемаларына багышланган Бөтенсоюз фәнни конференциясе булып үтте. Бу конференция СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты, СССР һәм ТАССР Язучылар союзлары, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты тарафыннан оештырылган иде. Казанда үткәрелгән конференция совет Көнчыгышы әдәбиятлары үсеше проблемалары буенча 1972 елда Бакуда, 1975 елда Ташкентта узган фәнни конференцияләрне кабатламый. Мәгълүм булуынча, Баку конференциясендә илебезнең Көнчыгыш әдәбиятларында реализмның тууы һәм тарихи үсеш юллары мәсьәләләре тикшерелде. Ташкентта узган фәнни конференциянең төп проблемасы итеп Көнчыгыш әдәбиятларында социалистик реализмның генезисы, ягъни нинди җирлектә тамыр җибәрүе мәсьәләсе куелган иде. Ә соңгы конференциядә катнашучыларның игътибар үзәгендә исә социалистик реализм әдәбиятлары үсешенең өлгереп җиткән теоретик һәм методологик мәсьәләләре торды.

Конференциядә тикшерелгән мәсьәләләрнең турыдан-туры бүгенге көнгә караган булуы алар хакында фикер алышуның идеологик яктан үткенләгән билгеләде.

Конференцияне ачканда А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтының совет әдәбияты бүлеге мөдире СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе социалистик реализмның гомуми теориясен үстерүдә күп милләтле совет әдәбияты туплаган тәҗрибәне, шул исәптән аз санлы халыклар әдәбиятларының тәҗрибәсен өйрәнүнең мөһим теоретик һәм идеологик әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте. Конференциядә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дөнья күләмендә барган идеологик көрәш мәсьәләләренә махсус багышланган (Г. И. Ломидзе, Ю. И. Суровцев, Л. П. Каюмов) докладлар укылды.

Конференция эшендә әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр белән бергә, Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан язучылар да катнашты. Анда барлыгы кырык биш доклад һәм чыгыш тыңланды. Докладларда гомум теоретик һәм гомум методологик мәсьәләләргә зур игътибар бирелде, социалистик реализмны күп милләтле совет әдәбияты масштабында гына түгел, ә бөтен дөнья әдәби процессы белән бәйләнештә тикшерүгә омтылыш ясалды.

«Социалистик реализмда типология һәм совет Көнчыгышы әдәбиятлары» дигән докладында Ленинград галиме А. Н. Иезуитов, бу иҗат методының катлаулылыгын исәпкә алып, социалистик реализмда типологик төрләрне (туры мәгънәсендә реалистик, революцион-романтик, реалистик-экспрессив төрләр) аерып карый. А. Н. Иезуитов социалистик реализм методы структурасын төп өч яссылыкта (идеологик,

сәнгатьчәлек, эстетик) тикшерергә, социалистик реализмда эстетик һәм сәнгатьчәлек дәрәҗәләре буенча типологик бүленеш үткәрергә мөмкин дип саный. Совет Көнчыгышы әдәбиятлары социалистик реализмның гомум типологик билгеләренә тулысынча җавап бирә һәм бу хәл ул әдәбиятларның идея һәм сәнгатьлелек ягыннан өлгергәнлекләре хакында сөйли. А. Н. Иезуитов фикеренчә, совет Көнчыгышы әдәбиятларында Ч. Айтматов башка каләм осталары кебек, реалистик-экспрессив стиль белән иҗат итүче язучылар бөтендөнья әдәби процессына да тәэсир итәләр.

Баку галиме А. А. Гаджиев «Әдәби багланышлар һәм әдәбиятларның үзара йогынтысын өйрәнүнең теоретик мәсьәләләре» дигән докладында, Баку конференциясеннән алып Казандагы конференциягә кадәр үткән чорда реализм турындагы теоретик фикер үсешен күздән кичереп, социалистик реализм эстетикасы һәм поэтикасының бүгенге мәсьәләләре бөтенсоюз күләмендәге әдәби һәм эстетик хәрәкәтне күз алдында тотып гомумиләштерелергә тиеш дип чыкты. Социалистик милләтләр культураларының бер-берсен баету һәм үзара якынаю процессы — җитлеккән социалистик җәмгыятьтә әдәбият һәм сәнгать үсешенең иң төп һәм тарихи әйдәп баручы юнәлеше. Бу процесс әдәби багланышларның күп яклы, үзара йогынтыларның бай һәм тирән булуын таләп итә.

Әдәби багланышлар һәм үзара йогынты проблемаларының аерым аспектлары — мәсәлән, бүгенге совет әдәбиятында «гареп-шәрык синтезы»ның үзенчәлекләре, шигырь тәрҗемәләренең сыйфатына карата куелган таләпләр хакында М. Х. Хәсәнов (Казан) һәм З. А. Әхмәтов (Алма-Ата) докладларында гаять кызыклы фикерләр әйтелде. З. С. Кедрина (Мәскәү) совет әдәбияты классиклары С. Айни, М. Әуэзов, А. Упит мираслары мисалында социалистик реализмның тууы һәм үсеше процессында фольклор һәм әдәби традицияләр синтезының төрле формаларын күздән кичерде. Ул чит ил «советологлары» уйдырмаларына каршы көрәштә социалистик реализм генезисын өйрәнүнең зур әһәмияткә ия булуын күрсәтеп үтте.

Күп кенә доклад һәм чыгышларда бер үк фикер — күп милләтле совет әдәбиятының нигезен тәшкил иткән социалистик реализм методы закончалыкларын тикшерүдә яңа методика һәм методлар куллануның зарурилыгы әйтелде. «Безгә үзебезнең үткән эш коралларыбыз системасын булдырырга кирәк»,— диде үзенең чыгышында Ю. И. Суровцев.

«Бүгенге совет әдәбиятында эстетик идеалның кайбер үзенчәлекле яклары» дигән докладында Й. Г. Нигъмәтуллина эстетик идеалга системалы якын килү социалистик реализм методының синтетик характерын һәм совет әдәбиятының прогностик функциясен ачарга мөмкинлек бирүен күрсәтте. В. А. Дмитриев (Мәскәү) «Социалистик реализм — тарихи яктан ачык эстетик система» дигән тезисның бәхәсле якларына тукталды.

Н. Г. Юзиев (Казан) татар поэзиясендә сәнгатьчә фикерләү формаларын баету мәсьәләсенә кагылышлы фикерләре белән уртаклашып, поэтиканың бүгенге иҗат практикасыннан беркадәр артта калуын әйтеп үтте. Галим эчтәлек һәм форма нисбәтен, бәйләнешләрен әзер килеш, ягъни төгәлләнгән әдәби әсәр өстендә генә түгел, ә җанлы иҗат процессында тикшерү ихтыяҗы өлгереп җитте дип саный. Поэтиканың психологик принципларын үстерү һәм шуның нигезендә сәнгатьчә фикерләү закончалыкларын үзләштерү, докладчы фикеренчә, язучыга иҗат процессы белән аңлы рәвештә идарә итү мөмкинлеге бирер иде.

А. Г. Яхин (Казан) докладында тапкыр фикер йөртү поэтикасын системалы һәм комплекслы тикшеренү тәҗрибәсе бәян ителде. Галим фольклорның ике жанрына (мәзәк һәм мәкаль) анализ ясап, аларның структур элементларын ачыклый, тапкыр фикер йөртү структурасының ничек төзелүен күзәтә.

М. К. Кошчанов (Ташкент), Г. Б. Хәсәенов (Уфа), Л. И. Залесская (Мәскәү), Л. А. Бекизова (Черкесск), А. Мамедов (Ашхабад), С. Х. Әхмәтов (Махачкала), А. Г. Әхмәдуллин һәм Ф. М. Хатипов (Казан), А. Садыйков (Фрунзе), Б. Б. Бадмаева (Элиста), А. А. Билюкова (Якутск), А. С. Зуева (Ижевск) докладларында совет Көнчыгышы әдәбиятлары үсешенең хәзерге этабына, стиль агымнары һәм әйдәп баручы жанрларга күзәтү ясалды. Милли әдәбиятларда стиль агымнарының күп төрлеләнгән билгеләп, докладчылар бүгенге этапта стильләр яшәешенең кайбер гомуми закончалыкларын күрсәтеп үттеләр. Мәсәлән, совет Көнчыгышына караган күп

кенә әдәбиятларда романтик стиль агымының көчәюе әйтелде. И. А. Солтанов (Ташкент), үзбәк әдәбиятында революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы чор романтизмын чагыштырып, романтизмның идея-эстетик функцияләре ягыннан сыйфат яңарышы кичерүен, социалистик реализм методы белән органик рәвештә бергә кушылуын ассызыклап үтте. Бүгенге поэзиядә романтик стиль көчәюенең сәбәбен Г. Б. Хөсәенов (Уфа) космик масштабта танып белү һәм фикер йөртүдә күрә, Й. Г. Нигъмәтуллина эстетик аңның «космик масштабка күтәрелүе, «космиклашуы» белән аңлата һәм моны совет әдәбиятының бүгенге этабында эстетик идеал үсешенең үзенчәлекләреннән берсе дип саный. Татар драматургиясе мисалында А. Г. Әхмәдуллин, татар прозасы нигезендә Э. Г. Нигъмәтуллин, хәзерге төрекмән прозасы материалында А. Мамедов романтик стиль агымының җанлануы әдәбиятта интеллектуаль, философик башлангыч үсүенә дә бәйле иканлеген исбатладылар.

Совет Көнчыгышы әдәбиятларында шартлы формаларның шактый киң кулланылуы да социалистик реализмдагы романтик стиль мәсьәләсе белән бәйләнештә аңлатыла. Т. Н. Галиуллинның (Алабуга) «Социалистик реализм һәм бүгенге поэзиядә сәнгатьчә шартлылыкның роле» дигән доклады шартлы формаларны типологик яктан классификацияләүгә багышланган иде. Докладчы матур әдәбиятта шартлылыкны өч типка бүлә: беренче шартлылык (реалистик стильгә хас кинаяә алымы), «аң ташкынын» гәүдәләндерү һәм чынбарлыкны икеләтә проекцияләү (чагылдыру) гә бәйле шартлылык, предметлылык һәм абстрактлылыкны тоташтыручы ноктада туып, автор җиткерергә теләгән фикерне һәм әсәрнең бөтен рухын билгели торган синтетик шартлылык. Бу соңгы тип романтик стиль агымы өчен аеруча характерлы.

Социалистик реализм методы эстетик концепциясенең философик эчтәлеге тирәнәя бара. һәм бу бөтенсоюз әдәби процессының әйдәп баручы тенденциясе дип бәяләнә. Совет Көнчыгышы әдәбиятларында да без шул ук тенденциянең күп төрле формалардагы чагылышын күрәбез. Шушы җәһәттән, докладларда (З. А. Әхмәтов, Л. А. Бекизова, А. Г. Яхин, Н. Г. Юзиев, Ф. Әхмәтова һ. б.) фольклор һәм шәрык классик поэзиясе (хикәят, миф, хикмәтле сүз һәм тапкыр фикер поэтикасы һ. б.) традицияләрен файдаланудагы үзгә хасиятләр мәсьәләсе дә үткен куелды. Ю. И. Суровцев, мәсәлән, фольклор жанрындагы «миф» төшенчәсен чит ил буржуаз идеологлары һәм каләм ияләре иңдергән идеалистик эчтәлектән арындыру кирәклеген искәртеп үтте.

Конференциядә күп милләтле әдәбиятыбызга тулаем хас булган тарихилык принцибын алга таба да тирәнәйтә, үстерә баруга зур игътибар бирелде. Ф. М. Мусин үзенең докладында менә шушы проблеманың кайбер теоретик аспектларына тукталып, фәнни һәм сәнгатьчә фикерләүдәге тарихилык, бүгенге чынбарлыкны һәм тарихи-революцион үткәнне сурәтләүдәге тарихилык кебек мәсьәләләрне алга куйды. М. Шукуров, бай фактик материалга таянып, таҗик әдәбиятында тарихилык принцибының егерменче еллардан алып бүгенге көнгә кадәрге үсешен күздән үткәрде. Аның раславынча, халыкның тарихи хәтерен чагылдыру ягыннан таҗик әдәбиятындагы тарихилык проза жанрларына хас күренеш, ул бигрәк тә психологик анализда ачык күзәтелә. Бүгенге казакъ әдәбиятында һәм Төньяк Кавказ әдәбиятлары прозасында тарихилык принцибы тарихи һәм тарихи-революцион роман жанрында калку чагылыш таба. Г. Бердибаев (Алма-Ата) һәм Л. А. Бекизова (Черкесск) докладлары әнә шул темага багышланган иде. А. Садыйков (Фрунзе) докладында бүгенге кыргыз әдәбиятын баетуда тарихилык һәм интернационализм принцибының роле хакында сүз барды.

Конференциядә шулай ук язучылардан А. Нурпеисов, А. Кекильбаев (Алма-Ата), Ф. Исәнголов (Уфа), П. Кадыйров (Ташкент), А. Коптяева (Мәскәү), К. Кулиев (Ашхабад), Б. Укачин (Горно-Алтайск), Г. Ахунов (Казан) чыгыш ясады. Алар әдәбиятта һәм әдәбият фәнендә халыкның художество-эстетик тәҗрибәсеннән тулырак файдаланырга чакырдылар. Мәсәлән, Ф. Исәнголов, П. Кадыйров чыгышларында иҗат психологиясе мәсьәләләре игътибар үзәгенә куелды, әдәби процессны прогнозлаштыру, совет Көнчыгыш әдәбиятлары буенча җитди социологик тикшеренүләр үткәрү проблемалары күтәрелде. П. Кадыйров фикеренчә, әдәбият белеменә караган хезмәтләрдә иҗат методы структурасында талант категориясенең роле мәсьәләсенә тиешенчә игътибар биреп җиткерелми. А. Коптяева исә әдәбият галимнәре игътибарын язучы иҗатында аналитик процессны тикшерү зарурлыгына юнәлдерде.

Йомгаклау сүзендә Г. И. Ломидзе әйткәнчә, конференциядәге докладлар һәм чы-

гышлар «ифрат эчтәлекле, проблемалы, теоретик характерда булды». Чыннан да, конференциянең тематикасы киң колачлы һәм күп төрлелеге белән аерылып тора. Бирерә кызыклы иҗади бәхәсләр барды, бөтен совет әдәбиятының ифрат та бай материалына таянып, тирәнтен өйрәнү-тикшеренүгә лаек булырлык фикерләр әйтелде.

Конференцияне япканда, Ю. И. Суровцев әдәбият галимнәре һәм язучыларның бу фәнни форумы «эшлекле, чын интернационализм рухында» үтте дип белдерде. Ул шулай ук конференциядә күтәрелгән мәсьәләләр арасыннан әдәби иҗатны прогнозлаштыру проблемасының зур әһәмияткә ия булуын күрсәтте. Бу — киләчәктә үтәчәк Бөтенсоюз конференцияләренең берсендә махсус тикшеренүгә лаек мәсьәлә, диде ул. Прогнозлау төрле юнәлештә алып барыла ала: әйтик, җитмешенче елларда кеше шәхесе концепциясе үсеше яисә көндәлек иҗат эшендә даими кулланыла торган принципка әверелеп килгән тарихилык принцибының ни рәвешле тирәная баруы хакында тикшеренүләр үткәрергә мөмкин. Ю. И. Суровцев фикеренчә, конференциядә ачыкланган методологик табышлар, һичшиксез, әдәбият белеменең киләчәк үсешенә этәргеч бирер. Иң мөһиме — конференциядә катнашучыларның катлаулы һәм бәхәсле теоретик мәсьәләләрне (мәсәлән, социалистик реализм методы һәм андагы юнәлешләр, метод һәм жанрлар нисбәте, социалистик реализм методының төрле стиль агымнарында гәүдәләнеше) конкрет хәл итүгә омтылуында.

Г. И. Ломидзе һәм Ю. И. Суровцев совет Көнчыгышы әдәбиятларында социалистик реализм проблемалары буенча киләсе конференцияне «киң колачлы иҗади уйланулар диапазонында», күп милләтле совет әдәбиятының башка регионнары галимнәре һәм язучылары катнашлыгында үткәрергә чакырдылар.

Конференция материалларын аерым җыентык итеп дөньяга чыгарырга карар кылынды.



**Зоя Сергеевна Кедрина,**

филология фәннәре докторы

# СОЦИАЛИСТИК РЕАЛИЗМ — КҮП МИЛЛӘТЛЕ СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫНЫҢ УРТАК КАЗАНЫШЫ

Социалистик реализм генезисы мәсьәләсе — иң актуаль проблемаларның берсе. Совет Көнчыгышы әдәбиятлары өчен ул, ихтимал, аеруча әһәмиятледер. Ә инде социалистик реализмны безгә, янәсе, көчләп тагылган әдәбият-сәнгать методы дип өзлексез лаф оручы чит ил «советологлары»на каршы көрәштә аның әһәмияте һичшиксез зур. Америка Кушма Штатлары советологлары, илебез халыкларының бердәмлеген какшату максаты белән, әдәбият фәне пәрдәсе артына яшеренеп, зур-зур «тикшеренүләр» язалар һәм шушы мәсьәләгә журналларда махсус саннар багышлыйлар. Советлар Союзында «милләтчелек рухы» чәчәк ата, диләр алар, ә руслар исә анда «өстенлек алып торучы милләт» булганлыктан, имеш, «совет милләтчелеге дә рус милләтчелеге белән тыгыз үрелгән». Шуңа күрә, тугандаш халыклар әдәбиятлары, янәсе, күп милләтле бердәм әдәбият буларак түгел, ә фәкать рус әдәбияты буларак кына үсә [1].

Хәтта Советлар Союзында милли телләрнең бер-берсен үзара баетуы, шул исәптән, «СССР халыклары телләренә рус теленнән сүзләр, сүз тезмәләре һәм төрле атамалар керүне» дә алар, совет кешеләренең немец фашизмына каршы Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы кебек үк, «рус милләтчелеге» чагылышы дип карыйлар [2].

---

[1] Review of National Leteraturs. 1972 ел., III, № 1, 183 бит.
[2] Slabic Review. 1973 ел, № 1, 20 бит.

Шуңа күрә дә, алты томда басылган «Күп милләтле совет әдәбияты тарихы»ның чит илләрдә зур кызыксыну белән каршы алынуы һич тә очраклы хәл түгел. Чөнки ул хезмәт совет әдәбиятының бердәмлеге һәм күп төрлелеге илебез халыкларының бердәм яшәеш процессы нәтиҗәсе икәнлеген кире кагылгысыз итеп раслый. Аны әдәбиятчыларыбызның күп еллар буе алып барган тикшеренүләренә таянып, күп милләтле совет галимнәре коллективы тудырган.

Совет Көнчыгыш әдәбиятларында социалистик реализмның барлыкка килүен тикшергәндә, бу әдәбиятларның тарихи үткәнен, үзенчәлекле үсеш юлларын исәпкә алып эш итәргә кирәк. Генезис проблемасын дөрес хәл итү бу әдәбиятларның милли үзенчәлеген төгәл билгеләргә, илебезнең күп милләтле һәм бердәм әдәбият-сәнгате системасында һәр әдәбиятка хас гомуми һәм хосуси билгеләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Хәлбуки, социалистик реализм генезисы мәсьәләсе безнең әдәбият теориясендә иң йомшак өйрәнелгән өлкәләрнең берсе дияргә була. Хәзерге көнгә кадәр галимнәребездән кайберәүләр, социалистик реализм методы принципларын халыкчанлык принцибына гына кайтарып калдырып, аны шактый ук ерак чорда туган дип күрсәтсәләр, икенчеләре социалистик реализм юлына аяк басуны ниндидер чиста язу мәктәбенә керүгә тиңләп булса кирәк, методны «үзләштерү» хакында сөйлиләр.

Социалистик реализм әдәбиятының формалашуын совет әдәбиятының кайбер классиклары иҗаты мисалында тикшереп карыйк. Садретдин Айни, Мохтар Әүэзов, Андрей Упит, Галимҗан Ибраһимов һәм башка каләм осталарының иҗатларында гомумсоциалистик һәм милли сыйфатлар үзенчәлекле диалектик бердәмлек тәшкил итә. Бу әдипләр тәҗрибәсе аеруча кыйммәтле, чөнки алар совет сәнгатенең уртак хәзинәсенә үзара бәйләнешлар һәм үзара йогынты ясау процессында яңарыш кичергән, үстерелгән милли-тарихи традицияләрне алып килделәр. Алар үзләренең әдәби практикасын иҗади яктан да нигезле алдылар, ягъни үзеннән-үзе, мөстәкыйль рәвештә туган һәм үз эчке көченә таянып үсә баручы социалистик реализм методының тере организмына яңа куәтләр өстәделәр. Шушы художниклар йөзендә методның «үзеннән үзе барлыкка килүенең» төрле тибын күрергә мөмкин. Айни шәрык поэзиясенең мең еллык тәҗрибәсеннән килә. Андрей Упит үз иҗатында дөньякүләм әдәби процесска, беренче чиратта, рус һәм француз классик әдәбиятына таяна. Әүэзов исә берьюлы өч чыганакка: туган телендәге фольклорга, борынгы шәрык традициясенә һәм рус классик реализмына нигезләнә.

Совет сәнгатендә көнчыгыш, көнбатыш һәм шәрык-гарәп традицияләрен кузаллаучы шушы әдипләр иҗаты уртак тарихи кануннар нигезендә үсә һәм тармаклана. Нәкъ шул закончалыклар һәр яңа дәвердә үз заманының үзенчәлекле яшәешен чагылдырырга, чорның әйдәп баручы көчләренә гайрәт өстәргә сәләтле яңа әдәбиятка нигез салучы художникларны мәйданга чыгара. Һәр олы художник үткәннең тәҗрибәсенә таянып һәм, берьяктан, аны тормыш, тарих таләпләренә нисбәтле рәвештә үзгәртә, яңарта барып, икенче яктан, башка халыклар әдәбияты-сәнгате казанышларыннан үрнәк алып, үз чоры рухын гәүдәләндерү өчен яңа чаралар, төс-буяулар эзли. Тарихи үсештә нинди баскычта тору, милли әдәбият-сәнгать традицияләренең нинди үсеш дәрәҗәсенә ирешкән булуы иҗади эзләнүнең юнәлешен, характерын, художникның кузаллау колачын һәм, ахыр чиктә, әдәбиятның төп үсеш юлын билгели.

Һәм каләм ияләренең эзләнүләре иң элек халыкчанлыкка, ягъни тарихи иҗат мәйданына чыгып килүче хезмәт иясе массаларының күп гасырлык хыял-омтылышлары яктылыгында яңалыкны күрә белү һәм заманның әйдәп баручы көче — пролетариатның социалистик революциясенә кушылып китеп, тормыш һәм сәнгать дөньясын аңларга һәм яңартырга омтылу, ягъни партиялелек аша тарихилык принцибын тормышка ашыруга юнәлдерелә. Шушы гомуми закончалык югарыда исемнәре аталган язучыларның барысы алдына да уртак бөек максатлар куя, һәм аларның һәрберсе төрле сукмаклардан килеп, бердәм совет әдәбиятының олы юлын салышалар.

Садретдин Айни гади бер шәрык авылында туып үсә, «изге Бохара» мәдрәсәләрендә сабак ала, җәдитчелек хәрәкәтендә якыннан катнаша, шәрык поэзиясен җентекләп өйрәнә һәм үзе дә искелек, торгынлыкка нәфрәт белдергән шигырьләр иҗат итә. Аны Бохара әмиренең боерыгы белән зинданга ябып, таяк белән суктыралар. Ул

Кызыл Армия госпиталендә дәваланып чыга. Шул рәвешчә, Айниның иҗади эзләнү юлы Бохара зинданы бусагасы төбеннән башланып китте дияргә була. Бу чорда ул әле рус телен яхшы белми һәм иҗатында иске шәрык әдәбияты материалына таяна. Язарына «азыкны» ул барыннан да элек тирә-ягында кайнап торган тормыштан ала, кыю рәвештә реализм сукмагыннан атлый. Бу атаманы әлегә ишетмәгән булса да, үзен үстергән халык турында яңа сүз, хак сүз әйтергә теләвен ул бик яхшы белә.

Әдәбият-сәнгать яңа юллар салучыларга хас булганча, Айниның әдәби һәм фәнни иҗаты янәшә үрелеп бара. Бу елларда инде ул атаклы таҗик-үзбәк шагыйре һәм шәрык поэзиясен, тарихын өйрәнгән галим буларак танала. Аның революциядән соңгы беренче чәчмә әсәрләрендә нәфис әдәбият һәм социаль-тарихи тикшеренү элементлары бергә кушыла. Әдип тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын тарих катламнары белән бергә күрәп алырга омтыла. Әдип һәм тикшеренүче галимнең фикере әсәрдән әсәргә тирәнәя бара. Әмир деспотлыгын фаш иткән «Бохара җәлладлары» әсәреннән соң ул халыкның социаль-экономик яктан изелү темасын күтәрә («Одина»), ә аннары «Дохунда» әсәрендә хезмәт иясе массаларының аңлы, актив протестын гәүдәләндерә. Ниһаять, ул бөтен тарихи барышны тулаем килеш, иркен һәм эзлекле төстә җанландырып күрсәтү эшенә керешә. Хезмәт халкының иректән мәхрүм ителеп колга әверелдерелүе, изү-газаплауларның көчәюе һәм протест тудыруы, феодаль җәмгыять шартларында азатлык хәрәкәте күтәрелә бару, Россиядән кергән яңа идеяләр тамыр җәя башлавы, революция давылы кузгалу һәм яңа азат тормыш ныгып урнашуы,— боларның барысы чорлар эпопеясе булып яңа әдәбиятның нигезенә ята.

Шунысы характерлы, Айни үзенең әсәрләрендә һәр чорга хас җыелма образ, типлар тудырырга омтыла. Башта әле ул образ-шәүлә булып кына гәүдәләнә — Бохара җәлладлары нәкъ әнә шундый — аннары, шәрык әдәбиятына хас булганча, гөнаһсыз килеш газап чигүче Одина образы сурәтләнә. Ә инде «Дохунда» әсәре битләреннән Айни прозасында Эргаш кебек актив образ — иске тормышны җимереп яңаны төзүче көрәшчеләр тибы калка.

Иске шәрык традициясенә таянып әдәбият мәйданына килгән Айни иҗатында әнә шулай акрынлап социалистик реализм принциплары тамыр җәя, үсә башлый. Автор партиялелек һәм халыкчанлыкны үзенең төп кыйбласы итеп карый, тормышның типик күренешләрен гомумиләштерү юлыннан атлап, тарихны тудыручы халык образын гәүдәләндерүгә кадәр күтәрелә.

Урта Азия халыкларының, капитализм стадиясен читләтеп, урта гасырчылыктан турыдан-туры социализмга күчүе закончалыкларын тикшерү һәм образлы гәүдәләндерүгә корылган, Айни тарафыннан нигезләнгән тарихилык принцибы соңрак таҗик һәм үзбәк совет язучыларының бөтен бер буыны иҗатына юнәлеш бирә. Алар, Айни тәҗрибәсенә таянган хәлдә, милли характерлар психологиясен гәүдәләндерү аша типик характерлар тудырырга киләләр. Остазларының тарихилык принцибын һәм традицияләрен үстереп, Җәләл Икрами, Сатым Улугзадә кебек язучылар үз әсәрләрендә Айниның сурәтләү алымнарын баета баралар һәм шул ук вакытта кайбер искергән нәрсәләрдән арыналар да.

Илебездә социалистик әдәбиятлар кулга-кул тотынып яңа биеклекләр яулаган дәвердә, С. Айни иҗатында да яңа этап башлана. Бу этап олы әдипнең А. М. Горький тәҗрибәсен үзләштерүе чорына туры килә. Иске шәрык әдәби традициясе Айни әсәрләрендә сыйфат яңарышы кичерә. Мәсәлән, «Коллар», «Ростовщикның үлеме» әсәрләрендә образ-тип бер үк вакытта типик характерга әверелә, ә «Истәлекләр»ендә (русчага тәрҗемәдә — «Бохара») бу яңарыш гаҗәп ачык бер характер ала. Биредә Әхмәт Донишка хас шәрык публицистик дидактикасы һәм хикәяләүдә иске шәрыкның традицион «тәсбих» композициясе алымы Горькийның иҗат тәҗрибәсе белән кушылып, чын осталарча һәм гаять тирән эшләнгән «Изге Бохара» образ-портретын барлыкка китерә. Ул, ифрат зур газаплар эчендә торгынлык, караңгылыктан котылып, яңа эпоха кешесен иҗат итү юлына аяк баса. Әсәрнең геройлары әле үзләренең милли тормыш-көнкүрешенә кендекләре белән ябышканнар, тик шулай да инде алар — киләчәкнең гомумсоциалистик идеалын үзендә йөртүче яңа кешеләр.

Художникка шушы портретны төгәлләргә үлем комачаулый. Ләкин әдәби традицияләр — үлемсез. Олы остазның эшен халыкның сөекле каһарманы турындагы

«Восе» романы белән С. Улугзадә дәвам иттерә. XIX йөздә халык күтәрелеше башында торган Восе — чын мәгънәсендә реалистик образ, аңарда характер һәм тип диалектик берлектә чагылдырыла. Әсәрдә таҗик милли характеры гәүдәләндерелә, халыкның тиранниягә каршы күтәрелеше тарихи барыш закончалыкларына җавап бирүе исбат ителә. Герой характерының эчке асылы, үз заманының иң алдынгы вәкиленә хас сыйфатлары аны табигый рәвештә, гаделсезлеккә корылган җәмгыятькә, урта гасырчылык тәртипләренә каршы актив протест, көрәш юлына этәрә.

Айни «Истәлекләр»енең кайтавазын без үзбәк мемуар әдәбиятында, аеруча Нәзир Сәфәровнең «Нәүруз» (1975 ел) әсәрендә тоябыз. Әсәр героеның бала чагы һәм яшьлек елларын сурәтләгән картиналар Октябрьга кадәрге чорда шәрык халкының социаль уянуы тарихы булып кабул ителә. Автор биредә гади генә бер гаилә тарихын тасвирлый; бу гаилә кешеләре революцион процесста нинди дә булса аерым күренекле урынга дәгъва итмәсәләр дә, аның аерылгысыз бер өлешенә әвереләләр. Әсәр нәкъ әнә шуның белән отышлы да. Айбекның «Балачак», Гафур Голәмнең «Шук малай» әсәрләре, Абдулла Каһһарның бала чак турындагы истәлекләренә карата да шуны әйтергә мөмкин булыр иде. А. Каһһар караңгы бер кышлактан чыгып, революциягә кушылган авыл малаен тирән психологик реализм белән сурәтли. Бу образда гасырлар буе басылып яткан халык акылы, күңел дөньясының ачылып китүе, «кечкенә» кешенең тормышны революцион үзгәртеп кору процессында үзе дә үзгәреп, бөек эшләр башкарырга сәләтле булып үсеп житүе сурәтләнә.

Бала күңелендә моңарчы күрелмәгән гаҗәеп яралгылар барлыкка килүен, яшь кешенең революциягә кушылуы темасын (тик бу юлы кышлактан чыгып түгел, ә бөтен авыл белән бергә), хикәяләүдәге шул ук «тәсбих» композициясен без Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле повестендә күрәбез.

Үз чиратында Г. Бәширов повесте рус реалистик традициясе вәкиле Василий Смирновның «Дөнья ачылганда» әсәренә аваздаш тоела. Бу ике әсәрнең баш геройлары Шурка белән Гомәр арасындагы охшашлык рус һәм татар авылының социаль һәм географик яктан мәгълүм дәрәҗәдә бер-берсенә якын торуы белән генә аңлатылмый. В. Смирнов һәм Г. Бәширов әсәрләренең охшашлыгы авторларның методологик яктан якынлыгы белән дә билгеләнә, чөнки татар әдәбияты Урта Азия әдәбиятларына караганда рус әдәбияты белән элгәрерәк туганлашкан.

Совет Көнчыгышы әдәбиятларында бала чак темасының зур урын билэп торуы социалистик реализм методы формалашу процессында гомуми уртак сыйфатлар туа баруы хакында сөйли. Аны революция барышында халыкның рухи дөньясы ничек яңаруын тулы һәм ачык итеп тасвирларга мөмкинлек бирә торган эпик форма эзләү дип әйтергә мөмкин. Кечкенә геройларның рухи үсешен тасвирлаган повестьлары белән язучылар халыкларның революциягә килү юлларын сурәтлиләр.

Инде килеп, латыш совет әдәбиятына нигез салган Андрей Упит иҗатын күздән кичерсәк, социалистик реализм методының тууы һәм үсеше аңарда бөтенләй башкача баруын күрербез. Россия революцион хәрәкәтендә катнашкан кеше буларак, ул социалистик сәнгать чыганакларына политик яктан җитлеккән язучы, публицист, теоретик, ныклы реализм тарафдары булып килә. Ул рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларын яхшы белә, бөтендөнья культура мирасын тәнкыйть күзлегеннән карап үзләштерә.

«Рус язучылары яшүсмер чагымнан ук минем иң яраткан авторларым булды,— дип яза ул.— Достоевскийны ике тапкыр, Тургенев белән Чеховны дүрт тапкыр укып чыктым, Лермонтов, Пушкин, Гоголь, Щедриннар да миңа бик кадерле, әмма Максим Горькийны барысыннан да артыграк яратам». («Знамя» журналы, 1977 ел, № 12, 230 бит.)

А. Упит Горькийны социалистик реализм методына нигез салучы итеп саный, әмма теоретик буларак, һәр мәсьәләдә аңа иярми. Мәсәлән, ул реалистик метод бердәмлеген яклап, романтизм элементларын мөстәкыйль метод итеп аерып алуга каршы чыга. Ул аңа гомумән реакцион романтизм итеп кенә карый. Үз иҗатында да А. Упит («Робежниеклар», «Яшел җир») аек реалист булып кала.

Айни кебек үк, А. Упит та үз иҗатына М. Горькийның зур йогынты ясавын таный, ләкин бу йогынты һәр ике язучының иҗатында төрлечә яңгыраш ала. Айни гавамнан типны, ә типтан исә индивидуаль характерны аерып ала. «Истәлекләр»ендә ул, мәсәлән, психологик яктан төгәл һәм ифрат җанлы сурәтләнгән индиви-

дуумнар галереясен тудыра. Андрей Упит исә, киресенчә, индивидуаль характерлардан революцион масса образын тудырырга омтыла. Упит фикеренчә, социалистик реализм сәнгатендә шәхес коллектив тормышы һәм хезмәттәшлеге стихиясе эчендә өлгереп килүче итеп, шул тормышның барлык борылышлары, катлаулылыгы, сикерешләре белән бергә — чынбарлыкта исә бу нәкъ шулай — сурәтләнергә тиеш. (А. Упит, Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. Латыш дәүләт нәшрияты. Рига, 1955 ел, 222 бит.) Латыш совет әдәбиятында А. Упит традицияләрен Виллис Лацис, Анна Саксе, Висвальд Лам һәм башка язучылар дәвам иттерәләр. Аларның әсәрләрендә ялгыз кешенең эшчеләр коллективына кушылып, фәкать шунда үзләренең чын кешелек юлын табулары һәм чын шәхес булып өлгереп җитүләре гаять эзлекле һәм калку гәүдәләндерелә. «Халыкның кичергән газаплары, җәберләүләр, ул кичергән кыенлыклар, аның түземлелеге һәм киләчәккә какшамас ышанычы Упит әсәрләрендә лаеклы чагылышын тапкан,— дип яза В. Лам.— Аның фикерен һәм күңелен әнә шулар туендырып тора, берәүнең күпләр арасында булырга тиешлегенә нык ышаныч бирә». («Дружба народов», 1977 ел, № 12, 263 бит.) Ә аның «Курчак һәм комедиант» әсәренең герое бу хакта менә нәрсә ди: «Ялгыз кеше ул яши алмый, бернинди эш майтара, ялгыз кеше тормышны бәяли дә алмый».

С. Айни традицияләре, социалистик сәнгать принципларына аның карашы таҗик һәм үзбәк әдәбияты чикләреннән ашып, социалистик реализм методы яшәешендә яңа традицияләргә нигез булган кебек, А. Упит традицияләре дә, Балтик буе республикалары әдәбиятларына таралуы белән бергә, шул ук Урта Азия һәм гомумән Совет Көнчыгышы язучылары тарафыннан да, совет әдәбияты-сәнгате һәм аның методының уртак нигезен тәшкил итүче мирас итеп карала.

Татар совет әдәбиятында һәм әдәбият фәненә нигез салган Галимҗан Ибраһимов иҗаты мисалында да шул ук фикерне раслый алабыз. Латыш художнигы белән турыдан-туры бәйләнеш тотмаса да, реализм принципларына карашында ул күп яклардан А. Упит фикерләренә якын тора, тормышны аның «үз формасында», тарихи эзлеклелек белән тасвирлануны мәгъкуль күрә. Г. Ибраһимовның сурәтләү стиле әле шул чорда ук татар язучыларына (мәсәлән, Кави Нәҗмигә) гына түгел, төрки телле әдәбиятларның башка вәкилләренә дә зур йогынты ясый. Казакъ язучысы Бәембәт Майлин, мәсәлән, беренче әсәрләрен Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» тәэсирендә иҗат итә. Бу стиль, гомум совет әдәбияты казанышлары белән баеп барган хәлдә, бүгенге татар прозасында (әйтик, Г. Бәширов, А. Расих, Г. Ахунов иҗатларында) яшәвен дәвам иттерә.

А. М. Горький, А. Толстой, С. Айни, А. Упит, М. Әүэзов, Г. Ибраһимов, А. Кадыйри, Айбек, С. Бородинны совет көнчыгышы әдәбиятларының тарихи романчылары үзләренең күмәк ориентирлары итеп саныйлар. Шулар арасыннан Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәби традицияләрен үз иҗатында бергә куша алган художникларның берсе Мохтар Әүэзов булды.

Көнчыгыш әдәбиятларында аңа кадәр аз үзләштерелгән жанрлардан проза һәм драматургия өлкәсендә иҗат итә башлап, ул бик тиз вакыт эчендә үзен өлгергән реалист язучы буларак танытты. Рус классик әдәбиятына юнәлеш тоткан хәлдә, М. Әүэзов үз халкының фольклор хәзинәсенә дә бик киң таяна. Аның беренче әсәре — «Иңлек — кибәк» трагедиясе (1917 ел) халык риваятенә нигезләнеп язылган. Мәгърифәтчелек идеяләрен бик яшьли сеңдергән, учительская семинария тәмамлаган яшь каләм иясе шул чорда ук инде рус классик әдәбиятын (бигрәк тә Тургенев әсәрләрен) яхшы белә һәм яратып укый, чит ил әдәбиятыннан да хәбәрдар була. Төпле белемнәр белән коралланган әдип тиздән казакъ халкының сөекле шагыйре Абай иҗатын халык арасыннан җыеп кабат тергезү, бу олы мирасны халыкка мөмкин кадәр тулырак итеп кайтарып бирү эшенә керешә. Һәм аның бу гаять киң колачлы эшчәнлеге әдәбият белеменең Абай хакындагы махсус өлкәсен тудырырга һәм дөньякүләм әһәмияткә ия булган «Абай юлы» роман-эпопеясен иҗат итүгә китерә. Шул рәвешчә, М. Әүэзов үз халкының иҗади традицияләрен, фольклор байлыгын җыеп һәм тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, аны бөтен тулылыгында дөньякүләм әдәбият-сәнгать хәзинәсенә китереп куша.

Барлык халыкларның культура мирасына булган тирән ихтирамы, аларның иҗади тәҗрибә җимешләрен зур тырышлык белән үзләштерүе (мәсәлән, кыргыз халык эпо-

сы «Манас» хакындагы фәнни хезмәте) М. Әуэзовның үз иҗатында яңа социалистик әдәбият-сәнгать методы тамыр җәеп үсеп китүе өчен ныклы нигез тудыра.

М. Әуэзов таянган көнчыгыш-көнбатыш сәнгате хәзинәсенең байлыгы яңа казакъ әдәбияты үсеше өчен уңдырышлы җирлек булып хезмәт итә. Казакъ язучыларының күп төрле иҗат индивидуальлегенә ия булган яңа буыны күтәрелеп чыгуында М. Әуэзов калдырган игелекле традицияләрнең дә көчле йогынтысы бар. Әуэзов традициясенә хас эпик киңлек, халык характерларын нечкә сиземләү һәм аларны өйрәнүдә дөньякүләм әдәби тәҗрибәгә таяну кебек сыйфатларны Әбдеҗәмил Нурпеисов һәм Тәхәви Ахтанов («Кан һәм тир» эпопеясе, «Каһәрле көннәр», «Дала сере» романнары), Әбеш Кикелбаев («Дала балладалары»), Сатымҗан Санбаев («Ак дөя», «Күпәҗәл») әсәрләрендә ачык тоярга була.

М. Әуэзов калдырган традицияләрнең йогынтысы совет Көнчыгышы һәм күп кенә шәрык илләре әдәбиятлары белән генә дә чикләнми. «Кыргыз һәм каракалпак тарихи романнары (Т. Касыймбековның «Сынган кылыч», Т. Кайыпбергеновның «Каракалпак кызы», «Маман би турында хикәят»), рус язучылары С. Бородин, М. Симашконың тарихи әсәрләре, Ә. Фәйзинең Тукай турындагы биографик романы, бүгенге әзербайҗан эпосы (М. Ибраһимов, С. Рагимов иҗатлары) һәм башка бик күп милләт язучыларының әсәрләре структур корылышлары һәм башка күп билгеләре ягыннан казакъ совет әдәбияты классигы белән аваздашлыклары хакында сөйлиләр.

Ә инде М. Әуэзовның әдәбият белеме өлкәсендәге гыйльми эшчәнлегенә килсәк, Казагыстан Фәннәр академиясе М. Әуэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институты эшчәнлегенең бу олы әдип традициясенә нигезләнгән булуын әйтү дә җитә. Ул совет әдәбиятын күп милләтле процесс буларак комплекслы өйрәнү проблемасын куйган совет галимнәренең беренчеләреннән берсе булды. Нәкъ менә әдәбият белеме өлкәсендә төрле милләт язучыларының тәҗрибәсе бергә кушыла. М. Әуэзов кебек үк, Айни да «Таҗик әдәбияты үрнәкләре» (1925 ел) исемле антологиясе белән таҗик әдәбият белеменә нигез сала. А. Упит та шулай ук «Яңа латыш әдәбияты тарихын» (1911 ел) яза, ә 1940 елдан башлап социалистик реализм теориясе өлкәсендә эшли башлый. («Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре», Рига, 1955 ел.)

Бу художникларның һәрберсе үз индивидуаль иҗат йөзләрен саклап калды, әмма аларның конкрет иҗат практикасында кристаллашкан методы уртак фәнни җирлеккә нигезләнгән иде. һәм ул методны алар марксизм-ленинизм позицияләреннән торып үстерә килделәр.

Совет милли әдәбиятларына нигез салучыларның иҗат тәҗрибәсе рус язучылары тарафыннан да кабул ителә. Төрле республикаларда яшәүче рус язучылары иҗатында бу бигрәк тә ачык сизелә. С. Бородинның (ул Айни әсәрләрен дә күп тәрҗемә иткән) тарихи әсәрләрендә дә, М. Шевердинның тарихи-революцион романнарында да Айни тәҗрибәсе йогынтысын күрә алабыз. Ә тарихи романчы Морис Симашко исә үз иҗатында Айни белән дә, Әуэзов һәм С. Бородин белән дә элемтәдә тора.

Безнең уебызча, социалистик реализм методын ачык эстетик система дип билгеләве белән Д. Ф. Марков бик хаклы. Үзара иҗади элемтәләр һәм бер-береңне иҗади баету процессы социалистик реализм методын камилләштерүгә, күп милләтле совет әдәбиятының бердәмлеген ныгытуга, ахыр чиктә исә, киң мәгънәдәге милли формаларның үзара якыная баруына илтә. Шуңа күркәм бер мисал рәвешендә Чыңгыз Айтматов иҗатын китерергә мөмкин. М. Әуэзовны ул үзенең юл башында торган художниклардан берсе дип атый. Халык тормышының һәр мөһим чорын ул гомумсовет проблемалары белән бәйләп карый белә һәм кыргыз халкының үзенчәлекле тормыш-көнкүрешен дөньякүләм реалистик тәҗрибәгә таянып сурәтли. Җитмешенче еллар ахырында исә ул, нивх халкы фольклорына нигезләнеп, «Диңгез яры буйлап чаба торган эт» әсәрен иҗат итте һәм үзеннән бик ерак җирләрдә яшәүче халык рухын никадәр нечкә тоярга мөмкин булуын күрсәтте.

Андрей Упитны дулкынландырган кеше һәм коллектив проблемасы бүген бөтенләй башка чор һәм буын, бүтән милләт язучыларын җәлеп итә. Яшь кыргыз язучылары Муса Мораталиев («Ике гомер») һәм Морза Гапаров («Киек каз») повестьлары нәкъ менә кеше гомерендә коллективның роле, ялгызлык һәм кумәклек мәсьәләләренә багышланган.

Татар язучысы Шамил Бикчуринның «Каты токым» романына мөрәҗәгать итсәк тә,

без шул ук мәсьәләгә тап булабыз. Коллективның аерым кеше тормышында хәлиткеч урын тотуы хакында В. Лам әйткәннәрне татар язучысы үзенчәлекле әдәби чаралар белән раслый. Бораулау мастеры Зөбәеров бригадасында сәер гадәтле кешеләр аз түгел. Һәрберсенең диярлек тормышта үз исәбе, үз бизмәне бар. Әмма йөкне башта төрле якка тартучы бу кешеләр, кумәк хезмәт эчендә кайнап, нык берекән коллектив барлыкка китерәләр. Шушы процесста һәркайсының характерындагы иң яхшы сыйфатлар канат җәя, ачыла бара.

Югарыда санап үтелгән әсәрләр стилистик яктан бик күп төрле булсалар да, бу күп төрлелек, ике-өч дистә еллар элегрәк язылган әсәрләргә караганда, милли үзенчәлек, милли көнкүрешкә ул кадәр үк нык бәйләнмәгән, стиль төрлелеге бүген инде күбесенчә авторларның иҗат индивидуальлегеннән килә. Татар язучысы Атилла Расихның «Язгы авазлар» һәм «Ике буйдак» романнарын алып карыйк. Аларда хәзерге авыл, аның экономикасы, хезмәт һәм культура мәсьәләләренә зур урын бирелә. Фән һәм практика, җитәкчеләр һәм масса, материаль һәм әхлакый проблемаларны хәл итүче кеше һәм гомумдәүләт мәнфәгатьләре белән яшәүче коллектив кебек гаять актуаль проблемалар күтәрелә. Боларның барысы турында автор нык эшкәртелгән реалистик алымда, геройларының конкрет эшен бик яхшы белеп яза. Г. Ибраһимов кебек үк тасвирда ул үзен иркен һәм ышанычлы тота, һәрнәрсәне исбатлап, тормышны аның үз формасында сурәтли. Шул ук вакытта, мәсәлән, Елизар Мальцев яисә Анатолий Ананьев кебек рус язучылары да якынча шундый ук стильдә иҗат итәләр дип әйтергә мөмкин. Атилла Расих романнары формасының милли үзенчәлеге элгәрерәк чорда иҗат иткән Кави Нәҗми әсәрләрендәге кебек күзгә бәрелеп тормый. А. Расихның уңай геройларына хас билгеләрне, үз-үзләренә карата кырыслык, көнкүрештә азга канәгать булу сыйфатларын якыннан төбәлеп күзәткәннән соң гына әсәрдә милли тәҗрибә җимешләрен аерып алырга мөмкин. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Күрәсең, эш төрле халыкларның кумәк хезмәт процессында мораль-этик яклардан бер-берсенә якыная баруында, аларның экономикасы, көнкүреш шартлары якын булуда, җитештерү мөнәсәбәтләре һәм коммунистик идеалларының уртак булуында.

Социалистик реализм методының үзенчәлеген билгеләп торган шушы процесс бүгенгенең актуаль проблемаларына багышланган әсәрләрдә тагын да көчәя төшә. Хәтта С. Санбаев, Ә. Мохтар кебек милли символиканы бик яхшы белеп, аеруча тирән милли үзенчәлекле формада иҗат итүче әдипләр дә, бүгенге чорны сурәтләгәндә совет әдәбиятына хас гомуми тасвир чараларын активрак кулланалар. Һәм авторлар күтәргән проблемаларның кайбер үзгә якларына, сюжет борылышларына (әйтик, күп кенә «көнчыгыш» романнарында ир белән хатын-кызның профессиональ мәнфәгатьләре арасында каршылык килеп туывы, шуның белән бәйләнешле шәхси кичерешләр тасвир ителә) якыннан төбәлеп караганда гына, без алардагы милли колоритны күрә алабыз.

Шунысын да әйтергә кирәк, совет әдәбиятының яңа туган жанрларында әлеге якынлык аеруча нык чагыла. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышында югалган кешеләрне табып, батырларның чын исемнәрен халыкка кайтару, онытылганнарны әдәбият чаралары белән торгызу максатын куеп язылган китапларны алыйк. Константин Симонов һәм Агния Барто, Сергей Сергеевич Смирнов һәм Юрий Корольков, Гази Кашшаф һәм Рафаэль Мостафин нәкъ шундый әсәрләр иҗат иттеләр. Һәм әгәр дә Р. Мостафинның геройшагыйрь Муса Җәлил турындагы китабы күп кенә башка әсәрләрдән аерылып тора икән, моңа милли формадан бигрәк, Муса Җәлилнең татар шагыйре булуы һәм авторның иҗат индивидуальлеге сәбәпче. Чөнки автор әлеге әсәрендә бер үк вакытта әдәбият белгече дә, язучы да буларак чыгыш ясый.

Күрәсең, әдәби әсәрнең формасы эчтәлеккә битараф була алмый һәм эчтәлек белән бергә үзгәреш кичерә. Чынбарлыгыбызның эчтәлеге — идеаллар, хезмәт, экономика, көнкүрешнең үзара якынаюы тасвирлаудагы якынлыкны китереп чыгара. Ул процесс, әлбәттә, дәүләт күләмендәге яңа законнар кебек үк тиз вакыт эчендә гамәлгә керми. Шул ук вакытта якынаю процессы милли традицияләрне ярлыландыру хисабына бармыйча, төрле әдәбиятларның бер-берсен баету нәтиҗәсе булып тора. Фикеребезне татар язучысы Гариф Ахунов иҗаты мисалында исбат итик. Аның «Хәзинә» романында сюжет — нефть өчен көрәш, кичәге игенчеләрдән эшчеләр формалашуы, элекке авыллар урынында шәһәрләр барлыкка килүе, хезмәт коллективында характер-

лар чыныгуы, семья көнкүреше һәм башкалар—болар барысы да, сурәтләү принциплары ягыннан караганда, бүгенге әзербәйҗан, үзбәк, казакъ язучылары романнарыннан аз аерыла кебек. Әмма, әсәргә әтрафлы анализ ясаганнан соң, без башкарак фикерләргә киләбез.

Гариф Ахунов романы татар фольклоры элементларына шактый бай. Халыкның образлы сөйләме, җыр-биюләр, мәкаль-әйтемнәр, этнографизм белән мавыгу нәтиҗәсе булмыйча, үз чорының типик шартларында яшәүче типик характерларга хас реалистик буяулар булып кабул ителә. Автор бирелә халык тормышының киң һәм күпьяклы күренешләрен тудыра, хезмәт һәм көнкүреш җәмгыятьнең һәм аерым кешеләр яшәешенең бер-берсеннән аерылгысыз өлешләре булып күз алдына баса. Милли үзенчәлек образларның үзенә аерым бер экспрессивлыгында, характерларның ихтыяр көче белән тыелгысыз ярсулык кебек сыйфатларны бергә берләштерүендә, сабырлык һәм кирелек, олы җанлылык һәм көнчелекнең үзара бәрелешләрендә калку чагылыш таба.

Әгәр без Г. Ахуновның «Хәзинә» романындагы Арслан образы белән әзербәйҗан авторы Мәһди Хөсәеннең «Апшерон» әсәреннән Таир образын янәшә куеп карасак, аларда ике чор аермасын гына түгел, милли аерымлыкларны да күрер идек. М. Хөсәеннең Таиры — изге күңелле өлкән оста янында акрынлап социалистик хезмәт алдынгысы булып өлгереп килүче садә бер авыл малае. Ахунов әсәрендә исә куәтле ихтыяр көченә ия булган, сабыр холыклы, саф һәм туры җанлы Арслан белән аның антиподы — талантлы һәм ярсу табигатьле, шул ук вакытта мин-минлек чире белән авыручы Кәрим—халык характерының капма-каршы якларын гәүдәләндерәләр. Әхосусый милек стихиясе белән (Шәвәли образы) тормышның әйдәп баручы көчләре (нефтьчеләр коллективы, Лотфулла) арасында кискен көрәшне сурәтләве, характерлар масштаблылыгы, эпик киңлек Гариф Ахуновның рус классик традициясенә дә, дөньякүләм сәнгать тәҗрибәсенә дә (Бальзак, Золя) һәм гомум совет әдәбияты хәзинәләре белән баетылган шәрык эстетикасына да бердәй дәрәҗәдә таянган һәм, үз чиратында, социалистик реализм методын, үз образлары һәм стиль ачышлары белән баетучы художник булуы хакында сөйли.

Илебез халыкларының күп гасырлык тормыш тәҗрибәсе белән табылган әдәбиятсәнгатебез методының эстетик яктан ачык система буларак иң асыл мәгънәсен билгеләүче социалистик интеграция процессында туплана килгән казанышлары барлык күп милләтле совет әдәбияты һәм аның методы — социалистик реализм тарафыннан үзләштерелә бара һәм әдәбиятларның үзара якынаюы нигезендә бер-берсен баетуларына ярдәм итә.

## Лидия Ивановна Залесская

# ЧОРЛАР АША ҮТЕП КИЛӘЧӘККӘ...

Бүгенге совет әдәбияты һәм сәнгате, мәгълүм булганча, фәнни-техник революция шартларында яши һәм үсә. Тик шулай да, «Бүгенге дөньяда әдәбият һәм сәнгать»[1] дигән мәкаләсендә М. Б. Храпченко бик хаклы рәвештә әйтеп үткәнчә, «безнең заман әдәбияты һәм сәнгатендә барган катлаулы процесслар һәм үзгәрешләрне бүгенге фәнни-техник революция һәм аның казанышлары йогынтысы белән генә аңлатып булмый. Бу үзгәрешләр һәм процесслар киң мәгънәсендә тормышның үз хәрәкәте, социаль яшәештәге, кешеләр психологиясендәге үзгәрешләр белән бәйләнгән... Бүгенге художество культурасы үсешендә фәннитехник революциянең тоткан ролен инкарь итү дә, яисә аны абсолютлаштырып күрсәтү дә дөреслеккә туры килми».

Безнең фикеребезчә, фәнни-техник прогрессның ролен абсолютлаштыру кайбер

[1] «Новый мир» журналы, 1977 ел, 9 сан, 243 бит.

язучыларны замандашыбыз образларын, чорның уңай героена хас сыйфатларны берьяклырак күрсәтә торган әсәрләр тудыруга алып килде.

Күренә ки, И. Дворецкийның «Чит кеше» пьесасындагы Чешков беркадәр дәрәҗәдә, В. Липатовның телевидение буенча да күрсәтелгән «Инженер Прончатов турындагы хикәяте»ндәге Прончатов, Г. Бокаревның «Корыч коючылар»ыннан Виктор Лагутин да, әдәбиятның башка кайбер геройлары да замандашыбыз характерындагы төп сыйфатларны дөрес чагылдырып бетерә алмыйлар диючеләр хаклы булып чыкты. Чешков, Прончатов һәм Лагутин — үз-үзләренә артык дәрәҗәдә ышанган, өлгер һәм шома, югары квалификацияле, нык куллы, эшлекле кешеләр. Әмма башкаларга карата мөгамәләдә алар чамасыз кырыс, кешеләргә яхшылык эшләү, изгелек хисеннән мәхрүм калганнар. Сүз, әлбәттә, христиан дине өйрәтүләрендәге пассив изгелек хакында түгел, ә социалистик гуманизм хисе, коммунистик җәмгыять төзүчеләргә хас булган актив һәм конкрет юнәлештәге яхшылык хисе турында бара. Югарыдагы саналган әсәрләрдәге «эшлекле кеше» төшенчәсе коммунистик әхлакның җиңүе хакына һәртөрле консерватизм, масаю, битарафлыкка каршы актив көрәш алып баручы «гуманлы, яхшы кеше»гә хас сыйфатларны инкарь итә кебек.

Бүгенге чорда коллектив белән җитәкчелек итүче кешенең нинди булырга тиешлеге хакында сөйләгәндә, партиябезнең XXV съездында Леонид Ильич Брежнев әйткән сүзләрне искә төшерәсе килә. Тирән белемгә ия булу, мәсьәләләрне иҗади хәл итү белән бергә, Леонид Ильич кешеләргә, аларның ихтыяҗларына һәм теләкләренә сизгер мөнәсәбәтнең никадәр мөһим нәрсә икәнлеген билгеләп үтә [1].

Бүгенге совет әдәбияты ФТР һәм хәзерге заман кешесен сурәтләү белән генә чикләнмичә, социаль-әхлак проблематикасын бик күп яклары белән чагылдыруга омтыла.

Үткән елны «Литературная газета»да басылып чыккан (28 сан) мәкаләсендә Ю. Андреев бүгенге әдәбиятта ике төрле тенденция хөкем сөрә дип күрсәтә. Аның фикеренчә, бер төрле язучылар киеренке рухи тормыш белән яшәүче («хаклык эзләүчеләр»), әмма актив хәрәкәттән, хаксызлык, яманлык белән көрәштән читтә тора торган кешеләрне сурәтлиләр. Ә кәлам ияләренең икенче төркеме исә, актив тормыш белән яшәүче геройларны сурәтләсәләр дә, аларның психологиясен, бай эчке дөньясын ачып бетермиләр. Мондый раслауларда дөреслек бик чамалы булуын әйтергә кирәк.

Андый тенденция, бүгенге чордан бигрәк, егерменче-утызынчы елларда язылган кайбер әсәрләрдә ныграк сизелә иде. Ул чагында, чынлап та, күп кенә язучылар актив хәрәкәт, актив гамәл геройларын сурәтләүне үзләренең төп бурычы дип санйлар иде. Хәзер исә әдәбиятыбыз ике төрле категория кешеләрен — тормыш һәм яшәү мәгънәсе хакындагы киренке уйлары белән мәшгуль булган пассив кешеләрне һәм хәрәкәт сөюче, эшлекле кешеләрне сурәтләү белән генә һич тә чикләнми. Күп милләтле әдәбиятларыбыздагы әсәрләргә мөрәҗәгать итсәк, алардагы социаль-әхлак проблемаларының никадәрле бай һәм күп төрле булуын күрербез.

Табигый ки, төрле милләт язучыларының игътибарын, беренче чиратта, совет кешеләренең яңа тарихи бердәмлеге — совет халкын, совет интернационализмы һәм патриотизмын сәнгатьле итеп тасвирлау бурычы җәлеп итә.

Заманыбызның бу мөһим проблемалары литвалы И. Авижюсның «Туган йорт җылысы», үзбәк язучысы Рәхмәт Фәйзинең «Галиҗанаб Кеше» дигән романы, латыш шагыйре И. Зиедонис, украин шагыйре һәм публицисты В. Коротич әсәрләрендә ышандырырлык гәүдәләнеш тапты. Алар үз халыкларының тормыш-көнкүрешен, культурасын, рухи яшәешен бөтен тирәнлегендә тасвир итәргә омтылалар. Совет кешеләренең яңа тарихи бердәмлеге шулай ук татар язучысы Шамил Бикчуринның «Каты токым» (1968—1972) романында да лаеклы чагылдырыла. Бу китапның русчага тәрҗемәсе 1974 елда «Современник» нәшриятында дөнья күрде. Илаһи-уптымы белән дигәндәй, производство темасына багышланган бу әсәрдә Татарстан нефтьчеләре тормышы, совет кешеләренең бердәм хезмәт процессында, төрле милләт вәкилләреннән оешкан коллективта рухи яктан үсү-ныгуы, яңа сыйфатлар белән баюы күрсәтелә.

Четерекле нефтьче хезмәте, бригададагы күмәк тормыш холык-фигыльләре, уй-хыяллары белән бер-берсеннән бик нык аерылып торган кешеләрне үз эченә

[1] Л. И. Брежнев. XXV съездда КПСС Үзәк Комитеты отчет доклады. Кара: «КПССның XXV съезды материаллары». Политик әдәбият нәшрияты. Мәскәү, 1976 ел, 70—71 битләр.

һаман ныграк тарта, мавыктыра бара. Һәм кешеләр акрынлап үзләренең ялгышларын аңлый башлыйлар, сай һәм нигезсез хыяллардан арына барып, бер-берсенә нык береккән, бер-берсен сүзсез дә аңлый торган дус һәм тату коллективта берләшәләр. Татарстан җире аларның икенче һәм яраткан Ватаны, язмышларының аерылгысыз бер өлеше булып китә һәм биредә алар үзләренең авыр, әмма чын бәхетләрен табалар.

Гариф Ахуновның да иҗат колачы фәнни-техник революциянең замандашыбыз характерына ясаган йогынтысы мәсьәләләре белән генә чикләнми. Аны да «киң мәгънәсендәге тормыш хәрәкәте», социаль яшәеш, кешеләр характерындагы үзгәрешләр кызыктыра һәм җәлеп итә.

«Хәзинә» романында язучы чынбарлыкны бөтен катлаулыгында, барлык каршылыклары белән, ә кешеләрнең характерларын үткен һәм тормышчан конфликтларда ачып бирергә омтыла. Әсәрнең үзәк геройларыннан берсе Кәрим Тимбиков характеры белән нәкъ әнә шундый каршылыклы, катлаулы шәхес итеп тасвирлана. Кәрим — ярсу һәм чуар йөрәкле, үз хезмәтенә бөтен күңеле белән бирелгән талантлы кеше. Бар дөньясын онытып, ул үзенең буровое белән генә яши, эштә тоташтан өчәр смена үткәрә. Бораулауда тагын да югарырак тизлекләргә ирешергә теләп, Кәрим һичнинди икеләнүсез тормышын куркыныч астына куя. Әмма хезмәт сөю, эш белән мавыгудан тыш, аңарда башкалардан өстен булырга омтылу, дан-шөһрәт сөю дә аз түгел. Яшь мастер эштә үзен дә аямый, бергә эшләгән, зур тырышлыклар куеп үзе эзләп тапкан бригада кешеләре белән дә исәпләшми. Ул үзенең якташы Арсланны тыелган алымнар кулланып эшләргә мәҗбүр итә, нәтиҗәдә, бәхетсезлек очрагына эләгеп, Арсланның аягы сына. Моннан соң да Кәрим гаебен танып, тукталып калмый. Данга омтылу, минминлек хисеннән исергән Тимбиков техника куркынычсызлыгын тупас рәвештә боза һәм фаҗигале төстә һәлак була.

Гариф Ахунов производство сферасын гына түгел, геройларының көндәлек яшәешен, шәхси тормышларын, тирән эчке кичерешләрне дә этрафлы итеп сурәтләргә омтыла. Шөһрәт сөюче, ярсу канлы Кәрим белән тыйнак гадәтле Арслан арасындагы эчке конфликт бу геройларның шәхси тормышларына да үтеп керә. Арслан сугышка кадәр үк, яшь егет чакларыннан, Мөнәвәрәне яраткан. Бу мәхәббәт хисе Мөнәвәрә Кәримгә кияүгә чыкканнан соң да сүнми. Әсәрдә пакъ һәм саф күңелле, мөлаем татар хатыны Мөнәвәрә образы тирән тәэсир калдыра. Тормыш Мөнәвәрәгә, аның үз шәхси сыйфатлары һәм характерыннан бәйсез рәвештә диярлек, кырыс сынаулар, авыр кичерешләр алып килә. Кәрим хатынын да, балаларын да үзенчә ярата, әмма характерындагы каршылыклар һәм шулай ук эшкә чамадан тыш бирелгәнлеге аркасында хатынының күңелендәге кичерешләрне сизми. Укытучы һәм йорт хозяйкасы, ике бала анасы Мөнәвәрәгә Кәрим белән булган тормышлары шатлык та, бәхет тә китерми. Бәлки әнә шуңа күрәдер дә, Арсланга карата яшь чагында туган хис аның күңел почмагында һаман да саклана.

Арслан да, һәм бәлки автор үзе дә, авыр язмышка дучар булуында тәвәккәллеге җитмәве һәм чамадан тыш сабырлыгы белән, Мөнәвәрә үзе гаепле дип саныйлар булса кирәк. Тик мондый караш тиешенчә акланмый. Мөнәвәрәнең бәхетсезлегендә Кәрим генә түгел, Арслан да гаепле. Ул героиняның газапларын күрсә дә, пассив позициядә тора. Оялчан һәм сабыр хатын, ихтыярсыздан, Арсланга Кәрим белән бәхетсез гомер итүе хакында сөйли. Ә бераз соңрак, Кәрим белән тора алмаячагына ышангач, ул Арсланнан киләчәктә ничек яшәү хакында киңәш сорый. Арслан исә хатын-кыз үз язмышын үзе, кеше киңәшеннән башка хәл итәргә тиеш, дип җавап бирә.

Романда чын милли характер буларак күңелгә сеңеп кала торган Лотфулла Дияров образы бар. Өлкән оста Лотфулла Дияров Кәрим Тимбиков кебек үк сәләтле һәм шулай ук үз эшенә бирелгән кеше. Тик ул Кәрим кебек күңелендә яшертен ниятләр йөртми, шөһрәткә омтылу, масаю аңа бөтенләй ят нәрсә.

Гаиләдә, шәхси тормышта да ул үзен бөтенләй башкача тота, «купшы тормыш» артыннан кумый, эгоистик инстинктлардан ул тулысынча азат. Лотфулла Дияровны чын интернационалист һәм гуманист сыйфатларына ия булган шәхес дип әйтә алабыз. Кәрим Тимбиковның уңай һәм кире сыйфатларын карт оста бик яхшы күрә, аны әхлакый һәм физик һәлакәттән саклап калу өчен тырыша. Иң кыйммәтле хәзинә — кеше, ә нефть исә кешеләр өчен алына дип саный ул.

Г. Ахунов әсәрендә совет гуманизмы проблемалары кыю рәвештә куелган һәм күп яклары белән хәл ителгән дә. Роман геройларын, мәсәлән, замандашларыбыз коммунистик киләчәк өчен генә көрәшергә, шуның хакына кыенлыклар кичерә белергә тиешләрме, әллә хәзерге заманда яшәүче кешеләр бәхетен кайгыртырга да бурычлылармы дигәнрәк сораулар да уйландыра.

Җанлы тел белән язылган, геройларының көндәлек тормышын, табигать күренешләрен тәгәл һәм нечкә буяулар белән тасвирлап, характерларны актив хәрәкәт, көрәш эчендә сурәтләп биргән бу роман, Ш. Бикчуринның «Каты токым» әсәре кебек үк, чорыбызның актуаль проблемаларын әдәбият чаралары аша хәл итүгә булыша.

Туфан Миңнуллинның Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында зур уңыш белән барган «Әлдермештән Әлмәндәр» исемле пьесасында да без татар совет милли характерының калку чалымнарын күрәбез.

Социалистик реализм методының шартлы, символик стилендә иҗат ителгән бу шаян комедия совет чорында үстерелгән халыкчан традицияләрне дәвам иттерә. Кешелек яшәешенең үзәгендә торган хезмәткә мөнәсәбәт темасы бу әсәрдә аеруча күркәм чагылыш тапкан. Хезмәт шатлыгы кешеләргә, тормышка мәхәббәт, рухи яшьлек бүләк итә. Әлдермеш авылы карты Әлмәндәр туксан бер яшендә дә барлык кешелек сыйфатларын, күңел дәртен саклап калган. Аның йөрәгендә Йөзембикәгә булган беренче сихри мәхәббәте әле дә исән, шул ук вакытта ул сугышта үлеп калган иренә турылык саклап яшәүче Хәмдебануның күңел сафлыгы алдында баш ия. Әлмәндәрнең яшь Йөзембикә белән очрашуы сурәтләнгән символик күренеш үзе үк күп нәрсәне аңлата. Газраил белән булган шартлы күренешләр Әлмәндәр картның тормышка төкәнмәс мәхәббәтен, аның яшәеш тамырларын ачып бирергә ярдәм итә. Бу җәһәттән Әлмәндәр оныгы Гөлфирәнең Мансур исемле егет белән очрашуын сурәтләгән күренеш хәтергә сеңеп кала. Ул күренешне Әлмәндәр карт белән Газраил бергәләп күзәтәләр. Әлмәндәр кебекләрне үлем алса ала, әмма җиңә алмый, ул тормышның үзе кебек үк мәңгелек. Әлмәндәр картка тагын шулай ук киләчәкне тою хас. Шушы киләчәк хакына күп еллар яшәр иде әле ул. Әсәрдәге яшүсмер Илсур образында яшәешнең дәвамы, киләчәк тормыш гәүдәләнә. Шәүкәт Биктимеров кебек гүзәл актерлар, талантлы бердәм коллектив тарафыннан тудырылган спектакльдә милли характерның иң яхшы сыйфатлары калку күренә, кеше үлеменең котылгысызлыгы һәм аның гуманистик эшчәнлегенең үлемсезлеге кебек мәңгелек проблемалар куела.

Үзенең хезмәтләрендә Г. И. Ломидзе гаять әһәмиятле бер фикерне алга сөрә: үз Ватанына бөтен йөрәге белән бирелгән кеше генә чын интернационалист була ала, ди ул. Үз халкының күңелен аңламый, аның үткәнен белми, халык тудырган культураның элекке һәм бүгенге үсеше белән кызыксынмый торган кеше башка халыкның да күңел дөньясын, аның культурасына хас үзенчәлекләрне, андагы казанышларны аңлый алмый. Күп милләтле бердәм совет социалистик культурасы үзенә хас йөзе, билгеләре булмаган, бер-берсенә ике тамчы судай охшаган культуралар җыелмасы түгел ул. Совет культурасы «...күп төрлелеге, кабатланмас төс-буяуларының муллыгы белән көчле — дип яза Г. И. Ломидзе.— Бердәмлек күп төрлелекне юкка чыгармый, ә күп төрлелек бердәмлек җирлегендә көч туплый һәм үсә. Бередә бернинди дә каршылык юк... Сәнгатьле фикерләүдән милли моментны, милли традицияләрне, тарихи милли тәҗрибәне алып ташлап булмый»[1].

Менә шуның өчен дә без, мәсәлән, татар язучысы Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» һәм башкорт шагыйре һәм әдибе Мостай Кәримнең «Озынозак бала чак» исемле автобиографик повестьларын чын дулкынлану белән укыйбыз. Бу әсәрләрдә халык характеры чыганаклары, тирәндә яткан тамырлары ачыла.

Г. Бәширов һәм М. Кәрим бала һәм үсмер чакларындагы күргән-тойган, кичергәннәре, үзләре туып-үскән гаилә, авыл тормышы, гореф-гадәтләр, көндәлек хезмәт һәм күтәреп кенә килә торган сирәк бәйрәм көннәре туган якларының табигате хакында сөйлиләр, һәм без татар, башкорт халыкларының тормыш-яшәеш рәвешен, аларның гаҗәеп дәрәҗәдәге хезмәт сөючәнлеген, сәләтен һәм тырышлыгын, ирек-

---

[1] Г. И. Ломидзе. Әдәбиятта патриотизм һәм интернационализмның әхлакый нигезләре. «Дружба народов» журналы, 1977 ел, 11 сан.

хөрлеккә омтылучанлыгын аермачык күреп торабыз. Бәширов әсәрендәге аз сүзле, бер карауга шактый ук кырыс күренә торган Бәшир — кечкенә Гомәрнең атасы — чыннан да, үзенә бер талант иясе, теләсә нинди эшкә кулы ята торган кеше. Бары тик гадел булмаган социаль тормыш шартлары гына аңа баш калкытырга, ярлылыктан, бөлгенлектән котылырга мөмкинлек бирми. Табигать һәм крестьян тормышы үзе аңа төпле акыл биргән, ул басма сүзгә һәм китап-гыйлемгә гомере буе хөрмәт саклап яши, балаларына да шуны васыять итеп калдыра.

Гомәрнең әнисе дә яхшы күңелле, шигъри җанлы хатын, тик авыр тормыш шартлары аны иртә картайткан. Шулай да ул күңеле түрендә яшьлек хисләрен саклап кала алган, җыр-музыка ярата, яшьләр уенын, җыр-биюләрен бирелеп һәм мавыгып карый.

Язучы, әлбәттә, үз ата-анасын идеаллаштыру юлына басмый, әсәрдә алар татар хезмәт ияләре вәкилләре булып сурәтләнә. Ул вакыттагы тормыш хәле, авыр социаль шартлар, ата белән ананы, кызлары Өммикамалны сөйгән егете батрак Әхәттән аерып, икенче авылга юньлерәк тормышлы кешегә кияүгә бирергә мәҗбүр итә.

Гомәр Бәширов хезмәт халкына хас югары әхлакый сыйфатлар, табигый сәләт һәм гаделлек хисе йогынтысында яшүсмер күңеленә шигъри орлыклар салынуын, азатлык һәм гадел җәмгыять өчен көрәшкә омтылыш яралуын төгәл реалистик буяуларда ышандырырлык итеп сурәтли.

Язучыларны кайчак, хаклы рәвештә, чорыбызның рухын һәм җанлы сурәтен, җитлеккән социализм эпохасы кешесенең характерын тудыру эшендә кыюсызлык күрсәтәләр дип шелтәлиләр. Әмма бүгенге язучы — безнең замандашыбыз күзлегеннән торып, аның уй-фикерләре, бәяләве, күңеле аша — халык характерының тамырларын, әдипнең яшьтәшләре, буындашларының революция алды чорындагы тормышын, шул дәвер геройларының хезмәт һәм ирек сөючәнлек, гуманизм, гаделлек эзләү кебек сыйфатларын, яисә соңрак, әйтик, утызынчы еллар каһарманнарының характеры ничек чыныгуын, Бөек Ватан сугышы еллары һәм аннан соңгы чорда төрле милләт вәкилләренең фаҗигале һәм героик язмышларын дөрес чагылдыру да зур әһәмияткә ия. Халык характерының ныгуы, рухи чыныгуы, яңа бердәмлек — совет халкы формалашуы — тарихи яктан анык, озак һәм катлаулы процесс, аның сәнгатьле сурәтен тудырганда бүгенге чорны, фәнни-техник революция эпохасы конфликтлары, тасвирлау белән генә чикләнү дөрес булмас иде. Мәсәлән, без бүгенге көн геройларына хас иң яхшы сыйфатларының формалашуын Гастелло, Зоя Космодемьянская, Муса Җәлил исемнәреннән башка күз алдына китерә алмыйбыз.

Муса Җәлил җитлеккән социалистик җәмгыять кешеләре өчен дә иң югары коммунистик әхлак кешесе, чын интернационалист, олы талант иясе һәм кабатланмас милли аһәңле шагыйрь булып кала.

Фашист тоткынлыгындагы коточкыч шартларда, үз иленнән, халкыннан еракта, вөҗданы белән күзгә-күз калып, һәр көнне үлем көткән килеш шигырьләр иҗат итү һәм күп кырлы бай рухи тормыш, илгә мәхәббәт хисе белән, якын кешеләреңне сагынып, халыкның һәм Ватанның киләчәге хакында уйлап яшәү өчен нинди сыгылмас рух көченә, легендар батырлыкка ия булырга кирәк.

Р. Мостафин «Герой шагыйрь эзләреннән», С. Шакир «Үлемнән көчлерәк» дигән китапларында, документларга таянып, шагыйрьнең легендар юлын күздән кичерәләр. «Соңгы сынау» дигән романтик поэмасында шагыйрь Илдар Юзеев патриот-шагыйрьнең күңел дөньясына үтеп, гомеренең соңгы көннәрендә һәм сәгатьләрендә ул кичергән уй-хисләрне җанландырып бирергә омтыла. Автор Муса Җәлилгә, фашистлар вәгъдә иткән яшәү мөмкинлегеннән ваз кичеп, үлемне сайлап алырлык рухи көч-куәт, таяныч биргән чыганаклар, мораль нигезләрне ачарга тели һәм күп яклардан моңа ирешә дә.

Нәкъ менә безнең чор, ягъни алтмышынчы-җитмешенче еллар әдәбиятында, замандашыбызның рухи дөньясы, коммунистик идеалларның җиңүе өчен аның актив көрәше белән тирәнлегендәге, тулы итеп сурәтләнгән әсәрләр тудырылды. М. Шолохов, Л. Леонов, И. Мележ, М. Стельмах, О. Гончар, Ю. Бондарев һәм башка күп каләм осталарының романнары «замандашыбызның яшәеш тарихын», Бөек Октябрь революциясе елларында, утызынчы еллар шартларында, Бөек Ватан сугышы чорында ул кичкән юлларны тасвирлауга багышланган. Әсәрләрдә тарихи конкрет характерлар сурәтләнә, үткән революция белән дә, үзләре яшәгән һәм социа-

листик яшәеш нормаларының җиңеп чыгуы күрәшкән чор белән дә аларны нинди җепләр бәйләп торуын без бик яхшы күрәбез һәм тоябыз. Иван Мележның «Сазлыктагы кешеләр», «Яшен сулышы» романнарындагы коммунист Апейка, В. Фоменконың «Җир хәтере»ндәге Степан Конкин һәм Сергей Голиков, М. Стельмахның «Кеше каны җирдә ятмый» романындагы Свирид Мирошниченко образларында, Әсгать Мохтарның «Чинар» романындагы Ариф Ачилов, Йонас Авижюсның «Юллар чатында авыл» әсәрендәге Арвидас Толейкис, Атилла Расихның «Язгы авазлар»ындагы Солтан Фәхретдинов, Юрий Бондаревның «Кайнар кар» һәм «Яр» әсәрләрендәге уңай геройларның эчке дөньясында киләчәк коммунистик җәмгыять кешеләренең рухи һәм әхлакый йөзен билгеле торган сыйфатлар ачык күзаллана.

Әлеге геройларга салкын акыл белән генә эш итү, мин-минлек бөтенләй хас түгел, инженер Прончатов, Виктор Лагутин һәм бигрәк тә Алексей Чешков кебек, шәхес һәм белгеч буларак үзләрен башкалардан өстен санау алар өчен ат нәрсә. Бу саф намуслы, олы йөрәкле кешеләр «һәрчак алда, кыенрак җирдә» булырга тырышалар. Әнә шундый бай рухи тормыш белән яшәүче, юмарт күңелле, кешелекле кешеләр булулары белән алар безне үзләренә тарталар да.

СССР язучыларының соңгы съездында Федор Абрамов, туган туфрактан аерылып, әле бер, әле икенче шәһәргә сугылып йөрүчеләрне түгел, ә үз хезмәтенә бөтен җаны-тәне белән бирелгән, җирнең чын хуҗалары булырлык кешеләрне тәрбияләү бурычлары хакында тирән дулкынлану белән сөйләде. Ф. Абрамов үз әсәрләрендә нәкъ әнә шундый җир кешеләре образларын тудырган язучы.

Татар прозаигы Атилла Расихның «Язгы авазлар» романында да җирнең чын терәге, аңа җан һәм куәт өрерлек чын хуҗа образы сурәтләнә. Югары белемле зоотехник Солтан Фәхретдинов министрлыктагы күнеккән тыныч эшен ташлап, теоретик белемнәре һәм практик эше белән кешеләргә күбрәк файда китерү өчен артта калган колхозларның берсенә китеп бара. Җиңел юлга басмаганлыгын ул яхшы белә. Яңа эшендә аңа ялкау әтрәк-әләмнәр, бюрократлар һәм аңсыз кешеләр комачаулык итүе генә җитмәгән, үз шәхесен бик зурга куеп, үзен алыштыргысыз дип санаучы райком секретаре Халиков та каршы чыга. Алар арасындагы бу тышкы конфликтка эчке, психологик бәрелеш килеп өстәлә.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы геройлары да үз туган җирләренә нык береккән кешеләр. Бөек Ватан сугышы фронтларыннан кайткан авыл егетләре Рушат белән Гатаны—характерлары белән бер-берсеннән нык аерылып торган ике сабакташ дусны — бер нәрсә берләштерә: фронт дәһшәтләре, хәтәр-куркыныч хәлләрне башларыннан кичереп исән калганнан соң да алар җайлы-рәхәт тормыш эзләмиләр. Авырлыклар аларны чыныктырган, туган авылларына батыр йөрәкле, җитлеккән ирләр булып кайтканнар. Сугыш елларында тәмам бөлеп, хәлсезләнеп калган авылда фронтовик егетләр җиң сызганып балалар укыту-тәрбияләү, атасыз малайларны үзләре кебек итеп үстерү эшенә керешәләр. М. Мәһдиевнең бу китабында гуманизм һәм патриотизм хисләре тыгыз үрелгән, әсәр геройлары җитлеккән социализм җәмгыяте кешеләре характерына хас булган күп рухи сыйфатларны туплаганнар.

Расул Гамзатов һәм Мостай Кәрим, Хәсән Туфан һәм Давид Кугультинов, Сибгат Хәким һәм Кайсын Кулиев кебек күренекле совет шагыйрьләренең лирик шигырь циклларында да без замандашыбыз характерларының тарихи һәм милли яктан анык чагылышларын күрәбез. Әмма олы шагыйрьләрнең лирик геройлары беркайчан да бер-берсен кабатламый.

Совет поэзиясенең иң нечкә лирик шагыйрьләреннән берсе Хәсән Туфанның һәр шигырендә диярлек шагыйрь күңеленең нинди дә булса бер ягы ачылып китә. Шагыйрь күңелен яктыртып торган хисләр шул дәрәҗәдә изге, шул чаклы бай һәм гүзәл ки, аның әсәрләрендә зур хәрефтән язылырга лаеклы чын кеше характеры калкып чыга. Шагыйрьдәге рухи ныклык, батырлык нинди җирлектә тәрбияләнгән, аның чыганаклары каян килә — бу хакта ул үзе сөйли. Бу аның үз халкы, авыр заманнар кичергән ата-бабаларының васыяте, алар калдырган традиция. Шагыйрь аларны кайгы-хәсрәт эчендә дә кешелек горурлыкларын саклап кала белүләре өчен хөрмәт итүен әйтә. Аның әтисе бөтен тирә-якка билгеле мич чыгаручы, пыяла куючы булган. Улын да хезмәтне сөяргә, намус һәм гаделлек белән яшәргә өйрәткән. Ә Тукай поэзиясе исә яшь егет күңелендә илгә, халыкка, бөтен Россиягә мәхәббәт уты кабызган.

**Тугры улың хәлдә, Русиям,**
**Кичтем барлык авыр елларны.**
**Бу — Тукаең биргән васыять**
**Юлларымны минем нурлады.**

**(«Эстафета», 1956 ел.)**

Ленин образы, ленинизм идеалларының җиңүенә какшамас ышаныч Хәсән Туфанның бөтен иҗаты аша үтә. Ленин ул — шагыйрь өчен сүнмәс яктылык, кешелекнең шаулы язы. Гафур Голәмгә багышланган «Ташкент багларында» исемле шигырендә Хәсән Туфан милли чикләнгәнлек хөкем сөргән чорлар турында искә ала. Ә хәзер исә шагыйрь үзенең дусты — атаклы үзбәк шагыйренә мөрәҗәгать итеп, халыкларны мәңгегә туганлаштырган «Ленин гасыры исәнлегенә» тост күтәрергә чакыра. Чөнки, шагыйрьнең ышануынча, Ленин ул иминлек, гаделлек һәм кешелеклелек билгесе.

Ленин идеалларының җиңеп чыгачагына, коммунизм тантанасына тирән ышаныч хисе шагыйрьгә, язмышындагы иң авыр, фаҗигале елларда да рухи төшенкелеккә бирелмичә, тормышка булган мәхәббәтен саклап калырга ярдәм итә: «Иртәгә дә яши алыр өчен бирешмәскә кирәк бүген дә», — ди ул. Шатлыклы көннәрдә дә, кайгы-хәсрәт килгәндә дә шагыйрь үзенең йөрәгеннән дәртле һәм эшчән булырга өнди.

Бөек Ватан сугышы башланган елда ук инде Хәсән Туфан «Алга барышлый» шигырендә үзен ил солдаты итеп санавын белдерә.

**Моңаерга бугай синең исәп!**
**Юк, ярамый, йөрәк, ярамый:**
**Кешелектә кем син!**
**Бер солдат ич!**
**Солдат кеше артка карамый,**
**Алга әйди үзен аямый!**

Ленинчыл гуманизмның, кешелеклелек һәм тынычлыкның җиңүенә шагыйрьнең ышанычы «Барган саен еллар җылырак» (1956 ел), «Тормышка мәхәббәт» (1959 ел), «Якыная бара» (1961 ел), «И тормыш!» (1963 ел) һәм башка шигырьләрендә куәтле шигъри гәүдәләнешен таба. «Сез кая барасыз, йолдызлар?» (1953—67 еллар) исемле шигырендә шагыйрь үзенең кырыс язмышы белән сөйләшә, бөтен тормышы һәм иҗатының төп максатын, яшәү мәгънәсен ачып сала:

**Мөмкин түгел иде**
**Безне кичә.**
**Мөмкин түгел бүген, иртәгә,**
**Мөмкин түгел безне, мөмкин түгел**
**«Юлдан язган кеше» итәргә!**
**Ә син, Җидегән, беләсеңме шуны!**
**Юк, белмисең: сиңа караңгы...**

Туган җирдән аерылу сагышы, сугыш газаплары һәм шагыйрьнең шәхси тормышындагы югалтулар ачысы «Агыла да болыт агыла», «Битараф ай», «Ромашкалар тирбәлә җилдә» кебек шигырьләрдә күңелләрне тетрәтерлек тирәнлек белән гәүдәләндерелгән.

**Дөньяның мин күрдем суын, күлен,**
**Урманнары, тавын, чүлләрен...**
**Тик күрмәдем, Идел, синең кебек**
**Сагындырган ягын күрмәдем.**

**(«Аралагыз мине, алмагачлар», 1956 ел).**

Шагыйрь күңеле югалтулардан әрнеп, ничаклы гына өзгәләнмәсен, аңарда киләчәккә, тарих тәгәрмәченең алга таба хәрәкәт итүенә тирәнтен ышанычны сүндерү мөмкин түгел. Бу ышаныч аның, мәсәлән, шул ук «Битараф ай» шигырендә дә бик ачык чагыла. Чор вакыйгаларының катлаулылыгы, драматик язмыш һәм шәхси кичерешләр шагыйрьне тормыштан, заманыбызның гуманистик идеаллары тантанасы өчен көрәштән читләштерә алмый.

Иссә дә кайчакта
Каршыдан җилләрең,
И тормыш, беркая,
Беркая синнән мин,
Беркая китмәдем!

Хәсән Туфан поэзиясе тормышны һәм кешеләрне яратырга, кешеләр бәхете өчен көрәшергә чакыра торган поэзия. Аның реалистик лирикасының төс-буяулары, сурәт чаралары ук үз халкының үткән һәм бүгенге тормышы белән аерылгысыз бәйләнештә тора. «Фикер колачының киңлеге, иҗат күкләренең биеклеге, дөньяда ниләр барганны тирәнтен аңлый алу, ихлас җанлы лиризм — менә нәрсәсе белән бай ул Хәсән Туфан шигърияте», — дип язды Леонид Мартынов [1].

Шагыйрь Сибгат Хәким лирикасы да югары камиллек дәрәҗәсенә ирешкән чынчыннан халыкчан поэзия, һәм аның да үз милли йөзе бар. Аның китапларында татар халкының үткәне, ул кичергән караңгы һәм якты чорлар бүгенге героик чынбарлык белән янәшә куеп карала. Кайчандыр җирдә КамАЗлар булмаган, ә батырлар — алар һәр халыкта булган... Утызынчы елларда социализм төзүдә катнашкан, Бөек Ватан сугышының алгы сызыгында торып сугышкан шагыйрь язмышын аның үз буыны һәм бөтен халык язмышыннан аерып алу мөмкин түгел. Әмма һәр чын художник язмышы кебек үк, аның язмышы, гомере һәм иҗаты кабатланмас бер аһәң, бер җыр...

Зур эшләрне безнең бар бит кылган,
Ташладың син, чорым, Магниткадан
Сталинградка безне, Дугаларга.

Сибгат Хәким шигырьләрендә солы кырының алтын-сары кыңгыраулары чыңлый, карабодай чәчәгенә кунган шәфәкъ нурлары күңелне җирсетеп сагышландыра, кырлар өстендә тургай җыры яңгырый, шуңа ук чыра яктысында кич утырып, эч серләрен бүлешә-бүлешә чыпта сугучы авыл кызларының басынкы моңнары килеп кушыла, яшьлек хатирәләрен, сүз куешкан таңнарны үзендә саклаучы иске кое бурасы, туган йорт — ата-баба рухын сеңдергән төп нигез телгә килә. Җир-анага һәм шагыйрьнең үз анасына багышланган шигъри юллар да үзенә бер нечкә моң белән өртелгән.

Мин аның каршында үземне
Шагыйрь дип атарга оялдым.
Мин түгел, ул — шагыйрь, тутырды
Нур белән ул өйне, өялдын...

— дип яза шагыйрь үзенең әнисе турында.

Туган җиргә, туып-үскән төбәгенә, халкына, аның теленә һәм шигъри сүзенә мәхәббәте С. Хәкимгә башка халыкларның рухи дөньясын, культура үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итә. Шагыйрь иң якын күршесе мари халкына гына түгел, Бөек Ватан сугышы елларында үзе азат итешкән барлык ил халыкларына һәм иҗатына тирән сеңдергән рус классик культура мирасына күңелендә олы хөрмәт саклый.

Сибгат Хәким — тотрыклы реалистик стиль шагыйре, ул тудырган образлар да җиргә нык береккән, ачык һәм ихлас күңелле кешеләр булып күзалдына баса. Алар лирик җанлы шагыйрь—безнең замандашыбызның күңел нурлары яктысында яшиләр.

Хәсән Туфан, Мостай Кәрим, Сибгат Хәким һәм башка олы шагыйрьләрнең һәрберсе үзләренә генә хас стиль чаралары белән безнең замандашыбыз — җитлеккән социалистик җәмгыять кешесенең күп кырлы һәм бай характерын тудыралар. Укучылар арасында киң танылган, зур тәрбияви әһәмияткә ия булган әдәби әсәр геройларының характерлары, кагыйдә буларак, актив хәрәкәт-гамәлдә, кискен һәм тормышчан конфликтларда ачыла.

Л. Н. Новиченко бик хаклы күрсәтеп үткәнчә, «Совет әдәбиятында социалистик мораль белән вак буржуаз, мещанлык карашлары арасындагы көрәшне чагылдыра торган традицион конфликт бүген дөньяга караш ягыннан күп кырлырак һәм үткенрәк

[1] Хәсән Туфан. Шигырьләр. Рус телендә. Татарчадан Р. Моран һәм Л. Хаустов тәрҗемәсе. Мәскәү, «Советский писатель», 1958 ел, 186 бит.

гәүдәләндерелә» (Тормыш хәрәкәте — конфликт хәрәкәте. «Литературная газета», 40 сан, 1978 ел).

Ни өчен безнең чорда да кайчак иске социаль шартларның юкка чыгуы белән бетәргә тиешле конфликтлар туа, турыдан-туры искелек калдыклары дип бәяләп булмый торган яңа тискәре күренешләр барлыкка килә? А. Расихның «Язгы авазлар» китабында җирнең чын хуҗалары булган зоотехник Солтан Фәхретдинов белән колхоз председателе Ифрат Аллаһияровка райкомның беренче секретаре — үз-үзе алдында намуслы, әмма үз шәхесен, фикерләрен һәм күрсәтмәләрен артык зурга куючы Халиков комачаулык итә. Әлбәттә, мондый кеше Солтан белән Ифратка гына түгел, бөтен колхозга зыян китерә. Шуның өчен Халиковны урыныннан алалар да.

Диас Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» дигән пьесасында барлык эчке рухи энергиясен, соңгы яшәү көчен Сатынский тәкъдим иткән яңа проект — свайлы фундаментны раслату, аңа тормыш бирү, төзелеш оешмасы эшчәнлегендә яңа стиль урнаштыру өчен көрәштә сарыф итеп бетергән олы йөрәкле кеше, горком секретаре Саттаров һәлак була; ә кайгыра-борчыла, уйлый белә торган кеше булып түгел, бары тик «югары» урынны югалтудан куркып, «номенклатур берәмлек» булып кына яшәүче бюрократ адәм җәзасыз кала.

Трагик потенциал, тискәрелек, явызлык белән килешмәүчәнлек рухы Б. Васильевның «Атмагыз аккошларга», Ю. Гончаровның «Соңгы урак өсте», удмурт язучысы Г. Красильниковның «Ел башы» исемле әсәрләрендә дә көчле чагыла.

Аяз Гыйләҗевнең аналитик стильдә иҗат ителгән «Югалган бер көн» исемле пьесасында вакыйга самолётлар очмый торган көнне кечкенә бер аэропортта бара. Автор төрле кешеләрнең характерларын ачу, эчке конфликтларны күрсәтү өчен бик кулай тормыш ситуациясе тапкан. Самолет көтеп торучылар арасыннан авыл карты кешеләрнең бер-берсен аңлый алмауларына зарлана. Күптән түгел ул үкенечле, кызганыч вакыйгага тап булган. Картның күз алдында иләмсез зур тракторлар, буровой вышка өстерәп, өлгереп килгән бодай басуын таптатып узганнар. Мондый кыргыйлык карт игенченең бөтен җанын тетрәткән.

Шушы ук вокзалда тракторчыларга бодай кырына керергә боерык биргән кеше дә утыра. Аны бу эше өчен урыныннан алганнар һәм ул хәзер шул кешеләр өстеннән шикаять бирергә тели. Шушында ук, буш сандык күтәреп, мәрхүм әтисенең әйберләрен алырга кайтучы икенче берәү утыра. Аның фикеренчә, авыру әтисен караган, тәрбия иткән хатында мал калдыру — гөнаһ эш.

Әлбәттә, һәр әсәрдәге кебек, әлеге пьесада да мещанлыкка, эгоизм, милекчелек психологиясенә каршы торучы кешеләр бар. Әйтик, бодай басуын таптаткан кешене эштән алучы геолог, баягы авыл карты, аэропорт хезмәткәре Йосыф һәм башка образлар җәмгыятебезгә хас төп мораль кыйммәтләрне, совет кешеләренең иң яхшы сыйфатларын чагылдыралар.

Һәр төрле мещанлык күренешләрен фаш итеп, кайчакларда карьера артыннан куучы ертлач кешеләрнең өстен чыгуын, ә кайсыбер очракларда хәтта намуслы, талантлы кешеләр һәлак булып, әшәке һәм түбән затлар, демагог һәм карьерачыларның җәзасыз калуларын сурәтләгәндә дә, язучылар безнең идеалларыбыз, максатларыбыз өчен ят булган күренешләрне бетерүгә ярдәм итәләр. Шунысын да әйтергә кирәк ки, әдәби конфликт тормышта туган конфликтларны һәр вакытта да төгәл туры китереп кабатламый. Әдәби әсәрдәге конфликт, язучының аңы аша үтеп, чынбарлыкның ниндидер мөһим якларын чагылдырырга тиеш.

Коммунистик җәмгыять кешесен тәрбияләүдә әдәбиятның роле проблемасы катлаулы һәм күп кырлы проблема. Коммунистик җәмгыять кешесен тәрбияләү — тарихи анык процесс, аның үткәне, хәзергесе һәм киләчәге бар. Төрле әдәби әсәрләрдә без моның өчесен дә яисә берсен генә күрәбез. Язучының үз халкы һәм үзе яшәгән заман алдында җаваплылык тоюы, оригиналь һәм үзенчәлекле талантка ия булуы мөһим. Шул чагында без үткән һәм бүгенге чорларны сурәтләгән әсәрләрдә киләчәк заман билгеләрен, коммунистик җәмгыять кешесе характеры чалымнарын күрә алачакбыз.

Флүн Мусин

# ТАРИХИЛЫК ЮЛЫННАН



Ныык үскән социализм һәм фән-техника прогрессы чоры әдәбияты үзендә тарихилык рухы көчәю белән характерлана. Тарихилык социалистик реализм теориясендә һәм эстетикасында да торган саен киңрәк урын ала.

Соңгы вакытта әдәбият галимнәрен бу принципның социалистик реализм әдәбиятында чагылышы мәсьәләләре кызыксындыра. Күренекле әдәбиятчы Б. Сучковның социалистик реализмга аңланган (осознанный) тарихилык хас дигән фикере яңадан-яңа яклаучылар таба. Әмма мондый тарихилык бер социалистик реализм әдәбиятына гына хасмы? Әдәбият фәнендә бу сорауга төрлечә җавап бирелә. Б. Сучков катгый рәвештә: «Социалистик реализмны аңа кадәрге реализмнан аера торган сыйфат ягыннан яңа принцип — ул аңланган тарихилык», — ди[1]. Академик М. Храпченко исә, киресенчә, «социалистик реализм әдәбияты тарихилыгының аңланганлыгы аны классик әдәбиятта чагылган тарихилыктан аера торган төп сыйфат булмавы»[2] турында яза. Аныңча, үткәндәге бөек художникларның тарихилыгы да киң иҗтимагый идеяләрне үз эченә алган һәм үзенең аңланган булуы белән аерылып торган. Шушы фикерне куәтләгәндәй, С. Петров мисалга Пушкин иҗатын китерә һәм аңа шулай ук аңланган тарихилык хас булуын, тик аның «мәгърифәтчел эчтәлекле»[3] булуын күрсәтә.

Кем хаклы соң? Сорауга җавап бирү өчен «аңланган тарихилык» төшенчәсенең үткәненә күз салыйк. Ә ул төшенчә Ф. Энгельсның 1859 елның 18 маенда Ф. Лассальга язган хатыннан алынган. Энгельс болай яза: «Сез хаклы рәвештә немец драмасына хас сыйфат дип күрсәтә торган зур идея тирәнлегенең, аңланган тарихи эчтәлекнең Шекспирча җанлылык һәм вакыйга байлыгы белән тулысынча кушылуына, ихтимал, киләчәктә генә ирешелер һәм, ихтимал, немецлардан бүтәннәр тарафыннан ирешелер».

«Аңланган тарихилык» төшенчәсе туугa нигез булган бу цитатадан күренгәнчә, Энгельс инде шул замандагы прогрессив немец драмасына аңланган тарихи эчтәлек хас дип санаган. Шул ук вакытта Ф. Лассальның «Франц фон Зикинген» дигән тарихи трагедиясен анализлап, Энгельс, язучының тарихи материалны нинди социаль-сыйнфый позицияләрдән торып үзләштерүе белән бәйле рәвештә, әсәре эчтәлегенең тарихи аңланганлыгы төрле дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Мәсәлән, ди ул, үзенең трагедиясендә сурәтләнгән тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне аңлатуга һәм бәяләүгә Лассаль Шиллер рухында, ягъни формаль буржуаз демократия позициясеннән чыгып килә. Ә чын тарихилыкка, Энгельс фикеренчә, чынбарлыкны һәм кешене заманның алдынгы революцион идеаллары һәм көрәше яктылыгында сурәтләгәндә генә ирешергә мөмкин.

Энгельс әйткәннәрдән шундый фикер туа: аңланган тарихилык, гомумән алганда, аерым бер иҗат методы күренеше генә була алмый. Киресенчә, ул төрле заман әдипләренә хас принцип. Тик аның аңланганлык дәрәҗәсе чорның иҗтимагый-политик һәм идея-эстетик фикере үсеше дәрәҗәсенә бәйле була.

Сәнгатьчә фикерләүнең тарихилыгы язучы, үзенең чикләнгән политик карашларына каршы рәвештә, үз әсәрләрендә тарихи процессның объектив закончалыкларын чагылдырган очракта гына «аңсыз» рәвештә гәүдәләнергә мөмкин. Бу моментка, Бальзак һәм Л. Толстой иҗатларын бәяләгәндә, Энгельс белән Ленин аеруча дикъкать иткәннәр иде.

Кыскасы, аңланган тарихилыкны, бер яктан, әдипнең дөньяга карашлары белән, икенче яктан, чорның тарихи эчтәлеге, аның социаль-фәлсәфи карашлары белән

---

[1] Б. Сучков. Ленин и проблемы современного искусства.— «Эстетика сегодня. Актуальные проблемы» дигән китапта. М., 1971, 126 бит.
[2] М. Храпченко. Рост литературы и проблемы теории.— «Знамя», 1976, 10 сан, 229 бит.
[3] С. Петров. Социалистический реализм в художественной литературе. М., 1976, 169 бит.

бәйләнгән тарихи категория итеп, үсештә, хәрәкәттә карарга кирәк. Мәсьәләгә шулай караганда, социалистик реализм әдәбиятының тарихилыгы, гомумән, сәнгатьчә тарихилыкның иң югары формасы булып алга баса. Чөнки ул дөньядагы иң алдынгы һәм иң революцион тәгълиматка — марксизм-ленинизмга, марксистик-ленинчыл философиянең һәм эстетиканың нигез принципларына таяна.

Бу уңайдан бер сорау туа: «Тарихилык социалистик реализмның башка нигез принциплары белән үзара нинди мөнәсәбәттә тора?» Сүз, беренче чиратта, тарихилыкның партиялелек белән үзара мөнәсәбәтләре турында бара. Чөнки кайбер фәнни хезмәтләрдә бу ике принцип арасындагы чикләр ничектер юкка чыгарылалар һәм алар бер үк төрле күренешләр итеп карала башлыйлар. Бер име әдәбиятчылар партиялелекне тарихилыкның иң югары формасы итеп карасалар, икенчеләре исә тарихилыкны автор һәм герой позициясенә кайтарып калдыралар. Хәлбуки, автор һәм герой позициясе барыннан да элек әдәбиятның партиялелеген билгели.

Әлеге карашлар һәм фикерләр, тулаем алганда, социалистик реализмның нигез принципларының үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсе әдәбият фәнендә әле аз тикшерелгән булуы һәм аны өйрәнүне көн тәртибенә ныклап кую кирәклеге турында сөйлиләр. Социалистик реализм әдәбиятында иҗат методы принциплары үзара гаять тыгыз мөнәсәбәттә яшиләр. Әмма бу хәл һич тә бер принципның икенчесен алыштыруына китерми. Биредә сүз бары тик аларның үзара йогынтысы турында гына барырга мөмкин. Социалистик реализм әдәбиятындагы тарихилыкның төп үзенчәлеге нәкъ менә аның ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык принципларына таянуыннан гыйбарәт. Шуннан совет әдәбиятының тарихи оптимизмы, тормышны һәм кешене тарихи перспективада күрсәтү сәләте барлыкка килә.

Тарихилык принцибының асылын билгеләгәндә, безнеңчә, В. И. Ленинның: «Марксизмның бөтен рухы, аның бөтен системасы һәр положениенең тарихи күзлектән генә, башкалар белән бәйләнештә генә, тарихның конкрет тәҗрибәсе белән бәйләнештә генә каралуын таләп итә»[1],—дигән сүзләре нигез булып торырга тиеш. Чөнки бары шул чакта гына тарихилыкның асылын марксистик-ленинчыл рухта аңларга һәм аңлатырга мөмкин. Дөрес, тарихилык турындагы бу һәм башка фикерләрен Ленин башлыча гыйльми фикерләүгә карата әйткән. Шуннан: «Фәнни фикерләү белән сәнгатьчә фикерләүдәге тарихилык принципларының үзара бәйләнышлары ничек соң?» дигән сорау туа. Әдәбият фәнендә бу сорауга җавап юк әле. Хәзергә бары түбәндәгене әйтергә мөмкин: фән белән сәнгать арасында яшәп килә торган мәгълүм аерымлыклар аларның тарихилык принципларына да кагылалар. Икенче яктан — фән-техника революциясе заманында фән белән сәнгатьнең үзара якынаюлары әлеге принципларның үзара мөнәсәбәтләренә дә билгеле бер эз сала торгандыр. Мәгълүм ки, дөньяны танып-белүнең бу ике төп формасының үзара якынаюлары аларның бер-берсенә йогынтысы көчәюгә, үзара бәйләнышлары ныгуга китерә. Алар бер-берсеннән өйрәнәләр һәм баеыйлар. Шул нигездә фәнни фикерләү белән сәнгатьчә фикерләүгә хас тарихилык принциплары арасында да яңа уртак нокталар хасил була.

Тарихилык принцибын тарихи категория итеп һәм үсештә карарга омтылу фәндә һәм тәнкыйтьтә аңарга бермә-бер игътибар артуга китерде. Бу эволюция барыннан да элек тарихи һәм тарихи-революцион үткәнгә багышланган әсәрләр җирлегендә карала. Аерым алганда, хәзерге сәнгатьчә фикерләүнең тарихилыгы көчәюенең тарихи жанр үсешенә, бу жанрның асылын аңлауга эз салуы күрсәтелә. Әгәр элегрәк елларда тарихи романның нигез сыйфаты итеп документальлек каралса, соңгы вакытта бу жанрның асылын болай аңлатуның җитәрлек булмавына игътибар ителә. Чөнки 60—70 нче елларда дөнья күргән тарихи әсәрләрнең барысы да тулысынча документальлеккә нигезләнми; алар арасында документаль булмаган чыганакларга — легендага, риваятькә яки мифка нигезләнеп язылганнары да шактый очрый.

Кыскасы, күп милләтле совет прозасында без язучыларның һәм документаль һәм мифологик чыганакларга актив мөрәҗәгать итүләрен күрәбез. Әдипләр тарафыннан файдаланыла торган материалның шулай төрле характерда булуы тарихи жанрда формаларның күп төрлелеген тудыра. Шушы материалның характерына

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Т., 35, Казан, 1964, 221 бит.

бәйле рәвештә 60—70 нче еллар совет прозасында ике төрле тарихи хикәяләүне күзалларга мөмкин. Аларның берсе классик совет тарихи романының бай традицияләрен дәвам итә. Сүз биредә ныклап өйрәнелгән документаль материалга нигезләнгән, конкрет тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышланган тарихи хикәяләү турында бара. Хәзерге тарихи әсәрләрдән С. Бородинның «Сәмарканд өстендә йолдызлар», Д. Балашовның «Марфа Посадница», П. Загребельныйның «Диво» һәм «Первомост», Г. Абшидзеның «Озын төн», Ә. Әлимҗановның «Махамбет угы» романнарында сюжет шул рәвешлерәк корыла. Шуның белән бергә, бу әсәрләрдә автор фантазиясенең көчәя төшүе күзгә ташлана. Аларда авторның роле үсә. Ул әле турыдан-туры, әле читләтеп хикәяүләүгә килеп кушыла, төрле заманнарны үзара очраштыра. Нәтиҗәдә әсәр композициясе тагын да катлаулана, дәверләр бәйләнеше тагын да тирәнәя төшә.

Әлеге сыйфатлар тарихи хикәяләүнең безнең көннәрдә шактый популярлашкан икенче төрендә тагын да көчәяләр. Бу төр хикәяләү документаль төгәллеккә азрак дәгъва итә һәм автор фантазиясенә киңрәк мәйдан ача. Биредә инде әсәр жанры да, проблематикасы да үзгәрә. Әлеге төр хикәяләү күбрәк ерак үткәннең башлыча әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрен күтәргән повестьта чагылыш таба. Мисал итеп В. Панованың «Таң аткандагы шәүләләр», В. Лихоносовның «Таманьда көз», Д. Балашовның «Галиҗәнап Новгород», А. Кәкилбаевның «Онытылган еллар балладасы», С. Санбаевның «Миф көткәндә» повестьларын алырга була. Бу форма белән соңгы вакытта шагыйрьләр һәм драматурглар да кызыксына башладылар. Ю. Марцинкявичюсның «Миндаугас» поэмасы, Т. Ахтановның «Ант» драмасы, М. Кәримнең «Салават» һәм «Ташлама утны, Прометей!», Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедияләре шул хакта сөйли. Ерак үткәндәге тормышның әхлакый-фәлсәфи проблемалары, андагы рухи башлангыч белән кызыксынып, бу әсәрләрнең авторлары легендага, кинаяле сүзгә (притча) яки фольклор символикасына мөрәҗәгать итәләр. Мондый проблемалар, мотивлар һәм чаралар кайбер тарихи романчыларның да игътибарын җәлеп итә. Мисалга В. Ивановның «Бөек Русь», Г. Гулиаоның «Фараон Эхнатон» һәм «Афина кешесе», Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романнарын китерергә мөмкин.

Безнең көннәрдә тарихи жанр бик хәрәкәтчән һәм заманның эстетик таләпләренә гаять сизгер. Әгәр 20—30 һәм 60—70 нче еллар тарихи әсәрләрен үзара чагыштырып карасак, без аларда бу принципның бигүк бертөрле чагылмавын күрербез. 20—30 нчы еллар әдәбиятындагы тарихилыкның тарих фәнендәге шушы ук принципка шактый якын торуы һәм хәтта аңа «буйсынуы» күзгә ташлана. Чөнки ул чорда язучы, тарихчы кебек үк, күбрәк тарихның социаль аспекты белән кызыксынды. Гомумән, совет әдәбияты үз юлын чынбарлыкны, шул исәптән тарихны да, аңлы социаль планда үзләштерүдән башлады. Безнең көннәрдә исә, нык үскән социализм заманында, социалистик реализмның бу принцибы үзгәреш кичерә. Хәтта ул хәзер тулырак, бөтенрәк булып, чыннан да, әдәби тарихилык булып гәүдәләнә дияргә мөмкин. Болар барысы иң әүвәл язучыларның чынбарлыкны, бу очракта тарихны, шәхес аша өйрәнүгә һәм яктыртуга омтылышлары үсүдә чагыла. Шул нигездә совет әдәбиятының психологизмы да кызыклы эволюция кичерә.

Безнең көннәрдә исә психологик анализның предметы шактый киңәйде. Чөнки хәзерге язучылар Маркcның кешеләрнең иҗтимагый тарихы һәр вакыт аларның индивидуаль үсеше тарихыннан гыйбарәт дигән фикеренә торган саен ныграк төшенәләр һәм тормыш агымын, тарих үсешен кеше күңеле, аның үсеше аша гәүдәләндерергә омтылалар. Әйтергә кирәк, тарихны шәхес аша танып-белүне алга куеп, хәзерге әдәбиятның тарихилыгы фәнни тарихилыкка да эз сала. Шул ук вакытта хәзерге тарихчылар үз хезмәтләрендә фантазиянең дә кирәклеген таныйлар. Мондый зарурлыкның сәбәбен аңлатып, тарих фәннәре докторы Р. Нәфыйков «Тарих һәм әдәбият» дигән темага багышланган сөйләшүдә («Социалистик Татарстан», 10 апрель, 1977 ел) болай диде: «Чөнки без, тарихчылар, өйрәнә торган тарих замандашлар алдына дөрес булып кына түгел, шигърияте дә булып басарга тиеш дип уйлыйбыз. Бу теләк бигрәк тә тарихи шәхесләрне күрсәтүгә карый. Чөнки бу шәхесләр, гадәттә, бай рухлы гүзәл затлар булганнар һәм шундый сыйфатлары белән безнең замандашларга да үрнәк булып торалар. Алар тарихи хезмәтләрдә дә әнә шундый затлар булып сурәтләнергә тиешләр».

Тарихи шәхесне сурәтләү хәзерге әдип өчен һич тә үзмаксат түгел. Киресенчә, авторлар биредә тарихи үткәннең аерым күренешләрен һәм мәсьәләләрен яктыртуны төп максат итеп куялар һәм тарихи шәхесне сурәтләүгә дә шушы максат яктылыгында килеләр. Әйтик, соңгы вакытта илебездәге төрле әдәбиятларда ерак үткәндә яшәгән шагыйрьләр белән кызыксыну көчәйде. Ә. Әлимҗановның «Махамбет угы», Г. Гулианың «Гомәр Хәйям турында хикәят», А. Якуповның «Олугбәк хәзинәләре» романнары, М. Кәримнең «Салават», Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедияләре, Ю. Марцинкявичюсның «Миндаугас» поэмасы һәм башкалар шул хакта сөйли. Мондый шагыйрьләргә игътибар көчәю барыннан да элек язучыларның үткән тарихи дәверләрнең рухи-әхлакый тәҗрибәсен, рухи эзләнүләрен һәм табышларын танып-белү, аларны хәзерге һәм киләчәк буыннарга җиткерү теләге белән бәйләнгән. Бу бөек шәхесләр үз көннәрендә заманның өметләрен һәм шомнарын, аның әхлакый казанышларын һәм фаҗигаләрен йөрткәннәр. Алар еш кына үз заманнарындагы гаделсез иҗтимагый строй белән тирән конфликтка кергәннәр һәм бу конфликт аларны һәлакәткә китергән. Әмма геройларның үлеме рухи торгынлык һәм томаналыктан өстенлек тантанасы булып яңгырый ул әсәрләрдә.

Әлеге әсәрләрнең кайберләрендә тормышта гаделлекнең һәм яхшылыкның тантанасы өчен шигырь белән дә, кылыч белән дә көрәшкән борынгы сугышчы шагыйрь образы тудырыла. Шуның белән алар икеләтә батырлык эшлиләр. Шул сәбәпле, хәзерге әдипләр бу сугышчы шагыйрьләрне үз заманының иң яхшы сыйфатларын, күркәм идеалларын һәм рухи казанышларын үзендә чагылдырган яңа герой итеп күз алдына бастыралар. Шундый сыйфатлары белән алар, дәверләр бәйләнешен үзләрендә гәүдәләнедереп, буыннан-буынга күчеп яшиләр.

Күп кенә әсәрләрдә күренекле революционерларның батырлыкларын күз алдына тулырак бастыру белән бергә, аларның рухи дөньясын тирәнрәк ачарга омтылыш көчәя. Андый очракларда үткәндәге легендар революционерлар тарихи яктан тулы канлы шәхес һәм заманның яңа герое булып күз алдына баса. Шул ук вакытта кайбер әсәрләрдә авторлар, иҗат фантазиясен документаль материал белән тыгыз бәйли алмау сәбәпле, бу шәхесләрне сәнгатьчә сурәтләгәндә әллә ни уңыш казана алмыйлар. Ә кайчак тарихи шәхес турында хикәяләүнең документаль төгәллегенә омтылып, документальлеккә артык ябышып яталар һәм фантазияне санга сугып бетермиләр шикелле. Хәлбуки, инде В. Г. Белинский тарихи шәхесләр турында язучы авторның иҗади күзаллауга тулы хокукы булуын әйткән һәм бу хәлне әдәби әсәр «тукымасының һәм механизмының таләпләре» белән бәйләп аңлаткан. Шул ук вакытта бөек тәнкыйтьче тарихи әсәрдәге фантазиянең мәгълүм чикләре булуына да дикъкать иткән. Андый әсәрләрдә иҗади күзаллау, һичшиксез кирәк, тик ул шәхеснең тарихи йөзен бозуга китермәскә тиеш. Дөрестән дә, фантазия белән артык мавыгуның тарихи шәхесне реаль җирлектән аерып күрсәтүгә китерүе дә ихтимал.

Соңгы вакытта безнең әдәбиятларда хезмәт иясе массаларының революция алды елларында иҗтимагый үзаңы уянуын, революцион көрәш юлына басуларын бөтен катлаулылыгы һәм үзенчәлекле яклары белән күрсәтүгә игътибар артты. Бу тенденция, аерым алганда, төрки халыклар прозасына хас. Мисалга Ә. Нурпеисовның «Кан һәм тир», И. Шихлының «Кызу агымлы Кура», Н. Сәфәровның «Каргышлы һәм өметле көн» романнарын, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестен һ. б. китерергә була. Туган халкының XX йөз башындагы катлаулы социаль-рухи уянуы процессын күрсәтергә алынып, Ә. Нурпеисов үз романында революциягә кадәрге ярым күчмә казакъ тормышына харктерлы булган бер моментка әледән-әле игътибар итә. Сүз казакъларның далада бер-берсеннән аерылган хәлдә, үзалдына гына яшәүләре турында бара. Бу хәл аларны социаль һәм рухи ялгызлыкка дучар итә иде. Автор «далада һәркем үзалдына гына яши, бер ялгызы үз көтүен яки байлар көтүен көтә иде» дип яза. Менә шушы ялгызлыкка дучар ителгәнлекне язучы революциягә кадәрге казакъ тормышының иң күңелсез күренешләреннән берсе итеп күрсәтә. Ә үз геройларының социаль-рухи үсешен ул, барыннан да элек, аларның әнә шул ялгызлык хисеннән арынуларында күрә.

И. Шихлының «Кызу агымлы Кура» романында исә иң кызыклысы — патриархаль яшәүнең туып килүче капиталистик мөнәсәбәтләр, гомумән, заманның яңа

карашлары белән конфликтка керүен күрсәтү. Бу фикер әсәрнең үзәк герое Джахандар аганың фаҗигале язмышы аша чагылдырыла. Ул патриархаль авыл тәртипләре буенча, бабайлардан калган иске гореф-гадәтләргә ияреп яшәргә күнеккән. Әмма «арслан йөрәкле» бу ир заманның яңа карашларын һәм идеяләрен аңлый алмый, нәтиҗәдә аның искергән карашлары һәм яшәү принциплары үсештәге чынбарлык белән конфликтка керәләр. Бу конфликт геройны фаҗигале үлемгә дучар итә.

Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишеге» белән Н. Сәфәровның «Каргышлы һәм өметле көн»енә килсәк, аларда геройларның социаль-рухи үсеше иҗтимагый инертлыктан һәм пассивлыктан арыну аша бара. Мондый үсешне булдырган факторлар итеп авторлар, бер яктан, ачлык-ялангачлыкны, байларның һәм патша администрациясенең башбаштаклыкларын, икенче яктан, шәригатьнең рухи изүен саныйлар. Империалистик сугыш башлану белән исә татар авылы Яңасала крестьяннарының һәм провинциаль үзбәк шәһәрчеге Җизаг кешеләренең болай да кыен тормышы тагын да авырлаша. Болар барысы кешеләрне ничектер айнытып җибәрә, алар үзләренең авыр тормышы, аның сәбәпләре турында уйлана башлыйлар. Татар авылы крестьяннары гына түгел, бәлки ерак үзбәк шәһәрчегендә яшәүчеләр дә «ачлык, яңа налоглар, Россия шәһәрләрендәге чуалышлар, патшаның фронттагы уңышсызлыклары, массаларның патшадан да, сугыштан да риза булмаулары турында» сөйли башлыйлар. Авторлар алга таба моңа кадәр ничектер ваемсызрак булып күренгән геройларының аңында һәм уйларында тирән үзгәрешләр башлануын, аларда үзләрен изүчеләргә карата ачы нәфрәт хисе тууын күрсәтәләр.

Әлеге әсәрләрдә хикәяләү еш кына яшь герой исеменнән алып барыла, авторлар үзләренең бала чакларын чагылдыралар. Язучыларның үз бала чакларына мөрәҗәгать итүләре хәзерге әдәби процессның фән-техника революциясе йогынтысында көчәеп киткән кызыклы бер тенденциясе чагылышы булып тора. Сүз әдипләрнең «дөньяны турыдан-туры, эмоциональ рәвештә кабул итүгә, бала чак поэзиясенә» омтылулары турында бара. Күренекле әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче А. Метченко алга табан хәзерге язучыларның бала чак темасына игътибарлары артуын «кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә сафлыкка омтылулары, дөньяны балаларча сафлык белән күрергә һәм аны үзенә әр-яңадан ачарга» теләүләре белән бәйләп аңлата. Г. Бәширов һәм Н. Сәфәров әсәрләреннән тыш, бу төр хикәяләүгә мисал итеп тагын В. Смирновның «Дөньяны ачу», Ю. Балтушисның «Сатылган еллар» романнарын, М. Кәримнең «Озын-озак балачак» повестен һ. б. китерергә мөмкин. «Дөньяны балаларча саф күз белән күрергә һәм аны үзенә әр-яңадан ачарга» омтылу ахыр чиктә әсәрләрдә сурәтләнгән чорның тарихи яктан тагын да объективрак күренешен тудырырга булыша.

Сәнгатьчә фикерләүнең тарихилыгы тирәнәю язучыларда әдәбиятта инде шактый яктыртылган темаларга кабат әйләнеп кайтып, аларны яңача «уку» теләге дә тудыра. Бу тенденция гражданнар сугышы һәм коллективлашу дәверләренә багышланган әсәрләрдә нык сизелә. Тарихилык хисләре тирәнәйгән хәзерге әдипләр шул киеренке еллардагы тормышны һәм көрәшне тарихи яктан тулырак күзалларга тырышалар һәм ул тормышның, көрәшнең яңа сәхифәләрен, яңа якларын ачалар. Әсәрләрдә бигрәк тә ул еллардагы көрәшне бөтен катлаулыгында, күп төрлелегендә һәм кискенлегендә ачуга омтылыш көчәйде. И. Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясен, Җ. Икраминың «Бохараның унике капкасы»н, Ф. Исәнгуловның «Ирегеткәй белән ат башы» романын искә алыйк. Бу әсәрләрдә сурәтләнгән аерым геройларның милләтчелек омтылышлары әсәрләрдә яңа тормыш юлына баскан халык массаларының коммунистик интернационализмы һәм идея-политик бердәмлеге белән бәрелештә җиңелүгә дучар була. Моның белән авторлар тарихи хакыйкатьне — социализм шартларында интернационализм һәм халыклар дуслыгы идеяләренең иске дөньядан калган милләтчелек һәм шовинизм карашларын җиңеп чыгуларын һәм тантана итүләрен чагылдыралар.

Әлеге әсәрләрдә революция казанышларын саклап калу һәм ныгыту өчен актив көрәшкә баскан геройларның характеры, иҗтимагый-әхлакый йөзе һәм үз-үзен тотышы төрле яклы һәм тирән итеп гәүдәләндерелә. И. Гази трилогиясендәге өяз чекасы председателе Шәрифҗан образы бик тә характерлы. Аның образында язу-

чы 20—30 нчы еллар героеның рухи яктан активлашуын күрсәтүне максат итеп куя һәм үз фикерен гәүдәләндерү өчен тышкы күренешләрдән геройның эчке дөньясына күчә бара.

Әгәр 20 нче еллар һәм 30 нчы еллар башы әдәбиятында мондый герой еш кына революцион аскетизм тарафдары итеп күрсәтелсә яки шәхси тормыш мәсьәләләрендә уңышсызлыкка дучар булса, И. Гази әсәрендә инде укучы бу геройда тулы канлы шәхси тормышка омтылыш тууын һәм аның шул давыллы елларда үз теләгенә ирешүен күрә. Шушы җирлектә социаль актив геройның рухи яшәеше дә активлаша.

Әмма Шәрифҗанның социаль-рухи җитлеккән шәхескә әверелүе әсәрдә һич тә нииндидер хосусый һәм бердәнбер күренеш булып калмый. Язучы аны безнең илдә яңа кеше формалашу процессының характерлы чагылышы итеп карый. Бу факт кабат бер мәртәбә хәзерге әдәбиятта тарихи-революцион үткәнне шәхес җирлегендә өйрәнүгә һәм күрсәтүгә игътибар артуы турында сөйли.

Хәзерге әдәби процессның тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге шунда: аңарда тарихилык үткәнне сурәтләүдә генә түгел, бәлки бүгенге үзгәрүчән заманны сәнгатьчә үзләштерүдә дә торган саен көчәя бара. Шул сәбәпле, бу принципка тәнкыйтьтә һәм әдәбият фәнендә дә караш үзгәрә. Элегрәк елларда тарихилык башлыча үткәнгә багышланган әсәрләргә генә хас дип каралса, хәзер ул бер үк дәрәҗәдә заман темасын яктыртуга да карый торган идея-эстетик категория итеп таныла.

Әдәбият галимнәрен һәм тәнкыйтьчеләрне: «Заман темасын яктыртуда бу принцип нидән гыйбарәт соң?» дигән сорау уйландыра башлады. Дөрес, совет әдәбият фәнендә бу сорауга тулы җавап юк әле. Бары аерым фикерләрне һәм күзәтүләрне генә очратырга мөмкин. Гомумән, әдәбиятта бары заман турында хикәяләүгә генә хас тарихилык юк һәм була да алмый. Сүз заман темасын яктыртканда бу принципның аерым сыйфатлары һәм таләпләренең чагыштырмача актуальрәк яңгыраулары турында гына барырга мөмкин. Безнең карашча, заман тормышын сурәтләгәндә тарихилыкның чынбарлыкны сәнгатьчә тирән үзләштерү, аның тарихи эчтәлеген ачу кебек сыйфаты аеруча актуаль төс ала. Бу моментка заманында М. Горький да «бүгенге көннең» тарихилыгы турында сөйләгәндә дикъкать иткән иде. Йомшаграк әсәрләргә тукталып, ул болай дип яза: «Очраклы хәлләр»гә нигезләнеп, алар анекдотик характер алалар, аларда әдәби әсәр өчен бик кирәк булган тарихилык сизелми».[1] Горький язучыларны заман тормышын «хәзерге көнгә монумент тудыру» максатында файдаланырга чакырды.

Идея-эстетик фикернең җитлеккәнлеге һәм чынбарлыкны танып-белүдәге тирәнлек рәвешендә аңланган тарихилык заман темасына багышланган әсәрләрдә төрлечә чагылыш таба. Барыннан да элек ул әдипләрнең хәзерге җәмгыять үсешенең магистраль тенденцияләрен һәм аның төп көчләрен сәнгатьчә үзләштерергә омтылуларында гәүдәләнә. Характерлы мисалларның берсе — ул хәзерге әдәбиятта эшчеләр сыйныфына игътибар тагын да көчәя төшү. Гомумән, соңгы вакытта бу сыйныфның хәзерге җәмгыятьтәге роле һәм урыны мәсьәләсе киң җәмәгатьчелекнең, беренче чиратта, иҗтимагый фәннәрнең дикъкать үзәгендә тора.

Эшчеләр сыйныфы эшчәнлегенең гомумфәлсәфи һәм гомумэстетик мәгънәсен ачыклаудан тыш тарихилык хисе хәзерге язучыларга тагын бу теманы яктыртуның милли үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен төшенергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Ә. Мохтар фикеренчә, Үзбәкстанда «эшче турында язу — милләтнең йөзе хакында язу дигән сүз», чөнки үзбәкләр, «милләт буларак, бары эшчеләр сыйныфы барлыкка килгәч кенә формалаша башладылар.» А. Лупан да Молдавиядә эшче темасын «милләтнең үсүе һәм яңаруы турында уйланулардан башка тирәнтен чишеп булмый» дип белдерә.

Чыннан да, эшчеләр сыйныфының тарихи роле, миссиясе милли республикаларда тагын да калкурак булып гәүдәләнә. Бу сыйныфның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә аларның экономикасында тирән үзгәрешләр хасил булды. Тарихи казанышлар, үз чиратында, халыкларыбыз тормышында зур социаль үзгәрешләргә китерделәр, аларның профессиональ-техник һәм рухи яктан үсүләренә булыштылар. Тарихилык хисе әдипләрнең игътибарын шушы социаль-рухи процессларга юнәлтә.

[1] М. Горький. Собр. сочинений в 30 ти томах, т. 27, М., 1953, 11 бит.

Әдипләрнең игътибары еш кына хезмәттәге бөек җиңүләрнең тарихи мәгънәсен ачыклауга һәм гәүдәләндерүгә юнәлтелә. С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасында КамАЗ төзелеше шагыйрь алдына нәкъ менә дәверләр капкасы булып баса. Бу төзелеш биеклегеннән шагыйрьгә борынгы Болгар иле һәм хәзер автозавод территориясендә калган татар авылы Гәрдәленең үткәне, 20 нче еллар башында ачлык газабын кичергән Идел буе, Курск дугасы һ. б. күренә... КамАЗны төзегәнгә кадәр шагыйрьнең туган халкына әнә шул юлны үтәргә туры килгән. Ә хәзер ул киләчәккә яңа адым ясый. Нурек ГЭСы төзелеше таҗик шагыйре Х. Фәйзуллоны шулай ук туган халкының бүгенге казанышларыннан аның үткәненә алып кайта. «Юл поэмасы»нда ул моны сукмак образы аша гәүдәләндерә. Сукмак таулар һәм үзәнлекләр буйлап урый-урый килгән дә, Нурек елгасына барып җиткәч, «киң трактка әверелгән». Заманыбызның мондый зур төзелешләре, икенче яктан, шагыйрьләргә буыннар һәм дәверләр бәйләнешен ачарга мөмкинлек бирәләр.

Хәзерге тәнкыйтьтә һәм әдәбият фәнендә тарихилыкны эстетик категория итеп карауга игътибар бирелә башлады. Чөнки чынбарлыкны тарихи барлыгында һәм катлаулылыгында күрсәтүне таләп итеп, бу принцип әдәбиятта сәнгатьчә эзләнүләрнең һәм табышларның да күп төрле булуын сорый. Шул ук вакытта ул үзе дә әсәрләрдә төрле формалар һәм чаралар ярдәмендә чагылдырыла.

Фән-техника революциясе заманында эшчеләр сыйныфының һәм сан, һәм сыйфат ягыннан үсүе аның хәзерге җәмгыятьнең иҗтимагый-политик һәм рухи тормышында роле тагын да артуга китерә. Шул сәбәпле, эшчеләр дөньясы сәнгать өчен зур идея-эстетик кыйммәткә ия. Бу хакыйкать безнең көннәрдә тәнкыйтьчеләр һәм язучылар тарафыннан да торган саен тирәнрәк күзаллана. Һәм әлеге факт аларның темага мөнәсәбәтендә тарихилыкның тирәнәюе турында сөйли.

Тарихилыкны сәнгатьчә гәүдәләндерүнең ике төп формасы турында сүз алып барырга мөмкин. Аларның берсе бу принципны тормышның үз формаларында чагылдырудан гыйбарәт, һәм ул әдәбиятта аеруча киң таралыш тапкан. Тарихилыкны бу рәвешле чагылдырганда хәзерге прозада аналитик башлангычның көчәюе күренә. Соңгысы, үз чиратында, хәзерге әдәби иҗатта документализм белән психологизмның көчәюенә китерде. Тарихилыкны гәүдәләндерүнең икенче мөһим формасы шартлылыкка нигезләнә. Биредә инде бу принцип синтезга омтылучы фәлсәфи фикерләү белән, типиклаштыру белән бәйләнгән. Шартлылык исә яшәеш күренешләрен һәм тенденцияләрен сәнгатьчә калку итеп күрсәтү өчен файдаланыла. Бу максатта әдипләр еш кына мифка мөрәҗәгать итәләр. Әмма мифка карашта социалистик реализм белән модернизм арасында принципиаль аерма бар. Модернистлар, Б. Сучков сүзләре белән әйткәндә, «мифны универсальләштерергә, аны сәнгатьнең олы һәм хәтта бердәнбер юлына әйләндерергә тырышалар».[1] Модернистларның бу концепциясен ренегат Р. Гароди аеруча актив пропагандалый. Социалистик реализм әдәбиятында исә миф дөньяны сәнгатьчә танып-белүнең үтемле чарасына әверелә.

Шул күзлектән Ч. Айтматов иҗаты аеруча игътибарга лаеклы. Үзенең «Ак пароход» һәм «Иртә килгән торналар» повестьларында ул миф ярдәмендә туган халкының бүгенгесе белән үткәне арасындагы рухи бәйләнешне, әхлакый чыганакларын калку итеп һәм зур көч белән гәүдәләндерә алды. Моның белән Ч. Айтматов кабат бер мәртәбә совет язучыларының да мифка мөрәҗәгать итәргә тулы хокуклы булуларын күрсәтте. Ә бит үткән елларда бу хокук еш кына инкарь ителә иде. Гомумән, соңгы вакытта күп бәхәсләрдән соң шартлылык социалистик реализм поэтикасында үзенә тиешле урын алды дияргә була.

Социалистик реализмның нигез принципларыннан берсе — аерым язучы иҗатының һәм бөтен әдәбиятның идея-эстетик җитлеккәнлегенең мөһим күрсәткече булган тарихилыкны өйрәнүгә әле игътибар җитәрлек түгел. Әдәби процессны тарихилык принцибы яктылыгында эзлекле рәвештә өйрәнү нык үскән социализм чоры әдәбиятының үсеш юлларын һәм тенденцияләрен тулырак һәм тирәнрәк күзалларга булышыр иде.

---

[1] Б. Сучков. Лики времени. Статьи о писателях и литературном процессе, т. I, М., 1975, 362 бит.

Маргарита Фәйзуллаева

# ХАЛЫК МУЗЫКАСЫ ҺӘМ КОМПОЗИТОР

„Музыканы халык тудыра, ә без аны оранжирлыйбыз гына», — дигән бөек рус композиторы М. И. Глинка. Бу сүзләр күпчелек татар совет композиторлары иҗатына да бик туры килә. Профессиональ татар музыкасы үзе дә халык музыкантлары, һәвәскәр башкаручылык, гомумән алганда, музыкаль фольклордан тамырланып үсеп чыккан. Моның шулай икәнлеген исбатлау өчен әле егерменче йөз башларында ук халык арасында шактый киң таралыш алган музыкаль пьесалар, инструменталь әсәрләр һәм җырларны искә төшерү дә җитә. «Тукай маршы»н, күп җырлар иҗат иткән Заһидулла Яруллин, «Садә», «Казан» маршларының авторлары Гали Зайпин, Хәбибулла Әхмәдуллин, беренчеләрдән булып татар көйләрен музыка кораллары өчен эшкәрткән һәм шул нигездә оригиналь әсәрләр яза башлаган Солтан Габәши, ниһаять, татар музыкасы йолдызлары булып танылган Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Фәрит Яруллин һәм башка бик күп композиторлар һәм музыкантларыбыз әнә шундый һәвәскәр башкаручылар — скрипкачы, гармунчы, җырчылар арасыннан чыккан[1].

Ә татар музыкасы классигы С. Сәйдәшев әле егерменче һәм утызынчы елларда ук халык моңнарын профессиональ музыка белән органик рәвештә бергә кушуның классик үрнәкләрен бирде. М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, Х. Вәлиуллин һ. б. композиторлар иҗатында да без музыкаль фольклордан иҗади файдалануның гүзәл үрнәкләрен күрәбез. Алар халык музыкасы хәзинәләренең күп кенә катламнарын тирәнтен үзләштереп, профессиональ музыкабызның төрле өлкәләрен һәм жанрларын туендыра, үзенчәлекле юнәлешләрдә баета килделәр.

Музыкаль фольклорны профессиональ иҗатта файдалану — күп яклы һәм катлаулы иҗади процесс. Һәр композитор аны үзенчә хәл итә. Шул ук вакытта һәр яңа дәвер, яңа буын өчен моның ниндидер уртак билгеләрен дә күрергә мөмкин. Биредә исә без нәкъ менә бүгенге көндә актив иҗат итүче яшьрәк буын композиторлардан берничәсенең иҗатына мөрәҗәгать итәбез. Музыкаль фольклорны алар нинди юнәлештә үзләштерә, бу өлкәдә үзләреннән нинди өлеш кертәләр соң?

Ренат Еникеевның фортепиано өчен язылган икенче сонатасы, Рафаэль Биляловның скрипка һәм фортепиано өчен иҗат ителгән фольклор-сюитасы, Шамил Шәрифуллинның солист һәм а капелла хоры өчен «Авыл көйләре» — эчтәлекләре, жанр һәм стиль үзенчәлекләре ягыннан бер-берсеннән шактый ерак торган әсәрләр. Әмма аларга халык моңнарын иҗади файдалану һәм үзләштерү җәһәтеннән күп кенә уртак сыйфатлар хас.

---

[1] Бу хакта кара: Ш. Монасыйпов. Татар скрипка сәнгате. «Казан утлары», 1979 ел, 1 сан.

Р. Еникеевның икенче сонатасы Хөсәен Ямашев истәлегенә багышланган һәм революция каһарманнары, аларның яшәеш асылы, үзләре сайлап алган юлга, халык бәхете өчен көрәш эшенә тугрылыклары хакында сөйли торган дулкынландыргыч поэма булып яңгырый. Әсәрнең кереш өлешенә автор тирән кайгы аһәңнәре белән сугарылган «Анам кабере янында» исемле халык көен кертә. Көй әсәрнең тукымасына органик төстә кушыла һәм аның эпиграфы булып китә. Әсәрнең буеннанбуена музыка табигый һәм тоташ агым булып бара, мелодик фикернең үсеш логикасы исә ачык аңлаешлы. Автор моңа монотематизм дип йөртелгән принципны эзлекле куллану аша ирешә. Музыкаль материалны үстерүдә монотематизм методы, мәгълүм ки, романтизм чорында аеруча киң таралган булган. Күңелне җәлеп итә торган аерым көйгә нигезләнгән хәлдә, күп кенә авторлар яңа һәм хәтта бер-берсенә контраст музыкаль темалар һәм образлар тудырганнар. Р. Еникеевның әлеге сонатасында яңа темалар һәм көтелмәгән аһәңнәр нәкъ менә «Анам кабере янында» исемле халык көеннән үсеп чыга. Мәгънәви эчтәлеге белән ул революция һәм Ватаныбыз каһарманнары рухына багышланган кайгылы моң булып әверелә. Әсәрнең керешендә көйне нәкъ халыкта башкарылганча, аның үз яңгырашында ишетәбез. Ә аннары музыкада яңа образлылык хасиятләре туа башлый, киеренке көрәш рухын чагылдыручы көчле характер гәүдәләнә, тема туктаусыз үсә, күтәрелә бара. Әсәрнең урта өлешендә ул инде матәм маршы булып ишетелә, гүя шул марш көенә атлап килүче халык агымы күз алдыннан үтә. Музыка табигый рәвештә героик башлангычны, революция эшен, җиңү темасын раслауга алып килә. Р. Еникеев сонатасында бер үк халык көе әнә шундый күп кырлы һәм тирән яңгыраш алган.

Рафаэль Билялов 1978 елда иҗат ителгән фольклор-сюитасында халык көйләреннән иҗади файдалануның башкача юлын күрсәтте. Фольклор материалы биредә композиторга халык көнкүрешенең ямьле һәм күңелле күренешләрен яисә борынгы риваятьләрне музыка чаралары белән җанлы картинадай күз алдына бастыру, эзлекле программа, төгәлләнгән бер хикәят итеп гәүдәләндерү өчен этәргеч булып хезмәт итә. Әсәрнең һәр кисәге бала чактан ук хәтергә сеңеп калган көйләргә нигезләнгән нәфис музыкаль образ булып җитлеккән. Сюита киң лирик яңгырашлы «Туган ил» көе белән башлана. Аңарда халкыбызның үз туган-үскән җиренә, табигатькә мәхәббәте, яшәү шатлыгы чагыла. Көйнең киң агышы, гармония һәм ритм кысаларының иркенлеге аңа шундый зур колачлы яңгыраш өсти. Әсәрнең икенче — «Шук малай» дип аталган кисәгендә, кинәттән дип әйтерлек, тормыш-көнкүрешнең ямьле бер күренеше — балалар уены күзаллана. Ул «Бала уйнатканда» исемле кыска көйгә нигезләнгән. Музыка чараларын автор шаянлык, җитезлек, күңелле уен характерын гәүдәләндерүгә буйсындырган. Скрипка һәм фортепиано партияләре җанлы, йөгерек, аларның музыкаль теле үткен, шаян интонацияләргә, төсмерләргә бай, тема үсешендә гармоник бизәкләр туктаусыз яңарып, алышынып тора.

Өченче кисәк — «Бишек җыры»нда музыка чаралары тагын үзгәрә. Бусы инде — йомшак лирик элегия. Р. Билялов биредә дә үзен музыкаль колорит, бизәк остасы итеп күрсәтә. Җемелдәп, уйнап торган гармоник бизәк-нурланышлар, йомшак һәм иркә ярдәмчел тавышлар, нечкә һәм төгәл эшләнгән музыкаль фактура, — барысы да бишек җыры «Әлли, бәлли»нең күркәм һәм бай яңгырашын тудыра.

Сюитаның дүртенче кисәге халыкта киң таралган «Алмагачлары» көенә корылган. Көй, кинәт ычкындырылган тыгыз пружинадай җитез бөтерелеп, күңел гамен үз эченә тартып ала. Музыкада хәрәкәт ритмы һаман кызулана барып, күңелле халык бәйрәмен күз алдына китерә, нәтиҗәдә гаҗәеп җанлы халыкчан колорит тудыруга ирешелә.

Сюитаның финал өлеше тагын да тирәнрәк тәэсир калдыра. Күңелдә борынгы чорларның мәһабәт картиналары җанлана. Әнә чал чәчле карт чәчән яшьләргә гыйбрәтле риваять сөйли... Мондый драматик борылышка авторны ул үзе сайлап алган «Бер алманы бишкә бүләек» исемле басынкы һәм тирән фикерле лиро-эпик җыр этәргән булса кирәк. Әсәргә салынган фикерне композитор өч кисәкле композициядә гәүдәләндерә. Композициянең урта өлеше башка кисәкләргә контраст төсендә ачык театраль яңгырашта хәл ителә. Безнең алда легенданың бер эпизоды җанлана, — гүя ки легенда герое кара көчләр белән кискен бәрелешкә керә. Көйдә аерым интонацияләр — халык темасы — элеккечә калса да, автор конкрет

эпизод эчтәлегенә бәйле рәвештә музыкаль актив динамик, горур аһәңнәр өсти, җырны яңа эчтәлек белән баета.

Мәгълүм булуынча, халык темасына багышланган сюита татар музыкасында егерменче елларда ук туган иде. Яңа шартларда да ул үзенең тормышчанлыгын югалтмый. Композиторларыбыз аңа әледән-әле әйләнеп кайталар. Заман үтү белән ул жанр тагын да югарырак баскычка күтәрелде, профессиональ яктан камилләшә төште дияргә мөмкин. Халыкның музыка иҗаты бередә тирәнрәк һәм кыюрак эшкәртелә, ул хәзерге чорга хас музыкаль сурәтләү чараларын үзенә ныграк сеңдерә бара. Р. Билялованың фольклор сюитасы нәкъ әнә шул фикерне раслый.

Яшь буын композиторларыннан Шамил Шәрифуллин соңгы елларда халык музыкасы белән тирәнтен кызыксынучы буларак танылды. Ул татар музыкаль фольклорының борынгы һәм моңарчы аз өйрәнелгән катламнарына үтеп керә, мөнәҗәт, бәет, борынгы мишәр көйләрен җыю һәм эшкәртүдә актив катнаша. Ульянов өлкәсе һәм башка төбәкләргә фольклор экспедицияләрендә яшь композитор күп санда үзенчәлекле иске көйләр язып алды һәм үзе җыйган халык көйләреннән җыентык туплады. Ш. Шәрифуллинның халык музыкасы җәүһәрләрен эшкәртү һәм иҗади үзләштерү нигезендә иҗат иткән әсәрләре белән музыкаль җәмәгатьчелек әледән-әле таныша тора. Кыллы квартет өчен концертино, мөнәҗәт темаларына орган өчен вариацияләр, флейта, кларнет һәм фагот өчен сонатино, а капелла хоры өчен «Мөнәҗәтләр» дип аталган концерт һәм башка әсәрләрендә композитор халкыбызның сирәк очрый торган көй-моңнарын, аларның үзенчәлекле яңгырашын калку күрсәтә белә, еш кына очракта халык көйләрендәге образлылык, мелодик материалны үзенең художниклык фантазиясе аша үткәреп, аларга заманча аһәң бирә.

Бередә Ш. Шәрифуллинның 1977 елда язылган әсәре — «Авыл көйләре» дип аталган вокаль-хор циклына тукталу кызыклы булыр. Солистлар һәм а капелла хоры өчен язылган ул әсәр җиде кисәктән тора. «Авыл көйләре» музыка сөючеләр игътибарын лирик сафлыгы, формасының нәфислеге, фольклор мотивларына нечкә музыкаль сурәтләү чаралары ярдәмендә заманча яңгыраш бирүе, халык музыкасын тоюдагы үзенчәлеге белән җәлеп итә.

Әсәрнең образлы эчтәлеге, халык музыкасын иҗади эшкәртү методлары, гармоник үзенчәлекләре нидән гыйбарәт соң? Исеменнән үк күренгәнчә, «Авыл көйләре»ндә автор халык музыкаль иҗатының аерым бер өлкәсен — элекке заманнардан бирле авылда җырланып килгән лирик җыр-көйләр хәзинәсен күрсәтүне максат иткән. Композиторның үз сүзләре белән әйткәндә, ул үзалдына борынгы авыл көйләрен архаик тышчадан «саклык белән арындырып», бүгенге чор кешесенең колагына якынайту, алардагы лирик агымны көчәйтү бурычын куйган. «Авыл көйләре» циклының үзенчәлеге аның гомумиләштерелгән сюжет линиясенә корылган булуында. Автор монда гомумиләштерелгән формада яшь егет һәм кызның мәхәббәт тарихын чагылдыра. Цикл сюжетлы музыкаль драматургиягә корылган. Беренче һәм икенче кисәкләрдә вакыйга төенләнә. Беренче кисәктәге «Туй җыры»ның поэтик тексты аша без авылга читтән килгән гармунчы егет белән танышабыз. «Гашыйк кыз җыры» дип аталган икенче кисәктә яшь кызның күңел дөньясы ачыла.

**Аягыма кигән итегемнең**
**Кузгаладыр аның олтаны;**
**Килгәндин бирле карап торам,**
**Сез икәнсез егетнең солтаны.**

«Мәхәббәт көе» дип аталган лирик кисәк циклда үзәк урынны алып тора. Бередә кыз белән егетнең дуэты яңгырый, образларның музыкаль характеристикасы тирәнәя. Ә өченче һәм бишенче кисәкләрдәге такмаклар әсәрдә үзенә күрә интермеццо ролен уйныйлар һәм алдагы кисәкләрнең драматизмын көчәйтүгә хезмәт итәләр. Үзенчәлекле такмакларда яшьләр уены һәм биюләре тасвирлана. Алтынчы кисәк — «Хәсрәт көе»ндә вакыйгалар драматик юнәлеш ала. Егетнең лирик-драматик җырында бәхетсез мәхәббәт сагышы ишетелә. Бередә Пенза мишәрләренең озын лирик көе файдаланылган.

**Хәсрәт арасында хәсрәтләр күп,**
**Гыйшык хәсрәтендин авыры юк...**

«Сагыш көе» дип исемләнгән җиденче кисәк ике гашыйкның аерылышуы, бәхетсез мәхәббәт хакында сөйли. Циклда автор халыктан язып алган мишәр көйләре һәм керәшен татарлары җырлары файдаланыла, озын һәм кыска лирик көйләр, такмаклар бер бөтен итеп берләштерелә.

Халык көйләрен Ш. Шәрифуллин ничек чагылдыра соң? Аларның интонациясен ни дәрәҗәдә саклый һәм үзеннән нинди яңалык кертә? Бу сорауларга җавап бирү өчен әсәрнең полифоник һәм гармоник яңгырашына кыскача тукталып үтәргә кирәк. Лирик-драматик һәм шаян рухтагы көйләр бу әсәрдә максатка ярашлы рәвештә төрлечә трактовка алалар. Җырларның лирик, психологик яисә интим лирик сыйфатлары тирәнәйтелә. Композитор халык көе белән бик сак эш итә, тавышка артык басым ясамый, музыка ресурсларыннан урынлы файдалана. Әсәр полифония (күп тавышлылык) муллыгы белән аерылып тора. Нәтиҗәдә көйләр гаять күп төрле төсмерләр белән байый. Шунысы да мөһим, полифониялелек әсәрнең беренчел чыганакларына, көйләрнең бөтенлеге, камиллегенә һич тә зыян китерми.

Татар композиторлары утызынчы елларда ук инде халык көйләрен эшкәрткәндә полифоник чаралар куллана башлыйлар. Соңрак алар опера һәм симфоник музыкада, инструменталь әсәрләрдә киң урын ала. Ш. Шәрифуллин исә бу өлкәдә аеруча зур осталыкка ирешкән, ул куллана торган күп санлы полифоник алымнар көйләрдәге образлылыкны төрлечә яктырта барырга, алардагы аһәңне туктаусыз яңарта торырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, өченче кисәктәге такмаклар шундый чаралар ярдәмендә халыкчан жанрдагы җанлы картина булып әверелә — аны көлкеле эффектлар, сурәт моментлары шулай җанландыра. Көйләрне полифоник үстерү музыкада күңелле уен-көлкене дә, сагыш-хәсрәтне дә калку итеп сурәтләргә ярдәм итә.

«Авыл көйләре»ндә композитор гармоник буяулар һәм чаралардан да бик иркен файдалана. Аның гармоник чаралары әсәрнең лирик рухын, халыкчан стилен бозмый. Фольклор материалын үстерүдә ул вариантлылык методын кулланып эш итә. Циклдагы көйләр халыктагыча беренчел хәләндә асылда бер генә тапкыр яңгырый һәм алга таба көйләр вариантлаштыру хисабына туктаусыз баетыла, үстерелә бара. Композиторның үзенең әйтүенчә, бу методны ул халык көйләренең интонацион үсешендәге эчке закончалыкларны өйрәнү аша үзләштергән. Ә ул закончалыклар логикасына төшенергә аңа фольклор материалларының күп санлы магнитофон язмаларын эшкәртү процессы ярдәм иткән.

Беренчел чыганакны, ягъни халык көен төгәл чагылдыру белән бергә, әсәрнең кайбер кисәкләрендә композитор көй материалыннан ирекле дә файдалана. Бу очракта көйгә яңа драматик интонацияләр өстәлә, аның образлы мәгънәсе, яңгырашы да үзгәреш кичерә. Циклның соңгы кисәге, ике гашыйкның аерылышу сагышын сөйләүче сопрано һәм тенор дуэты әнә шундый планда хәл ителгән. «Сагыш көе»нең музыкасы, яңа интонацияләр кабул итеп, геройларның психологик халәтен, кичерешләр киеренкелеген чагылдыруга кадәр күтәрелә.

Татар опера һәм симфоник музыкасында да халык көйләре чыганакларыннан ирекле файдалану үрнәкләрен шактый күп санарга мөмкин. Авторларның максатына кулай рәвештә бу метод һәр очракта да үзенчәлекле төстә кулланыла. Мәсәлән, Н. Җиһановның «Сабан туй» симфониясендә «Сабан туе» көе, драматик борылышлар алып, эпик яңгырашлы тема — симфониянең төп образы булган халык һәм аның рухи куәте, бөеклеге темасы үсешенә этәргеч бирә.

Әйтергә кирәк, Ш. Шәрифуллинның гармоник почеркы шактый үзенчәлекле. Кайбер эпизодларда ул, Европа гармоник системасының классик принципларыннан читкә китеп, пентатоник гармониягә таяна. Әле XX йөз башларында ук Гречанинов, Эйхенвальд кебек композиторлар татар халык көйләрен эшкәрткәндә пентатоник мелодика нигезендә туган гармонияне куллануның зур мөмкинлекләрен күргәннәр һәм әсәрләрендә файдалана да башлаганнар. Хәер, андый тәҗрибәләр һәр очракта да тиешле нәтиҗә бирмәгән. Бирелә, чыннан да, татар музыкаль фольклорын ти-

рәнтен белү таләп итеЛә. Авторларның талантына, сәнгатьле сиземләвенә дә күп нәрсә бәйләнгән. Ш. Шәрифуллин пентатоник гармонияне табигый куллана.

«Авыл көйләре»нең тагын бер кызыклы үзенчәлегенә тукталып үтмичә булмый. Әсәрдә халык башкаручылыгы өчен типик алымнар, аерым әйткәндә, гармунда уйнау алымнары да чагылыш таба. Хор циклның төрле кисәкләрендә гармоник фонны имитацияли һәм бу алым аерым драматургик функция башкара, бер сүз белән әйткәндә, гармунчы образын, яшьләр уены күренешләрен сиземләргә ярдәм итә. Шуның белән авыл көйләренең чын рухы һәм характеры җанландырыла.

Әйткәнебезчә, композиторның әсәрдә мишәр һәм керәшен татарлары җырларын файдалануы үзе үк әһәмиятле күренеш. Төрле сәбәпләр аркасында бу көйләр композиторларыбыз тарафыннан әле аз өйрәнелгән. «Авыл көйләре» музыка культурабызда моңарчы җитәрлек үсеш алмаган жанр — хор концертлары формасына якын торуы белән дә кызыклы һәм әһәмиятле.

Халык көй-моңнарын традицион музыкаль сурәтләү чаралары ярдәмендә үзләштерү белән бергә, Ш. Шәрифуллин циклның һәр кисәгендә халыкчан чыганакларны үстерүдә индивидуаль принцип һәм методлар да куллана. Ул алымнарны композитор халыкның үз танып-белү тәҗрибәсе, фикер йөртүдәге үзенчәлекләреннән таба. Гадәти сурәт чараларын файдаланган хәлдә, ул бүгенге тыңлаучыга аңлаешлы һәм якын телдә көйли. Музыкаль фольклор хәзинәсен әнә шулай заманча ишетү һәм ишеттерүгә Ш. Шәрифуллин бөтендөнья музыка сәнгате казанышларын өйрәнү, рус совет профессиональ хор иҗаты алымнарын иҗади файдалану аша килә. Аның «Авыл көйләре» әсәре фольклор һәм профессиональ музыка сәнгате арасындагы үзара бәйләнеш мәсьәләсен өйрәнү, ачыклауга саллы өлеш булып тора.

Мәкаләбезне тәмамлап, шуңа басым ясыйсы килә: татар совет композиторлары халык музыка иҗатын өйрәнү, үзләштерүдә төрле методлар кулланып эш итәләр, аңа торган саен тирәнрәк керә баралар. Фольклорның профессиональ музыкага тәэсире, заманыбыз рухы таләп иткәнчә, куәтле һәм чиксез процесс ул.

Шунысы куанычлы, яшь композиторларыбызның зур төркеме музыкаль фольклорның тирәндә яктан катламнарына кыю үтеп кереп, халкыбызның борыннан ук килгән олы иҗат мирасын киң колач белән, заман биеклегеннән торып үзләштерәләр. Ә бу исә профессиональ музыканың эмоциональ эчтәлеген, рухын һәм колоритын, яңгыраш мөмкинлекләрен арттыруга хезмәт итә.

# БАТЫРЛАРГА ДАН ҖЫРЛАП

Самат Шакирның «Үлемне җиңгән батыр»[1] җыентыгында Ватаныбыз азатлыгын яклаган дистәләрчә каһарманнар белән очрашасың. Аны укыганда авторның хәрби-патриотик темага язган башка китаплары да күз алдына килә. Бу китапларның геройлары барысы да гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр. Шунысын да әйтергә кирәк, алар укучы яратып укырлык документаль әсәрләр. Яу кырларында безнең халкыбыз искиткеч зур батырлыклар күрсәтте, исемнәре тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган каһарманнар тудырды. Менә шул каһарман якташларыбызның батырлыгын төкми-чәчми, дөрес һәм сәнгатьле итеп укучыларга җиткерүдә язучы Самат Шакирның хезмәте зур һәм ул мактауга лаек.

Мәсәлән, татар халкының фронтта батырларча һәлак булган утыздан артык төрле буын язучыларының әсәрләрен туплаган «Алар сафта» китабы укучылар тарафыннан яратып кабул ителде. Ә аннан соң патриот-шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй турында «Үлемнән көчлерәк» дигән документаль әсәр язды Самат Шакир. Фашизм тоткынлыгында, гитлерчыларның үз өнендә дошманга каршы яшерен оешма төзеп, баһадирларча көрәшкән бу шагыйрьне немец палачлары Дахау концлагеренда җәзалыйлар һәм крематорийда яндыралар. Самат Шакир аның фронтта язган әсәрләрен һәм көндәлекләрен эзләп табып, «Сугыш язмалары» дигән җыентыгын чыгарды.

«Сугыш язмалары» чыгу уңае белән язучы Ибраһим Гази болай дип язды: «Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларны эзләүче Самат Шакирны искә алу урынлы. Ул фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән сугышчы-шагыйрь, полковник Хәйретдин Мөҗәйнең фронт көндәлекләрен эзләп тапты һәм бастырып чыгарды. Бу — туган иленә соңгы сулышына хәтле турылыклы булып калган совет офицерының кайнар тойгылары, бу — бик мөһим кешелек документы. Мондый китаплар яшьләребезне тәрбияләүдә зур роль уйныйлар».

Бөек Ватан сугышы кырларында — окопларда һәм землянкаларда, бик кыска ял вакытларында язылган солдат хатлары еллар үткән саен тагын да кадерлерәк, тагын да кыйммәтрәк була баралар. Аларны җыйнау, халкыбызга, аерата яшь буынга җиткерү — иң изге эшләрнең берсе. Бу юнәлештә дә Саматның зур тырышлыгын әйтергә кирәк. Ул сугыш чоры истәлекләрен авыллардан, шәһәрләрдән җыйнап, архивлардан эзләп табып, семья членнарыннан һәм музейлардан күчереп алып «Солдат хатлары» дигән китап чыгарды. Сугышчы солдатның үй-хисе, шатлыгы, борчылулары, дошманга булган нәфрәте, туган илгә мәхәббәте, җиңүгә ышанычы чагыла бу хатларда. Язучы аларны анализлый, хат язучыларның тормыш юлларын өйрәнә, исән калганнары белән очрашып сөйләшә, штаб документларын укый, архивларда эзләнә, сугышчыларның күрсәткән батырлыклары өчен нинди орденнар һәм медальләр белән билгеләнүен ачыклый. Шактый катлаулы һәм кыен эш бу!

1941 елның ноябрендә Мәскәүгә ыргылучы фашист-илбасарларына каршы көрәштә совет сугышчылары аеруча зур

[1] Самат Шакир. Үлемне җиңгән батыр. Казан, 1978.

батырлыклар күрсәтә. 28 панфиловчының каһарманлыгы бөтен дөньяга билгеле. Бу дивизиядә күп төрле милләт уллары белән берлектә татар халкы уллары да нык һәм кыю сугышалар. С. Шакир архивларда озак эзләнеп, исән калган сугышчыларны табып, легендар Панфилов дивизиясе төзелгән һәм сугышкан урыннарга барып, материаллар җыйный һәм «Үлемсезләр» дигән китап яза. Моңа тагын 28 панфиловчы-геройны тәрбияләгән полк комиссары Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров батырлыклары турында «Полк комиссары» дигән очеркны да өстәргә кирәк. Ул рус, татар, башкорт һ. б. телләрдә басылып чыкты.

Данлыклы Сталинград сугышларында илебезнең бәйсезлеге өчен көрәшеп һәлак булган өч баһадир: испан егете капитан Рубен Ибаррури Руис, очучы рус егете майор Владимир Каменщиков һәм татар егете артиллерист-капитан Хафиз Фәттахетдинов турында язылган «Легенда егетләре» повесте — С. Шакирның зур уңышы. Әсәрдән өзекләр рус, башкорт, чуваш, мари телләрендә басыла һәм уңай бәяләнә.

Язучы үзенең геройларын эзләп илебезнең әле бер почмагына, әле икенче чигенә барып чыга, дәһшәтле бәрелешләр булган урыннарын карый, анда каһарманлык күрсәткән батырларга дан җырлый. Мәсәлән, латыш җирендә дошман тылына үтеп кереп, ике тәүлек буена искиткеч чыдам, кыю сугышкан, өч-дүрт мәртәбә яралануга да карамастан, атышуны дәвам иткән ун батыр егетнең кемнәр икәнен белү өчен язучы шактый юллар урый. Бу ун батыр — сигез милләт улы — соңгы сулышларын алганда да Ватан-анага тугрылыклы калалар. Кечкенә отрядның командиры башкорт Хәкимҗан Әхмәтгалин була. Иң элек язучы аның семьясын эзләп таба, сугышчының фронттан язган хатларын укый. Аннары татар егете Якуб Шәкүровның семьясын эзләп, Омск шәһәренә юнәлә, таҗик Чутан Уразов эзләреннән Таҗикстанның Гиссар районына юл тота, украин Петро Сырожкин, кара-калпак Орынбай Абдуллаев, чуваш Федор Ашмаров һәм башкаларның туган җирләренә сәфәр чыга. Нәтиҗәдә шул ун Советлар Союзы Герое турында «Һәйкәлдә чәчәкләр» дигән әсәр туа. Бу әсәр «Казан утлары» журналында, аның өзекләре русча, башкортча, таҗикча, үзбәкчә, чувашча басыла. Хәрби-патриотик темага язылган «Утлы өермә», «Ташлардагы язулар», «Алиш» һ. б. китаплары язучының диапазоны шактый киң булуын, әдипнең тынгысызлыгын күрсәтәләр. Тәнкыйтьче Хәсән Хәйри Самат Шакир иҗаты хакында болай дип язган иде: «Ватан сугышы геройлары турында озак эзләнеп язган очерклары һәм шигъри әсәрләре, минемчә, аңа аеруча зур популярлык китерде һәм ул нәкъ шул әсәрләре белән үзенең иҗат йөзен, мөмкинлекләрен күрсәтә алды. Сталинград батырлары, геройшагыйрь Х. Мөҗәй һәм башкалар турындагы хезмәтләре, китаплары, очерклары, һич тә арттырмыйча әйтергә мөмкин, үзе бер батырлык, иҗади ачыш! Аның хәзер дә зур активлык белән дәвам иткән бу эшчәнлеге әдәбият өчен генә түгел, гомумән, тарихыбыз өчен дә онытылмаслык хезмәт булып тора һәм булачак».

«Үлемне җиңгән батыр» дигән китабын укыганнан соң мин озак уйланып утырдым. Китапта язылганнар барысы да дөрес, документаль, ә геройлары — исән кешеләр һәм, Ватаныбызны саклап, яу кырында ятып калганнар. Шуларның каһарманлыгын сурәтләү язучыдан зур эшчәнлек һәм осталык таләп итә. Әдип андый осталыкка ирешкән дияр идем мин.

Арыслан йөрәкле солдатларыбызның берсе — «Үлемне җиңгән батыр» әсәренең герое Гомәр Гыймадетдинов. Ул Украинаның Хмельницкий шәһәрен фашистлардан азат итүдә зур батырлыгы белән күзгә ташлана — өч-дүрт мәртәбә яралана, ә соңыннан немецлар аңа автоматтан төзәп аталар... Ут Гомәрнең яңагына һәм иягенә тия. Фашистлар аны үлде дип уйлый, әмма Гомәр ниндидер могҗиза белән исән кала. Егетне ярым үлек хәлендә өч кечкенә бала күреп ала да якын авылның биш-алты хатын-кызы сугышчыны үлемнән коткарып кала. Берникадәр дәваланганнан соң госпитальгә озаталар. Отряд җитәкчесе Гыймадетдинов үзенең һәм сугышчыларының документларын җыйнап, батырларча һәлак булулары турында белешмә язып, окоп читенә күмгән була. Менә шул документларны еллар узгач кызыл эзтабарлар табып ала һәм мәктәп музеена куялар. Соңыннан мәктәп ишегалдында каһарманнар истәлегенә һәйкәл куела һәм анда иң беренче итеп Гомәр Гыймадетдинов исеме языла. Кызыл эзтабарлар егерме елдан соң Совет Армиясе архивыннан Г. Гыймадетдиновның туган җире күрсәтелгән документ табалар, аның әтисе Баһау абзыйга: «Улыгызның кабере безнең

мәктәп ишегалдында, карарга килегез»,— дип хат язалар. Гомәр Гыймадетдинов хатны укып, озак уйланып тора, күзләре яшьләнә, авыр, кан коюлы сугыш картиналарын хәтерли... Аннары ул балаларга җавап яза. Хмельницкий шәһәре хезмәт ияләре, укучы балалар чакыруы буенча барып, Г. Гыймадетдинов үзенең һәм коралдашларының һәйкәленә тере чәчәкләр куя. Аны Хмельницкий шәһәренең почетлы гражданины итеп сайлыйлар.

Унсигез язма тупланган бу китап зур кызыксыну һәм дулкынлану белән укыла. Азин дивизиясе сугышчысы Хәкимулла Шаһиморатов, Кушка һәм Бохара фронтында басмачыларга каршы көрәшкән һәм 21 яшендә Сугышчан Кызыл Байрак ордены алган Мөкаррәм Каһарманов, Каракюм чүлендә инглизләргә һәм басмачыларга каршы көрәшкән Шәриф Әхмәдиев, Бөек Ватан сугышында Суворов ордены алуга лаек булган полковник Гали Йосыпов, «Кече җир» батыры Әгъләм Шәрәфиев, ике үлемне җиңгән Рой Гатауллин, Берлинны бомбага тотуда катнашкан Иркен Имамов, фашизм оясындагы империя канцеляриясен штурмлаучы подполковник Исхак Гомәров, разведчик Насырьян Гайнуллин һәм башкалар турындагы әсәрләр, безнеңчә, аеруча уңышлы яңгырый.

С. Шакирның рейхстагка беренчеләрдән булып Җиңү байрагы элгән татар егете Гази Заһитов турында повесте, патриот-шагыйрь Муса Җәлил белән очрашкан, 1941 елның август аенда ук Берлинны өч мәртәбә бомбага тоткан полковник Гали Борһанов, легендар Азинның ординарецы Якуб Әбдерәшитов, Фурмановның дусты, аны фетнә вакытында үлемнән алып калган хәрби комиссар Бари Шаһабетдинов, 1936—37 елларда үзе теләп Испаниягә киткән һәм немец-итальян фашистларына каршы көрәшкән очучы, Бөек Ватан сугышында һава армиясенең баш штурманы булган генерал Мөхәррәм Галимов, Франциядә немец илбасарларына каршы көрәшкән партизан Мидхәт Гайсин турында язган очерклары газета-журнал битләрендә басылдылар, җәмәгатьчелекнең уңай бәясен алдылар. Шушы әсәрләре, «Үлемне җиңгән батыр» китабы өчен мин аңа Муса Җәлил премиясе бирергә кирәк дип уйлыйм.

**ФАТИХ БУЛАТОВ,**
**отставкадагы генерал-майор.**

**М. Әхмәтҗанов,**
**М. Гайнетдинов**

# ЛӘЙЛӘ БЕЛӘН МӘҖНҮН КЫЙССАСЫНЫҢ ТАТАРЧА ВАРИАНТЫ

Ләйлә белән Мәҗнүннең романтик мәхәббәте хакындагы хикәя урта гасырларда көнчыгышның күп шагыйрьләрен илһамландырган. Хәзерге татар укучысы бу сюжетка язылган әсәрләрдән әзербәйҗан шагыйре Низами Ганҗәвинең (1141—1203) өлкән әдибебез М. Максуд тарафыннан 1948 елда тәрҗемә итеп бастырылган «Ләйлә белән Мәҗнүн» поэмасы аша таныш. Бу популяр сюжет татар әдәбиятында төрле чорларда күп мәртәбә кабат-кабат мәйданга чыккан. Мәсәлән, Өмбә мулласы Габделгафур Динмөхәммәт углының XIX йөздә шигырь белән «Ләйли-Мәҗнүн» дигән әсәр язганлыгы билгеле [1]. Ф. Халидинең 1902 елда басылган «Мәшһүр гашыйк — мәгъшук Ләйли илә Мәҗнүн хикәясе», Г. Г. Рәшиди (Чартуши)нең 1917 елда чыккан шигъри «Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе» нәкъ шул хакта сөйлиләр. ТАССРның Арча районы Түбән Көек авылыннан 1973 елда табылган кульъязмада Ләйлә белән Мәҗнүн хикәясе саклану, бу дастанның татар әдәбиятында XVIII йөздә дә яшәгәнлеген күрсәтте.

Кульъязма, язу стиленә караганда, XVIII гасыр ахырларында төзелгән. Истәлекнең бер битендә Ишнияз бине Ширнияз исеме телгә алыну да аның XVIII гасырның икенче яртысында төзелгәнлегенә бер дәлил булып тора.

Ишнияз бине Ширнияз Харәзем якларыннан килеп Казаклар һәм Каргалы мәдрәсәләрендә дәрес әйткән [2]. Кульъязма табылган Түбән Көек авылыннан ерак булмаган Казаклар авылы ул укыткан авыл булса кирәк. Кайбер хәбәрләргә караганда Ишнияз бине Ширнияз Кышкарда да укыткан булган. Бу галим 1776 елдан башлап Оренбург Каргалысында укыта башлаган һәм шунда 1791 елда вафат булган [3].

Кулыбызга төшкән кульъязма бу галимнең үзенеке яисә ул укыткан берәр шәкертнеке булгандыр, күрәсең. Ул тулы түгел, бары өч биттән тора. Шул өч кәгазьдә Ләйлә-Мәҗнүн дастаныннан башка ике тулы һәм биш тулы булмаган хикәя сакланган. Аларның эчтәлеге белән танышу китапның яшьләргә тәрбия максатыннан чыгып төзелгән дәреслек булу ихтималын күрсәтә. Тел җәһәтеннән караганда ул татар әдәби телендә язылган. Тел, стиль, композиция һ. б. үзенчәлекләрен күрсәтер өчен, кульъязмадагы Ләйлә-Мәҗнүн хикәясен күчереп үтәбез.

---

[1] Хөсәен Әмирхан. Тәварихе Болгария. 1883, 47 бит. Өмбә хәзерге ТАССР, Биектау районында.
[2] Ш. Мәрҗани. Мостафадел әхбар. 2 том. Казан, 1900, 216 бит.
[3] К. Насыйри. 1878 ел календаре. 30—31 битләр.

## Ләйлә белән Мәҗнүн

Хикәят. Кадим[1] заманда Зәед дигән остазның ике шәкерте бар иде. Бере кыз иде. Аның аты Ләйлә иде. Бере егет иде. Аның аты Мәҗнүн иде. Соңра бу Ләйлә илә Мәҗнүн балигъ улдылар. Һәр икесе бигаят[2] күркәм иделәр. Бәгъде, Ләйлә Мәҗнүнгә гашыйк улды. Шул кадәр кем, бикарар[3] улды, әмма Мәҗнүннең күңеле төшмәс ирде. Бу Ләйлә бу кадәр зиннәт[4] илә Мәҗнүннең алдындыйн үтәр ирде. Мәҗнүн аңар карамас иде. Соңра Ләйлә гаҗиз улып, мөзәйинә[5] варды иде. Әйде: «И, мөзәйин, бәне[6] зиннәтләгел, шул кадәр кем, бәнем кеби — җиһанда улмасын», — диде. Бундыйн соң бу мөзәйин ул кадәр зиннәтләде, күргән кемсәнә хәйран улды. Бу зиннәт илә Ләйлә кайтып бер иске ивгә керде. Муйнина йеп тагып, аллаһе табарәкә вә тәгаләгә ялварды, еглады: «Ярабби, бу зиннәтне бәндин китәрмәгел»[7], — диде. Таң улды. Торып, карады, әмма зиннәтләре китмәде. Шат улып догалар кылды. Соңра киенеп, зиннәтләнеп тә кем хушбуйланып, Мәҗнүннең хозурындыйн[8] үтте. Мәҗнүн күзенең бер кыйрыкы[9] илән каракан ирде, мең җан илә гашыйк улды. Шулкадәр, әгәр янына барсаң, сулаган сулуындыйн, — Ләйлә, — дигән аваз килер ирде. Акрынлык илә янына варды. Соңра Мәҗнүн бикарар улып сахрайа[10] чыкты. Ләйлә күрде, Мәҗнүн урынында юк. Шул заман бер кешесене йибәреп караттый. Тапмады. Кайтып әйтте: «Тапмадым», — дип. Ләйлә аһ ордый. Кинә йибәрди: «Сахрага бар, эзләп тапкыл», дию. Бу кемсәнә сахрада йөреде. Мәҗнүнни тапдый. Күрди кем, бер йирә[11] яткан, күзен йомган. Аһ-ваһ илә: «Ләйлә!» — дию чакрып, күккә бакып ятыр. Кайтып Ләйләгә хәбәр бирди: «Шул йирдә, шул хәл илә ятадыр», — диди. Ләйлә буны ишедеп, чагырып, йөгереп-йөгереп, чыгып сахрайа бардый. Мәҗнүнне күрди, аһ орып ятыр. Барып, пәрдәсене Мәҗнүн өстенә күеп күләгә ясадый вә әйди: «И, Мәҗнүн, мәгъшукаң—бән кәлдем», — дию. Мәҗнүн күзене ачтый. «И җаным, сән-бәнем, күңелемгә сәнең мәхәббәтеңдин гайри нәрсә сыйгмайдыр, сән киткел», — диде вә кулын болгады. Ләйлә мең хәсрәт илә еглаю кири кайттый, ивгә керди, вафат улдый, хак тәгаләгә җаныны тәслим кыйлдый. Бу Мәҗнүн ивенә кайтып керәчәк заман сорый: «Каный Ләйлә?» — дию. Әйделәр: «Ләйлә вафат улдый», — диделәр. Андыйн соң Мәҗнүн егламак илә чыкып каберләр өстинә менди. Барып йитдектә бер кызчыгазга уградый. Андыйн сурдый: «Әй, кызчыгаз, каный Ләйләнең кабери? Бәңа күргүзгел», — тиди. Ул кыз әйди: «Мән гашыйкман дию дәгъва кылырсән, хакыкый мәгъшук улсаң, Ләйләнең кабрене белер ирдең», — дию әйди. Бу Мәҗнүн моны ишедеп каберләр арасына варып борынын куеп искәди. Йөри торгач, бер кабердин Ләйләнең исе кәлди, борнина керди. Шул заман, искәде ирсә, вафат булдый. Ләйләнең кабере ярылып, бу — кабрә инди.

Бундыйн соң остазларый Зәед төш күрди. Шийлә бер олуг бостан. Ул бостан эчендә һәр әнваг[12] агачлар вә йимешләр туп-тулу торыр. Бу бостанның бер тарафында...

* * *

Хикәятләрнең үзенчәлекләренә караганда алар — дидактик әсәрләр җыентыгы, яки уку китабының аерым битләрен тәшкил итәләр кебек. Шунысы кызыклы, элеккеге гасырларда да («Нәсихәт әс-салихин» һ. б.) һәм XIX йөздә дә тәрбия китапларында («Фәзаил эш шөһүр», «Тәрбияле бала», «Шәкертлек әдәбе» һ. б.) тәрбияви хикәятләр озын-озын дидактика-үгет, өйрәтүләр арасында биреләләр. Шундый нәсихәт җыентыкларында Түбән Көек кулъязмасы хикәятләрен хәтерләткән бик күп материаллар сакланып калган. Ә бу яңа табылган кулъязмада исә ул хикәятләр нәсихәт сүзләре белән бүлгәләнмәстән генә бирелә. Димәк, үткән заманнарда ул хикәятләр аерым хрестоматия рәвешендә дә яшәгәннәр. Бүген күп санлы кулъязмаларга чәчелеп калган андый хикәятләрнең дөньяви һәм әдәби мотивларга язылганнарын барлау, җыю, үткән чорлар әдәбиятының кайбер үзенчәлекләрен өйрәнүгә шактый материал бирә алыр иде.

---

[1] Кадим — борынгы, иске.
[2] Бигаят — чиксез.
[3] Бикарар — чарасыз, гаҗиз.
[4] Зиннәт — бизәнү.
[5] Мөзәйинә — косметик врачка.
[6] Бәне — мине.
[7] Китәрмәгел — җибәрмә, алма.
[8] Хозурындыйн — каршыннан.
[9] Кыйрыкы — кырые.
[10] Сахрайа — сахрага.
[11] Йире — җиргә.
[12] Әнваг — төр.

# ПРОФЕССОР ТАҺИРОВ

*(1903—1977)*



Тарихчы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, Ватан сугышы ветераны, Татарстан китап палатасына нигез салучы профессор Рифгать Шакирҗан улы Таһировның тууына 75 ел тулып узды. Ул 1903 елда Казанда укытучы Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһиров семьясында туа. Аның әтисе Октябрьга кадәрге чорда халык мәгарифен прогрессив юлга кую, татар халкына аң-белем бирү өлкәсендә күп эшли, татар язуын реформалаштыруга зур өлеш кертә, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр төзи.

1923—1928 елларда Казандагы Көнчыгыш педагогия институтында укый.

Студентлык елларында ук Р. Ш. Таһиров җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Пролетар студентларының Татарстан өлкә бюросының җитәкчесе, РСФСР халык мәгарифенең Татарстан югары уку йортлары һәм техникумнары буенча җаваплы секретаре, Татарстан халык мәгарифе коллегиясе секретаре, Мулланур Вахитов исемендәге Үзәк көнчыгыш китапханә-музейда Көнбатыш Европа әдәбияты бүлеге мөдире вазифаларын үти. Шул ук елларда ул профессор В. Ф. Смолин җитәкчелегендәге археологик экспедицияләрдә катнаша, «Татарстан республикасында 1917—1918 елларда революцион хәрәкәт хроникасы» дигән мәкаләсе белән чыгыш ясый.

ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Ленин институты кушуы буенча ул Ленинның Казандагы тормышы турында архив материаллары эзләп таба һәм «Красная Татария» газетасының 1930 ел, 15 май санында «В. И. Ленин Казан университетында (Казан университеты материаллары буенча)» дигән мәкалә бастырып чыгара. Бу мәкалә «Студент Татарстана» (1930 ел, 15 май) һәм «Кызыл Татарстан» (1930 ел, 14 май) газеталарында да басыла.

1924 елда аның «Китапханәләрдә сәяси мәгариф эш» дип исемләнгән тәүге китабы дөнья күрә. Шул ук елда ул РСФСР китапханәчеләре съездына Татарстаннан делегат итеп сайлана.

1925 елда Татарстан Совнаркомы Р. Ш. Таһировның «Казанда Татарстан үзәк китап палатасы оештырырга кирәк» дигән тәкъдимен кабул итә. Һәм бу эшкә беренчеләрдән булып ул үзе керешә. Татарстан үзәк китап палатасы 1925 елда Р. Ш. Таһиров инициативасы белән оештырылып, бүгенгә кадәр үзенең эшен дәвам иттерә.

Р. Ш. Таһиров библиография эшен үстерүгә керткән өлеше өчен Мәскәү университеты каршындагы рус библиография җәмгыятенең действительный члены

итеп сайлана. 1926 елда Бакуда булып үткән Беренче Бөтенсоюз тюркологлары съездында катнаша.

1930 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының гомуми тарих кафедрасына эшкә чакырыла.

1928 елда Татарстан Совнаркомы карары буенча Р. Ш. Таһиров «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте»нең җитәкчеләреннән берсе итеп билгеләнә. Шушы җәмгыятьтә эшләве нигезендә ул Татарстан тарихы һәм СССР тарихы буенча фәнни мәкаләләр яза. Шулардан «Татарстандагы крестьяннар хәрәкәте тарихыннан (1917 ел)», «Галимҗан Сәйфетдинов биографиясеннән» дигән мәкаләләрен күрсәтеп үтәргә була.

30 нчы елларда Р. Ш. Таһиров Көнчыгыш педагогия институты каршындагы рус педагогия җәмгыяте члены, Татар мәдәнияте йорты каршындагы татар педагогия җәмгыяте члены, Татарстанны өйрәнү җәмгыяте члены, Чувашияне өйрәнү җәмгыяте члены, Казан дәүләт университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте члены, Мәскәү университеты каршындагы рус библиография җәмгыяте члены. Ул педагогия-методика һәм библиографиягә караган күп санлы фәнни хезмәтләр дә яза.

Сугышка кадәр чордагы тормышы турында ул үзе болай дип искә ала: «Минем яшьлек Ватаныбызның революцион үзгәрешләр кичергән чорына туры килде. Без ул вакытта гомуми революцион күтәрелеш шартларында эшли идек. Ул вакыттагы мәдәни хәрәкәтнең иң алдынгы сафларында торып, без фәнни-тикшеренү эшләрен, мәктәпләрдә уку-укыту процессын, мәктәптән тыш эшләрне, совет учреждениеләренең, китапханәләрнең сәяси-мәдәният эшләрен оештыруда актив катнаша идек. Ул вакытта безне үзенә җәлеп итмәгән, безне кызыксындырмаган бер генә эш тә юк иде. Ул вакыт безнең шәхси интересларыбыз да юк иде төсле. Барысы да җәмгыять өчен, барысы да җәмгыять интересларына буйсындырылган иде».

1942 елның 25 июненнән 1945 елның апреленәчә Рифгать Таһиров Сталинградтан Берлинга кадәр диярлек авыр сугыш юлы үтә. 1943 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. Соңрак полк һәм бригада штабларында парторг вазифасын үти.

Сугыштан соң ул Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казан дәүләт педагогия институтында эшли. Көнбатыш Европа илләре һәм Америка тарихын укыта, күп санлы фәнни мәкаләләр һәм берничә монография яза.

1953 елда Казан җәмәгатьчелеге Р. Ш. Таһировның тууына 50 ел һәм фәннипедагогик хезмәтенә 25 ел тулу уңае белән тантана үткәрә. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм «Халык мәгарифе отличнигы» дигән значок белән бүләкләнә.

Тарихчы профессор яшьтән үк татар әдәбияты белән кызыксынып килә. Татар әдәбияты буенча библиографияләр бастырып чыгара. Һ. Такташ, Г. Кутуй белән якыннан таныш була, тәнкыйтьче Г. Кашшаф һәм шагыйрь Сирин белән язышып тора. Аның архивында Г. Кашшафтан, Сириннан, Ә. Ерикәйдән, И. Кәлимуллиннан алынган хатлар, китаплар бар.

1968 елда Рифгать Таһировның «I Интернационал» буенча рус һәм совет историографиясе» дигән монографиясе дөнья күрә. Бу аның докторлык диссертациясенең 1 кисәге иде. Р. Ш. Таһировның бу хезмәте чит илдә (Венгриядә) һәм үзебезнең матбугатта зур бәя ала. Мәсәлән, «Вопросы истории КПСС» журналының 1970 ел, 8 нче санында болай дип язылган: «Р. Ш. Таһировның бу китабы I Интернационал проблематикасын өйрәнү өчен генә түгел, Россиядәге иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү өчен дә казаныш булып тора» (113 бит).

1956 елдан башлап ун ел буена ул Казандагы югары партия мәктәбендә һәм КПССның шәһәр комитеты каршындагы марксизм-ленинизм кичке университетында «Иң яңа тарих», «Халыкара мөнәсәбәтләр һәм СССРның тышкы политикасы тарихы» курсларын укытып килә.

Профессор Р. Ш. Таһиров гомеренең соңгы көннәренә кадәр актив җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм лектор буларак хезмәт итеп килде.

ОРКЫЯ ШАКИРОВА-ТАҺИРОВА.

# КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВКА 50 ЯШЬ



*Әдәбият-сәнгатьнең кайсы өлкәсенә аяк басма, ул синең тумыштан килә торган сәләтең, рухи кодрәтең өстенә, бөтен жаның-тәнең белән бирелеп иҗтиһад итүеңне, үзең сайлаган сәнгать төренең риясыз энтузиасты һәм карусыз хезмәтчесе, чын-чыннан иҗат каһарманы булуыңны таләп итә.*

*Әдәби-нәфис тәрҗемә өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтен каһарманлык белән тиңләү, беренче карашка, дан-шөһрәт җимешләрен үлчәмичә өләшеп, аларны сәнгатьләр сарае түренә менгереп утырту кебегрәк нәрсә булып тоелырга мөмкин. Чынлыкта эш башкачарак тора. Беренче тәрҗемәче — профессионаллар шушы өлкәгә килгәндә үк инде түрдән урын алу, шөһрәт казану түгел, әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнгән килеш хәтта әдип булып танылуның да ни дәрәҗәдә четерекле нәрсә икәнлеген белеп килгәннәр. Тәрҗемәче эш процессында оригиналь әсәр авторы белән бергә бер үк уй-хисләр һәм иҗат ялкыны белән янса да, күңеленә сеңдергән һәр образ, һәр күренешнең үз телендәге сурәт-билгеләрен эзләп иҗат газаплары кичерсә дә, аның үз шәхесе һәрчак диярлек автор күләгәсендә кала. Әмма ул иҗат дәртеннән, талант һәм нечкә зәвыктан, әдәбиятка фидакарь мәхәббәттән һич мәхрүм түгел.*

*Яхъя Халитов, Рәис Даутов, Таһир Нурмөхәммәтов кебек тәрҗемәчеләребез соңгы ун-унбиш ел эчендә рус классик әдәбияты һәм совет әдәбияты җәүһәрләре тәрҗемәләрен зур сәнгать таләпләренә җавап бирерлек итеп башкарып чыгулары белән татар телендәге тәрҗемә әдәбиятын яңа үрләргә күтәрделәр. Мондый казанышлар реалистик татар совет тәрҗемә мәктәбенең ныклап аякка басуы турында сөйли.*

*Менә шушы мәктәпне үстерү, аны иҗади тәҗрибә җимешләре белән баетуда Кыям Миңлебаевның эшчәнлеге дә күренекле урын били.*

*Беркем дә, тәрҗемәче булып тумаган кебек, сиздермәстән һәм кинәт кенә оста иҗатчы булып китми, билгеле. К. Миңлебаев та яшьлек елларында үк тезмә һәм чәчмә әсәрләр язып каләмен чарлый башлый, классик әдәбиятны, сәнгатьнең башка төрләрен тәфсилле өйрәнү-үзләштерү, белем-тәҗрибә туплау, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшләү дәвамында акрынлап аның күңелен дөнья һәм рус әдәбияты корифейларының атаклы әсәрләрен бөтен гүзәллеге, кабатланмас рухы, төс-бизәкләре белән татар укучысына җиткерү теләге биләп ала.*

*К. Миңлебаевка күптән түгел илле яшь тулды. Шуның яртысы диярлек әдәби тәрҗемә иҗатында үткән. Аның тәрҗемәсендә рус һәм совет авторларының егермеләп китабы дөнья күргән. Шулар арасында В. Шишковның мәшһүр «Хәсрәт дәрьясы» әсәренең тәрҗемәсе аерым урын алып тора.*

*Әмма тәрҗемә эшендә камил осталык тау өярлек хезмәт һәм тәҗрибә аша гына килә икән. К. Миңлебаев тәрҗемәсендә бөтен совет әдәбияты горурлыгы*

*булган «Хождение по мукам» трилогиясен укыганнан соң әлеге фикер тагын да ныгый төшә. Татар укучылары шушы тәрҗемә аша да бөек художник А. Толстойның иҗат дөньясын рәхәтләнеп гизә, гомерлек рухи хәзинә итеп үзләштерә алырлар дип әйтә алабыз. Димәк, Кыям Миңлебаевның киләчәктә дә мондый иҗади җиңүләре аз булмаслыгына ышаныч бар диган сүз.*

*Бу санда хөрмәтле укучыларыбызга К. Миңлебаевның үз иҗат тәҗрибәсе, тәрҗемәче иҗаты хакындагы уйлануларыннан чыгып язылган «Тәрҗемә үрләре» исемле мәкаләсе кыскартып тәкъдим ителә.*

## Кыям Миңлебаев

# ТӘРҖЕМӘ ҮРЛӘРЕ

Илебездә милли культуралар үскәннән-үсә, халыклар бер-берсе белән көннән-көн ныграк аралаша. Һәр халыкның культура-әдәбият өлкәсендә ирешкән уңыш вә казанышларын башка халыкларга аңлау-күрсәтүдә тәрҗемәнең роле әйтеп бетергесез.

Хәзерге тәрҗемәчеләребез — сугыштан соңгы елларда югары белем алган, шул заманда поэзия вә прозаның киң колач белән үсеп китүенә чын күңелдән сөенгән һәм, киресенчә, тәрҗемә эшенең исә торышына җаны әрнегән, көенгән кешеләр. Көенмичә мөмкин түгел, чөнки ул дәвердә тәрҗемә эшенә җитәрлек әһәмият бирелми, әллә ни зур таләп куелмый, һәм тиешенчә хәзерлеге булмаган кешеләрнең теләсә нинди китапны алып, аны юньләп укып та чыкмаган килеш, әсәрнең идея эчтәлеген дә төшенеп бетмәгән, авторның стиль үзенчәлекләрен ныклап үзләштермәгән килеш, аннан-моннан гына, эштер-өштер генә аударып ташлау очраклары еш булгалый иде. Әдәбиятка яңа аяк басучы яшьләр әнә шул җөмләгә-җөмлә, сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф күчерелгән әсәрләрне өйрәнә-тикшерә торгач: «Юк, болай ярамый бит!» — дигән фикергә килделәр, ягъни әнә шул тәрҗемәләргә анализ ясау нәтиҗәсендә ничек тәрҗемә итмәскә икәнлегенә тәгаен ышандылар.

Бүгенге тәрҗемә мәктәбе һич тә буш урында барлыкка килмәде. Әлбәттә, яшьләр өчен өлге булырлык тәрҗемәләребез моңарчы да бар иде инде.

Әдәби тәрҗемә тарихында беренчеләр сафына без бүген, мәсәлән, Кәшфи Басыйровны куярга тиешбез. Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган бу язучының исеме бүген зур хөрмәт белән, олылап телгә алынырга хаклы. Аның тәрҗемә итәр өчен әйбер сайлавы гына да игътибарга лаек: ул Н. В. Гогольнең «Үле җаннар» поэмасын һәм М. Ю. Лермонтовның гүзәл әсәре «Безнең заман герое» романын тәрҗемә итеп калдырган. Бу язучының тәрҗемәдә гаҗәеп оста кулланган шагыйрәнә алымнарына, оригиналдагы бөтен байлыкны төкми-чәчми, һәр ике бөек әдипнең стиль үзенчәлекләрен төп-төгәл, җырлап торырдай итеп гәүдәләндерә алуына бүгенге көндә дә хәйран каласың. Бөек пролетар язучысы М. Горькийның иҗаты белән безнең укучыларыбыз Сәрвәр Әдһәмова, Ибраһим Гази тәрҗемә иткән әсәрләрне укып таныштылар. Классикларны тәрҗемә итүдә Сәгыйть Фәйзуллинның күрсәткән хезмәте дә игътибарга лаек. Шул ук вакытта аның теоретик хезмәтләрен дә, бүгенге тәрҗемәчеләребезнең остазы булуын да һич онытырга ярамый. Язучы Афзал Шамов — тәрҗемә өлкәсендә күп эшләгән кеше. Әмма аның арада бер яраткан хезмәте бар, ул да булса — «Капитан кызы». А. С. Пушкинның шушы гүзәл әсәре тәрҗемәсен ул әле бүгенге көндә дә камилләштерү өстендә эшли.

Урта буын язучылары да бу өлкәдә көчләрен сыный торалар. Үзләренең күңелләренә ошаган, яратып укый торган әсәрләрне тәрҗемә итү, һичшиксез, уңай

нәтиҗә бирә ,язучыларыбызның колачын киңәйтеп, иҗади фантазиясен көчәйтеп җибәрә. Әйтик, Гариф Ахунов психологик картиналарны тасвирлау осталыгына М. Шолоховтан өйрәнсә, Нурихан Фәттах сюжетны мавыктыргыч итеп корырга бөек француз язучылары Виктор Гюго белән Оноре де Бальзактан өйрәнә. Авторның фикер агышы, тасвирлау манерасы тәрҗемә итәргә алынган язучының табигатенә туры килгән, телгә мөнәсәбәтләре якын булган очракта, һичшиксез, тәрҗемә дә уңышлы чыга.

Бүгенге көндә заман таләбенә тулысынча җавап бирә алырдай тәрҗемәләрне нигездә урта буын вәкилләре башкара. Бу иптәшләрне профессиональ тәрҗемәчеләр дип атарга туры килә, чөнки аларның һәркайсы билгеле бер дәрәҗәдә әдәби сәләткә һәм югары белемгә ия булу белән генә чикләнеп калмыйча, тәрҗемәнең теориясен ныклап өйрәнде һәм төрле тәрҗемә ысулларын бизмәнгә салып караган, күп төрле четерекле мәсьәләләргә тәмам төшенеп җиткәннән соң гына иҗат юлына басты, ягъни ирекле тәрҗемә итүдәй җиңел кәсепкә дә кызыкмады, шулай ук әсәрнең сүзен-сүзгә, җөмләсен-җөмләгә әйләндереп чыгу мөмкинлегенә дә алданмады, бәлки үз алдына таңгәл тәрҗемә бирүне максат итеп куйды. Бу юл, бердәнбер иҗат юлы буларак, тәрҗемәчедән көчен кызганмыйча, ару-талуны белмичә эшләүне, әдипләрдән әдәби осталыкка өйрәнүне, стиль өстендә чокчынуны, әсәр мөмкин кадәр татарчарак яңгырасын өчен төрле вариантлар, яңадан-яңа синонимнар эзләүне, камилләшүгә омтылуны таләп итә.

Нәрсә тәрҗемә итәргә? Ничек тәрҗемә итәргә? Фәкать үзең тулысынча ошаткан китапны гына, фәкать күңелеңә хуш килердәй әсәрне, үзең мөкиббән китеп укырдай язучыны гына тәрҗемә итү эшенә алынырга һәм бөтен көчеңне-җегәреңне шуңа салырга кирәк. Тәрҗемә эше, әдәбиятның башка тармаклары шикелле үк, зур сәләт булуын да, иксез-чиксез көч сарыф итүне дә сорый.

Тәрҗемәдә хәзер ничек тә, моңарчы күп кулланылып, таушалып беткән сүзләрдән һәм сүз тезмәләреннән, гомумән күп сүзлелектән качу-котылу ягын карыйлар, кат-кат эшлиләр, әсәр җиңелрәк укылсын, табигыйрак яңгырасын өчен тырышалар һәм шуның белән әдәби телебезне баетуга үзләреннән өлеш кертәләр.

Мөхтәрәм язучыбыз Фатих ага Хөсни шулай бервакыт прозаны ничек итеп шигъри дәрәҗәгә, сәнгать дәрәҗәсенә җиткерүенең серен чиште: «Кул белән генә түгел, колак белән язарга кирәк, кычкырып укый-укый язарга кирәк, нәкъ менә шунда музыкасы килеп чыга. Сүзләрнең бер-берсенә яңгыраш ягыннан охшамавы, сүздәге хәрефләрнең урынлымы әллә урынсызмы куелган булуы кычкырып укыганда гына тотыла...»

Бу таләп тәрҗемәчеләргә дә бик нык кагыла.

Тәрҗемәче алдына куелган бурычларның да иң нечкәсе, четереклесе — ул да булса авторның стиленә төшенеп җитү, әсәрнең язылу манерасын, көен тоя белү, шуннан соң инде, авторга тирән хөрмәт саклаган хәлендә, ул тасвирлаган картиналарны түкми-чәчми генә үз телендә гәүдәләндерү, әсәрнең тел байлыгын, эмоциональ куәтен, бизәкләрен үз җирлегеңә күчереп утырту. Тәрҗемәченең иҗади йөзен нәкъ әнә шундый оста алымнар, нәкъ әнә шундый киң колачлылык билгели.

Тәрҗемәнең алгы сызыгында кемнәр бар соң? Классик әдәбиятны бүген кемнәр тәрҗемә итә соң?

Иң әүвәл атаклы рус язучысы А. И. Купринның «Атышу» романын, шулай ук повесть вә хикәяләрен нәкъ татарча язылган әсәрләр дәрәҗәсенә җиткереп халкыбызга бүләк иткән Раис Даутов исемен әйтер идем. Тәрҗемә иткәндә гомумән һәркем диалогларны бирә алмыйча азаплана, шулар белән чиләнә. Раис менә шул иң читен эштә дә гаҗәеп уңышка ирешә: Купринның геройлары саф татарча сөйләшәләр һәм шул ук вакытта һәркайсына хас үзенчәлекле индивидуаль сыйфатларын да югалтмыйлар. Р. Даутов тәрҗемә иткән әсәрләрдән яңа Ф. М. Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» дигән әсәрен телгә алырга кирәк. Рус әдәбиятында иң авыр, иң катлаулы романнардан саналган шушы китаптагы психологик төеннәрне тәрҗемәчебез укучыга аңлаешлы итеп чишә һәм һәр сурәт-күренешне тәгаен үз телебездә аермачык тасвирлап чыга. Хәзер Р. Даутов Америка язучысы О. Генри әсәрләрен тәрҗемә итү өстендә эшли.

Икенче бер югары культуралы тәрҗемәчебез Яхъя Халитов төрле халык вәкилләре белән «кул биреп сөйләшә», ягъни литва язучысы В. Лацисны, кыргыз язучысы

Ч. Айтматовны, рус язучысы М. Шолоховны, Америка язучысы М. Ридны, Бельгия язучысы Шарль де Костерны татар укучылары нәкъ әнә Я. Халитовның тырышлыгы белән үз ана телебездә уку бәхетенә иреште. Классик әдәбиятны тәрҗемә итүдә зур хезмәт куйган бу каләм иясе бүгенге көндә күренекле француз язучысы А. Дюманың «Өч мушкетер» дигән мәшһүр романы тәрҗемәсен эшләп бетерде. Укучыларга бу зур бүләк булачак.

Болардан башка әле тагын Таһир Нурмөхәммәтов, Саимә Ибраһимова, Фәния Гайнанова кебек тәрҗемәчеләребезнең соңгы елларда башкарган эшләре хакында да иркенләп сөйләп булыр иде. Фәния Гайнанова, мәсәлән, әлерәк кенә рус әдәбияты классигы И. А. Гончаровның «Гыйбрәтле язмыш» романын тәрҗемә итеп бетерде. Гәрчә аның тәрҗемәләре күп булса да, моңарчы классик әдәбиятта үзенең көчен сынап карау ысулында И. С. Тургеневның «Язгы сулар» дигән повестен гына тәрҗемә иткән иде. Һәм аның тәрҗемәсенә тел-теш тидерерлек булмады.

Шул ук китапка кергән «Ася» һәм «Беренче мәхәббәт» повестьларын исә Вакыйф Зыятдинов тәрҗемә итте. Н. Г. Чернышевский бик тә яраткан, ә инде Н. А. Некрасов үзенең соклануын «саф алтыннан коелган шигърият лабаса» дип белдергән «Ася» повестен икенче бер телгә тәрҗемә итү зур кыюлык сорый.

Тәрҗемәләр җиңел укыла, повестьларның өчесенең дә гүзәллеге, шигъри аһәңе оста бирелгән дип әйтәсе килә.

Классик әдәбиятны татарчага тәрҗемә итү үрнәкләреннән иң яңасы, китап булып 1978 елда гына басылып чыкканы — И. С. Тургеневның «Аучы язмалары».

Аны укыганда ничәмә-ничә чакрымнарга сузылган сихри урманны да, басу-тугайны да, елга буйларын да, шул табигать кочагында яшәүче «затлы урман кәртлекләре», йомшак мамыклы үрдәкләр, җитез кыр тавыкларының да хәтсез күп икәнлеген күз алдыңа китерәсең... Һәм нинди сокландыргыч, камил итеп эшләнгән образлар галереясе: монда алпавытның ниндие генә юк та, крестьянның ниндиләре юк! Әмма иң нык эшләнгән, типлар дәрәҗәсенә җиткерелгән образлары — ике арадагы кешеләр, байга эт кебек турылыклы, алпавыт малын күз карасыдай саклаучы бурмистр, конторчы, урман каравылчысы һ. б. арадашчылар.

«Аучы язмалары» тәрҗемәсендә дә Вакыйф Зыятдинов хикәяләрнең татар телендә күңелгә ятышлы табигый яңгырашын бирүгә ирешкән. Ә бит рус әдәбиятында аеруча зур ихтирамга лаек булган, Н. А. Некрасов сүзләре белән әйткәндә, Пушкинннан кала иң зур шагыйрь И. С. Тургеневның теле искиткеч бай, мул бизәкле, тәрҗемә өчен бик тә авыр, катлаулы.

Вакыйф Зыятдинов сүзләрнең музыкасын тоя-сиземли: әүвәл теге яки бу төшенчәнең гадирәк әйтелешен алып, катлаулырагын, баерагын азактан китерә һәм һәр хикәянең матур агылышын бирә.

Язучының стиль үзенчәлекләре дигәндә, аның ни рәвешле язуына, нинди җөмләләр төзүенә, тел байлыгына һичшиксез әһәмият бирү белән бергә, юл арасына салынган мәгънәсен дә күздән ычкындырмаска кирәк. «Аучы язмалары» исә бу яктан алганда бигрәк тә үзенчәлекле урын алып тора. Әдип үзенең әйтергә теләгәнен турыдан-туры язарга кыенсына, шуңа күрә мәгънә төсмерләрен, эчке халәтне еш кына юл арасыннан, персонажларның тел төбеннән шәйләргә кала.

Әйтик, менә «Бурмистр» хикәясе.

Йомшак табигатьле булып күренергә тырышучы алпавыт аш-су остасы утырган арбаның күпердән чыкканда авып китүенә бик борчыла: тәгәрмәч астында калган остаиың «куллары исән» икәнлеген белгәч исә бик тиз тынычлана. Алпавытның авылга килеп керүе һәр җан иясе тарафыннан олуг афәт, гарасат буларак кабул ителә: сабый балалар тизрәк өйләренә кереп посалар... Алай гынамы соң! «Хәтта тавыклар да йөгерә-йөгерә капка асларыннан кереп качтылар...» Вакыйгалар әнә шулай бер-бер артлы җиңел вә табигый агыла. Арадашчылар исә байга тәлинкә тотарга күнегеп беткәннәр. Алпавыт Пеночкинның коляскасын күрүгә бөтен авыл дер калтырап төшкән иде; ә менә аның ялчысы — бурмистр Софрон, тегенең күзенә карап ялганлый: «...килеп чыгуыгыз белән авылыбызны ямьләндереп җибәрдегез...» — ди.

«Льгов» хикәясендәге Кузьма да алпавытка турыдан-туры тел-теш тидермәс: «Егерме яшьтә ничек өйрәнчек булмак кирәк?» — дигән сорауга ул:

«Баең теләгәч, буласың икән ул. Рәхмәт төшкере, тиз үлеп китте...» — дип җавап бирә.

«— Аш пешерергә кайда өйрәндең соң?

— Аңа өйрәнеп торалар димени? Хатыннар пешерә ич әле!..

— Гаиләң бармы? Өйләндеңме?

— Юк, атакай, өйләнмәдем, мәрхүмә Татьяна Васильевна — урыны оҗмахта булсын! — беребезгә дә өйләнергә рөхсәт итмәде...

— Нәрсә хисабына яшисең соң хәзер? Эш хакы аласыңмы?

— Нинди эш хакы ди ул, атакай... Ашарга бирелә, анысына да шөкер инде! Бик канәгать. Байбикәбезгә генә озын гомер бир, ходаем».

Карап торышка бернинди ризасызлык, бернинди киная дә юк шикелле. Тик инде персонажның шөкеранә кылуы чын күңелдән түгел икәнлеген һәм авторның да ниләр әйтергә теләвен укучы, әлбәттә, күреп тора.

Китапта диалогларның әнә шулай бирелеше телебездәге мөмкинлекләрнең иксез-чиксез икәнлеген исбатлый. Әмма шундый да бай телле, гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле һәм катлаулы, тәрҗемә өчен искиткеч авыр китапны татар теле җирлегенә оста гына күчереп чыккан тәрҗемәчебез ара-тирә сөртенгәләп тә куя. Китаптагы күңелне рәнҗетердәй җөмләләр, эзлеклелек сакланмаган урыннар, миңа калса, тиешле игътибар җитмәүдән, кайта-кайта укып тикшерергә вакыт тапмау аркасында килеп чыккан аянычлы хәл. «Я уже прежде по ее платью, телодвижениям и выговору, узнал в ней дворовую женщину — не бабу и не мещанку...», «Мин бая ук инде аның өс киеменә, үз-үзен тотышына карап, хатын да түгел, мещанка да түгел, ә хезмәтче икәнлеген шәйләп калган идем...» (22 бит, «Ермолай белән тегермәнче хатыны»). Уңышсызрак килеп чыккан. Биредә тәрҗемәчебез «не баба и не мещанка» дигәнне, ихтимал, төшендереп бирергә тиеш булгандыр: сала хатыны белән кала хатыны арасындагы бер кеше, яки: авылдан киткән, шәһәргә җитмәгән бер хатын, бер зат иде...

Татар телендә сингармонизм законнары хакимлек итә. Күренекле әдибебез Фатих ага Хәсни бу мәсьләдә болайрак фикер йөртә: сүзләрне бер җепкә тезгәндә, әлбәттә, аларның яңгырашына, музыкальлегенә игътибар итәргә кирәк, алай гынамы соң, хәтта әле җөмләләрнең бер-берсенә бәйләнеп китүен дә һич истән чыгарырга ярамый.

Әмма кайбер яшьрәк буын язучыларыбыз еш кына моңа игътибар итеп җиткермиләр, кирәкле синонимны эзләп азапланмыйча, беренче очраган сүзне язалар да куялар! Ә бит андый сүзләр җөмләдән, ватык клавишлар сыман, бүлтәеп чыгып торалар; кычкырып укый башласаң — без монда ялгыш кына килеп эләктек, дип колагыңны тондырып бетерәләр. Бу хәл татарча язылган әсәрләрдә дә, шулай ук тәрҗемә әсәрләрендә дә күренгәли. Вакыйф Зыятдинов сингармонизмга исә хилафлылык китерми, шуңа күрә аның тәрҗемәсен рәхәтләнеп укыйсың: «Ике-өч мәртәбә чәй дә эчеп алдым, берничә тапкыр йокларга да ятып карадым, тәрәзәләргә, стеналарга ябыштырылган язуларны да укып чыктым: эч пошудан тәмам зарыгып беттем» (195 бит). Монда сүзләр, җепкә тезелгән мәрҗәннәр кебек, үз урыннарына куелган, синонимнар дөрес сайланган.

Нәтиҗә итеп шуны әйтәсе килә. Рәхәтләнеп укыла торган, иҗади тәрҗемә бирә алган Вакыйф Зыятдинов — әдәбиятта яңа кеше түгел инде. Аның ярыйсы ук күләмле тәрҗемәләре бар: Н. Островскийның «Давылда туганнар», Вьетнам хикәяләре, Г. Тушканның «Җура», М. Максимовның «Камо» әсәрләре. Димәк, аның «Аучы язмалары»н тәрҗемә иткәндәге уңышлары һич тә очраклы хәл түгел: ул инде югары квалификацияле иҗат кешесе булып җитлеккән, аның осталыгына, тел байлыгына сокланырга була.

Гомәр Саттаров

# ИСЕМНӘРЕБЕЗ БАКЧАСЫНДА

Барлык төр ялгызлык исемнәре, мәгълүм булуынча, җәмгыять төзелеше һәм аның тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Совет властеның алтмыш еллы дәвамында татар теленең барлык тармаклары да киң колачлы, тирән һәм катлаулы үсеш процессын кичерде. Социалистик тормыш, яңарыш торак пунктлар (шәһәр, авыл, поселок һ. б.) топонимиясенә һәм антропонимиягә (бигрәк тә исем-фамилияләргә, псевдонимнарга) тәэсир ясамый калмады. Телебезнең ялгызлык исемнәре (ономастика) тармагында да яңа сыйфатлар барлыкка килде, үзгәрүүсү процессы барды һәм ул хәзер дә дәвам итә.

Башта шуны әйтеп үтәргә кирәк: һәрбер телнең ономастик лексикасына күмәклек исемнәренә караганда киңрәк дәрәҗәдә, зуррак күләмдә сайланмалылык сыйфаты хас. Хәзерге гомумтатар милли әдәби теленең бик ерак гасырлардан килә торган җир, су, таш, яшен, ут, үлән, тамчы, ак, кызыл, ике, өч, җиде, көн, төн һ. б. сүзләре аерым бер җәмгыять, буын, коллектив яки шәхес зәвыгына карап башка сүз белән алмаштырыла алмый. Болар барлык иҗтимагый җәмгыятькә һәм буыннарга да шул мәгънәләрендә даими хезмәт итәләр. Хан, чура, ишан, мулла, мөрит, морза, мәдрәсә, азан, сука, тәпәч, калдырча кебек титуллар, дини терминнар, иске житештерү коралларының социалистик җәмгыять шартларында кулланылыштан төшеп, исемнәренең архаизмнарга әверелүе күмәклек исемнәре сферасында сайланмалылык процессының үзенчәлекле чагылышына мисал була ала.

Антропонимиядә һәм топонимиядә лексик сайланмалылык бер үк дәрәҗәдә түгел. Антропонимик сайланмалылык топонимик сайланмалылыктан шактый киң һәм хәрәкәтчән. Ул тормыш агышы, кеше гомере диалектикасы, көн саен кемнеңдер тууы һәм кемнеңдер дөньядан китүе белән бәйле. Антропонимик сайланмалылык гаиләдә яңа туган ир яки кыз балага традицион яки җәмгыятьнең туктаусыз үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килә торган яңа предмет, билге һәм күренешләрне белдерүче күмәклек сүзләрдән ясалган заманча исемнәрне сайлап, зәвыкка туры килгәнен кушу мөмкинлеге белән аңлатыла.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, татар антропонимиясендә баю, тулылану, яңару процессы, нигездә, дүрт төрле юл белән бара.

Борынгы исемнәрне традицион рәвештә яшь буынга бирү дәвам итә. Ерак гасырлардан килә торган, чыгышлары белән төрле гореф-гадәтләр, мәҗүси йолалар белән бәйләнешле төрки-татар исемнәре (мәсәлән, Тимер, Алтын, Булат, Миңлегөл, Арыслан, Карлыгач, Аяз, Үлмәс, Айсылу, Айтуган, Айдар, Алмаз, Чулпан, Тансык, Таңсылу, Илбарис, Сөендек, Миңсылу һ. б.) активлаша. X гасырдан башлап болгар-татарларга ислам дине аша керә башлаган гарәп һәм фарсы исемнәренең җыйнак-җиңел әйтелешкә (күбесенчә, ике иҗеккә корылып), матур яңгырашка һәм дөньяви мәгънәгә ия булганнары да кулланылышта кала. Мәсәлән: Фәрит, Фәридә, Хәмит, Гомәр, Галия, Халит, Халидә, Мансур, Вахит, Сания, Гадил, Наил, Наилә һ. б.

Борынгы дини ышанулар (тотемизм һәм анимизм), ислам дине йолалары, туганлык терминнары, колбиләүчелек һәм феодализм чоры сословие титуллары, кәсеп-һөнәр атамалары белән мөнәсәбәтле кеше исемнәренең күбесе, аерата социалистик җәмгыять кешесенең югары әхлак сыйфатларына, аңы һәм культурасы дәрәҗәсенә, эстетик зәвыгына туры килми торганнары, Октябрьдан соң кулланылыштан төшеп кала бардылар. Чыннан да, хәзерге яшь буынга караган исемнәр арасында Балтабай, Бишбалта, Байбүре, Бүрехан, Котбай, Котлыбие, Кочкар, Җанбай, Көбәк (иске татар телендә көбәк — «эт»), Ташбай, Чалбай (Идел болгарлары телендә чал — таш, шуннан «Чаллы» исеме), Ташбикә, Таштимер, Байбакты, Байкилде, Ханкилде, Бикмулла, Мәүләкол Мәүләбай, Балабәй (шуннан Бәләбәй шәһәре атамасы), Балаәмир (шуннан Идел болгарлары шәһәре Балымер атамасы), Булгарслан («Үгезарс-

лан»), Бабахан, Колчура, Чурабай, Биккол, Аллагол, Сәеткол, Коләхмәт, Колгали, Морзахан, Чураман, Чурмантай, Чакмак, Чакмагыш, Үтәмеш, Әлдермеш, Тозак, Динмөхәммәт, Ихразетдин, Гыйбадулла, Сәетхуҗа, Сәрвәретдин, Мөхетдин, Сәйфелмөлек һ. б. бик күп исемнәрне очратмыйбыз диярлек.

Телебездә гарәп һәм фарсы исемнәренең һәм кушма төзелешле гибрид исемнәрнең таралышы һәм кулланылышы төрле дәвердә төрлечә булган. Болгар-татар теленә гарәп һәм фарсы исемнәре Идел-Кама Болгариясендә 922 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәннән соң алына башласалар да, XIX йөзгә кадәр халыкта киң таралышка, кулланышка һәм популярлыкка ия булмаганнар. Бу чорга кадәр татарларда борынгы төрки-татар исемнәре күбрәк кушылган. Болгар-татар кабер ташларындагы, сан алу кенәгәләрендәге һәм башка тарихи чыганаклардагы кеше исемнәре нәкъ менә шуны раслыйлар. XIX йөздә бу хәл бик нык үзгәрә. Татарлар арасында ислам дине белән гарәп һәм фарсы исемнәре киң тарала. Алар, башлыча, ислам диңен, Мөхәммәт һәм башка пәйгамбәрләрне, алланы олылауга, аларның илаһи сыйфатларын атауга нигезләнгән (Нәбиулла, Рәсүлулла, Мостафа, Гыйсмәтулла, Сафиулла, Әхмәдулла, Халикъ, Хәлиулла, Хәйбулла, Сөббух, Җәббар һ. б. кебек) исемнәр иде.

Татар балаларына исем кушуда әлеге дини-реакцион тенденцияне Бохараның схоластик мәдрәсәләрендә укып кайткан һәм барлык изүче көчләрнең милли-рухи терәге булып әверелгән мулла-мөдәррисләр алга сөрә һәм Октябрьга чаклы яңа туган сабыйга исем бирү, аны рәсми теркәү эшенең татарларда муллалар кулында булуы шуңа китерә.

Дин әһелләре мондый исемнәрне махсус рәвештә пропагандалап, аларны туплап, аерым китапчыклар, циркулярлар бастырып чыгарганнар. 1848 елда Казанда «Исме алаһе тәгалә әл-хәсәни», 1865 елда «Аврадия Фәтхия», 1899—1900 елларда ахун Бендуковның «Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафикъ китап», 1914 елда Кәримовларның »Унбер Әхмәт исемнәре» һ. б. китаплар бастырып таратыла. Бу китапларда исемнәрнең дини ягы макталып, аларның шәригатькә туры килүе таләп ителә. Аллаһе тәгаләнең туксан-тугыз күркәм исеме санап чыгыла һәм аларның мәгънәләренә аңлатма бирелә.

Татар һәм башкорт байлары һәм муллалары, имештер, 1897 елгы перепись вакытында мөселманнарны православныйлар итеп язачаклар, чукындырачаклар һәм аларга рус исемнәре бирәчәкләр дигән ялган хәбәрләр таратканнар (бу турыда карагыз: К. Ф. Фасеев. На путях пролетарского интернационализма. Казань, 1971 ел, 33 бит).

Шуңа да карамастан, XX гасыр башында, Беренче рус революциясе йогынтысында, татар антропонимиясендә демократик, прогрессив тенденция барлыкка килә һәм үсеш ала. Аның асылы халык арасында традицион саф төрки-татар исемнәрен кушу гадәтен яңартудан һәм шулай ук дөньяви эчтәлекле гарәп һәм фарсы исемнәрен пропагандалаудан гыйбарәт була.

Беренче рус революциясеннән соң татар антропонимиясендә фанатик руханилар, муллалар җитәкли торган реакцион агым белән демократик агым арасындагы көрәш тагын да кискенләшә. Татар демократик антропонимик хәрәкәтен Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Бабич кебек күренекле әдипләр һәм халкыбызның башка прогрессив җәмәгать эшлеклеләре җитәкли.

Г. Тукай «Исемнәребез хакында» («Ялт-йолт» журналы, 1911 ел, 4 июнь саны) дигән махсус мәкаләсендә татар халкына: «һәр нәрсәнең гүзәлен яратабыз бит. Бәс, мин телимен ки, Бохара муллаларының бөтен черек нәрсәләренә безнең арада бәһа беткән кеби, киләчәктә ул әфиун башлар уйлап чыгарган ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын», — дигән ялкынлы өндәмә белән мөрәҗәгать итә. Г. Тукайның ихлас күңелдән әйтелгән бу олы теләгенә халык шул елларда ук колак сала. Күренекле татар язучысы Ф. Әмирханның «Исемнәрне татарчалаштыру мөнәсәбәте белән» («Мәктәп» журналы, 1914 ел, 5 сан) дигән оптимистик мәкаләсе әнә шул турыда бик ачык сөйли. Совет чынбарлыгы исә Г. Тукайның әлеге изге теләкләренең тормышка ашуы өчен барлык шартларны тудырды. Халыкның диннән, исламның төрле хорафатларыннан арынуы — шул шартларның берсе һәм гаять мөһиме.

Бөек Октябрьдан соң татар антропонимиясендә бөтенләй яңа исемнәр барлыкка килде.

Тамыр сүзне тамыр сүзгә кушып сүз ясау төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, бик борынгы заманнарда ук актив чара булган. Шушы юл белән хәзерге татар телендә күп кенә кеше исемнәре ясала яки элек ясалган исемнәре актив кулланышка алына. Мондый кушма исемнәрнең бер компоненты булып **ил, гөл, ай, нур, ал, фән** сүзләре аеруча еш катнаша. Мәсәлән: Илсөя, Илсөяр, Илдус, Дусил, Илшат, Илус, Илусә, Илгиз, Илгизәр, Илдар, Илсур, Илнур, Илтөзәр, Илбизәр, Илдан; Гөлгенә, Гөлшат, Гөлсинә, Гөлнур, Гөлусә, Гөлусәр, Гөлчәчәк, Гөлзирәк, Гөлназ, Гөлнәзек, Гөлсөяр, Гөлшаян, Гөлйөзем, Гөлнара, Гөлҗәүһәр; Айнур, Айназ, Айзат, Айкаш, Айшат, Айгөл, Айзирәк; Нурбәхет, Нурзирәк, Нурсинә; Алсинә, Алгөл; Таңнур, Таңчулпан, Таңгөл, Таңсылу; Фәнзаман, Фәндус, Фәндусә, Фәнзил, Фәнзилә, Фәнзирәк, Фәннур, Фәнсөя һ. б.

Күрүебезчә, хатын-кыз исемнәре кушма тамырдан гыйбарәт ирләр исемнәренә хатын-кыз җенесен белдерә торган -а, -ә, -ия кушымчалары ялгану юлы белән барлыкка килгән. Берничә исемнең әлеге кушымчалар ялгану юлы белән вариантлары, төрдәшләре пәйда булды: Гөлнар-Гөлнара, Нәркиз-Нәркизә, Дилбәр-Дилбәрә-Дилбәрия, Раушан-Раушания, Гүзәл-Гүзәлия, Ләйсән-Ләйсәнә-Ләйсәния һ. б.

Тамыр сүзгә иркәләү-кечерәйтү һәм башка кушымчалар ялгану юлы белән дә яңа исемнәр ясала: Гөлкәй, Гөлдәй, Гөлгенә, Гөлем, Гөлгенәм, Гөлия, Нурлан, Нуркай, Алсу, Татлы, Татлыкай, Назлы, Назлым, Көлемсәр һ. б.

Гамәлдәге исемнәрнең структур төзелешенә һәм әйтелеш-яңгырашына охшату, ияртү, чагыштыру юлы белән яңа исемнәр ясау — киң таралган күренеш. Татар антропонимиясендә гарәп һәм фарсы телләреннән алынган күп кенә бер үк мәгънәдәге сүзләр ирләр өчен дә, хатын-кызлар өчен дә исем булып йөри. Аларда гарәп һәм фарсы телләренә хас булган род категориясе чагылыш таба: Сабир-Сабира, Хәлим-Хәлимә, Зәки-Зәкия һ. б. Менә шуңа аналогия ясау, охшату нигезендә күп кенә яңа исемнәр барлыкка килде. Мәсәлән: Алмаз-Алмазия, Дулкын-Дулкыния, Азат-Азадия, Наз-Наза, Руф-Руфа, Бәйрәм-Бәйрәмия, Эльмер-Эльмера, Эльвир-Эльвира, Эльфир-Эльфира һ. б. Бу мисалларда шулай ук рус теленең йогынтысы шактый нык сиземләнә.

Г. И. Богин «Лингвистик күренешләрнең психологик аспекты» («Вопросы общего и германского языкознания» җыентыгы, Уфа, 1964 ел, 15 бит) дигән мәкаләсендә Октябрьдан соң татарлар һәм башкортлар арасында **-ра, -са, -за, -рә, -сә, -зә** иҗегенә беткән яңа хатын-кыз исемнәренең киң кулланылышка кереп баруы (мәсәлән, Венера, Луиза һ. б.) һәм моңа әйтелеш-яңгыраш ягыннан иске һәм яңа исем арасында охшашлыкның кеше психологиясенә зур йогынты ясавы турында язган иде. Моңа өстәп, татар гаиләләрендә ир һәм кыз балаларга башлыча әтисе, әнисе яисә иң өлкән абыйсы, апасы исеменә рифмадаш исем бирү гадәте булуын әйтергә кирәк. Мәсәлән, элек Әхмәтша-Җиһанша-Гаделша-Мөбәрәкша-Дәүләтша; Мәһинур-Шәмсенур-Бибинур-Җиһаннур дип кушкан булсалар, хәзер шул рәвешне саклап: Сибгать-Тәлгать-Рифгать; Самат-Марат-Ренат; Гөлфинур-Гөлнур-Чәчкәнур; Әлфия-Зәлфия-Гөлфия; Рәмзия-Фәнзия-Фәрзия; Рауза-Луиза-Лениза һ. б. кебек исемнәр бирәләр. Менә шуның тәэсирендә, мәсәлән, Рауза, Фәйрүзә, Фирәзә, Фәнүзә кебек **-за, -зә** иҗегенә рифмадаш яңгырый торган Луиза, Эльза, Лиза, Лениза, Ленуза һ. б. яңа исемнәр таралыш алды.

Октябрьдан соң татарлар арасында кайбер кеше исемнәренең аерата киң таралу, популярлашуына телдән тыш факторларның сәбәпче булуын да күрсәтеп үтәргә кирәк. **Илсөяр** һәм **Кадрия** исемнәренең киң таралуына, популярлашуына Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» (1936 ел), Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» (1938 ел) повестьларының героинялары, бу әсәрләрне укучының яратуы, әлеге образларга тирән симпатия белән каравы сәбәп булды дисәк, ялгышмабыз шикелле.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай хөрмәтенә борынгы Тукай исеменең яшь буын вәкилләренә бирелүе дә күп нәрсә турында сөйли. Тугандаш башкорт халкының баһадир улы Салават Юлаев, герой шагыйребез Муса Җәлил, Бөек Ватан сугышында һәлак булган Фатих Кәрим, Гадел Кутуй хөрмәтенә ир балаларга Салават, Җәлил, Фатих, Гадел исемнәрен кушу да күркәм гадәткә әверелде. Галиябану, Зөбәрҗәт, Әнисә, Зәйтүнә, Нурия, Зөләйха, Раушания, Резеда, Рәйхан, Фазыл, Сәрия, Фирдәвес, Әлфия, Рәмзия, Сания, Мәдинә һ. б. исемнәрнең киң таралуында шул исемдәге татар халык җырларының тәэсире сизелә.

Табигатьтәге, тормыштагы, күркәм күренешләрне яки социаль-политик төшенчәләрне белдерүче атамалар да кеше исемнәре итеп бик күптәннән кулланыла, туктаусыз байый, тулылана. Совет власте елларында Ирек, Азат, Бүләк, Очкын, Ялкын, Ләйсән, Ләззәт, Зәвык, Тырыш, Тамчы, Йөзем, Йолдыз, Алма, Якут, Хөррият, Дулкын, Ташкын, Таң, Нур, Байрак, Туфан һәм башка исемнәр барлыкка килде яисә активлашты.

Октябрь революциясеннән соң татар ономастикасына рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән байтак кына исемнәр алынды. Аларның бертөрлеләре тамыр һәм яки нигез сүздән гыйбарәт: Лена, Марат, Марс, Венера, Идеал, Идея, Лариса, Эльмира, Эльза, Люзия, Октябрина, Роберт, Альберт, Розалия, Розалина, Марсель, Аида, Спартак, Фрунзе, Рафаэль, Альбина, Земфира һ. б. Икенчеләре исә аббревиатур, ягъни кыскартылган кушма исемнәр. Аларның күбесе яңа һәм революцион төшенчәләрне белдерүче сүзләрдән, атаклы кешеләрнең исемнәреннән кыскартылып ясалганнар: Вил-Вилен-Вилена (Владимир Ильич Ленин), Владлен-Владлена (Владимир Ленин), Марлен (Маркс, Ленин), Изил (исполнитель заветов Ильича), Ким (Коммунистический интернационал молодежи), Ленуза (Ленин-Ульянов заветлары), Лениз-Лениза (Ленинские заветы), Ленар-Ленара (Ленинская Армия), Дамир-Дамира (Да здравствует мир).

Хезмәт халкына азатлык китергән революция сүзен икегә бүлү юлы белән Рева һәм Люция дигән исемнәр барлыкка килде. Аббревиатур исемнәрнең Вил, Ким, Изил, Дамир, Дамира, Люция, Ленар, Ленара, Лениза кебек тирән эчтәлекле һәм матур яңгырашлы берничәсе хәзер дә — татар антропонимиясенең популяр лексемалары.

Антропонимиябездә аббревиатур исемнәрнең, топонимиябездә аббревиатур атамаларның таралуы Бөек Октябрьдан соң сүзлек хәзинәбезнең үсүенә рус теленең зур йогынты ясавын күрсәтә. Совет чорында рус телендә төрле типтагы бик күп кыскартылган кушма сүзләр барлыкка килде. Телнең гомуми системасына хас булган бу күренеш ялгызлык исемнәре тармагына да үтеп керде. Аларның байтагы татар теленә, аның антропонимия һәм топонимиясенә кабул ителде.

Телебезгә рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәрнең кайберләре хәзерге вакытта, әйткәнебезчә, аерата киң таралышка ия. Күренекле совет ономасты, ЮНЕСКО каршындагы Ономастик фәннәр халыкара комитетының почетлы члены В. А. Никонов «Төрки халыкларда кеше исемнәре» (карагыз: В. А. Никонов. Имя и общество. «Наука» нәшрияты, Мәскәү, 1974 ел, 85—130 битләр) дигән мәкаләсендә, 1967 елда татарлар арасында ир балаларга Альберт, Роберт һәм Марсель кыз балаларга Лилия, Роза, Резеда, Эльмира, Венера, Лена исемнәренең бик күп бирелүен (Татарстанда, мәсәлән, 1967 елда өч йөз малайга Альберт исеме кушылган) хәбәр итә. Бу хәл исемнәребезнең интернациональләшә баруы тенденциясен дәвам итүе хакында сөйли.

Октябрь революциясеннән соң, шактый гына географик атамалар, кеше исемнәре итеп бирелү аркасында, топонимнан антропонимга әверелделәр. Мәсәлән: Идел, Урал, Казбек, Һиндия, Алтай, Байкал, Рейн, Рим, Лена, Марсель, Дунай, Иргиз, Ашказар һ. б. Кеше исемнәре белән географик атамалар арасында электән дә үзара күчешү булган. Мәсәлән, Килдеураз, Миңлебай, Әлмәт (Әлмөхәммәттән кыскарган), Акъегет, Күккүз, Пәрәү, Балтач, Азнакай һәм башкалар. М. Болгари, Әл-Казани, Г. Кандалый, Г. Курсави, Г. Чокрый, Г. Утыз-Имәни, Ш. Мәрҗани һәм башка нисбә фамилияләр үрнәгендә әдәби псевдонимнарны топонимга нигезләп алу күренеше совет чорында тагын да активлаша төште. Мәсәлән, Г. Иделле, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фатих Сәйфи-Уфалы, М. Сөндекле, С. Урайский, Г. Болгарская, Г. Кайбицкая, Г. Камская һ. б.

Бөек Октябрьдан соң татар исемнәренең үсеш-үзгәрешендәге кайбер тенденцияләрдән чыгып, СССР халыкларының тугандаш семьясында яшәгән татар халкының социаль-экономик, политик һәм культура казанышлары антропонимиябездә дә киң чагылыш таба дип нәтиҗә ясый алабыз.

Соңгы елларда рус, украин, белорус, молдаван, латыш, казакъ, үзбәк, башкорт һәм башка халыкларда кеше исемнәре сүзлекләре аерым китап булып басылып чыкты. Якын киләчәктә бездә дә шундый сүзлекнең басылып чыгуы зарури. Ул ата-аналар, паспорт өстәле һәм ЗАГС хезмәткәрләре өчен бик кирәкле кулланма булачак.

# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНДА КӨН-АЙ АТАМАЛАРЫ

Халкыбызның гореф-гадәтләре, күп гасырлар дәвам иткән тормыш-көнкүреш рәвеше соңгы елларда аеруча киң колач белән фәнни нигездә өйрәнелә, күп нәрсәләр тикшерелә, һәм ачыклана бара. Шулай да бу хактагы мәгълүматлар күп тупланган дип әйтергә бик иртә әле. Мәсәлән, халык уеннары, кайбер йолалар, халыкның табигать хакындагы белемнәре һәм күрәзәчелеге һ. б. турында аерым хезмәтләр хәзергә бик аз.

Халыкның мең еллык тәҗрибәсе аның көн-ай атамаларында да чагылыш тапкан. Мәсәлән, Саба, Мамадыш, Балык Бистәсе һәм башка кайбер районнарда яшәүче керәшен татарларында сакланып калган көн-ай атамалары бу яктан аерата кызыклы. Керәшен татарлары үткәннәрдән бик күп гореф-гадәт һәм көнкүреш элементларын саклап килгәннәр. Аларның кием-салымында Балкан болгарлары, венгр, Кырымның тау татарлары, төрекмәннәр белән уртаклык бар. Җыр-көйләре хакында да шуны ук әйтеп була. Бигрәк тә Балкан болгарлары, Кырым татарлары, Дагстан татарлары көймоңнарына якынлык сизелә. Гомумән, керәшеннәрдә сәнгатькә, культурага, халык иҗатына кагылышлы кызыклы нәрсәләр аз түгел. Биредә без көн-ай атамаларын гына күздән кичереп үтәбез.

Алар Европада кабул ителгән латин календаре айларына тәңгәл килми. Ачай (ач ай) — декабрьның икенче, гыйнварның беренче яртысы, ярсай (ярсу ай?) — гыйнвар-февраль, сөвәр (сәүер) — февраль-март, кадерләш (кадерләшү) — март-апрель, сабан ай — апрель-май, чәчәк ай — май-июнь, балкуар — июнь-июль, алмай (алма ай) — июль-август, көзбагар — август-сентябрь, көз ай — сентябрь-октябрь, боз ай (кайбер төбәкләрдә «кара көз») — октябрь-ноябрь, сугым ай — ноябрь-декабрь. Тәвис елында бер көннән торган унөченче — «артык ай» да бар. Күренә ки, ай атамалары халык тормыш-көнкүреше белән аерылгысыз бәйләнгән, елның һәр фасылына хас билгеләрне һәм халыкның көндәлек шөгылен чагылдыра.

Шунысы игътибарга лаек, керәшен татарларында сакланган ай атамаларының кайберләре мишәр диалектында, Касыйм татарлары һәм караим шивәләрендә, Кырым татарлары һәм нугай телендә дә очрый. Ләкин һәр шивәнең үзенчәлекләре дә бар.

1974 елда Мәскәүдә чыгарылган «Караимчә-русча-полякча сүзлек»тә караимнәрнең ай атамалары китерелгән. Биредә аерымлыклар тагы да күбрәк. Чагыштырып карыйк: артарык ай — март-апрель, курал ай (бу атама мишәрләрдә һәм касыймлыларда да бар) — апрель-май, башкускан ай — май-июнь, йаз ай — июнь-июль, улаг ай — июль-август, чирик ай (цирик ай, чүрүк ай) — август-сентябрь, айрыксы ай — сентябрь-октябрь, кюз ай (киз ай, күз ай) — октябрь-ноябрь, согум ай — ноябрь-декабрь, кыш ай — декабрь-январь, каракыш ай — январь-февраль, сювюнч ай (сүйүнц ай) — февраль-март.

Караимнәрнең ай исемнәре, төрле аерымлыкларга да карамастан, ясалу принциплары ягыннан башка төбәкләрнеке белән уртак. Гомумән, ай атамалары татар теленең төрле диалектларында да төрле вариантларда очрый.

Керәшен татарларының көн атамаларында да аларның үзләренә генә хас аерымлыклар бар. Атна гадәттә татар ялыннан (җомга) башлана. Лениногорский районының Федотовка авылында җомганы «татар атнасы» дип тә йөртәләр. Бу атамалар христиан дине тәэсирендә туган булса кирәк. Тулаем көн атамалары: татар жалы (ялы) — җомга, келәү көне (кәтерләү көне) — шимбә, базаркөн — якшәмбе, базар арты эш көне — дүшәмбе, тегермәнче он тартыр — сишәмбе, аулагый (аулак өй) көне — чәршәмбе, атна кич — пәнҗешәмбе.

Көн атамаларында керәшен татарларының көндәлек тормышы да, татарларның борынгыдан килгән гореф-гадәтләре дә чагыла. Кайбер көн-ай атамаларының мөселман диненә кадәрге чорга барып тоташуы да ихтимал. Боларга охшаш ай, көн исемнәре, әлбәттә, башка төрки халыкларда да бар. Ләкин аларның күбесенең аерым бер географик җирлеккә, безнең урта полосага нык бәйләнешле булуы күренә.

Шунысы кызык, ай атамалары татар һәм бигрәк тә керәшен татарлары фамилияләрендә дә сакланып калган. Ачаев, Сабанаев, Алмаев, Кузаев, Ярсаев, Бузаев (Бузин), Балукаров (Балкуваров), Каракозов, Каракузин һәм башка фамилияләр дә шактый еш очрый.

Бәлки бу фактлар галимнәребезгә аларның киләчәк эзләнүләре-тикшеренүләрендә бер этәргеч бирер.

**ӘХМӘТ ГАДЕЛ.**

# УЙНАП ӘЙТСӘҢ ДӘ, УЙЛАП ӘЙТ

*Татар халык мәзәкләре*

XIX гасырның икенче яртысында күп кенә китаплар һәм календарьлар чыгарган, бер үк вакытта халык иҗатын җыю һәм бастыру буенча шактый хезмәт күрсәткән татар укымышлыларының берсе Шиһабетдин Рәхмәтуллин 1895 елда чыккан «Чын мәзах» китабына җәя эчендә «Уйнап булса да уйлап әйтелә торган сүзләр» дигән аңлатма өсти. Ш. Рәхмәтуллин, күрәсең, китап исемен гарәп телендәге «мәзах»тан алгандыр. «Мәзах» гарәпчә шаярту, шаяру мәгънәсенә туры килә. Мәзәк термины кулланыла башлаганчы халык иҗатының бу жанрын бездә «латыйфа» дип йөртү таралган була. Элеккерәк заманнарда шул ук гарәплӛрдән алынган «латыйфа» атамасы төрки халыкларның күбесенә уртак булып китә.

Фәнгә әлегә мәгълүм булган беренче мәзәк җыентыгы 1845 елда Казанда «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде» исеме белән чыга. Төрекләрдән тәрҗемә ителгән бу җыентыктан кала (ул кайбер үзгәрешләр белән 31 мәртәбә нәшер ителә), тагын Октябрьга кадәр гарәпләрдән, французлардан, инглизләрдән, голландлардан һ. б. халыклардан тәрҗемә ителеп төзелгән латаиф — мәзәк җыентыклары да басыла.

Татар халкы арасында таралган мәзәкләрнең чыганакларын барлый башласаң, гомумән, тәрҗемә сюжетларның шактый булуы күзгә ташлана. Дөрес, аларның күпчелеге халыкның көнкүреш дөньясына яраклаштырып үзгәртелә. Әмма саф татар җирлегендә халыкның үз күңелендә, үз поэтик традицияләре нигезендә туган мәзәкләр үзәк урынны алып торалар дисәк хата булмас. Мондый мәзәкләр СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында меңгә якын берәмлек белән исәпләнә. Алар фольклорчылар тарафыннан Татарстан районнарында, күрше республика һәм өлкәләрнең татарлар яшәгән төбәкләрендә язылып алынганнар.

Соңгы елларда Урал татарлары иҗаты өйрәнелә башлады. Фольклорчылар Пермь, Чиләбе өлкәләрендәге дистәләгән татар авылларын йөреп чыктылар һәм берсеннән-берсе үткенрәк күп кенә мәзәкләр дә язып алдылар.

Гадәттә җирле мәзәк геройларының барлыкка килүенә тирә-якта җорлыгы, шаянлыгы белән дан тоткан берәр мәзәкчән кеше сәбәпче була. Мәсәлән, Пермь өлкәсе, Октябрь районы, Калтай авылында Сәйпүк мәзәкләре киң таралган. Сәйпүк (Сәйфулланың кушаматы) ярлы бер кеше була. Аның эшкә уңган, җыр-биюгә, тапкыр сүзгә оста булуы, шуның белән бергә, кетмәгән җирдән кызыклар ясап куюы халыкчан Сәйпүк образы тууга нигез була. Саратов өлкәсе, Дергач районы, Алтата авылында исә Кәпет бабайны (Кәрибулла) авылның Хуҗа Насретдины дип йөрткәннәр. Аның турында бик күп мәзәкләр сөйләнә. Менә шуларның берсе:

«Кәпет бабайны сарыклар фермасына каравылчы итеп куялар. Бер төнне, күрәсең, йоклап китә, бүреләр моның өч баш сарыгын ашап китәләр. Иртән тавыш куба. Моңа:

— Ни карадың, ник сакламадың?! — дилəр икəн.

Бу əйтə:

— Бүрелəр бик күп иде. Ə мылтыгым юк. Кычкырсам да китмəделəр. Нишлəмəк кирəк...

Ярый. Моны шулай ачуланалар да икенче көнне идарəдəн бер мылтык бирəлəр.

— Күрү белəн ат бүрегə! — ди мылтыкны китерүче.

— Соң атуын атармын да мин, хəзер аерып белмим бит инде кайсы бүренең гаепле икəнен. Теге вакыт караңгы иде бит, — дип җавап бирə Кəпет бабай».

Менə шул рəвешле теге яки бу урында булган гайре табигый һəм көлке-кызык хəллəр, җор-зирəк кешелəр мəзəк жанрын баетып, төрлəндереп торучы сəбəплəрнең берсе дип əйтергə кирəк.

1976 елда Татарстан китап нəшрияты татар халык авыз иҗатының төп жанрларын туплаган 12 томлык җыйналма чыгара башлады. Аның бер томына мəзəклəр тупланды. Ул китапта институтның фольклор фондында экспедициялəр вакытында җыелган мəзəклəр белəн бергə төрле төбəклəрдə яшəүче һəвəскəрлəр җибəргəн текстларның матур гына үрнəклəре дə аз түгел. Əлеге томны төзү дəвамында халык иҗатын җыю белəн шөгыльлəнүче аерым кешелəрнең фондтагы коллекциялəренə еш мөрəҗəгать итəргə туры килде. Мəсəлəн, Татарстанның элеккеге Столбище районы, Хəерби авылыннан Гариф Вафин 1959 елда фондка əкиятлəр, бəетлəр белəн бергə дистəлəгəн мəзəклəр язылган дəфтəрен тапшыра. «Мəзəклəр» томына ул коллекциядəн алтмышка якын өсəр сайлап алынды. Татарстанның Арча районы, Кенəр авылында Марсель Əхмəтҗанов кечкенəдəн халык иҗаты белəн кызыксынып, аларны аерым дəфтəргə язып барган. Ул 1973 елда үзенең язмаларын фондка бүлəк итə. Ике дистəгə якын мəзəк шуннан алынды. Республикабызның Баулы районыннан Җ. Гыйззəтуллина, Буа районыннан Г. Минаев, Кукмара районыннан Ə. Гайфетдинов, Г. Шəрипова һəм башка күп кенə исемнəрне рəхмəт əйтеп телгə алырга мөмкин булыр иде.

Журналны укучылар игътибарына тəкъдим ителгəн түбəндəге текстларның күбесе алдагы елда дөнья күрəчəк «Мəзəклəр» томыннан алынды.

**Асия САДЫЙКОВА,**
**Казан тел, əдəбият һəм тарих**
**институтының фəнни хезмəткəре.**

## АҢЛАТКАН

Бер колхозчы эштəн кайткан саен ат арбасына печəн салып кайта икəн. Улы əтисенең бу караклыгын ошатмыйча, ник алай итəсең инде, ди икəн.

— Кайтканда йомшак булсын дип салып кайтам, — ди икəн əтисе.

— Алайса, барганда печəнеңне нигə салып бармыйсың соң? — дигəч, колхозчы:

— Атка җиңел булсын дип əйтəм, — дигəн.

## СƏГАТЬ НИЧƏ

Əби оныгыннан сорый:

— Улым, сəгать ничə, кара əле, — ди.

Оныгы җавап бирə:

— Бер угы кое сиртмəсенə караган, икенчесе Гайниҗамал апаларның өй кыегына караган.

## КИРƏГЕН БИРГƏН

Бер бик юаш кеше булган. Бер көнне күршесе ни өчендер аны бик нык тиргəгəн. Бу бер сүз дə каршы əйтə алмаган, шулай да күңелендə бик нык ачу тотып, күршесе белəн бер дə сөйлəшми йөргəн.

Йөри торгач бервакыт урамнан бик кызуланып кайткан да хатынына әйткән:

— Күрше очрады, бик ачуым килеп йөри иде, ну кирәгген бирдем, — дигән.

Хатыны:

— Ни булды? Әллә суктыңмы? — дигән икән.

— Сугарсың аңа! Бияләй эченнән нығытып бер йодрыгымны күрсәттем, — дип әйткән ди.

### ЯРАТТЫМ

Бер егетнең яраткан кызы булган. Ләкин бу турыда кызга әйтергә батырлыгы җитмәгән. Кыз кияүгә чыккач:

— Ул кыз белән мин өч ел йөрдем, тик үзе генә белмәде, дип әйткән ди егет.

### ЗӘЙТҮНЕ ӨСТӘЛ АСТЫНДА

Хуҗа Насретдин бер байның өенә кергән. Бай бу вакытта зәйтүн мае ашап утыра икән. Хуҗаны күргәч, майны тиз генә өстәл астына яшереп куйган.

— Я, Хуҗа,— дигән бай,— әйдә, бер корьән укып җибәр әле,— дигән. Хуҗа шунда укып та җибәргән:

— Вәәтдини, ватури, сиңа...

— Тукта, Хуҗа, ялгыштың, — ди бай. — Вәзәйтүни дигәнең кая куясың?

Хуҗа бер дә аптырап тормыйча:

— Зәйтүне әнә анда, өстәл астында, — ди.

Бай яшерелгән майны өстәл өстенә чыгарып куярга мәҗбүр була.

### ҮЗ АКЧАСЫ ҮЗЕНӘ БУЛСЫН

Хуҗа Насретдин кибеттән кайтышлый исәпләп караган да, кибетче акчаны артык кайтарып бирүен белеп:

— Хатын, хатын! Кибетче акчаны артык кайтарган, үз акчасы үзенә булсын, бар үзеңә бер кием галош алып кайт! — дигән.

### ТИГЕЗ ЯШӘҮ

Элекке заманда бер ярлы:

— Тигез яшәп булмый шул, — дип зарлана икән. Икенче бер ярлы моңардан:

— Ничек инде тигез яшәп булмый? — дип сораган.

Беренче ярлы әйткән:

— Минем бит чәем бар, шикәрем юк. Кайвакыт шикәр була, чәй булмый, — дигән.

— Минем шикәрем дә, чәем дә юк. Мин тигез яшим! — дигән икенчесе.

### СОРАВЫНА КҮРӘ ҖАВАБЫ

Бер иләкче: «Иләк-миләк ямарга бармы?» — дип урамда кычкырып йөргәндә бер мулла ишеген ачып:

— Гайфулла, аның иләге иләк инде, миләге нәрсә соң? — дип сораган иде ди, иләкче:

— Хәзрәт, сез дә «әлкарыйгатен-мәлкарыйга» дип әйтәсез бит. «Әлкарыйгатен» каргадыр инде, «мәлкарыйгате» нәрсә соң?» — дип әйтте ди.



## МӘЧЕТТӘ НИШЛИЛӘР

Борын заманда бер мари үзенең малае белән мәчетле бер татар авылына килеп кергән ди. Өйлә вакыты икән. Азан әйткәнне ишетеп, малай:

— Әти, бу ни? — дип сорый. Атасы:

— Бу, улым, мөселманнарның сходы, — ди.

— Ә синең анда булганың бармы?

— Булдым бер-ике мәртәбә, — ди атасы.

— Анда нишлиләр соң, әти? — ди малай. Атасы:

— И улым, анда кергәч, мулла идерә, бөктерә, уңга карата, сулга карата, шакмак саната да, өйгә тарата, — дигән.

## НИНДИ ЧИ ТАЛ БУЛСЫН

Көннәрдән беркөнне бер агай базарда сату өчен коры имән казыгы төяп барган. Базарда моның янына бер рус кешесе килә дә сайлый башлый. Шуннан, мин сайлаганны хуҗа карап торды, ничә казык алганымны санагандыр инде, дип уйлап:

— Сколько штук считал? — дип сорый.

Теге абзый ачуланып:

— Җәһәннәм, нинди чи тал булсын, ди, коры имән казыгы бит, ди.

## НИЗАМ БЕЛӘН НӘҖМИ

Бервакыт Низам белән Нәҗми ат белән авылга кайтып килгәндә, атларына су эчерү өчен бер рус авылына кое янына туктаганнар. Коеның чиләге булмаган. Низам белән Нәҗми, русча белмәгәнлектән, бер-берсенә «син кер дә, син кер» дип тарткалашканнар. Ниһаять, Низам бер өйгә кереп киткән. Русча сүзләрне буташтыргалап, чиләк сораган. Хуҗа хатыны Низамга:

— Возьми, — дигән. Низам чиләкне алмастан, чыгып Нәҗмигә кычкырган.

— Нәҗми, бу сине чакыра бит! — дигән.

Ишектән Нәҗми йөгереп кергән. Ә хуҗа хатыны:

— Одному давала, не дам,— дигән, моны ишеткәч, Нәҗми чыгып:

— Нишләп мине чакырсын, Низам дип әйтә бит! — дигән.

## ЗАКАЗ БУЕНЧА

Бер төркем картлар сөйләшеп утыралар икән. Бер шома телле, шук күңелле Ибраһим атлы карт узып бара икән. Төркемнән берәү сүз кушкан моңар:

— Әй, Ибраһим агай, бер ялганлап кит әле.

— Ялганлап торырга вакыт юк. Иске почта тавында он белән баржа баткан. Шунда ашыгам, — дип, тиз-тиз китеп барган.

Картлар да өйләреннән капчыклар алып, баржага йөгергәннәр. Барсалар — он да юк, баржа да юк. Икенче вакыт күреп бабайдан сорыйлар:

— Ник теге вакытта ялганладың? — диләр.

— Үзегез ялганларга куштыгыз бит, — ди карт.

## ХАРАП БУЛГАН

Бер кеше үзенең дустына кунакка килгән. Хуҗа табынга яңа гына аертылган май куйган. Кунак сыпырта гына икән. Өйгә кайткач:

— Ну, ашадым да соң май! — дип мактана ди бу. Хатыны моңа:

— Майны күп ашарга ярамый, сукырайта ул, ди икән.

Бу кеше икенче тапкыр кунакка килсә, өстәл өстендә бер нәрсә юк ди. Кире әйләнеп кайткан да:

— Әллә сукырайдым инде, өстәлдә бернәрсә дә күрмәдем, — дип әйтте ди.

## ТУЗЕМЛЕГЕ КАЛМАГАЧ

Бер кызны кияүгә ярәшәләр. Ләкин бу ураза ае кергән чак була. Рамазан узмыйча никах укырга ярамый, имеш. Бер көнне бу кыз суга бара. Су буенда бер эт сузылып яткан була.

— Бүре кыргыры, рамазан ае кебек сузылып яткан бит, — ди кыз ачуланып.

## ҮЗ СЕМЬЯҢА РӘНҖЕП БУЛМЫЙ

Бер егет мич башында хыялланып ята икән.

— Эх, җылы да соң монда. Хатын алсам, аны менә шушы җылы урынга яткырырмын.

Егет бер кеше ятарлык урын калдырып, кырыйгарак шуа.

— Шуннан безнең кечкенә бәбәебез булыр. Ул менә монда ятар. Егет тагын бер кадәр урын калдырып, кырыйгарак килә.

— Шуннан алла уң кылса, безнең тагын бер улыбыз туар...

Егет тагын да баягыча эшли.

— Бер биргәнгә бирә ул... безнең өченче балабыз да туар. Ул чакта миңа монда ук ятарга туры килер...

Егет шуа торгач, дөп итеп идәнгә егылып төшә.

— Зарар юк, — ди бу, янбашын тотып, — үземнең семья төртеп төшерде.

## ГАРАНТИЯ КАЙДА

Бер кеше хатыны хыянәт итә дип шикләнә икән. Көнләшә торгач уйлый-уйлый бу авыруга сабышкан. Хәле бик начарлангач, хатынын чакырып сорый икән ди бу:

— Хатын, мин барыбер үләм инде, зинһар әйт әле, син миңа хыянәт иттеңме? — дип.

— Мин әйтүен әйтер идем дә бит, ярый ла, син үлсәң, ә терелә калсаң? — дигән хатын.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы ачык җыелышы булды. Җыелышның көн тәртибенә «КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият — сәнгать тәнкыйте турында»гы карары яктылыгында әдәби тәнкыйтьнең торышы» дигән мәсьәлә куелган иде.

Докладчылар — «Идел» альманахының редакторы Мансур Вәлиев һәм «Казан утлары» журналының әдәби тәнкыйть бүлеге редакторы Ринат Мөхәммәдиев бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйтьнең ничек үсүе, андагы уңай күренешләр һәм кимчелекләр хакында җентекләп сөйләделәр.

Фикер алышуларда язучылар Җәвад Тәрҗеманов, Афзал Шамов, Рафаэль Мостафин, Ибраһим Нуруллин, партбюро секретаре Туфан Миңнуллин, идарә председателе Гариф Ахунов иптәшләр катнашты. Тәнкыйтьчеләребез гадел, кыю, кимчелекләргә карата аяусыз булырга, иптәшләрчә эшлекле төстә иҗат итәргә тиешләр — җыелышта кузгатылган төп фикер әнә шулар иде. Яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләү мәсьәләсе дә җыелышның игътибар үзәгендә булды.

## МУЗЫКА ХӘЗИНӘЛӘРЕН — ХАЛЫККА!

Казанның Актерлар йортында «КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары яктылыгында музыка белеме һәм музыкаль тәнкыйтьнең торышы һәм алдагы бурычлар» дигән көн тәртибе белән зур киңәшмә уздырылды.

Киңәшмәне ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин ачты. Докладны сәнгать фәннәре кандидаты Мәхмүт Нигъмәтҗанов сөйләде. Өстәмә докладларда һәм фикер алышуларда музыка белгече Л. Исәнбәт, З. Сәйдәшева, М. Фәйзуллаева, Татарстан Композиторлар союзы идарәсенең оештыру секретаре К. Тажиева, Татарстан радиокомитетының художество тапшырулар редакциясе баш редакторы Р. Кәримов, сәнгать фәннәре кандидатлары Я. Гиршман, Р. Вамба-Исхакова, Казан телестудиясе режиссеры Э. Ключарев, СССРның халык артисты, профессор Н. Җиһанов, сәнгать фәннәре кандидаты Г. Касаткина иптәшләр катнашты.

Киңәшмәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

## КИНО ОСТАЛАРЫ КИҢӘШӘ

Казанда кино сәнгате осталарының конференциясе булды. «1978 ел йомгаклары һәм КПСС Үзәк Комитетының июль һәм ноябрь (1978 ел) Пленумнары карарлары яктылыгында студиянең бурычлары турында» докладны Казан кинохроникасы студиясенең баш редакторы — СССР Кинематографистлар союзы члены Р. И. Копосов сөйләде. Конференциягә Мәскәүдән, Куйбышевтан, Мордовиядән, Чувашстаннан, Мари АССРдан кунаклар чакырылган иде. Алар арасында РСФСР Госкиносының кино чыгару Баш идарәсе начальнигы Ю. В. Симеранов, СССР Кинематографистлар союзының художестволы фильмнарны тәрҗемә итү буенча Бөтенсоюз комитеты члены, режиссер Г. П. Калитиевский, Үзәк документаль фильмнар студиясе режиссеры, СССРның халык артисты, СССР Дәүләт премиясе лауреаты профессор Л. М. Кристи, СССР Кинематографистлар союзының Идел буе бүлеге идарәсе члены Ю. Т. Долженко бар иде.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире иптәш М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## СӘХНӘ ОСТАСЫН ОЛЫЛАУ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында СССРның халык артисты Фуад Халитовка 70 яшь, иҗади эшчәнлегенә 50 ел тулуга багышланган тантана булды. Тантанада шәһәр җәмәгатьчелеге катнашты.

Җыелышны Татарстан АССР культура министры И. Н. Алиев ачты. Юбилярны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев котлады, совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм житмеш яшь тулу уңае белән, СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән аңа Халыклар Дуслыгы ордены тапшырды.

Мәшһүр артистның тормыш һәм иҗат юлы турында драматург Туфан Миңнуллин сөйләде. Аннары юбилярны котлаулар булды.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ӘДИП ЮБИЛЕЕ

Актерлар йортында күренекле татар совет язучысы Әмирхан Еникигә 70 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Аны кереш сүз белән прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗев ачты. РСФСРның

М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким юбилярның тормышы һәм иҗат юлы турында сөйләде. Аннары юбилярны котлаулар булды.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Төзүчеләрнең культура сараенда күренекле татар совет шагыйре Әнвәр Давыдовның тууына 60 ел тулуга багышланган кичә булды. Кичәне шагыйрь Сибгат Хәким ачып җибәрде. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында, шигъриятенең үзенчәлекләре турында докладны «Казан утлары» журналының баш редактор урынбасары, шагыйрь һәм прозаик Әхсән Баянов сөйләде.

Кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, шулай ук шагыйрьнең туганнары, авылдашлары катнашты.

* * *

Куйбышев өлкәсенең Камышлы авылы халкы да үзләренең якташлары — Әнвәр Давыдовның юбилеен тантаналы рәвештә билгеләп үттеләр. Кичәне Камышлы авыл советы башкарма комитеты председателе Ф. Ә. Зәйнуллин ачты. Шагыйрьнең иҗаты турында доклад һәм истәлекләр тыңланды. Партиянең район комитеты секретаре иптәш Ә. М. Хәиров Камышлы авыл культура йортына Әнвәр Давыдов исеме биреләчәге турында хәбәр итте.

Кичәдә шагыйрьләр Нәби Дәүли һәм Роберт Миңнуллин катнашты. Алар шагыйрь иҗаты турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар, икенче көнне урта мәктәп укучылары белән очраштылар.

## ЯШЬ ӘДӘБИЯТЧЫЛАР ФОРУМЫ

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында өч көн дәвамында яшь тәнкыйтьчеләрнең республика семинары эшләде. Семинарны кереш сүз белән Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Язучы һәм тәнкыйтьче Мөхәммәт Мәһдиев яшь тәнкыйтьчеләр алдында әдәби тәнкыйтьнең актуаль мәсьәләләре турында сөйләде. Яшь тәнкыйтьчеләр республикабыз матбугат органнарының җаваплы хезмәткәрләре белән очраштылар, бүгенге тәнкыйть турындагы мавыктыргыч диспутта катнаштылар.

Семинарның соңгы көнендә сөйләшү тагын да конкретрак төс алды. Анда яшь тәнкыйтьчеләрнең иҗатлары тикшерелде. Тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр Рафаэль Мостафин һәм Фәрваз Миңнуллин җитәкчелек иткән семинарларда Р. Мөхәммәдиев, Р. Кукушкин, Р. Сверигин, Р. Абдуллина, Р. Лотфуллин, Ф. Зөлкарнәевләрнең әдәби тәнкыйть эшчәнлегенә житди анализ ясалды. Соңгы елларда әдәби тәнкыйть өлкәсендә уңышлы эшләгән яшьләрдән Ринат Мөхәммәдиев, Равил Кукушкин һәм Рифат Сверигин СССР Язучылар союзы члены лыгына тәкъдим ителде.

Семинар эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КИҢӘШМӘСЕ

Март аенда Мәскәүдә яшь язучыларның VII Бөтенсоюз киңәшмәсе уздырылды. Аны СССР Язучылар союзы һәм ВЛКСМ Үзәк комитеты үткәрде. Киңәшмәдә катнашучылар арасында Казаннан яшь прозаик Н. Гыйматдинова, тәрҗемәче Р. Ахунов, Чаллының яшь шагыйрьләре Н. Алешков, Е. Кувайцев һәм П. Юлаев та бар иде.

## «ХАЛЫК БЕЛӘН ПАРТИЯ БЕРДӘМ»

Совет халкы туган партиябез җитәкчелегендә гасырларга тиң юл узды. Аның горурланып сөйләрлек казанышлары ифрат күп, дөнья алдында күрсәтерлек эшләре бихисап. Март аенда Татарстанда Сынлы сәнгать музеенда ачылган күргәзмә әнә шуңа багышланган иде. Күргәзмәгә халкыбызның героик олы юлын чагылдыручы экспонатлар СССР Үзәк революция музееннан алынды. Ул «Халык белән партия бердәм» дигән исем астында оештырылды.

Күргәзмәне КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты.

## СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Ул кичә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында булды. Бирегә күп санлы шигырь һәм җыр сөючеләр РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким кичәсенә җыелды. Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Аннары сәхнәгә шагыйрь үзе күтәрелде. «Шагыйрьнең әйтер сүзе — әсәрләрендә,— диде ул.— Мин сүзне үземнең шигырьләремә җырларыма, поэмаларыма бирәм».

Залда республикабызның күренекле артистлары башкаруында С. Хәким әсәрләре, композиторларыбызның шагыйрь сүзләренә язган җырлары яңгырады. Концерт программасында Сара Садыйкова, Заһид Хәбибуллин Әнвәр Бакиров, Рөстәм Яхин кебек күренекле композиторлар катнашты. Соңыннан С. Хәким үзенең шигырьләрен укыды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясендә чираттагы утырыш булды. Ул яшь шагыйрь Рәфикъ Юнысов иҗатын тикшерүгә багышланды. Утырышта Зөлфәт яшь автор иҗатына анализ ясады, аның үзенчәлекле якларын күрсәтте.

Утырыш Рәфикъ Юнысовның шигырьләр җыентыгын Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә дигән карарга килде.

* * *

Шагыйрьләр секциясенең март аенда уздырылган утырышында Мәскәүдә яшәүче яшь шагыйрә Нурия Измайлова иҗаты тикшерелде. Чыгыш ясаучылардан шагыйрьләр Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов,

И. Юзеев, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, язучы Н. Фәттах, «Азат хатын» журналы редакторы В. Ихсанова һәм башка иптәшләр шигърияткә талантлы шагыйрә килүен билгеләп, шигырьләренең заманча фикерләргә, образларга бай булуын күрсәтеп үттеләр. Яшь шагыйрәнең кулъязмасы бертавыштан хупланды һәм Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

* * *

Балалар әдәбияты секциясе яшь һәм башлап язучыларның әсәрләре белән даими кызыксынып килә һәм аларга һәрчак иҗади-практик ярдәм күрсәтеп тора. Мәсәлән, соңгы өч утырышта Фияза Гатауллинаның яшьләр өчен язылган хикәяләре, Раушания Низамованың кечкенәләргә атап язган чәчмә әсәрләре, Фирдәвес Әһлиуллинаның нәниләргә язылган әкиятләре укып тикшерелде. Әсәрләрне тикшерүдә Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев, язучылар Ләбибә Ихсанова, Шамил Рәкыйпов, Адлер Тимергалин, Мәгъсүм Хуҗин, Роза Хафизова, Госман Бакиров, Камил Кәримов, шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Нур Гайсин, Резеда Вәлиева, Җәүдәт Дәрзаманов, тәнкыйтьче Равил Кукушкин һәм башка иптәшләр катнашты. Алар балалар өчен язучы яшьләрне хуплап каршыладылар, яшь авторларга балалар әдәбиятының үзенчәлекләре хакында сөйләделәр, эшлекле киңәшләр, тәкъдимнәр әйттеләр.

### «КАЗАН ЯЗЫ»

Тукай көннәре алдыннан Казандагы культура сарайларында, клубларында һәм тулай торакларында «Казан язы» исемле традицион әдәби-музыкаль кичәләр уздырылды. Татарстан язучыларының IX съезды алдыннан уздырылган әлеге кичәләрдә татар әдипләре Г. Ахунов, Туфан Миңнуллин, В. Нуруллин, М. Хәбибуллин, Р. Гатауллин, Р. Батуллин, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, шулай ук танылган җырчылар актив катнашты.

### КИТАП СӨЮЧЕЛӘР ЯНЫНДА

РСФСР китап сөючеләре җәмгыятенең Татарстан бүлеге, республика китап сәүдәсе конторасы белән берлектә, Казанның 3 нче китап кибетендә татар әдәбияты айлыгы үткәрде. Татар әдәбиятын тагын да киңрәк пропагандалау максатыннан оештырылган бу айлыкта язучылар белән очрашулар уздырылды, аерым әдипләр иҗатына багышланган сөйләшүләр булды. Шундый очрашуларның берсендә шагыйрьләр Сибгат Хәким, Зәки Нури һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин катнашты.

### СТУДЕНТЛАР ЯНЫНДА

Казан дәүләт педагогия институтының яшь иҗат көчләрен берләштергән «Илһам» әдәби түгәрәге, сигезенче март уңаеннан, бер төркем хатын-кыз язучыларны үзенә кунакка чакырды. Очрашуда катнашкан шагыйрә Гөлшат Зәйнашева, язучылар Кояш Тимбикова, Диләрә Зөбәерова һәм Роза Хафизова студентларга үз иҗатлары турында сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар. Кичәдә студентлар язган шигырьләр дә яңгырады.

### ИНТЕРНАТ-МӘКТӘПТӘ ОЧРАШУ

Казандагы 10 нчы интернат-мәктәп укучылары күренекле шагыйрь, Бөек Ватан сугышы ветераны Зәки Нури белән очраштылар. Шагыйрь укучыларга үзенең иҗаты турында, «Казан утлары» журналы турында сөйләде, үзенең шигырьләрен укыды. Очрашуда шулай ук шагыйрьләр Роберт Миңнуллин һәм Госман Садә катнашты.

### ЯЗУЧЫ — УКУЧЫЛАРЫ ЯНЫНДА

Буа шәһәренең культура йортында СССР Дәүләт премиясе лауреаты язучы Гомәр Бәширов китапларына багышланган укучылар конференциясе уздырылды. Язучының иҗаты турында журналист Г. Шәйхиев сөйләде. Аннары язучы үзе сүз алды. Ул укучылар белән китапның яшь буынны тәрбияләүдәге роле турындагы уйланулары белән уртаклашты, китап пропагандалауга кагылышлы мәсьәләләргә кагылды, үзенең иҗат планнары белән таныштырды.

Аннары Г. Бәширов М. Вахитов исемендәге урта мәктәп укучылары, медицина училищесы укучылары белән очрашты.

### «ЯЛКЫН» РӘССАМНАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

Март-апрель айларында Казан Яшьләр үзәгендә «Ялкын» журналы рәссамнарының күргәзмәсе булды. Халыкара Сабыйлар елына һәм «Ялкын» журналының 55 еллыгына багышланган бу күргәзмәдә үн график-рәссамның әсәрләре куелган иде. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Тавил Хаҗиәхмәтовның журнал тышлыгына ясаган рәсемнәрен, язучыларыбызның повесть һәм хикәяләренә, поэма, әкият һәм шигырьләренә иҗат иткән күз явын алырдай иллюстрацияләрен тамашачылар бик яратып кабул иттеләр.

Рәссамнар Мансур Рәхимов, Хәбир Әхмәтҗанов әсәрләре исә олы юл үткән журналның үсеш этапларын күзалларга ярдәм итте. Лотфи Насыйров, Суфия Насыйрова, Рәшит Сафиуллин, Айдар Үтәганов иллюстрацияләре үзләренең заманча булулары, әдәби әсәр рухын нечкә һәм тирән тоеп, аңлап эшләнүләре белән аерылып тора.

Бу күргәзмә Халыкара Сабыйлар елына рәссамнарыбызның, «Ялкын» журналының үзенчәлекле бүләге булды.

* * *

Дербышка поселогындагы 2 нче интернат-мәктәптә укучыларның республика биология олимпиадасында катнашучылар белән язучылар очрашуы булды. Очрашуда катнашкан язучы Михаил Скороходов әдәби әсәргә материал җыю турында сөйләде, Роберт Батуллин үзенең әкиятләрен укыды, шагыйрь Разил Вәлиев бүгенге балалар әдәбияты белән таныштырды.

Соңыннан язучылар сорауларга җавап бирделәр.

### ШИГЫРЬ һӘМ ҖЫР КИЧӘСЕ

Казан дәүләт медицина институтының чыгарылыш студентлары әдәби-музыкаль кичә үткәрделәр. Кичәгә шагыйрьләр Ра-

вил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, җырчы Рафаэль Сәхәбиев һәм композитор Марс Макаров та чакырылган иде. Әдипләр студентларны татар совет әдәбиятының бүгенге торышы белән таныштырдылар.

## ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ОЧРАШУ

Казанның Актерлар йортында Германия Федератив Республикасыннан килгән студент-яшьләр белән иҗат яшьләренең очрашуы булды. Очрашуда шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, артистлар Алсу Гайнуллина, Шамил Бариев, Татар дәүләт академия театры директоры Ә. Ш. Хөсәенов катнашты. Әңгәмә вакытында сүз — бүгенге татар әдәбияты, татар сәнгате турында барды. Кунаклар үзләре дә сорауларга җаваплар бирделәр һәм герой-шагыйрь Муса Җәлилнең немец теленә тәрҗемә ителгән шигырьләрен укып күрсәттеләр.

## СӘНГАТЬ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Актерлар йортында даими рәвештә уздырыла торган «Олы юлның маяклары» исемле әдәби-музыкаль кичәләрнең чираттагысы кырыгынчы еллардагы татар культурасы үсешенә багышланды. Кичәдә филология фәннәре кандидаты Бәян Гыйззәт Татар дәүләт академия театры тарафыннан кырыгынчы елларда куелган спектакльләр турында сөйләде, театрның Бөек Ватан сугышы елларында аеруча актив иҗат итүен ассызыклап билгеләп үтте.

Музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина үзенең чыгышында шушы чорда музыка өлкәсендә ирешелгән уңышларга тукталды, радио, филармония, опера һәм балет театры репертуарларының идея-художество ягыннан тагын да баюы турында әйтте, татар музыкасында музыкаль комедия, балет, симфоник поэма, симфония кебек яңа жанрлар барлыкка килүен билгеләп үтте.

Әдәби-музыкаль кичәдә РСФСРның халык артисткасы Зөләйха Хисматуллина, Татарстанның атказанган артисткалары Разия Тимерханова, Вафирә Гыйззәтуллина, танылган җырчылар Флера Сөләйманова, Рафаэль Ильясов, баянчылар Рокыя Ибраһимова, Ирек Галимов, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Алевтина Миркина кырыгынчы елларда иҗат ителгән музыкаль әсәрләрне башкардылар, РСФСРның атказанган артисты Айрат Арсланов шушы елларда язылган кайбер әдәби әсәрләрне укыды.

## ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАН КУНАКЛАРЫ

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында тугандаш Башкортстанның сәхнә осталары Казан шәһәрендәге гастрольләрен башлап җибәрделәр. Алар шәһәрнең күп кенә культура сарайларында, клубларында чыгыш ясадылар.

Кунаклар арасында РСФСРның атказанган артисты, Салават Юлаев премиясе лауреаты Мәгафур Хисматуллин, Башкортстанның халык артисты, композитор Бәхти Гайсин, РСФСРның атказанган артисты Мөхәммәт Идрисов, республиканың танылган артистлары Флюра Ногманова, Фәридә Мостаева, Радик Харисов, Светлана Баишева, Зөлфирә Фәрхетдинова, Хәмит Ишбулдин, Равил Кучуковлар да бар иде. Бай концерт программасын сәхнә осталары Башкортстан АССР төзелүгә 60 ел тулуга багышлап әзерләгәннәр.

## ХАЛЫК ТЕАТРЫНА — 5 ЕЛ

Әлмәттәге татар халык театрына 5 ел тулды. Шушы кыска вакыт эчендә аның коллективы күзгә күренеп үсте, осталыгын арттырды, репертуарын баетты. Үзешчән артистлар шәһәрдә һәм авылларда 200 ләп спектакль куйдылар.

Күптән түгел бу театр тамашачыларга драматург Туфан Миңнуллинның «Күрше кызы» исемле пьесасы буенча әзерләнгән яңа спектакль күрсәтте. Сәнгать сөючеләр аны җылы каршыладылар.

## ЧИЛӘБЕ ҮЗЕШЧӘННӘРЕ

Чиләбенең трактор төзүчеләр Культура сарае каршында күп еллардан бирле татар халык театры эшләп килә. Коллективның чыгышларын тамашачылар һәр вакыт яратып карыйлар. Күптән түгел үзешчән артистлар драматург Хәй Вахитның «Ике килен-килендәш» комедиясен сәхнәләштерделәр. Спектакльнең режиссеры — театр җитәкчесе Гата Сәлимов, рәссам — Егор Четыркин. Рольләрне ЧТЗ эшчеләре — үзешчән артистлар башкара. Җәүһәрә Нәфыйкова, Равил Хуҗахмэтов, Әдип Нәфыйков, Хәнә Фәйзуллина кебек үзешчәннәрнең уйнавы тамашачыларга аеруча ошый.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан китап нәшрияты директоры **Гараф Низаметдин улы Шәрәфетдиновка РСФСРның атказанган культура работнигы дигән** мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыкаль сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе солисты **Гали Ильясовка Татарстан АССРның халык артисты,** бию сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет солисткасы **Ансария Кретовага** һәм Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет солисткасы **Халисә Шәрәповага Татарстан АССРның атказанган артисты ди**гән мактаулы исемнәр бирелде.


## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 50 яше тулу уңае белән шагыйрь **Илгиз Нурулла улы Кәлимуллин** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының һәм РСФСР Верховный Советы Президиумының **Почет грамоталары** белән бүләкләнде.

# ЯДКАРЬ

**ФАСИЛ ӘХМӘТОВ**
музыкасы

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
сүзләре




Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсез бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш —
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Уртак иде хисләр, айлы кич..әг —
Без кертмәдек анда ятларны.
Күңелләрдә йөргән дуслык хисе —
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Бергә откан өмет тулы җырны
Йөрәк инде мең кат ятлады.
Үткәннәрдән бары шул җыр калды,
Ул җыр — безгә яшьлек ядкаре.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Алда безне истәлекле олы бәйрәмнәр көтә. 1980 нче елда даһи Ленинның тууына — 110, автономияле Татарстан республикасы төзелүгә 60 ел тулу тантаналарын билгеләячәкбез. Журналның быелгы 7 нче санынннан шул вакыйгаларга багышланган язмалар — очерклар, публицистик мәкаләләр, җырлар, шигырьләр урын ала башлаячак. Профессор Мидхәт Мөхәррәмовның «Ленин декреты белән» исемле тирән эчтәлекле мәкаләсе журналның киләсе ай санын ачып җибәрә.

7 нче санда Сез язучы Атилла Расихның «Сынау» исемле яңа романы белән таныша башлаячаксыз. Проза әсәрләре әле моның белән генә дә чикләнми. Роман янәшәсендә Миргазыян Юныйсның яңа әсәре — «Табу һәм югалту» исемле кечкенә күләмле повесте бирелә. Повесть ир белән хатынның ифрат катлаулы мөнәсәбәтләрен тасвирлый. Егет белән кыз чакта бер-берсен күз карашыннан ук аңлап ала торган кешеләр, гаилә корылгач, бала булгач, әллә ничаклы низаглар алдында югалып калалар. Моңарчы матур әдәбият та күбрәк игътибарны кыз белән егет мөнәсәбәтләренә генә бирә килде. Кеше гомере исә гаиләле тормышта уза. Яңа повесть кешеләрнең шул мөнәсәбәтләрен тәфсилләп күрсәтүе ягыннан укучы өчен шактый кызык тоелыр.

Поэзия бүлегендә төрле буын шагыйрьләренең иҗат үрнәкләре тәкъдим ителә. Өлкән шагыйрь Нәби Дәүли шигырьләре «Хатлар килә миңа» исемле циклга тупланган. Бу санда яшь шагыйрьләрнең әсәрләре аеруча күп. Моңа сәбәп тә бар. Күптән түгел Азнакайда яшь һәм башлап язучыларның зона конференциясе булган иде. Шунда иҗатлары тикшерелгән һәм хупланган яшь шагыйрьләр Марсель Галиев, Әхмәт Гадел, Нур Әхмәдиев, Роберт Рәкыйпов журналда яңа әсәрләре белән катнашалар.

Очерклардан М. Зариповның «Яңа эш — киң колач» исемле язмасы авыл хуҗалыгын үстерү проблемаларын күтәрә, аларны чишү юлларын күрсәтә.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Р. Мостафинның КамАЗ турында язылган әсәрләргә ясаган анализы бар.

Укучы 7 нче санда әдәбият тарихына караган язмаларны да, китап күзәтүгә багышланган мәкаләләрне дә, «Елмаеп та, көлеп тә...» рубрикасына урнаштырылган юмористик әсәрләрне дә яратып укыр.

Журнал, гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыкларын эченә алган язма белән тәгәлләнә.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210